# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Данис ХӘЙРУЛЛИН. Оча сүзләр... *Шигырьләр.* ....3

Марат КӘБИРОВ. Гомер. *Повесть.* ....8

Рифә РАХМАН. Гашыйк булган көннәр... *Шигырьләр.* ....54

Әлфис ГАЯЗОВ. Кайсы яктан чыга соң бу кояш? *Роман.* ....59

Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА. Без – адашкан автобуста... *Шигырьләр.* ....139

Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ. Юлаучылар. *Хикәя.* ....143

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА. Казан теле сине күрергә... *Шигырьләр.* ....159

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлфия ИСХАКОВА. Аламачы бабай дәресләре. *Хикәя.* ....163

ЯҢА ИСЕМНӘР

Айсылу КӘЛИМУЛЛИНА. Кулга алам каурый каләмне... *Шигырьләр.*....166

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Венера МАКАРОВА. Самара йолдызлары. ....169

*Әбүгалисина мәгарәсе:* Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. *Нәсел шәҗәрәсе кайларга китә... (Каюм Насыйриның 200 еллыгын каршылап)*....174

*Фотоархив:* Әдәби мизгелләр. ....180

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Фәсәхәт апа, Гамил Афзал, Сәйфи Кудаш, Сөембикә Кудашеваның Рәдиф Гаташка язган хатлары. ....182

*Әдәби сканворд.* Рәис ГАБДУЛЛА төзеде. ....187

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Сөй халыкның дөньясын... *(Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына – 135 ел).* ....188

Әдипләрне интернетта танытты *(Әхмәт Дусайлының тууына – 75 ел).* *Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 8 (1222) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.07.2024, график буенча 30.07.2024, басылып чыгу вакыты 05.08.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1610. Тираж 4450.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2024 ел



Данис
Хәйруллин

# ОЧА СҮЗЛӘР...

## Талпыну

Көн иде ул, яп-якты вә ап-аяз бер көн иде,
Кояшның күккә чөелгән тәңкә ягы күн иде.
И, акты халык, акты таш урамнар, тулып-тулып:
Чишелде чирнең изүе, шатландык: сулык-сулык
Елаштык, көлдек, биештек, йодрык сугып бәрмәгә –
Тагын бер бастык аякка мең калып күтәрмәгә!
Менә без! – мендәр чиреннән күтәрдек башны тәмам,
Безгә дә ирек басуыннан иреште бер тәгам.
Ачылды хыял дөньясы, типте йөрәк куш кебек.
...Аһ, бер талпыну булган ул канат ярган кош кебек.
Үтте-китте ул заманнар, калмады бер эзе дә.
Үзгә без, әмма йөзебез һәнүз ватык көзгедә.

## Адашу

Бу заманга каян килеп чыктым соң мин,
Ни, нәрсә дип, күз яшемне сыктым соң мин,
Өмет диеп, өммәт диеп, хөрмәт диеп,
Уты төшмәс чакмага ник суктым соң мин?

Борылам да карап торам үткән юлга,
Үткәннәрне барлап торам үпкәм мулга:
Замананың тышаулары арта бара,
Чыбыркысы күчкән саен кулдан кулга.

Бу заманны каян эзләп таптым соң мин,
Ник Гаязның инкыйразын тактым соң мин
Муеныма, куеныма?.. Беләә торып,
Кар базына нигә утлар яктым соң мин?

---

Данис ХӘЙРУЛЛИН (1945) – *шагыйрь; «Хәтер», «Йөрәк тибеше», «Казлар ник көлә?» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Адаштыра тома сукыр уйлар кереп,
Томалана акыл кысыр туйлар күреп...
Бүре булып уласаң да, ишетмиләр –
Адым саен колакчыны төшкән бүрек...

## Ваемсыз

Нигә ул йөрү дисең, йөзең чытып,
Хозурлан кымыз уртлап, йөзем сытып –
Үртәлсен үргә менмәк узаманнар,
Үрчесен битарафлар синнән шытып!

Көн вә төн кил кан-мәмер – ни табасың,
Һәр иртә ялтырат коймак табасын.
Тотсалармы бер-бер хилаф эш белән –
Шайтан... диген, танма, нигә танасың!

Ваемсыз дип вәкарьләнсә бичәләр,
Ни калдырасың син безгә дисәләр,
Ни әйтим: мал дип нигә талаштыру –
Берүземә бишәү-алтау бит алар...

Әкияти гомер очы бер чыктымы,
Алда көтәчәк сине, бел, чып-чыны:
Түмгәгең калыр, калса, бер – исемсез
Һәм кычыткан, булмас хәтта чыпчыгы!

## Сорылык

*Кайсы юллар, нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?!*
Дәрдемәнд

Инде атмас дигән соры таңнар ата;
Кем арбасы, безне кай упкынга тарта?
Чиксезлеккә чигелгән күз карашлары
Чигенә дә җир өстенә кире кайта.

Көн тудымы, баш калкытып соры комнан,
Җәнҗал кошы кан агыза томшыгыннан:
Тынлык тынган, чынлык чыккан чыгырыннан,
Ләң-ләңнәре ычкынганнар чылбырыннан.

Тәрәзләргә тарта-тарта кырык карта,
Акылларын акшарлаучы затлар арта.
Ике дөнья арасына сыялмаган
Зимагурлар җир әйләнеп кире кайта.

Мәңге тузмас дигән тузлар каерыла.
Пар-пар килгән парлар парлап аерыла.
Бу Җир күптән күчәреннән күчәр иде,
Тотып тора аны мисле Ае гына.

Дигәннәре – Тәңренең тау бөркетләре,
Булып чыга канатлы йон бөртекләре...
Ни кәгазь бар, ни каләм бар, и кариэм,
Боларны да тарихыңа беркет әле!

## Көзге

Син көзгегә кара, и туганым,
Чагылышың өйрән – аллы-артлы,
Һәм табарга тырыш хакыйкатьне –
Көзге чалыш, әллә дөнья шартлы!

Укып кара, өсне аска куеп,
Уңны сулга куеп укып кара! –
Башмагыңның башын бормасаң да
Уңы сулдан, сулы уңнан бара.

Син көзгегә кара, и туганым,
Чагылышың өйрән – аллы-артлы:
Һәм белерсең, безнең бу дөньяда
Барысы да бер көнлек һәм шартлы!

## Сүз канаты

Оча сүзләр, оча гына канатланып,
Бер үк сүзләр бөтерелә кабатланып:
Төн буена төнбоектай йомыла да
Таң кошыдай чыр-чу килә чуар халык.

Оча сүзләр – канатлары тиеп китә:
Берәү ава, берәүләре биеп китә;
Куначасын табалмаган тавык кебек,
Кемсәләрне тиреслеккә өеп китә...

Себерә дә түгә канат түрләреңнән,
Җиде күмә, җиде алып гүрләреңнән.
Оча сүзләр, очсызланып беткәндә дә,
Арыналмый бәндәләре сүз гареннән.

Үскәннәрне үсендерә сүз канаты,
Үсәлмасаң, исем тага сүз канатып,
Очкан сүзләр очкан инде, очачагы
Куначасын табар әле, түз, канатым!

## Шәүлә

Елларны елларга тапкырлап
Бүлсәң дә, кушсаң да, алсаң да,
Гамәлнең әмәлен табалмый,
Калдыгы булып бер калсаң да,

Җөпләрнең җаена тиенеп,
Башларың таҗларга төрсәң дә,
Син – бары узгынчы бер шәүлә
Чак кына буялган кершәнгә...

Шәфәкъвтә шәйләнгән күләгәң
Эңгердә эри дә югала.
Беләсең, югалган төсмергә
Исем дә, бәя дә юк аңа!

Йөрсәң дә күкләргә кизәнеп:
Кайгы – эш!.. минем дип, кайгы – дан!..
Йә үзең сыгылып төшсәң дә,
Данымны югалткан кайгыдан;

Тотсаң да дулаган атларны,
Чапканда арбасын җимереп,
Барыбер кайтырсың чабыштан –
Беренче булсаң да... җиңелеп!

Күләгәң хозурын онытып,
Фанида хет күпме шаула син –
Туганы юк әле моңарчы
Узучы үзенең шәүләсен!

***

Дөреслекне берәү тапкан, ди, бит
Һәм түшенә алып таккан, ди.
Нәкъ шул чакта табучыны табып,
Елан телле ялган чаккан, ди:

«Табышыңны миңа бүләк ит син,
Исәп итсәң исән калырга –
Мин сакларммын аны кар бөртеген
Төргән кебек җылы камырга».

Шуннан башлап, имеш, көне-төне
Дөреслекне эзли дөньялык:
Камыр батырларның карьясеннән
Табар микән аны дөм халык?

## Егәр

Без һәммәбез – егәр, бер йомарлам,
Без һәммәбез – акыл (бер чама...).
Берни түгел безгә күккә ашу,
...Арба тагып уйнау борчага.

Үз егәрен үзе санламаган –
Табалмас ул чорның бөтенен.
Сүнгән чакта уттан хутлырак без,
Янган чакта – черек төтене...

Биеклекне бөеклеккә тиңләп,
Җирне күккә димләп, чор ага.
Йолдызлардан көнләп үләм инде
Менеп төшкән саен чормага...

## Яфсарту

Яфсарталар кайчак танышлар да,
Яфсарталар инде, нишлисең –
Яратканнар белән генә түгел,
Яфсартканнар белән ишле син.

Әчелеге, төчелеге телнең
Килеп җитә җиде ят аша.
Мин онытмыйм, сез дә онытмагыз –
Тел өстендә илләр саташа.

Яфсарталар көнгә яраклашып,
И, сөйлиләр юкны бар итеп.
Фәрештәдәй канат җәймәкчеләр,
Күрсәләр дә женгә пар итеп.

## Истә

Морҗалардан зәңгәр төтен чыга,
Җил тарата учак җылысын.
Нигә, әнкәй, утлы еллар узгач,
Ул чакларны сагынып елыйсың?

Күккә таралсы күк томаннар
Урамнарны нигә урый соң?
Нигә, әнкәй, безнең киләчәкне
Учакларга карап юрыйсың?

Төтеннәрне талап, җилләр исә,
Тәрәзләргә китә сугылып.
Кемгә, әнкәй, нидер әйтмәкче син,
Утлы кисәүләргә сузылып?

Төш бу дисәм, төшкә охшамаган –
Бигрәк җете иде төсләре.
Бу төш, әнкәй, гомер буе истә,
Башкалары искә төшмәде.

## Вакыт кошы

Бусы – харам... Сыйпап башларыңнан,
Биздерә дә кичке ашларыңнан,
Йокысызлык йоктыра да Вакыт
Чыгып оча мендәр асларыннан.

Һәм әйләнеп кайта таңга таба,
Ашыктыра, сулышларга каба,
Кар-боз дими, яңгыр-явым дими –
Кулларыңнан җитәкли дә чаба.

Өлгер генә яңа җирләр алып,
Чиратларда торып, чирләр алып.
Вакыт кошы ашыктыра диеп –
Чаба бәндә, чабатасын салып...

Бусы – язык... Кулыңдагы азык
Чак-чак кына кала төшми язып:
Шикәр чире... Шикле читләр чире...
Чыгара да сала Вакыт, казып!

Бусы – харам... Сыйпап башларыңнан,
Биздерә дә кичке ашларыңнан,
Йокысызлык йоктыра да Вакыт
Чыгып оча мендәр асларыннан.

## Матурлык

*Тормыш иптәшем, укытучы*
*Фатыйма Вәгыйзь кызына*
*75 яшь тулу уңаеннан.*

Бу шигырьне сиңа багышлыйм мин
Һәм үземнән-үзем көнләшәм:
Сабырлыгың, зирәклегең белеп,
Кирәклегең белеп эндәшәм.

Бу шигырьне сиңа багышлыйм мин,
Иң якыным – тормыш иптәшем:
Моңа кадәр бәхет бергә булды,
Моннан соң да бездән китмәсен!

Телләремнән өзелеп төшкән сүзне
Кемгә юллыйм, сиңа юлламый:
Син моңлансаң, сандугачлар тына,
Син сүз алсаң, заллар суламый.

Авылымның күпме сабыйларын
Өйрәттең син хәреф танырга:
Яңа буын күтәрелеп чыкты,
Колмак салган кебек камырга.

Булгандыр ул, минем тарафтан да
Кырысрак булган чакларым;
Син анда да сизгер була белдең –
Минминлекне минем чакмадың.

Ярты юләр ярын мактый, диләр.
Мин мактамыйм сине, мин котлыйм.
Ярты гасыр бергә гомер кичеп,
Дәшми калам икән – мокыт мин!

## Бөтерчек

Өйрәтте дөнья танырга
Бирнәсен дә, тирмәсен дә.
Белдек хәтта әйләнгәнен
Җирнең кояш тирәсендә.

Чорсыз чорлар шаукымында
Әйләндереп җибәргәннәр –
Шулай ди галим-голәмә
Һәм дә бераз җил бәргәннәр...

Шул бөтерчек җирне урап
Кайтып барам өемә, соң.
Йә, әйтегез, бу ачышлар
Менә миңа ниемә соң?..

И дөньялык, без кемнәр соң –
Бераз гына сиздер инде!
Бөтерчектә тузан туе:
Алары шул сездер инде!



Марат
Кәбиров

# ГОМЕР

ПОВЕСТЬ

1

Шәһәр урамы буйлап акрын гына атлап килгән уртача буйлы, тулы гына гәүдәле ханымның күзләре әле бер, әле икенче кибеткә сугылып узды. Тик ул, инде борылам, инде керәм дигән җиреннән тыелып, үз юлын дәвам итте. Куе кара кашлары астыннан караган күзләрендәге моңсулык иреннәрендәге елмаюга да тамып төште. Балалар кибете янына җиткәч, ул тукталып калды. Керергәме-юкмы дигәндәй икеләнеп торды. Үзе дә аңламастан, уң кулы белән инде өлгереп җиткән корсагын сыйпап куйды.

И, нинди генә хатын-кыз яратмый икән кибетләрдә йөрергә. Карынындагы сигез айлык баласы, менә-менә дөньяга киләм дип торганда – бигрәк тә. Айгөл инде аңа кием-салымнарны да, уенчыкларны да, башка кирәк- яракларны да күптән хәстәрләп куйган иде. Шулай да юл уңаенда очраган балалар кибете янына җиткәч тыелып кала алмады. Нәрсәләр барлыгын белеп, кулыңа тотып карасаң да, күңелгә рәхәт булып кала. Үзенә кием сайлаганны карындагы бала да белеп торадыр, ул да шатланадыр кебек тоела. Бәлки, чынлап та, шулайдыр. Берәр матур әйбер очратып, сокланып карый башласаң, бала да тернәкләнеп китә, тибенергә тотына. Аның шулай хәрәкәтчәнлеге анасының да күңелен күтәреп җибәрә. Ул елмаеп куя. Баласы белән бергәләшеп, сөйләшә-сөйләшә, кибеттә әйбер сайлап йөриләрдер шикелле тоела башлый.

Кибет ишеге төбенә җиткәч, Айгөл бер мизгелгә тукталып калды. Эчтә үзен нинди хәлләр каршылаячагын уйлаудан иреннәренә кунган елмаю юкка чыкты, күңелен рәнҗү-кимсетелүгә тартым хис биләп алды. Юк, моны кимсетү дип кабул итәргә, рәнҗергә ярамый инде. Тәртибе шулай булгач, берни дә эшли алмыйсың. Бер Айгөл өчен генә кертелгән чикләү түгел бит, бөтен халык шушы канунга буйсынып яши. Шулай булгач, ничек бар, шул килеш кабул итәргә генә кала.

---

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Онытма таңнарыңны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Тик бер мизгелгә хатынның күңелендә өмет чаткылары балкып китте. Бәлки... Бәлки, ул кануннарны юкка чыгарганнардыр инде. Дөнья бит көн саен, сәгать саен үзгәреп тора. Матбугат чаралары моны кемузардан кабатлап, халыкның аңына сеңдерергә тырыша. Һәм сеңдерә дә. Айгөл дә кайчан гына әле битлек киюгә каршы иде. Чир йоктырудан сакламый диләр бит инде аны. Ә киеп йөрүне мәҗбүри итәләр. Шунсыз син беркая да керә алмыйсың. Кибеткә керсәң, җыйган әйбереңөчен түли алмыйсың – сатучылар борып чыгара. Автобуска утырсаң, икенче тукталышта ук төшереп калдыралар яки штраф салалар. Менә шулай булгач, теләсәң-теләмәсәң дә, битлек киеп йөрергә мәҗбүр буласың. Өстәвенә, кибетләрдә дә, җәмәгать транспортларында да биш минут саен кабатлап торалар: «Битлек киегез... Дистанцияне саклагыз... Алырга җыенган әйберләргә генә кагылыгыз... Электрон акча белән түләргә тырышыгыз...» Гел шулай кабатланып торгач, үзеннән-үзе хәтергә сеңә, мотлак үтәлергә тиешле кагыйдәгә әйләнә икән. Хәзер Айгөл урамга битлексез чыкса, үзен киемсез кебек хис итә. Үз чирен башкаларга йоктырырга тырышып йөргән җинаятьче кебек.

Могҗизага өметләнеп керсә дә, берни дә үзгәрмәгән булып чыкты. Ишек төбендә алтмыш яшьләр тирәсендәге ир сакта тора. Керүчеләрнең документларын тикшерә. Айгөл алдындагы ир кәгазен күрсәтте дә узып китте, аның хатыны чәйнәнеп алды:

– Бигрәк хәтәр кыланган булалар инде, – диде ул, сумкасын актарып. – Менә күреп торырсыз, сайлаулар җитсә, тагын чирләүчеләр санын киметерләр, бернинди куар-код сорап тормаслар. Ә хәзер халыкны сарык урынына күрәләр...

Ул, кирәкле кәгазен табып, сакчының кулына тоттырды. Тегесе «узыгыз» дигәнне аңлатып баш какты һәм Айгөлгә борылды:

– Куар-кодыгыз?

Айгөл гаепле елмайды:

– Өйдә калдырганмын...

Сакчы аңа баштанаяк күз йөгертеп алды да көрсенеп куйды:

– Үткәрә алмыйм, гафу итегез.

– Мин бер генә минутка, – дип үҗәтләнде хатын. – Әнә теге бүлектән генә урап киләм.

Сакчы уң кулы белән стена почмакларына ишарәләде:

– Булмый, адым саен камералар тора.

– Ә үтенеп сорасам?

– Мине эштән куачаклар. – Сакчы монысын ярымпышылдап әйтте: – Зинһар, аңларга тырышыгыз.

Айгөлнең артында кешеләр җыела башлаган иде инде.

– Тоткарламагыз, зинһар, – дип кычкырды бер ханым һәм тирә-ягына каранып өстәп куйды: – Йөри шунда җыен әтрәк-әләм, чират озынайтып.

Гади генә бер хатын иде бу. Симез дә, ябык та түгел. Киенүе дә, бизәнүе дә исеңдә калдырырга теләсәң дә, калдырып булмый торган. Гомер буена муллыкка коенып, бер кайгы-хәсрәт күрмичә, тормышның асылын белмичә яшәгән байбичә булса, бәлки, гафу да итәр идең. «Берәр миллионер яки начальник хатыныдыр, шуңа кылтаядыр инде, бахыр...» – дип кызганыр идең. Гомерләрен алтын читлектә үткәреп, тормышның нәрсә икәнен дә

белмәгән килеш кылтаеп йөрүчеләр һәрвакыт кызгану тойгысы уята. Ә бу... Бер ягы белән дә Айгөлдән өстенлеге булмаган соры бичә... Хәер, аның өстенлеге юк түгел икән шул. Аның куар-коды бар...

Айгөл нәфрәт тулы карашын аңа төбәде. Бер мизгелгә күз алдыннан шундый күренеш үтте. Аның көйдергеч карашлары тәэсирендә хатын, кара көеп, көл өеменә әйләнде, һәм ишектән кергән җил аның бер өлешен туздырып алып китте. Шул мизгелдә үк җыештыручы хатын килеп җитте һәм көл өемен, соскысына себереп, чүп савытына ташлады. Мондый бәндәләрнең урыны, бәлки, чынлап та, чүп арасында булгандыр. Әмма чынбарлык аз гына башкача иде. Айгөлнең нәфрәтенә карап кына, берни дә үзгәрмәде. Теге хатын һаман үз урынында калды һәм телефонындагы куар-кодны сакчының борын төбенә китерде. Тегесе баш каккач, тирә-якта хәбәре дә булмагандай, кибеткә узды. Айгөл аны карашлары белән озатып калды да ишеккә юнәлде. Сәер инде кайбер кешеләр, синең алда аз гына өстенлекләре булса да, әллә кем шикелле кыланалар.

Урамга чыккач, Айгөл талгын адымнар белән метро ягына атлады. Ноябрь урталары булса да, урамда вак кына яңгыр сибәли. Һавада кара болытлар хакимлек итә. Күкне болытлар томаласа, җирнең дә төсе үзгәргән шикелле була икән, җир генә түгел, күңел халәте дә үзгәрә, күңел дә кояш нурына сусап, болытлар күләгәсендә кала. Айгөлнең дә кәефе юк иде. Әллә һава торышы шулай тәэсир итте, әллә теге хатын сәбәпче булды, аңламассың. Менә шушы ярымкараңгылык хөкемендәге урамда, төрле төсләрдәге битлекләр кигән кешеләр арасында ул үзен чит-ят итеп, башка дөньяга эләккән кебек итеп тойды.

Метрога җитәрәк борынына тәмле ис килеп бәрелде. Әллә нинди татлы ризыклар исе бергә катнашкан да чәчәкләр гөлләмәсе шикелле үк тәмле исләр шәлкеме хасил иткән. Айгөл кинәт үзенең ачыгуын тойды. Юк, бу хәтта ачыгу да түгел, ач кешегә ни бирсәң, шуны ашый, аңа бары тик тамагын туйдырырга гына булсын. Ә Айгөлнең ниндидер тәмле ризык ашыйсы килә иде. Өйдә тиз генә әзерләп булмый торган. Үзенчәлекле, затлы ризык. Шашлык бугай... Әйе... Һәм ул, иснең кайдан таралуын эзләп, тирә-ягына күз салды.

Метрога терәлеп диярлек торган кафедан тарала икән. Һәм Айгөл, үзе дә сизмәстән, шунда атлады. Шушы татлы искә исереп, гипнозланган кеше рәвешендә кафега килеп керде. Һәм үзенең ник болай итүенә үкенеп куйды. Ишек төбендә сакчы тора иде. Ишек каршысындагы стенада зур тасма сузылган һәм анда эре хәрефләр белән язып куелган: «Игътибар! Кафеда куар-коды булмаган гражданнарга хезмәт күрсәтелми!»

– Куар-кодыгызны күрсәтегез! – Сакчы Айгөлнең каршысына ук килеп басты. Аның артык якын басуыннан кыенсынып, хатын бер адымга чигенергә мәҗбүр булды. – Куар-кодыгыз булмаса, тоткарламагыз.

Бу сакчы яшьрәк иде, егерме бишләр тирәсендәдер. Үзен дөнья кендеге итеп тоюы, һәр сүзенең, һәр гамәленең хаклылыгын белеп эш итүе әллә кайдан аңкып тора. Үзенең хаклы һәм мәңгелек икәненә нык ышанган мондый затлар белән беркайчан да борчагы пешмәячәген аңласа да, Айгөл бәхетен сынап карарга булды.

– Мин онытып калдырганмын...

– Куар-кодсыз хезмәтләндерү юк. – Сакчы стенадагы язуга ымлады. – Барыгыз, чыгып китегез.

Сакчы егет Айгөлне, терсәгеннән алып, ишеккә әйдәде. Карышуның файдасы юк иде. Тик хатын бирешергә теләмәде:

– Сабыр итегез! – Ул тукталып, егетнең күзләренә төбәлде. – Мин монда утырырга җыенмыйм бит. Кирәкле ризыкны алам да китәм.

Егет бирешә торганнардан түгел иде:

– Ярамый, – дип кистерде ул кире каккысыз тавыш белән. – Үзегез белән алырга теләсәгез дә, урамнан заказ бирергә кирәк. Ә иң яхшысы – өегезгә кайткач, телефон аша.

Егет Айгөлне кабат терсәгеннән эләктерде, әмма хатын аның кулын селтәп җибәрде:

– Нәрсә, сез җансызмы әллә? – диде ул, ачуланган кыяфәт чыгарып. – Мин авырлы. Ә авырлы кешегә теләгән нәрсәсен ашарга кирәк. Югыйсә бу баласында чагылачак.

Монысын әби-апалардан әллә ничәшәр кабат ишеткәне бар иде Айгөлнең. Әгәр йөкле хатын теләгәнен ашамый икән, аның баласы зәгыйфь булып туарга мөмкин. Авылда бер егетне хәтта «Күгәрчен күз» дип тә йөртәләр иде. Аның әнисе авырлы вакытында күгәрчен ите ашарга теләгән, әмма андый мөмкинлеге булмаган һәм улының күзләре күгәрченнекенә охшаш булып туган. Моны күреп торгач, «әбиләр әкияте» итеп кенә карый алмыйсың инде. Хәер, табиблар үзләре дә кире какмый. Организмга тиешле матдәләр җитешмәүдән дип аңлаталар... Ә Айгөлнең... Айгөлнең шашлык ашыйсы килә икән... Сарык итеннән эшләгәнне...

– Мин сезнең балагыз өчен җавап бирә алмыйм, – диде егет йөзендәге елмаюга төрелгән салкынлык белән. – Гафу итегез, тәртибе шундый.

– Оят түгелме сезгә?

– Түгел, – диде сакчы тыныч кына. – Сезгә гарьлек булырга тиеш. Чөнки сез, саклану чараларын инкарь итеп, башкаларга чир йоктыру куркынычы тудырасыз.

Айгөл нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачуга, яннарына кырык биш яшьләр тирәсендәге бер ханым килеп басты. Аның янында сакчының үзен тотышы үзгәрүгә карап, Айгөл бу ханымның зур кеше икәнен чамалады. Шундук аның күкрәгендәге бейджикка күз салды. Исем-фамилиясен истә калдыра алмады, тик аның астындагы язудан ханымның кафе директоры икәненә төшенде.

– Узсын, – диде директор сакчыга һәм Айгөлгә борылды. – Нишлисең инде, шуны таләп итәләр бит... Ә сез – башка мәсьәлә. Йөкле хатынны тоткарларга берәүнең дә хакы юк. Узыгыз, хәзер китерерләр.

Бу ханымның исем-атын бик тә белергә теләсә дә, Айгөл кабат аның күкрәгенә текәлергә кыймады. Якты елмаю белән рәхмәт укып, тәрәзә янындагы кечкенә өстәл янына барып утырды. Кеше бик күп түгел иде. Илле яшьләр тирәсендәге бер пар, арырак ялгызы гына бер кыз утыра. Айгөлгә бер өстәл аша гына ике ир бәхәсләшә, болары, муен артын бераз кыздырып алганнар бугай, бик тавыш чыгармаска тырышсалар да, ара-тирә кычкырыбрак сөйләшеп алалар. Залны күзәтә-күзәтә, киемнәрен элүгә, официант килеп җитте. Айгөл заказ бирде дә кулын юып килде. Ул арада тәлинкәгә вак итеп туралган шашлыкны яшелчәләр, тәмләткечләр белән бизәп китереп тә җиткерделәр. Официант түгәрәк ике булочка, бер чәйнек чәй дә алып килгән. Айгөлнең акча түләргә җыенуын күреп, ул баш какты:

– Рәхмәт, – дип елмайды үзе. – Бер тиен дә түләргә кирәкми. Директор шулай кушты.

Айгөл нәрсә әйтергә дә белми калды. Официант китеп тә барды. Хатын карашлары белән директорны эзләп карады да, тапмагач, игътибарын өстәлгә юнәлтте. Тәлинкәдәге ризык күзләрне сөендерерлек дәрәҗәдә матур да, авыз суларын агызырлык тәмле дә иде. Әмма бер-ике кисәкне алып кабу белән Айгөлнең күңеле булды. Моңа кадәр тәкатьсезләнгән теләге канәгатьләнде. Ул, эчке бер ләззәт белән күзләрен йомып, бераз утырды да чынаягына чәй агызды. Карынындагы бала тыпырчынып куйды. Ул да сөенәдер, шатлыгыннан биеп ятадыр шикелле тоелды. Хатын елмайды. Шундый күтәренке күңел белән чәен эчеп бетергәч, алдындагы тәлинкәгә күз салды. Бушлай бирсәләр дә, моны ташлап калдырырга кирәкмидер инде. Бәлки, өйгә кайткач, тагын шуны ашыйсы килер. Авырлы хатынның нәрсә теләгәнен алдан әйтеп булмый. Ул сумкасыннан, андый-мондый хәл булса дип, гел йөртә торган целлофан капчыкларның берсен алды да, тәлинкәдәге ризыкны шунда салып, сумкасына тыкты. Һәм урыныннан кузгалып, кассадагы кызлар янына килде.

– Бик зур рәхмәт сезгә, кызлар! – дип елмайды ул. – Чынлап та, бушлай булдымы бу? Түләргә кирәкмиме?

– Юк, юк, кирәкми, – диеште кызлар. – Кергәләп йөрегез. Тагын килегез.

Ишек янына җитүгә, өчесе дә бер рәвешле костюмнар кигән өч ир-егет килеп керде. Боларның барысы да таза, нык гәүдәле утыз биш яшьләр тирәсендәге ирләр иде. Алар үзләрен хуҗаларча тотып, түргә уздылар.

– Директорны чакырыгыз, – диде берсе кассада утырган кызларга. – Без аның монда икәнен беләбез.

Икенчесе залда утыручы клиентларга карап сөрәнләде:

– Хөрмәтле гражданнар, куар-кодларыгызны күрсәтергә әзерләнегез.

Ул арада директор ханым күренде.

– Нәрсә булды? – диде ул, бу ирләрне өнәп бетермәвен яшермичә. – Ник сугыш чыккандай кыланасыз?

Бая директорны чакырган ир турыдан-туры әйтеп салды:

– Сез кешеләрне куар-кодсыз үткәрәсез дигән хәбәр бар, тикшерергә килдек менә.

– Болай да клиентлар азайды, – дип шелтәләде директор ханым. – Ә сез булганнарын да өркетеп йөрисез. Кем әйтте сезгә куар-кодсыз керәләр дип?

Үзе шундук ишек тоткасына үрелгән Айгөлгә күз атып алырга өлгерде. Аңлады Айгөл. Бер мизгел дә кичекмичә ишек артына чыкты. Урамда әле булса караңгы һәм яңгыр сибәли иде. Кафедан таралган тәмле ис кенә ничектер юкка чыккан, һәрхәлдә ул хәзер борынны кытыклап интектермәде. Әмма күңелне әллә нинди шик тырмады. Кай арада кем хәбәр иткән? Ничек шулай тиз килеп өлгергәннәр? Бер мизгелгә ул үзен гаепле итеп тойды. Директор ханым, үзе дә авырлы булган кешедер, мөгаен, аны аңлады, ярдәм күрсәтте, игелек итте. Ә ул аның яхшылыгына... Һәрхәлдә, аның кылган игелеге үз башына таяк булып төшә язды. Ярый әле, Айгөл нәкъ вакытында кузгалды, ярый әле, чыгып өлгерде... Игелек иткән өчен җәза көтеп яши торган чорга килеп җиттекмени соң?

Айгөл, сизелер-сизелмәс кенә борылып, кафе ишегенә күз ташлады. Теге

өчәү йөгереп чыгарлар да аны эләктереп алырлар һәм, үзләре белән алып китеп, төрмәгә ябып куярлар сыман тоелды. Һәм ул, ашыга-ашыга, метрога юнәлде. Тизрәк кайтып китәргә кирәк. Бу заманда өеңә бикләнеп ятудан да яхшысы юк. Һава суларга теләсә, әнә, балконга чыгар. Ә поликлиникага барасы булса? Бүгенге кебек? Килгәндә, ярый, ире Илдар китереп куйды. «Бүген эшләрем күп булачак, такси белән генә кайтырсың», – диде ул. Ә Айгөл поликлиникага ук такси чакырмады, бераз җәяү йөрисе килде. Һәм менә... Бәлки беркая да йөрергә кирәкмидер? Әнә, әбиләр элек тапканнар бит әле балаларын. Бер врачка да күренмәгәннәр, хәтта роддомга да бармаганнар, басу читендәге агач төбендә бәбиләгәннәр.

Метрога төшәр алдыннан саклык постында бу уйлар отыры көчәйде. Тагын куар-код сорадылар. Булмагач, кире бордылар. Монда ялынып-ялварсаң да, файда булмас иде – күзәтүче камераларның чуты-чамасы юктыр. Элегрәк, террорчылар белән куркыткан заманда ук, андый камераларны һәр почмакта бар дип сөйлиләр иде. Хәзер тагы да күбрәктер инде. Шуңа Айгөл берсүзсез кире борылды.

Автобус белән генә кайтыр. Ләкин тукталышта ук өметен өзделәр.

Килеп туктаган автобусның алгы ишеге төбендә озын чират хасил булган иде. Күптән инде чиратларның ни икәнен белмәгән Айгөл өчен бу бик сәер тоелды. Янында торган хатыннан сораштырмакчы булган иде, башта бераз күзәтеп торырга булды. Сәбәбе гади генә икән. Кондуктор автобуска керергә теләүчеләрнең куар-кодын тикшерә. Моңа өйрәнмәгән кешеләр кесәләрен, сумкаларын актарып, документларын чыгарып күрсәткәнче озак кына вакыт үтә. Өстәвенә, билет та алырга кирәк. Шунлыктан чират барлыкка килә. Кешеләр канәгатьсезләнә, төрле яклап кондукторга кычкыралар. Куар-код алырга өлгермәгәннәре йодрыклап ташланырга да әзер, тик аларны нәрсәдер тыеп тора. Бәлки шаһитларның күп булуы, күпләренең телефоннан видеога төшереп торуыдыр.

Айгөл нишләптер ишетмәгән иде бу хакта... Дөресрәге, ишетсә дә, әһәмият бирмәгән иде. Ул мондый нәрсәнең булуы мөмкин түгел дип уйлый, ә хәбәрләрне чынбарлык түгел, бары тик явыз телләрнең чираттагы гайбәте дип кабул итә иде. Явыз телләр дә күп бит хәзер. Теләсә-нинди буш хәбәрләр таратып, халыкны куркытырга, котыртырга гына торалар. Ә бу хәл чынбарлык булып чыкты. Ышанырлык та түгел, бер карасаң. Кем йөри инде бу заманда автобусларда? Халыкның хәерчерәк катламыннан башка беркем дә утырмый бит аларга. Шул хәерчеләрне үзара талаштырып яту кемгә кирәк икән?

Хәтта куар-коды булган хәлдә дә зур корсагы белән Айгөл мондый мәхшәр эченә керергә җөрьәт итмәс иде. Автобус бит ул! Монда халык консерва эчендәге балыклар шикелле бер-берсенә терәлеп, елышып барырга мәҗбүр. Кибетләрдә минут саен: «Дистанция саклагыз!» – дип кычкырсалар да, монда аны бар дип тә белмиләр. Эчең аркаңа береккәнче кысарга да күп сорамаслар. Алла сакласын...

Такси чакырырга туры килер...

Телефонның теге очыннан бер тукталыш арасы күпме торганын әйткәч, Айгөл үз колакларына үзе ышанмыйча кабатлап сорарга мәҗбүр булды:

– Нәрсә? Өч йөз илле?

– Әйе. Сез барасызмы?

Хатын янә автобус тукталышына карап алды. Анда инде чын-чынлап мәхшәр купкан, ярсыган кешеләр кондукторны сөйрәп алып сугыша ук башлаганнар иде. Кондуктор – Азиядән килгән кеше, урыс телен чатан-ботан китереп кычкыра: «Нәрсә, мин гаеплеме әллә? Югарыдан шулай кушалар, ә миңа яшәргә, биш баламны асрарга кирәк...» Тик аның биш баласы берәүне дә кызыксындырмый, дүрт тарафтан йодрыклар ява. Ниһаять, аны аяктан ектылар. Котырынган кешеләр, егылып яткан кондукторны аяклары белән читкә эткәләп, автобус ишегенә ташланды...

– Барасызмы? – дип кабатлады такси диспетчеры. – Сузмагыз. Монда бер сез генә түгел.

Мондый дорфалыктан Айгөлнең ачуы килде. Башка вакыт булса, берәр саллы сүз әйтеп, телефонны ташлар иде. Тик әле алай кыланып булмый. Өстән яңгыр сибәләп тора, бераз арыткан да.

– Барам, – диде ул, ачуын җиңәргә тырышып. – Җибәрегез.

– Яхшы. Көтегез.

Телефонны куйдылар. Кызыксынуы көчле булса да, Айгөл тукталыш ягына карамаска тырышты. Күңелендә ниндидер курку бар иде. Әле кайчан гына бер-берсенә елмаеп эндәшә торган итагатьле кешеләр үзләре кебек үк яллы эштә йөргән кондукторны өзгәләп ташларга да күп сорамый икән. Хәер... Чиратны тоткарлыйсың дип, үзенә дә бәйләнде бит теге хатын. Куар-код тикшерүчеләрне дә кемдер чакырган бит инде, әләкләшкән. Югыйсә кайдан белерләр иде? Кайчан гына соклангыч булып тоелган дөнья, якты-ягымлы кешеләр беркадәр үзгәргән иде. Кара болытлар, караңгы күк, салкын яңгыр һәм явызлана барган кешеләр. Бу чынбарлык түгелдер, ә коточкыч кинолардан бер күренештер сыман тоелды. Айгөл анда ялгыш килеп эләккәндер. Яки куркыныч төш күрәдер. Чынбарлыкның мондый булуы мөмкин түгел.

**2**

Кулында әлегә куар-код булмаса да, Айгөл вакцина ясатуга каршы түгел иде. Моннан биш-алты ай чамасы элек ул хәтта үзен караучы врач белән дә сөйләште. Карыныңда балаң булганда, мондый авырулардан сакланырга кирәк. Ә әлегә иң кулай юл вакцина ясату кебек иде. Мондый вакытта иң беренче бала турында уйлыйсың бит инде, ниндидер сәяси төркемнәрнең фикерләре тәэсирен югалта. Ире Илдар белән бергәләшеп бардылар. Карарлары катгый, җиңнәре сызганулы иде. Тик табиб Айгөлгә бик ашыкмаска киңәш итте.

– Азрак сабыр итегез әле, бу вакытта сезгә бернинди прививка да киңәш ителми, – диде ул. – Аннан соң, йөкле хатыннарга әлеге чирдән вакцина ясатырга ярамый дигән сүз дә бар.

Айгөл моны бик авыр кабул итте:

– Әгәр чир эләктерсәм? – диде ул, күзләрен мөлдерәтеп. – Әгәр балага йокса?

Табиб беркадәр уйланып торды да кулларын гына җәйде:

– Әлегә бу хакта бернинди мәгълүмат та юк, – диде гаепле кыяфәт белән. – Сакланырга тырышыгыз. Кеше күп җыелган урыннарда бик йөрмәгез.

Айгөл елмайды.

– Чирле кешеләрнең иң күп җыелган урыны поликлиника инде, – диде ул. – Монда килмичә дә булмый бит...

Табиб иңнәрен генә сикертеп куйды. Айгөл аны гаепләмәде. Бу поликлиникада табиблар гел алышынып тора, күбесе – укуын тәмамлап кына килгән яшьләр. Алар монда бераз тәҗрибә туплыйлар да яхшырак урынга күчеп китәләр бугай. Тәҗрибәләре аз булгач, белемнәре дә шул чамарактыр инде. Алардан бик әллә нәрсә көтәрлек тә түгел.

Өенә кайтып, интернетны актарып карагач та, шундыйрак фикерләргә юлыкты. Вакцина кадатырга ярамаганнар исемлегендә төрле хроник чирләр белән беррәттән йөклелек тә бар иде. Ә кайбер чирләргә «с осторожностью» дип куйганнар. Монысы көләсене генә китерде. Тирә-ягыңа карана-карана, шприц энәсен акрын гына кертергә кирәк микән? Гомумән, интернеттагы фикерләр капма-каршы һәм кайсына ышанырга да белерлек түгел иде.

Бу зәхмәткә каршы вакцина уйлап табылгач, кешелек икегә бүленгәндәй булды. Берәүләре аның зыянлы булуы турында сөйләде, икенчеләр файдасын мактап туялмады. Ике якның да дәлилләренә ышанырга мөмкин иде бугай. Беренчеләре вакцина ашык-пошык уйлап табылган, тиешле тикшеренүләр узмаган, киләчәктә нинди нәтиҗәләргә китерүе билгесез дип хәбәр таратты. Ике-өч елдан вакцина ясатучыларның күбесе үлеп бетәчәк, йә яман чирдән гарипләнеп калачак дигән хәбәрләр дә булды. Чынмы-ялганмы, әмма куркыныч хәбәрләр хәтергә ныгракябыша, ышанырга мәҗбүр итә, моны акылың кире какса да, күңелдә шик кала. Шуңадыр инде вакцина ясатырга халык бик атлыгып тормады. Уйлап карасаң, ике-өч елдан соң нәрсә булачагын кем төгәл әйтеп бирә ала инде? Әле монда иртән торгач ни булырын да күз алдына китерү авыр. Ә болар «ике-өч елдан соң»...

Икенче берәүләр аның афәттән котылу өчен бердәнбер чара булуын халыкка сеңдерергә тырышты. Бу фикер власть тирәсеннән чыкканлыктандыр инде, аңа ышанучы бик табылмады. Төрле җитәкчеләр, табиблар, матбугат чаралары туктаусыз кабатлап торса да, бу дөреслек булып тоелмады. Югыйсә акылы булган кеше табибларның сүзен тыңларга тиеш кебек... Кайберләренең прививка ясату турында белешмә сатып алулары турында да сөйләделәр. Чирлеләр санын күрсәтүче статистика мәгълүматларының илдәге сәяси вакыйгаларга бәйле рәвештә үзгәреп торуы да үзенекен итте. Сайлаулар чорында яки Конституциягә төзәтмәләр кертелгән вакытта авыручылар саны азаеп торды. Икътисадка йогынты ясый алырдай дөньякүләм чаралар вакытында да халыкны вакцина кадату турында белешмә яки куар-код сорап аптыратмадылар. Ә хәлләр бераз тынычланып калгач, чир белән көрәшү кискенләшә төште. Боларның барсын да күреп-ишетеп торган халык каршы дәшмәде, әлбәттә, тик югарыдагыларның сүзен үтәргә дә бик атлыгып тормады.

Теге вакытта, май азаклары иде бугай, ире Илдар ясатты. Ул да вакцина тарафдары түгел иде, әмма хатыны йөкле булгач, каршы килмәде. Хатынын да, баласын да сакларга кирәк. Өстәвенә, эше дә гел кеше арасында. Журналист ул, гомер буена йә командировкада, йә ниндидер очрашуда. Әлегә кадәр төчкереп тә караганы юк, бәлки, прививканың файдасыдыр.

Айгөлнең прививка ясату теләге беразга онытылып торды. Үзенең якыннары арасында чир йоктыручылар юк, ә матбугаттагы, социаль челтәрләрдәге хәбәрләр бик ерактагы вакыйгалар сыман тоелды,

аларның монда килеп җитәчәгенә бик ышанырлык түгел иде. Таныш түгел кешеләрнең фаҗигасе җиңелрәк кабул ителә бит инде, алар өчен күңел өзгәләнми, хәтта иң авыр дигәннәрен дә бер әрнү дулкыны белән каршылыйсың да тиздән онытасың. Ә инде «бу айда фәләнчә кеше вафат булган» дигән хәбәрләр сан гына булып тоела, шул саннар артында торган кеше язмышларын, меңнәрнең тормышын җимергән фаҗигане күрә алмыйсың. Мондый чикләнгәнлек, бәлки, адәм баласының үз-үзен саклау инстинкты сыманрак нәрсәдер, әмма ул кайчагында авыр хәлгә дә калдыра...

Ил башына төшкән фаҗига аерым кешеләрне читләп уза алмый. Зур түрәләр, абруйлы белгечләр мөһим дип саный икән, вакцина ясатырга кирәк. Соңгы мәгълүматлар буенча, моны авырлы хатыннарга да рөхсәт итә башлаганнар. Алай гына да түгел, бу иң мөһим чараларның берсенә әйләнгән икән. Карындагы балага бернинди дә зыяны юк диләр. Ә йөкле чагында хатын-кыз организмы җитди үзгәрешләргә дучар була, иммунитеты, төрле чирләргә каршы тору сәләте кими. Шуңа күрә авырлы хатыннарның чир йоктыру куркынычы күпкә арта. Мондый очракта иң ышанычлы саклану чарасы вакцина ясату диләр.

Хәтта артык файдасы булмаган очракта да шунсыз сиңа куар-код бирмиләр. Куар-кодың булмагач, өеңнән дә чыга алмыйсың. Чыгуын чыгасың инде... Тик син бер хокукы да булмаган мәхлукка әйләнәсең. Беркөнне әле эш урыныннан да шалтыратып сорадылар. Прививка ясату яки ясатырга ярамау турында белешмә алып килергә кирәк икән. Югарыдан шулай кушканнар. Әлбәттә, моны инкарь итеп тә булыр иде. Тик җитәкчеләре әйбәт кеше, аны авыр хәлгә куясы килми. Ничек кенә уйласаң да, кай якка гына карасаң да, прививка ясатмый чараң юк. Бу мөһим. Илең өчен дә. Якыннарың өчен дә. Үзең өчен дә.

Айгөл катгый карарга килде дә һәртөрле икеләнүләргә, шикләнүләргә урын калдырмас өчен икенче көнне үк кадатып та куйды. Моның бер кыенлыгы да юк икән. Башта акушер-гинеколог тикшереп, рөхсәт бирә. Айгөл аңа еш күренә иде, әледән-әле тикшерелеп тора. Шулай булгач, бөтен мәгълүматлар әзер иде. Бу юлы ул хатынның ниятен хуплады гына:

– Ясатырга кирәк, баланың сәламәтлеге өчен бу бик мөһим. – диде ул хәстәрлекле тавыш белән. – Чирнең өченче дулкыны башланды, ә аны булдырмау өчен вакцинадан да ышанычлырак ысул юк.

Айгөл баш кагып елмаеп кына куйды. Бу хакта ул интернеттан укып та белә иде. Табиб артыгын өстәмәде. Гомумән, күзәтеп торсаң, хәзерге табибларның сүзе интернеттагы рәсми чыганаклардан артык аерылмый. Хәтта язып биргән дарулары да бермә-бер диярлек туры килә. Кайчагында Айгөл: «Әллә болар да интернеттан карап кына дәвалыйлар инде», – дип шаяртып та куя.

Терапевт яңа кеше иде. Яшь кенә егет. Айгөлне игътибар белән тыңлады да: «Нәрсәгә зарланасыз? Бер җирегез дә борчымыймы?» – дип сорады һәм, хатынның күзгә бәрелеп торган чире юклыгын белгәч, сүзгә вакыт әрәм итми генә белешмә язып бирде.

Бары тик вакцина ясый торган бүлмәнең ишеге төбендә генә чират иде. Бүлмә поликлиниканың бер як почмагында, бүтән вакытларда Айгөл бу тирәгә якын килмәскә тырыша, теге чир белән бәйле булгач, бераз шикләнеп

карый иде. Ә бу юлы озак кына көтәргә туры килде. Күңелендә барыбер шик таралмады. Үзе артыннан чират алучы табылгач, аны кисәтеп, беркадәр урамда йөреп керде. Көн болытлы булып, яңгыр сибәләп торса да, урамда тынычрак иде. Урап керүгә чираты да җитте.

Гадәти укол ясаган кебек кенә кадап чыгаралар икән, бернәрсәсе дә сизелми. Шундый җиңел генә процедурадан соң, куар-код бирәләр, һәм син җәмгыятьнең тулы канлы әгъзасына, чын кешегә әйләнәсең. Барысы да гади генә. Барысы да кеше өчен. Һәм, чынлап та, поликлиникадан чыгуга Айгөлнең адымнары җиңеләеп калгандай тоелды, зур кибет ишек төпләреннән борып җибәргәндәге үпкә-ачулары кубып төште. Хәер, анысы иң мөһиме түгел иде әле. Иң мөһиме – баласы исән-сау тусын, һәртөрле чир-сырхаулардан азат булсын.

Кайтышлый, юл уңаендагы мәчеткә кереп, хәер дә биреп чыкты. Гел шушы мәчеткә йөриләр алар. Монда татар карты бар. Ишек төбеннән үк диярлек каршы ала, бөтен шартларын китереп укый, дога кыла, теләкләрен тели. Айгөл әле дә сабыеның сау-сәламәт булып тууы, үсеп җитүе өчен доганы аерым укытты, мулла теләкләрен теләгәндә, күңеленнән генә үзе дә кабатлап утырды. Һәрбер ана шулай буладыр инде ул... Баласына җил-яңгыр тидермәү хакына үзе тәмуг газапларын кичәргә дә әзердер.

Һәрхәлдә, Айгөл әзер иде. Тик ул газапларның бик якында икәнен генә белми иде әле.

### 3

– Беренче өч көне авыррак булыр, – дигән иде табиб. – Температура күтәрелү, баш авырту, хәлсезлек кебегрәк күренешләр килеп чыгарга мөмкин. Ә соңыннан барысы да аруланыр. Гадәттә, шулай була.

Әмма Айгөл беренче көнне дә, икенчесендә дә, өченчесендә дә бер үзгәреш тә сизмәде. Үзен, гадәттәгечә, бик сәламәт хис итте. Хәтта иммунитетым көчледер минем, югыйсә болай җиңел уздырмас идем дип тә уйлап куйгалады. Шулай гына була күрсен инде. Шулай булыр әле. Мәчеткә керүенең дә файдасы тими калмагандыр.

Ләкин соңгы арада Илдар гына бераз ютәлләп тора. Хәзер бит һәр төчкерүгә дә: «Теге зәхмәт түгел микән?» – дип шикләнеп куя торган заман. Әмма Илдар – вакцина ясаткан кеше, болай дип уйларга бер сәбәп тә юк. Гадәти гриппның да бик котырган чагы бугай. Элегрәк аның белән дә атналар буе урында ятып авырган чаклар бар иде. Хәзер яңа чир күз өстендә каш булды – бүтән төрле авыруга игътибар иткән кеше юк, алар үткенче чир генә булып тоела. Ярый, узар әле. Илдар ул – эше тынгысыз булгач, вак-төяк авыруларны аяк өсте үткәреп күнеккән кеше.

Әмма бик затлы дип күнегелгән дарулар эчүгә карамастан, авыруы көчәя генә барды. «Иртәгә врачка күренәм» дип уйласа да, икенче көнне эшендә яңа мәшәкать килеп чыкты. Ә температурасы төшмәде, баш авыртуы бетмәде, ютәле дә тирәнәйде, хәлсезлегенә зарланды. Һәм Айгөлгә вакцина ясатканның өченче төнендә «Ашыгыч ярдәм» чакырырга туры килде. Илдарны үзләре белән алып китәргә булдылар. Айгөл озата барырга җыенган иде, ире каршы төште:

– Йөрмә, җаным, анда әллә нинди чир эләктерүең бар. Үзем ерып чыгармын.

Ашыгыч ярдәм табибы да шундый фикердә иде:

– Барып тикшеренүе әйбәт булыр, анда ПЦР да, компьютер томографиясе дә ясыйлар. – Бу уртача гәүдәле утыз-утыз бишләр тирәсендәге ханым иде. Махсус киемнән, битлектән булгач, артыгын билгеләү мөмкин түгел. Тавышы матур, ягымлы. – Әгәр кайтырга кирәк булса, такси чакырыр. Ирегез авыр итеп, күкрәк белән сулыш ала. Салып куярга да мөмкиннәр. Алмаш киемнәрен әзерләп җибәрсәгез, бик яхшы булыр.

Айгөл аңа сәерсенеп карады:

– Теге чир түгелдер бит?

– Әйтеп булмый әлегә, – диде табиб. – Симптомнарына караганда...

Айгөл сүзнең дәвамын ишетергә теләмәгәндәй ашыгып бүлдерде:

– Ул бит вакцина ясаткан иде. Май ахырында ук!

Табиб бераз тынып торды да ягымлы гына итеп аңлатып бирде:

– Аңа хәзер биш-алты ай чамасы вакыт үтте, – диде ул, һәр сүзенә басым ясап. – Ул арада чир дә үзгәрде. Бу – мутациягә тиз бирелә торган вирус, яңа штаммнар барлыкка килә. Икенче төрле әйтсәк, без генә аның белән көрәшмибез, вирус та безнең белән көрәшә. Элек ясаткан вакцина хәзер тиешенчә тәэсир итә алмый. Шуңа күрә ирегездә дә...

– Юк... – Айгөл, сытылмаска тырышып, иреннәрен тешләде. – Илдар әле иртән генә әйбәт иде...

– Юк, сез әлегә бик борчылмагыз...

– Ничек кенә булмасын, тикшерү үтеп кайтса, яхшы булыр, – дип, сүзгә кушылды ир-егет табиб, ул моңа кадәр бик сөйләшмичә генә үз эшен эшли иде. – Үзе поликлиникага барса, анда чират зур, атналарга сузылырга мөмкин. Ә монда бер сәгатьтә тикшерелеп кайта.

Илдарны алып киттеләр. Һәрвакыт юлда йөреп күнеккәч, ирнең алмаш киемнәре дә, башка кирәк-яраклары да әзер иде. Айгөл машина өй почмагына кереп югалганчы, подъезд алдында басып озатып калды да өенә кереп житү белән кычкырып елап җибәрде. Матбугатта, интернет чараларында күргән-ишеткән хәбәрләр шунда гына чынбарлыкка әверелде. Ул, элегрәк андый хәбәрләрне күргәч, «Нигә элегрәк дәваланмаганнар икән, нигә үлем чигенә җиткәнче көткәннәр?» дип уйлый иде. Менә шулай кинәт кенә килеп чыга икән бу чир. Көтмәгәндә килеп алалар икән...

Озак елады ул. Соңрак үзен тыярга, игътибарын бүтән нәрсәләргә юнәлтергә тырышты. Торып, чәй куйды. Тик тамагыннан ризык үтмәде. Кичә юган керләрен үтүкләргә маташып карады. Күңеле үсмәде. Телевизорны кабызды. Экранда шатлыкларыннан нишләргә белмичә, елмая-елмая сикергәләгән җырчылар аның хәсрәтеннән көләләрдер, аны мыскыл итәләрдер кебек тоелды. Һәм ул, нәфрәт белән пульт төймәсенә басып, икенче каналга күчте. Монысында ниндидер эчпошыргыч сериал бара иде. Өсте бөтен, тамагы тук булып, житеш тормышта яшәгән сау-сәламәт кешеләрнең мәхәббәт проблемалары аңа бик вак нәрсә булып тоелды. Карарлык нәрсә юк иде.

Аптырагач, телевизорны сүндереп, телефонын алды. Интернетта чокчынып утыру элек тә күпкә кызыграк иде. Тик бу юлы аның да тәмен тапмады. Бер мәгълүматтан икенчесенә күчеп гомер үткәрде. Әмма берсенә дә дикъкать бирмәде, мәгънәсенә үтеп кермәде. Илдарның «ашыгыч ярдәм»

машинасына кереп утырган чагы күз алдыннан китмәде. Спортчылар кебек таза гәүдәле иренең бабайларча бөкрәеп, хәлсез адымнар белән атлап баруы... Машина баскычыннан менәлмичә берничә тапкыр талпынып куюы... Алпан-тилпән килеп, утыргычка атлавы... Һәм утыргач, авыр сулап куюы... Айгөлгә карап елмаерга тырышса да, күзләре тулы моңсулык иде аның... Мәңгелеккә хушлашкандагы шикелле... Менә шул күренеш Айгөлнең бөтен дөньясын томалады. Ул ирен бүтән беркайчан да күрмәстер кебек тоелды.

Бераздан телефоны шалтырады. Бу Илдар иде.

– Мине салдылар, җаным, – диде ул, тавышын көррәк чыгарырга тырышып. Шат һәм сәламәт күренергә теләсә дә, көчәнүе сизелеп тора иде. – Әле эчкә укол кададылар. Хәзер система куялар. Хәлем әйбәт. Син үзеңне сакла. Тикшерен. Миндә булгач, сиңа да йогарга мөмкин.

– Мин бит вакцина...

Илдарның таләпчән тавышы бүлдерде:

– Тикшерелергә кирәк. Миндә бар икән, син дә куркыныч астында. Иртәгә үк поликлиникага бар яки врач чакыр. Өйгә чакырт.

Айгөл нәрсә әйтергә белмичә катып калды.

– Ярар, – диде бераздан. – Барырмын.

– Өйгә чакыр, – диде Илдар. – Шулай яхшырак булыр. Ярый, җаным, мин башкача сөйләшә алмыйм. Соңрак, яме.

Телефонның теге очындагы хатын-кыз тавышы да трубкага эләкте. Ул ерактанрак ишетелсә дә, аермачык аңлашыла иде.

– Хатыныгызмы? – Ягымлы тавышта елмаю чаткылары да чагылган кебек булды. – Әйе, аңа да тикшерелергә кирәк. Тик иң яхшысы «ашыгыч ярдәм» чакырту булыр. Алар кайвакыт биш-алты сәгать көттерә. Әмма поликлиникага йөри башласа, тагы да озаккарак китәчәк.

– Җаным, – Илдарның тавышы якыннан ишетелде. – Иң яхшысы – син «ашыгыч ярдәм»гә шалтырат. Шулай уңайлырак булачак. Озакка сузма.

– Яхшы, кадерлем.

– Үзеңне сакла. Улыбызны да.

– Исән-сау терел. Без сине яратабыз.

– Мин дә сезне... Ярый, сау бул. Хәзер система куялар.

Телефонда өзек-өзек пипелдәгән тавышлар ишетелде. «Элемтә өзелде...» дип уйлады хатын. Һәм бу аңа бик тә авыр булып, аларның икесе арасындагы бәйләнеш өзелү мәгънәсендә ишетелде. Бәйләнеш... Өзелде...

Шушы шиктән котылырга, телефоннан сөйләшмәгән хәлдә ватсап аша язышу мөмкинлеге барлыгын, бәйләнешнең әле өзелмәвен үз-үзенә исбатларга теләгәндәй, хатын смс язып җибәрде. «Иртәгә нәрсәләр китерим?» Җавап бераз көттереп килде, тик ул да күңел юатырлык түгел иде. «Әлегә берни дә кирәкми. Килеп йөрмә, монда барыбер күрештермиләр. Үзең тикшерел. «Ашыгыч ярдәм» чакыр».

Паникага бирелергә ярамый. Тынычланырга кирәк. Айгөлдә бернинди дә чир юк. Ул бит әле яңа гына прививка ясатты. Ә Илдар... Алла кушса, ул исән-имин савыгыр. Күр дә тор менә, беркадәр дәваланыр да нәкъ элекке кебек дәртле басып, елмаеп кайтып керер. Боларны күз алдына китерүгә, Айгөлнең кәефе беркадәр күтәрелеп киткәндәй тоелды.

## 4

Айгөл иртән тиргә батып уянды. Башта ул үзенең кайда ятканын аңлый алмыйча торды. Мунчада түгел бит инде ул. Анда шулай нык кына чабынып чыгып, җәймә ябынып бераз ятып торсаң, бөтен чүпрәк-чапрак лычма суга әйләнә торган иде. Ләкин мунчадагы тир ничектер үзгәрәк, манма су булса да, тәнгә дә, күңелгә дә җиңеллек бирә. Ә әлегесе куе һәм ябышкак тир иде. Торып утыруга ук өшеттерергә тотынды. Ул, тиз генә ваннага барып, җылы су белән коенып чыкты. Тәне бераз җиңеләеп калгандай тоелды. Тешләрен чистартып, чәчләрен көйләп бетерүгә башы авыртырга тотынды. Авыртуны бераз басмасмы дип, кофе кайнатып эчте. Тамак төбендә нәрсәдер кырып торган шикелле иде, кайнар кофедан соң ул басылды. Иртән уянгач, тамак төбе гел коргаксыган кебек була бугай ул, моңарчы игътибар гына ителмәгән бугай. Ә баш авыртуы бетмәде, ул көчәйде генә. Башта лепкә тирәсе таш булып каткандыр шикелле иде, бераздан авырту чигәләргә дә төште һәм кысып-кысып алды. Иң хәтәре әнә шул иде. Кысып алганда, Айгөлнең күз аллары караңгыланды, башы әйләнде, шул халәт тагын аз гына дәвам итсә дә, чыдарлыгы калмас шикелле булды.

Температурасы утыз җиде иде. Моны иң авыр температура дип әйтәләр. Хәлсезлеге дә, тирләве дә, баш авыртуы да шуннандыр инде. Ләкин бу ашыгыч ярдәм чакырырлык дәрәҗәдә кебек тоелмады. Хәзер аларның эшен болай да бик күп дип әйтәләр, бишәр-алтышар сәгатьтән соң гына килгән чаклары да еш була икән. Аларны борчырга ярамый инде. Яхшы түгел. Бәлки болай да узар әле. Айгөлнең температурасы күтәрелгән яки башы сызлаган вакытлары моңа кадәр дә булгалый иде. Дарулар эчкәч гадәттә үтә ул. Кайчагында кофе да ярдәм итә. Саф һавадан урап керү дә. Кайчагында тиз генә, кайвакыт берничә сәгатьтән соң. Әмма бүген барысы да берьюлы ишелеп төште. Шуңа гына бераз авырырактыр.

Баш авыртуы аз гына басылгандай булды. Әмма хәл кермәде. Аз гына хәрәкәтләнсә дә, тир бәреп чыкты. Илдардан берничә тапкыр хәбәр килде. Ире үз хәле әйбәтлеген әйткән, Айгөлгә тикшеренергә кушкан. Хатын җавап язып тормады. Теләге дә юк иде, нәрсә дип язарга да белмәде. Аралашасы килми иде аның. Әллә нинди халәт инде шунда, аңлап та, аңлатып та булырлык түгел. Шулай да үзен мәҗбүр итеп, терапевтка язылырга булды. Әмма телефон артында күпме утырса да, дәүләт хезмәтләре сайтында языла алмады. Гел «сервер хатасы бар, соңрак кереп карагыз» дигәнрәк җавап чыкты. Инде тәмам өметен өзеп, дежур табибны чакырды.

Табиб төштән соң гына килде. Башы авыртуы хәзер бүтән рәвешкә кергән иде. Чигәсен кысып алмый, әмма күзләре, борыннарын, колакларын күзгә күренмәс нәрсә белән томалап куйган шикелле. Ул нәрсә кыса. Кайчагында башы эчендә ниндидер җан иясе чыгар урын эзләп бәргәләнәдер, әле колакларыннан, әле күзләреннән чыгарга тырышып чәбәләнәдер кебек була. Температурасы утыз сигез ярым. Үзе тирли, үзе өши. Ләкин Айгөл моның әшәке чир икәненә ышана алмады. Яңа гына вакцина кадатты бит. Бәлки шуның тәэсиредер. Бәлки грипптыр. Ара-тирә ютәлләп тә, төчкереп тә ала бит. Грипптыр инде бу. Авырлы хатынның көчез организмында анысы да үзен хуҗа итеп тотарга маташадыр.

Дежур табиб аның сүзләрен тыңлады да кардиограмма ясады. Аркасын, күкрәкләрен тыңлап карады. Укол ясады. Аннан соң рецептлар язып бирде.

– Вируска охшамаган, – дип юатты аннан соң. – Шулай да ПЦР ясарга килерләр. Өйдә торырга кирәк булыр. Алар алдан шалтыратырлар сезгә. Хәлегез авырайса, «ашыгыч ярдәм» чакырыгыз.

Ул киткәч, бераз хәл кергәндәй булды. Укол тәэсир итте бугай. Һәм Айгөл даруханәгә чыгып керде. Табиб күрсәтмәләрен бик төгәл итеп үтәргә тырышса да, даруларның әллә ни ярдәме сизелмәде. Беркадәр вакыттан теге уколның да тәэсире бетте бугай, башы сызларга тотынды. Ире белән сөйләшмәгәннәрен искә алып, Айгөл телефоннан шалтыратты. Трубканы алмадылар. Аннан соң үзенең хәлләрен ватсап аша язып җибәрде.

«Температура бар, баш авырта, дежур врач килеп, дарулар биреп китте. ПЦРга яздырам диде. Кайчан килере төгәл билгеле түгел...» Илдарның җавабы кыска булды. «Хәлләрем әйбәт, борчылма. «Ашыгыч ярдәм» чакырт. Хәзер үк шалтырат. Алар тиз генә килми. Әлегә сөйләшәлмим. Соңрак язышырбыз». Айгөл аңа: «Исән-сау терел, җаным. Мин сине яратам!» – дип язды да телефонын читкәрәк алып куйды.

Берәр сәгать узуга температурасы тагын утыз сигез ярымга җитте. Баш авыртуы басылмады. Хәлсезлек... Монысы бигрәк үзәккә үтә торган нәрсә икән. Дару эчкәндә идәнгә төшкән кәгазь кисәген иелеп алып, чүп савытына салырлык та чамасы юк иде. Күргән саен эчне пошырып тора үзе, ләкин алып булмый, ирендерә дә, куркыта да – иелсә, тора алмас кебек . Бераздан сулыш алганда, күкрәге авыртып-авыртып китүен тойды. Тирәнрәк сулаганда яки ютәлләгәндә, бигрәк нык авырта, күкрәк сөякләре чатнагандай тоела. Бу хәлеңдә беркая да барам диярлек түгел инде. Ә ПЦР үткәрергә дип шалтыратучы булмады. Якында гына түләүле лаборатория бар да... Бәясе кыйбат бугай. Булсын. Белешергә кирәк әле, бераз хәл кергәч.

Хәл кермәде. Караңгы төште. Бүген көн буена бер тәгам дә капмавын исенә төшереп, кухняга чыкты. Нәрсәдер пешерергә, ашыйсың килмәсә дә, ашарга кирәктер инде. Тик Айгөлнең берни пешерәсе килми иде. Ашау теләге дә юк. Җылымса суга бер төймә чыжлап эри торган С витамины салып эчте. Әллә суы җылырак булды, әллә даруы шундый... бик тәмсез булып тоелды ул. Хәтта укшытып та куйды. Атлаган саен башына суккандай иде. Сулыш алган саен күкрәге кысылды. Җиңелчә генә. Әмма ул гел кабатланып торгач, теңкәгә тия, ачуны чыгара иде. Көчсезлек тә үртәлдерде. Хәтта юк кына нәрсәне эшләргә дә хәлең җитмәсен әле...

Ятып торырга кирәк. Ләкин баш сызлавы, күкрәк читлегенең кысылуы яткач та тынгылык бирмәде. Киресенчә, урынга ятканнан соң, аларга игътибарны күбрәк бүләсең икән. Сулыш алган саен авырту көтәсең, аһылдап куясың, тагын сулыш аласың, тагын көтәсең... Өстәвенә тирләтә... Карынындагы бала да тынып калды. Ул да хәлсездер инде. Тибенеп алу түгел, бармакларын кыймылдатырга да иренеп ятадыр. И бала... Нинди дәверләргә туры килдең син... Исән-сау гына була күр инде. Төкле аягың белән дөньяга ту, кайгы-хәсрәтсез үсеп, кеше бул. Ходай үзе сакласын инде сине. Чир-чорлардан, бәла-кайгылардан, ялгыш адымнардан... Син тугач, бәлки, дөнья да үзгәреп китәр әле, зәхмәтле авырулар юкка чыгар, кешеләр ягымлырак булыр, күкләр аязланыр... И, шулай гына булсын иде дә бит...

Кинәт ишектә кыңгырау шалтырады. Айгөл, көч-хәл белән урыныннан

торып, ишек янына килде. Күзчектән карарга омтылды, тик чайкалып китте. Һәм авырлык белән телен әйләндереп:

– Кем бар? – дип сорады. Җавапны озак көттермәделәр.

– Ашыгыч ярдәм.

Айгөл ишекне ачты да залга узды, диванга барып утырды.

– Узыгыз, – диде ул, керүчеләргә урын күрсәтеп. – Тик... Мин чакырмаган идем бугай...

Табиблар бер-берсенә карашып алдылар. Берсе кулындагы кәгазьне актарды:

– Илдар чакырган, – диде ул. – Сезнең ирегез. Дөресме?

И, рәхмәт инде аңа. Айгөл үзе батырчылык итмәс иде әле, нәрсәгәдер өметләнеп, нәрсәдер көтеп ятар иде. Килүләре бик вакытлы булды. Айгөл «дөрес» дигәнне аңлатып баш какты, тик шундук үкенеп куйды – башы сулкылдап авыртырга тотынды.

**5**

Хәлиткеч мизгелләрдә кеше организмының яшерен көчләре хәрәкәткә килә, аның мөмкинлекләрен арттыра дигән сүз бар. Шул дөрес бугай. Айгөл, авыртуга чыдый алмыйча диванда тәгәрәп ятканда, фани дөнья белән бәхилләшү чигенә җиткән шикелле иде. Ә «Ашыгыч ярдәм» машинасына чыгып утыргач, җиңеләеп киткәндәй булды. Бәлки табиблар кадаган укол да ярдәм иткәндер инде. Бәлки алай гына да түгелдер. Һәрхәлдә баш сызлавы да, бөтен буыннар авыртуы да, хәлсезлек тә юкка чыкты. Сулыш алуы гына кыенрак иде, тик анда да күкрәк сөякләренең кысылуы беркадәр басылып калгандай тоелды. Муен тирәләрен, күкрәк араларын лычма су иткән тирләү дә булмаса, ул бөтенләй сәламәт кеше кебек күренер иде.

Хастаханәнең кабул итү бүлегендә биш-алты авыру чират көтә иде. «Ашыгыч ярдәм» табибы Айгөлне шулар янына утыртып куйды да паспорты белән полисын сорап алды, документларын теркәлү бүлегенә тапшыргач, кабат килде:

– Бераз көтегез инде, чакырып алырлар сезне, – диде ул ягымлы тавыш белән. – Без кузгалабыз. Исән-сау терелегез.

Айгөл үзен яхшы хис итә иде. Ул елмайды:

– Рәхмәт сезгә. Үзегез дә авырмагыз.

Бу мизгелдә аның бар күңеле якты хисләр белән тулган иде. Табибларның тырт-мырт эндәшеп торганнарын да күргәне бар хатынның. Әле шулкадәр ягымлылыкны татыгач, үзен табибларның игелеге белән сыйлангандай итеп тойды. Күңеленә җылы йөгерде. Бүтән кешеләрдән күчкән күңел җылысы ул үзе бер тылсым бит инде, үзе бер дәва.

Озак көтәргә туры килмәде. Теркәлү өстәлендә утырган өч-дүрт хезмәткәрнең берсе аның фамилиясен атады. Боларның барысы да яшел халаттан, башлары да, йөзләре дә каплаулы, өстәвенә, буй-сыннары да бер чама. Ир-егетме, хатын-кызмы икәнлекләрен дә тавышларыннан гына аерырга мөмкин. Айгөлне чакыручы хезмәткәр ир-егет затыннан иде. Хатын якынрак килгәч, берничә сорау биреп, кайчан авырый башлавын, вакцина ясату-ясатмавын, нинди чирләре барлыгын сораштырды да тагын бераз көтәргә

кушты. Бу юлы бөтенләй көттермәделәр, урынына барып утырганчы ук яшел халатлыларның берсе аның фамилиясен атады да үзе белән иярергә кушты.

Теркәлү өстәленнән ерак түгел генә урында чаршау белән каплаулы итеп берничә бүлмә ясаганнар. Аларның берсендә йөрәк тибешен яздыралар икән. Аннан чыккач, икенче бүлмәгә керәсе, монысында тамырыннан кан алдылар. Өченче бүлмәдәге табиб авызын ачтырып, тамак төбен тикшерде, аннан соң борын тишекләренә ниндидер таяк тыгып карады. ПЦР анализы дигән нәрсә шушы була икән. Бүлмәләрне үтеп чыгуга яшел халатлыларның берсе үз артыннан ияреpгә кушты да, беркадәр атлагач, «Компьютер томографиясе» дип язылган бүлмәнең ишек төбендә калдырып китте.

– Чак кына көтеп торыгыз, чакырып алырлар, – диде ул, ягымлы итеп. – Менә утырыгыз монда.

Ул күздән югалып та өлгермәде, ишек ачылды да Айгөлне чакырдылар.

– Билегезгә кадәр чишенегез, – диде бүлмәдәге ханым һәм кушетка сыманрак урынга чиста җәймә җәйде. – Аннан соң менә монда чалкан ятарсыз. Сүзләргә колак салырга кирәк булыр.

Айгөл урынга яткач, шприц тотып килеп җитте:

– Йодка аллергиягез юкмы?

– Юк, – дип елмайды Айгөл. – «Ашыгыч ярдәм» машинасына утырганнан алып, аның хәле арулана барды, ә хәзер ул үзен сау-сәламәт кеше шикелле тоя, шуңа күңеле дә күтәренке иде. – Бернәрсәгә дә аллергия юк.

– Бик яхшы, – дип дәртләндерде табиб ханым. – Ә хәзер беләгегезне менә монда куегыз.

Уң беләгенең терсәктән югарырак җирен җилем тасма белән кысып куйгач, Айгөл йодрыкларын ачып йомып алды. Табиб ханым укол ясады.

– Аз гына ятып торыгыз, – диде ул, әйберләрен җыеп. – Өшемисездер бит?

– Юк. Рәхмәт.

Ханым кулларны ничек куярга кирәклеген күрсәтте дә чыгып китте. Бераздан кайдадыр урнашкан тавыш көчәйткечләрдән:

– Әзерләнегез! – дигән сүз ишетелде. Һәм Айгөл яткан кушетка, хәрәкәткә килеп, бастырып куелган зур гына бөҗра шикелле нәрсә эченә керде. – Сулыш алыгыз.

Шул рәвешле «Сулыш алыгыз», «Сулыш алмагыз» дия-дия, кушетка берничә тапкыр теге бөҗра эченә кереп чыкты. Аннан соң: «Тәмам. Киенергә мөмкин», – дигән тавыш ишетелде. Айгөл киемнәрен рәтләп бетерүгә, табиб ханым килеп җитте дә кулындагы кәгазьне Айгөлгә сузды:

– Теркәлү өстәленә тапшырырсыз инде, – диде ул.

Теркәлү өстәленә кәгазьне биргәч, аңа бераз гына көтәргә куштылар. Бу юлы ун-унбиш минут тирәсе утырырга туры килде. Ул арада Илдар белән язышып алдылар.

«Рәхмәт сиңа, җаным! Бераз авырып, хәлсезләнеп ята идем. Син чакырган табиблар килгәч, җиңеләеп киттем. Әле хастаханәдә. Анализлар алдылар, тикшерәләр. Барысы да әйбәт булырга тиеш. Кәефем бик яхшы. Үзең ничек?»

Җавап тиз килде:

«Әйбәт, кадерлем. Монда яхшы карыйлар. Больницага салабыз дисәләр,

карыша күрмә. Бу – бик четерекле авыру, җитди нәрсә. Анализларың билгеле булгач, хәбәр итәрсең».

«Әйбәт булыр, Алла боерса. Минем бит элек тә баш авырта иде. Хәлсезлек тә булгалады, температура да. Авырлы хатынның көйсезләнүе бетәмени инде. Бары тик бөтенесе бергә килгәне генә юк иде. Салкын гына тигәндер ул, беркөнне туңдырма ашаган идем бит. Син үзең исән-сау бул инде. Тизрәк савыгып чык».

Бераздан Айгөлнең фамилиясен атадылар һәм кулына кәгазьләр тоткан ак халатлы ир-егет аның янына килеп басты.

– Кызганыч, техник сәбәпләр аркасында, ПЦР нәтиҗәләре иртәгә генә билгеле була, шуңа күрә вирус бармы-юкмы икәнен төгәл әйтәлмим. – Ул кулындагы кәгазьләрне актарды. – Үпкәгезнең зарарлануы 15 процент. Бу зур күрсәткеч түгел, башка сәбәпләр нәтиҗәсе булырга да мөмкин. Әлегә хастаханәгә салмый торабыз. Анда ятучыларның үпкәсе нигездә 40 проценттан да ныграк зарарланган. Әгәр сездә вирус булмаса, алардан йогу ихтималы бар. Нәтиҗәләр билгеле булгач, сез дежур врачны чакырырсыз, әгәр чир бар икән, ул хастаханәгә юллама язып бирер. Әлегә менә бу даруларны эчегез.

Айгөл әлеге чир турындагы мәгълүматларны күзәткәләп барса да, үпкә зарарлануы, процентлар турындагы сүзләрне бик аңлап җитмәде. Әлегә хәле яхшы кебек тоелгач, тизрәк өенә кайту теләге дә юк түгел иде. Чире булса, шундук белерләр иде. Үпкәнең зарарлану күрсәткече түбән булгач, димәк, анда әлеге зәхмәт түгел инде, бу бары тик салкын тию генә. Туңдырма галәмәте генә бу. Үзен сау-сәламәт итеп тою теләге бөтен шик-шөбһәләрдән дә көчлерәк иде. Тиздән ул тулы ышанычка әверелде. Юк анда бернинди авыру да! Юк. Булырга да тиеш түгел. Ә хастаханәгә салсалар, берсүзсез булачак. Андагы җыен авыру кеше арасында, әлбәттә, йогачак ул. Шуңа иң хәерлесе – өенә кайту.

Табиб кайсы даруларны кайчан, ничек эчәргә кирәген аңлатты да саубуллашып китеп барды. Айгөл аны юньләп тыңламады да, рецепт кәгазендә барысы да күрсәтелгән, анда булмаса, даруларның үзләрендә ничек кулланырга дигән язу бардыр. Аның өчен иң зур сөенеч вирус табылмавы иде. Димәк, анда чир юк, димәк, ул сау-сәламәт. Һәм шундук иренә язып җибәрде: «Вирус юк. Өйгә кайтам». Бераздан Илдарның җавабы килде: «Ура! Котлыйм, җаным!» Моны укыгач, Айгөл баскан урынында үрә сикереп, үзе дә «Ура!» дип кычкырудан чак тыелып калды. Шатлык бит инде.

Теркәлү өстәлендәге кызлардан хастаханә адресын сорады да такси чакырды. Бу юлы хәтта такси бәясе дә кыйммәт булып тоелмады. Ул чиксез шат, күңеле күтәренке иде.

## 6

Әгәр кеше нәрсәдер ишетергә тели икән, ул аны мотлак ишетәчәк. Хәтта син бер сүз әйтмәсәң дә. Нәрсәгәдер ышанырга тели икән, моның өчен аңа бернинди дә дәлил кирәкми.

Айгөл дә үзенең сау-сәламәт икәненә ышанырга теләде. Сау-сәламәт... Бу дәвердә һәркем шундыйрак караште инде. Хәтта бер көлтә чире булганнар да, вирус эләктермәсәләр, үзләрен сау-сәламәт дип хис итә. Башка авыруларны санга да сукмый, алар вак-төяк булып кына күренә.

Икенче көнне шыбыр тиргә батып, манма су булып уянса да, бөтен тәне, буыннары авыртса да, башы сызласа да, урыныннан торырлык хәле булмаса да, ул моны вирус галәмәте дип башына да китермәде, бары тик салкын гына тигән, даруларны эчкәч үтәчәк дип уйлады. Чынында да, шулай уйларлык бар иде. Гади генә грипп та тиз китми бит инде, ким дигәндә, берәр атна тирәсе җәфалый, кайчагында урында яткыра. Андый чакта да бер хәлең булмый, температураң күтәрелә, башың авырта, ютәлләтә, күкрәкләр кысыла, борының кипми. Нинди генә кыйммәтле дарулар эчсәң дә, үз вакыты җитмичә, чир китә белми.

Хәтта икенче көнне телефонына килгән язмада анализ күрсәткечләренең «уңай» дип билгеләнүен дә ул үзенчә кабул итте. Уңай, димәк, әйбәт. Башка вакыт булса, болай итмәс иде. Тик бу юлы башы сызлый, бөтен тәне авырта, сулышы кыса һәм хәрәкәтләнергә генә түгел, ә уйларга да ирек бирми торган хәлсезлек изә иде. Мондый вакытта чынбарлыкны тулы көенчә кабул итеп булмыйдыр...

Икенче көнне Айгөл башын да күтәрә алмады. Хаҗәтханәгә барып килде, даруларын капты, су эчте – шуның белән вәссәлам. Сәгатьләр буена үрсәләнеп, бәргәләнеп ята торгач, хәле бетеп тынып кала. Шул чакларда кайвакыт бераз йоклап ала. Телефоны тавышсызга көйләп куелган. Иренә дә язмый. Язу түгел, аның хәбәрләрен укымый да. Сөйләшерлек тә, язышырлык та хәле юк. Ул әсирлектә, күзгә күренми торган төрмәдә яткан бер хокуксыз тоткын хәлендә иде.

Мондый күренеш ике көн чамасы дәвам итте. Хәзер инде элекке ышанычы юк иде. Грипп-фәлән генә түгел, ахры, бу. Алай гына булса, бераз аруланыр иде. Ә ул көннән-көн начарая гына. Хәтта карынындагы баласы да юньләп хәрәкәтләнми. Үзенең дә тамагына ризык капканы юк. Ашыйсы да килми. Авызында бары тик дарулар ачысы гына. Хәтта үзеңне мәҗбүр итәргә тырышып, нәрсәдер ашарга маташып карасаң да, аннан шул дарулар тәме килә. Укшыта.

– «Ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк...

Айгөл инде ничәнче тапкыр кабатлыйдыр бу сүзне. Ләкин зиһенен туплап, көчен җыеп, телефонга үрелә алмый. Үрелсә дә, сөйләшерлек рәте булмый. «Алло, ашыгыч ярдәм». «Тыңлыйм сезне». Нәрсә дип әйтергә иде соң әле? Теге очтагы ханым бер-бер артлы сораулар бирә. Ә ул сорауларны башта аңларга кирәк, аннан соң фикереңне туплап, дөрес җавап бирергә. Югыйсә бик авыр нәрсә дә түгел инде. Ләкин иң кирәкле чакта гына зиһене таралып китә. Нәрсә дияргә белми туктап кала. Тынлык озакка сузыла. Теге очта сорауны кабатлыйлар. Ә Айгөл һаман җаваплый алмый, үзенең шул халәтенә оялудан каушап төшә. Һәм трубканы куярга мәҗбүр була. Беркадәр вакыт узгач, теге уй кабат хәтеренә килә, һәм ул онытмас өчен тагын кычкырып кабатлый:

– «Ашыгыч ярдәм» чакырырга...

Шул рәвешле озак кына маташкач, әлеге фикер дөрес юнәлеш алгандай тоелды:

– Илдар чакырсын, – диде ул һәм авыр сулап куйды. – Хәле булса...

Һәм онытканчы, аңа язып җибәрде. «Ашыгыч... ярдәм... чакыр...» – шушы өч сүзне язганда, әллә ничә хата китте. Төзәтте. Тагын хаталанды. Тагын төзәтте. Ахыр чиктә телефонын читкә алып куйды. Тик шундук

баласы турында уйлады да кабат кулына алды. Болай ярамый иде. Көчле булырга кирәк. Өч кенә сүз бит ул. Хаталы булсын. Илдары аңлар әле.

Ниһаять! Язып җибәргәч, авыр сулап куйды. Өстеннән йөк төшкәндәй тоелды. Күзләрен йомып, бер мәлгә тынып калды. Күзләренең йомыла, тәненең йомшара баруын тоеп торып утырды. Көч-хәл белән атлап, коридорга чыкты, фатир ишегенең келәсен ычкындырды. «Ашыгыч ярдәм» килсә, кирәлми тормасын. Аннан соң кабат урынына барып ятты. Күңеле бераз тынычланып калгандай тоелды. Авыртулары да басыла бугай. Юк инде, басылмый. Бары тик хис-тойгылары тупаслана, кабул итү үткенлеге генә югала.

Шул халәтендә күпме яткандыр, бер мәлне утны яндырдылар.

– Саумысыз! – дип сөрәнләде ир-ат тавышы. – Ашыгыч ярдәм. Өйдә кеше бармы?

Яшел халатлы икәү бүлмәгә узды. Берсе, ир-егет, утыргычны үзенәрәк шудырып, нәрсәдер язарга тотынды, икенчесе, түгәрәк кенә ханым, Айгөлнең беләкләрен, балтырларын ялангачландырып куйгач, кардиограмма яздырды. Күлмәген күтәреп, аркаларын тыңлап карады.

– Җыеныгыз, – диде ул озак маташып тормастан. – Хастаханәгә салабыз.

Айгөл көч-хәл белән торып басты. Нәрсә эшләргә белмичә, алан-йолан каранып торды. Киенергә кирәк. Киемнәре кайда иде соң әле? Шкафта. Авырлы хатын белән көтелмәгән хәлләр дә булырга мөмкин дип, ул бала тудыру йортына алып бара торган әйберләрен алдан әзерләп куйган иде. Шуны алырга кирәк. Һәм үзенә киенергә. Айгөл адымнарын шудырып, икенче бүлмәгә атлады. Аның хәлен күреп торган табиб ханым култыклап алды.

– Әйдәгез, – диде ул баштан сыйпаган ягымлылык белән. – Ашыкмагыз. Иплән кенә киенербез.

– Рәхмәт, – дип, көчкә телен әйләндерде Айгөл. – Рәхмәт.

Икенче бүлмәгә кергәч, ул киемнәрен шкафтан алып тезеп куйды. Табиб ханым киенергә ярдәм итте. Әллә ни матур түгел инде, тик уңайлы, чиста киемнәр. Ишек төбенә җиткәч, курткасын эләктерде. Һәм үтенечле карашын табибка төбәде:

– Әнә теге шкафта сумка бар иде...

Табиб ханым сумканы эләктерде. Айгөл тагын фатир эченә күз йөгертте.

– Газ янып калмый микән?

Ир елмая биреп, бүлмәләрне тикшереп чыкты.

– Утлар сүнгән, тәрәзәләр ябылган, – диде ул бераздан. – Хәтта суны да басып куйдым. Бернигә дә борчылмагыз.

Айгөл елмайгандай итте. Тик чыраен сыткан кебек кенә килеп чыкты.

– Үзегез төшә аласызмы? – диде табиб ханым.

– Ә? – Айгөл аны аңламый торды. – Үзем?

– Әйе. Бәлки носилка алып менәргәдер?

– Ә-ә-ә... Юк-юк, рәхмәт...

Һәм табиблар, Айгөлне ике яклап култыклап, баскыч мәйданчыгына атладылар. Карават янында торганда гына хәллерәк кебек тоелган икән, мәйданчыкка чыгу белән башы әйләнә башлады, буыннары йомшарып, аяклары чалыш-чолыш килде. Ә урамга чыккач, бөтенләй авыраеп китте. Үзенең табибларга мәшәкать өстәвеннән бераз кыенсынып та куйды Айгөл. Әмма тегеләр аны-моны сиздермәде, күтәреп диярлек алып бардылар.

Машинага кергәч, табиб ханым тагын сорап куйды:

– Утырып бараласызмы? – Һәм Айгөлнең аңлый алмый торуын күреп өстәде: – Бәлки ятып барырсыз?

– Юк, – диде хатын гаепле тавыш белән. – Ерак түгел бит...

Чынлап та, ерак түгел иде. Бу юлы кабул итү бүлегендә аны көттереп тормадылар. Кай арададыр ярдәмгә бер ханым килеп җитте. Ул коляскага утыртып, тиз-тиз генә теге бүлмәләрдә йөртеп тикшерү үткәртте дә, коляскага кислород баллоны тоташтырып, Айгөлгә битлек кидереп куйды. Һәм теркәлү өстәленә килеп:

– Кәгазьләрне соңрак төшеп алырмын, – дип, Айгөлне хастаханә эченә алып кереп китте. – Сез урнаша торырсыз. Тиздән ярдәм күрсәтерләр.

Палатада ул үзе генә иде. Ярдәмче ханым урынын җәеп бирде.

– Киемнәрегезнең барысын да чыгармасагыз да була, – диде ул, хатынның сумка актарырга маташуын күреп. – Иртәгә сезне башка хастаханәгә күчерерләр.

Айгөлнең җылы киемнәрен капчыкка салып, үзе белән алды.

– Ашыйсыгыз килмиме?

Айгөл баш чайкады.

– Әгәр ачыксагыз, дүртенче постка килерсез. Мин шунда булам.

Аннан соң күп тә үтмәде, яшел халатлы яшь кенә ханым килеп керде дә Айгөлнең эченә һәм янбашына укол ясады.

– Хәзер тагын киләм, система куябыз, – диде ул елмаюлы тавыш белән. – Бәдрәфкә барасыгыз булса, барып килегез.

Айгөл баш какты. Әлегә бөтен дөньясы кара томанга төренгәндәй булса да, кайдадыр еракта яктылык чаткысы шәйләнә иде.

**7**

Икенче көнне бүтән хастаханәгә күчерделәр. Анда ничек барганын да юньләп хәтерләрлек рәте юк иде Айгөлнең. Башы сызлый, бөтен тәне авырта, хәле юк. Өстәвенә, шыбыр тиргә баткан. Ютәле дә көчәйде, башта кых-кых килеп кенә тора да тамак төбен нәрсәдер кытыклата, аннан бөтен үпкәне дер селкетеп ютәлләтергә тотына. Шул рәвешле изаланып, тын юлының кайсыдыр җирендә утырган какырык кубып чыккач кына, беркадәр тынычланып кала. Иртәдән бирле шулай. Йөткерә-йөткерә инде эч мускулларына кадәр авырта башлады. Кайчагында кабыргалары да черегән койма такталары шикелле чәчрәп очардай тоела.

Әнә шундый төрле уйлар һәм сызланулар белән ул үзенең кайсы хастаханәгә килүен дә бик аңлап бетерә алмады. Кабул итү бүлегенә керү белән тәгәрмәчле кәнәфигә утыртып, каядыр алып киттеләр. Лифтта аз гына күтәрелгәч, табиб посты янында тукталып тордылар да озата килүче нәрсәдер әйтте. Нинди палатага салырга икәнен сорады бугай. Аны шунда алып керделәр.

Палата пөхтә иде. Дүрт кешелек икән. Түрдә зур гына тәрәзә, аны жалюзи дип аталган нәрсә белән каплап куеп була. Ачып җилләтергә теләсәң, форточкасы да, ачылмалы өлгесе дә бар. Өстәл, кул белән көйләп була торган караватлар, аксыл төстәге тумбочкалар, берничә утыргыч. Бүлмәдәге хатыннарның икесе йөкле иде, өченчесенең авыры күзгә бик

бәрелеп тормый. Айгөлне китерә килгән хезмәткәр җылы киемнәрен капчыкка салып алып китәргә әзерләп куйды.

– Табибларны чакырырга кирәк булса, менә мондагы төймәгә басарсыз, – дип, баш очындагы стенага беркетелгән җайланманы күрсәтте. – Ә монысы – кислород битлеге. Торым-торымга kiяргә кирәк. Хәзер табиб килер, ул барысын да аңлатыр. Бәдрәф менә бу бүлмәдә. Кайнаган су кирәк булса, коридорда электр чәйнекләре бар. Ашны да шунда микроволновкада җылытырга була. Сорауларыгыз бармы?

Айгөл баш чайкады. Хезмәткәр чыгып китте. Хатын палатадашлары белән исәнләште дә, көч-хәл белән бәдрәф бүлмәсенә кереп, киемнәрен алыштырды. Пөхтә, иркен иде монда. Душ та бар. Хәлең булса, керләреңне чайкап куярга да мөмкин икән. Айгөл юеш киемнәрен полиэтилен капчыкка бөгәрләп салды да душ астында тирләрен юып төшерерлек кенә итеп коенып чыкты. Яхшылап сөртенде. Аннан чиста киемнәрен киде. Ничектер җиңелрәк булып калды, хәтта сулыш алулары иркенәеп китте бугай. Тик бу халәт озакка бармады, ванна бүлмәсеннән чыгу белән башы әйләнде, бөтен тәне таркалып төшкәндәй тоелды, һәм ул чалыш-молыш адымнар белән көч-хәлгә караватына барып ауды.

Бераздан шәфкать туташы килеп керде:

– Әлегә юынмаска тырышыгыз, – диде ул, Айгөлнең кибеп өлгермәгән чәчләрен күреп. – Үпкәгезнең ике ягы да кырык биш процент зарарланган. Сатурациягез бик түбән. Кислород битлеге аша сулагыз. Чалкан ятмаска тырышыгыз.

Ул тиз генә Айгөлнең эченә укол ясады да чыгып китте. Бераздан кире әйләнеп кереп, янбашына, беләгенә укол кадады. Аннан соң система куйды. Шулар тәэсире булдымы, Айгөлнең хәле аруланып китте, сызланусыз мизгелләр белән ләззәтләнеп ятты да бераздан изрәп китте, күзләрен йомды. Тулы канлы йокы дип булмый инде моны, әмма сызланулардан беркадәр арынып торган ара үзе бер ял сыман иде. Ара-тирә онытылып китте, кай арададыр күкрәге кысуга чыдый алмыйча ыңгырашып, күзләрен ачты, тавыш чыгармаска, башкаларга комачауламаска тырышып, беркадәр үрсәләнеп ятты да тагын онытылды. Әллә йоклап китте, әллә, хәле бетеп, һушын җуйды. Кайчагында палатадашларның ыңгырашуы яки бик тавышланмаска тырышып кына нәрсәдер сөйләшүләре колагына керде.

Авыры беленеп торган хатыннарның икесе электән үк таныш булганнар икән. Бер вузда укыганнар бугай. Ишеткәннәренең өзек-ертык өлешеннән Айгөл шуны чамалады. Икесе дә – укытучылар. Хәтта исемнәре дә аваздаш. Нәсимә белән Надя. Нәсимә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булган, мәктәпләрдә татар теле дәресләрен киметә башлагач, кыскартуга эләккән. «Һәртөрле бәйгеләрдә укучыларым гел мактаулы урыннар ала иде, шул килеш тә мине җибәрделәр, ә артык эш майтара алмыйча ялагайланып, күз буяп йөрүчеләр калды, шунысы аяныч, – дип сөйли ул. – Хәтта илдәге сәясәткә караганда да ныграк үзәккә үтә». Аның хәлен Айгөл яхшы аңлый кебек. Бу хакта Илдар белән дә бик күп тапкырлар сөйләшкәне бар. Инде туган телеңне мәктәпләрдән кысрыклап чыгару дәрәҗәсенә килеп җиткәч, җаваплы урыннар биләгән татарларга уй керергә тиеш иде кебек. Ә юк. Алар һаман сукыр килеш кала, ялтыр данга, ялган дәрәҗәгә, киләчәге билгесез малга алданып, милләт язмышы белән уйный. Нәсимә дә яраткан эшен югалткач, озак кына

йөргән: идән юучы да, аш пешерүче дә, тәрбияче дә булып алган, базарда да сату иткән. Соңгысы акча китерә торган эш булса да, күңеле ятмагач, озак чыдамаган, курслар узып, рус теле укытучысы булып кабат мәктәпкә кайткан. Кайчагында Надя белән икесе көлешеп тә алалар инде: «Син татар башың белән рус теле укытасың, мин – рус башым белән инглиз теле», – дип. Надя андый ук маҗараларга тарымаган. Мәктәптән инглиз телен дә кысрыклый башласалар, бөтен дөнья ду кубачак бит. Шуңа аның фәне халыкара яклау астында, куллану даирәсе киң, ихтыяҗ зур. Ул әле дәресләрдән тыш репетитор булып та ярыйсы гына эшли икән. Кызык инде дөнья...

Айгөл кайчагында боларның сүзләренә кушылып китәрдәй була да, хәлсезлеге ирек бирми. Йомшак, ягымлы итеп сөйләшә торган матур кешеләр. Гайбәт чәчмиләр, юк-бар сөйләмиләр. Хәтта зарланып алулары да укытучылар дәрәҗәсендә.

– Изоляция кешеләрне аерды. Элеккедәй аралашулар болай да бетеп бара иде. Хәзер туганлык, дуслык кебек хисләргә урын тарайды бит. Барысын да мөлкәт артыннан чабу алыштыра. Ә изоляция... Шуның аркасында хәтта туган белән туган да үзара йөрешми башлады. Хәтта ата-ана белән бала бер-берсенә килергә курка...

– Алай дисәң дә инде, – дип, Надя йомшак кына каршы төшә. – Сездә дә шулай булдымы икән... Әле чир чыккан гына вакытта ватсапка төрле видеороликлар килә иде бит. Көлке кебек тоела торган иде. Кечкенә бер кытай кешесенә хулиганнар бәйләнә. Әзмәверләр шундый, бер сукса, өзә торган. Ә теге төчкерә. Моңа барысы да шикләнеп карый, куркалар. Ә ул үзенең тәэсир көчен сизеп алгач, теге хулиганнарны куып алып китә. Хәтта шул да кызык кебек иде. Бер карасаң, Кытай кайда да, без кайда бит инде. Бу чир безгә кадәр берничек тә килеп җитә алмас сыман иде. Ә ул... Ике-өч ай да көтеп тормады хәтта. Менә без илләр, халыклар, милләтләр дигән булабыз. Һәркем үзенең өстенлеген күрсәтергә тырыша. Аермалар бардыр инде ул. Бар инде алар. Ә уйлап карасаң, барыбыз да – адәм баласы. Аралар ерак булса да, язмышлар якын. Хәзер менә бөтенебез бер хәлдә.

– Бер үк хәлдәге аерым кешеләр... – дип көрсенеп куя Нәсимә.

Чынлап та, шулай шул. Аерым кешеләр булса да, язмышлары бер чама. Хәтта чир эләктерү, хастаханәгә килү, авырудан газаплану рәвешләре дә бер-берсенә охшаш. Үлем барысын да тигезли дип әйтәләр. Чир дә тигезли икән. Һәрхәлдә, ул кешеләргә барысының да тигез икәнен аңлатырга тырыша. Шулай кебек тоела инде кайчагында.

Болар да хәлләре әйбәт чагында торып утырып, шулай гәпләшеп алалар да, бераздан әле берсе, әле икенчесе начараеп китә. Кайвакыт хәтта торып, су эчәрлек рәтләре дә булмый. Андый вакытларда палатадашларның өченчесе ярдәмгә килә. Глүсәнең хәле әйбәт... Их, алай дип булмый шул... Сәламәтләнеп килә инде Глүсә. Ләкин хәлен әйбәт дип булмый. Ходай күрсәтмәсен аның тәкъдирен. Ул баласын югалткан. Кесарево ясап алганнар, тик сабые үле туган.

**8**

Глүсәне бер сүз белән генә сурәтләп булмый. Әйбәт хатын инде ул. Ярдәмчел. Үз аягында булгач, ныграк ыңгыраша башласаң да, йөгереп килеп җитә. Йомышың булса, шундук ярдәм итә. Җылы сүзләр әйтеп

юатырга да иренми. Кайгысы зур булса да, аны сөйләп, зарланып йә елап йөрми. Аның хакында да Айгөлгә укытучылар сөйләде. Үзе бер авыз сүз дә ычкындырмады.

Айгөл аны бик өнәп бетермәгән иде. Тавышы көчле. Кирәкмәгән чакта, авыртынып, җаныңны кая куярга белми бәргәләнеп яткан вакытта ишетелгәч, бигрәк ямьсез булып тоела. Ямьсез тавышлы кешеләр, гадәттә, кычкырып сөйләшүчән була бугай. Бу да бер минутка да диярлек тик тормый, телефоннан әле тегенең, әле монын белән аралаша. Тыңлап сокланырлык, фәһем алырлык нәрсәләр дә сөйләшмиләр, җыен юк-барны чәйнәшәләр. Телефонның теге очындагы кешеләр шуннан тәм таба микән, әмма аның тавышы озаккарак сузыла башласа, Айгөлнең җене котыра иде. Глүсә үзе дә бер чирдер, ул да адәм балаларының сабырлыгын сынар өчен дөньяга җибәрелгәндер кебек тоела.

Шалтыратышып сөйләшер кешесе калмаса да, тынгылык бирми. Телефонын кычкыртып куя да... Ютубны карый микән инде ул, аудиокитап тыңлый микән... Кайчагында сөйләүченең тавышы бик ягымлы була, әкият тыңлап йоклап киткәндәй тоеласың. Әмма күзләреңне йомып тынычланып калуга, бөтен дөньяга үзен ишеттерергә теләгәндәй реклама акыра башлый. Монысының тавышы Глүсәнекеннән дә хәтәррәк. Әллә нинди дошмани, гайрәтне чигерә торган.

Шуңа күрә Айгөл аны бик өнәп бетерми иде. Ләкин, нинди югалту кичергәнен белгәч, карашы үзгәрде. Андый кайгыдан соң ана кешегә, ни кылса да, гаеп түгелдер кебек тоелды. Берәү булса, кайгысын сөйләп, зыр килер, үз язмышын яки табибларны тиргәп, зар-яшен түгәр иде. Ә бу берни дә сиздерми. Янындагы йөкле хатыннарны борчымаска тырыша. Алар да әллә кайда түгел бит, яткан урыннары оҗмах түре түгел, хәлләре авыр, киләчәкләре билгесез. Менә шуларны аңлагач, Айгөлгә ул бик сабыр, кешелекле, якты күңелле хатын булып тоелды. Телефон тавышына гына түзәргә була, элекке радио сыманрак нәрсә инде ул, бер уйласаң.

Карыймы-тыңлыймы инде ул, тик Глүсә телефонының бөтен белгәне – гел әлеге чир турында. Ул әллә нәрсәләр сөйли. Һәркем белеп торган көндәлек ыгы-зыгылардан башлап адәм ышанмастай хәлләргә кадәр җитә. Әлеге авыруның тарихын, ничек таралуын, моңа кемнәр гаепле булуын. Бүгенге көндә хакимиятнең нинди максатларда эш йөртүен, нәрсәләрне халыктан яшерүен, нинди җинаятьләр кылуын... Берсен дә калдырмый. Хәлең булып тыңлабрак ятсаң, кай урыннарда, чынлап та, кызыксынып китәсең. «Әстәгъфирулла тәүбә! Чынлап та шулай микәнни? Алай ук түгелдер инде. Булмас...» дип уйларга мәҗбүр буласың. Кайчагында бик ышанырдай урыннары да килеп чыга. Беренче карашка, күзләр маңгайга менәрлек мәгълүматларны да шулкадәр тормышчан итеп аңлатып, дәлилләп биргәч, тагын ышанган кебек тоеласың.

Айгөлнең җанын иң рәнҗеткәне әлеге чирнең акча эшләү өчен кемнәрдер тарафыннан уйлап чыгарылган булу ихтималын ишетү иде. Диктор бик тәфсилләп, абруйлы шәхесләрнең фикерләрен китереп, документаль мәгълүматларга сылтамалар белән сөйләсә дә, бу адәм ышанырлык хәл түгел иде. Һәрхәлдә Айгөлнең ышанасы килмәде. Ничек инде адәм баласы акча өчен шундый зур кабахәтлеккә бара алсын? Бу бит берничек тә башка сыймый, күз алдына китереп булмый торган хәл!

Иң беренче теләге сөйләүче китергән чыганакларны эзләп табып, аның ялганлыгын фаш итү булды. Ләкин аның әлегә моны эшләрлек мөмкинлеге юк, үз хәле хәл иде.

Бу хакта сүз каткач, Глүсә кул гына селтәп куйды:

– Акча өченме? Акча өчен хәзер кайбер кеше ата-анасын сатып җибәрергә мөмкин. Ә җиде ятларның хәсрәтеннән аның чәч бөртеге дә селкенми. Акча рулит!

Бер карасаң, Глүсә дә хаклы иде. Бу чир башланып, саклану чаралары мәҗбүригә әйләнгәч, күпләр битлек тегеп сату эшенә кереште. Берсен иллешәр сумнан җибәрделәр. Хөкүмәт даруханәләренә арзан хакка кайтып төшкәч кенә, тукталдылар. Монысы әле вак-төяк эшмәкәрләр гамәле. Ә бер шәһәрнең мэры, ниндидер тегү фабрикасын алдан сатып алып, битлек тегүгә җайлаштырып куйган, шуның белән миллионнар эшләгән дип сөйләделәр. Әлеге чирдән саклый алу мөмкинлеге бар дип исәпләнгән бөтен төр даруларның бәясе әллә ничә тапкырга күтәрелде. Хәтта сарымсак, лимон, имбирь ише нәрсәләрнең дә хакын арттырдылар. Әллә кая барасы да юк, әнә, шәһәр транспортларына куар-кодсыз керү тыела дип белдергән көнне үк такси бәяләре ничек сикерде! Югыйсә ул болай да бик арзан түгел иде бит инде.

Беркем дә кешеләр турында уйлап: «Халык болай да авыр хәлдә, очын-очка ялгап кына яши, чир эләктергән кешеләрнең хәле тагы да мөшкелрәк, аларга бераз ярдәм булсын әле», – дип тормый. Һәркем үз кесәсен калынайту ягын каера. Хәтта кешеләрнең фаҗигасе белән акча эшләү дә – бүген гадәти күренеш. Аның өчен беркем дә гаепләми. Киресенчә, кешелеклелек турында сөйләү, кемнедер яхшылыкка өндәү үзе үк сантыйлыкның бер төре булып тоела. Менә шушы җәмгыятьтә кемнәрдер вирус ярдәмендә акча эшләргә, сәяси максатларын чынга ашырырга тели икән, бу бер дә адәм ышанмаслык хәл булып тоелмый.

Баштарак кызыксыну уятып, төрле уйларга этәрсә дә, тора-бара Глүсәнең телефоны да ялкыта башлады. Чын дөресен генә аңлатып бирерлек булсын иде ул. Ә монда алай түгел. Бер тапшыруда бер төрле сөйлиләр, кире кагып булмаслык дәлилләр белән бер нәрсәне исбат итәләр. Шаккатып, ышанып тыңлап торасың. Икенче тапшыруда бөтенләй киресен сөйлиләр. Монысында да җитди чыганакларга таянып, какшамас дәлилләр белән исбатлыйлар. Монысына да ышанасың. Шул рәвешле, үзеңне нәрсә сөйләсәләр, шуңа ышана торган бер мәхлук итеп тоясың. «Дөреслек кайда соң?» дип уйларга мәҗбүр буласың. Ә дөреслек юк. Кем сөйли – шул хаклы. Дөреслек белән Ялган игезәк балалар кебек аерып алгысыз. Менә шундый дөньяда үзеңне адашып калган юлчы кебек хис итәсең, эш-гамәлләреңнең генә түгел, ә уйларыңның да, хәтта гомереңнең дә мәгънәсе югала. Карыныңдагы балаң кызганыч кебек була: «Нинди коточкыч дөньяга бирәм мин сине, балакаем. Бәхет-тәүфыйкларыңны Ходай берүк үзеңә атап бирсен инде. Явызлар гөнаһы өчен җавап тотарга, бинахакка газап кичерергә язмасын...»

Шундый уйлы-моңлы көннәрнең берсендә Надяның хәле начарланып китте. Иртәнге якта әйбәт иде әле ул, хәтта Нәсимә белән гәпләшеп тә яттылар. Ни турында сөйләшүләрен Айгөл белә алмады, аларның пышылдашуы

астында йокымсырап киткән иде. Кыска вакытлы йокы, уяну, сызлану, тагын аз гына йокымсырап алу. Хәле арулангандай тоела башласа, башына уйлар керә. Әллә нәрсәләр уйлап, әллә ниләрне күзаллап бетерә. Кайвакыт уйлары Глүсәнең телефоныннан ишеткән хәбәрләр тирәсендә бөтерелә, күп очракта туачак сабые турында була. Торып йөрерлек рәте калмагач, көне дә, төне дә бер төрле кебек тоела. Бер Айгөл генә түгел, Надя белән Нәсимә дә шулай интегә инде. Тик аларның торып утырырлык, сөйләшерлек хәле бар кебек. Әнә шул хәлле шикелле тоелган Надя кинәт авыр-авыр сулый башлады. Кислород битлеген киеп, тирән суларга тырышып, озак кына яткач, калтыранырга тотынды, юрганын алып, баштанаяк төренде.

– Өшим, кызлар, өшим... – дип пышылдады ул. – Әллә температурам бар инде.

Глүсә шундук, медсестра янына барып, градусник алып килде. Утыз тугыз ярым. Шәфкать туташы ашыгып чыгып китте. Бераздан Надя ютәлләргә тотынды. Моңа кадәр палатадагы берсе дә артык ютәлләми иде. Ара-тирә генә. Ә Надяның йөткерүе тирәннән, калын тавыш белән. Моны хәтта ирексез ютәл дип тә әйтергә мөмкиндер. Надя үзе катышмый, күкрәге эчендә нәрсәдер бар, шул тышка атылып чыгарга тырышып тыпырчынадыр кебек иде. Надя да аның хәрәкәтләренә ияреп тартыша, авызыннан саргылт-яшел сыекча юрган өстенә чәчри. Надяның анда кайгысы юк, ул ике кулы белән эчен тоткан. Әйтерсең лә аны тулгак тота, ә баласы авызыннан чыгарга тырыша. Бераздан Надя юрганына капланды да косарга тотынды. Ул арада берничә яшел халатлыны ияртеп табиб килеп җитте һәм, бераз күзәтеп торганнан соң, хатынны каядыр алып китәргә боерды. Шәфкать туташы кай арададыр беләгенә укол ясады һәм санитар хатыннар Надяны караваты-ние белән палатадан алып чыгып китте.

Надяны башкача күрә алмадылар. Өч көннән соң җыештыручыларның берсе кереп, аның тумбочкасындагы әйберләрне пакетка салып алып чыкты. Моны күзәтеп торган Нәсимә:

– Башка палатага күчтеме әллә? – дип сорады.

Җыештыручы ханым аңа бертын төбәлеп торды да:

– Башка дөньяга, – дип пышылдады.

Нәсимә көтелмәгән хәбәрдән күзен шарландырып, өнсез калды.

– Ә баласы? – Глүсә яткан урыныннан ук торып басты: – Баласы исәнме?

Җыештыручы хатын башын гына чайкады. Һәм тирән көрсенеп:

– Шундый хәлләр... – диде дә ишеккә ашыкты.

Хәбәр сау-сәламәт кешене дә аяктан егарлык иде. Әле генә синең янында сөйләшеп яткан кеше кинәт кенә үлеп китсен әле. Бу кызганыч та, куркыныч та иде. Әҗәл ерак түгел, ул кайдадыр бик якында йөри. Кайчан кемнең караватына килеп, кулын сораячагы гына билгесез.

Бераздан палата күз яшьләренә, хәлсез тавыш белән үксүләргә күмелде.

**9**

– Син балаңны югалткансың, Надялар бергәләп китте, – дип, Глүсәгә төбәлде Нәсимә икенче көнне. – Әҗәл якында йөри. Хәзер минем чират.

Айгөл юрганына төренеп, хәлсезләнеп яткан җиреннән аңа ялт итеп караш ташлады. Нәсимә аның үз уйларын кычкырып әйткәндәй тоелды.

Әҗәл, чынлап та, якында йөри иде. Хастаханәдә генә түгел, хәтта урамда, әле сау-сәламәт чагында да, төрле авыр хәбәрләрне ишеткәндә, ул шулайрак уйлап куя, үзен дошманнар басып алган шәһәрдә, кемнәрнеңдер кул астында яшәгән шикелле тоя иде. Сугышта яшәгән кебек. Кайдан нинди пуля яки снаряд ярчыгы килеп тиярен беркем дә белми. Пуля һәм снаряд урынына хәзер вирус. Аның кайчан, кемнән эләгерен беркем дә белми. Беркем дә иртәгә, алай гына түгел, берничә сәгатьтән үзен нәрсә көткәнен төгәл әйтә алмый. Әнә бит, Надяның хәле дә иртәнге якта ару гына кебек тоелган иде, ә төш узуга ашыгып алып киттеләр. Һәм менә...

– Фаҗигагә чират алмыйлар, – дип кырт кисте Глүсә, – Яхшыга өметләнергә кирәк. Бәлки безнең палатаның планы тулгандыр инде.

Аңа җавап бирүче булмады. Нәсимә баш каккандай итеп кенә куйды. Ә Айгөлнең анлык та хәле юк иде. Ул өнсез-хәрәкәтсез генә килеште. Уйлары белән генә. Чынлап та, яхшыга өметләнергә кирәк.

Күңелне төшерергә ярамый. Төшенкелеккә бирелү – зур гөнаһ, чөнки бик күп фаҗигаләрнең нигезендә шушы халәт ята: ул синнән хыянәтче, кол яки бар нәрсәдән өметен өзгән кансыз җинаятьче ясарга, хәтта үз-үзеңә кул салырга мәҗбүр итәргә мөмкин. Артык тирәнгә кермичә, хәтта бер кеше мисалында гына алганда да, бу – үзе үк җанны газап читлегенә кертеп бикләүче авыр һәм йогышлы чир. Ишек-тәрәзәсез караңгы бүлмәдә берьялгызың калган шикелле. Монда сиңа чикләнгәнлек, караңгылык һәм ялгызлык хуҗа. Син шуларның колына әйләнәсең.

Бераздан Глүсәнең телефоны кабат телгә килде. Бу юлы ул ниндидер радионы тыңлый иде бугай. Дөнья буенча статистик мәгълүматлар тапшыра.

– Джон Хопкинс университеты мәгълүматларына караганда, 2021 елның ноябренә дөнья буенча барлыгы 261 408 886 кеше чир йоктырган, вафат булучылар саны – 5 198 753. Иң күп каза күрүчеләр Америка Кушма Штатларында: 48 215 571 авыруның 77 659-ы якты дөньядан киткән. Германиядә 5 782 961 авыруга 100 895 үлем очрагы туры килә. Россия буенча чир эләктерүчеләр – 9 403 480, үлүчеләр – 267 527 кеше…

Диктор бу хәбәрләрне чебеш санаган бер җиңеллек белән хәбәр итсә дә, Айгөлгә ул авыр тәэсир итте. Бу саннар артында кеше язмышлары ята иде. Киткәннәрнең өзелгән гомерләре, калганнарның яралы күңелләре.

Кайлардан гына килеп чыкты соң шушы афәт?

Бу дөньяда бер нәрсә дә Ходай ризалыгыннан башка эшләнми диләр бит. Ник Аллаһы Тәгалә шундый казалар җибәрде икән соң? Гөнаһларыбыз шулкадәр күп җыелды микәнни? Бардыр шул. Югыйсә бу дәрәҗәдә газапланырга, куркырга, соңгы тиенеңә кадәр даруларга чыгарып салырга мәҗбүр итмәс иде. Кешеләрне ярата диләр бит. Үзең яраткан җаннарны бер дә юктан гына ничек итеп шулкадәр җәзаларга мөмкин?

Миллионнарның гомерен өзгән зур сугышлар кебек үк эпидемияләр дә әледән-әле булгалап торган. Бәлки кешелеккә һәрвакыт әнә шундый тетрәнүләр кирәктер. Адәм баласы бит ул үз тормышыннан канәгатьләнә, булганына сөенә белми. Тирә-якка күз салсаң, бүген дә аны ачык күрергә мөмкин. Өсте бөтен, тамагы тук бүгенге кешенең, әллә нинди авыр эшләрдә җан тире түгеп эшләми дә. Тик ул бер нәрсәдән дә канәгать түгел. Аңа һәрвакыт нәрсәдер

җитми. Байлар байлыкларыннан каза күрә, ярлылар – ярлылыктан. Ялгызлар ялгызлыктан интегә, парлылар – гаилә проблемаларыннан. Хатын-кызлар хатын-кызларны кимсетүдән зарлана, ир-атлар – ир-атларны кимсетүдән.

Ләкин бит узган гасыр белән генә чагыштырсаң да, кеше бүген күпкә рәхәтрәк яши. Ата-бабалар хәтта оҗмахны да бу дәрәҗәдә итеп күз алдына китерә алмагандыр. Ләкин кеше үзенең рәхәт яшәвенә тиз күнегә, аның ләззәтен күрми-тоймый торган җан иясенә әверелә. Шәхси рәхәтлеккә омтылуның чикләре юк. Ул яңадан-яңа кичерешләр, тойгылар, аларның мең төрләрдә чагылышын таләп итә. Һәм, нәтиҗәдә, кеше тормышны яратудан туктый. Ул ярата белми башлый.

Һәм ул үзенең шушы халәтен дә аңлый алмаслык дәрәҗәгә төшә. Кемнән генә сорасаң да, уйлап та тормастан ул: «Мин бу тормышны яратам!» – дип җавап бирергә мөмкин. Аннан берәүнең дә аерыласы килми. Ләкин бу ярату түгел. Бу – әҗәл артындагы билгесезлектән курку гына. Әгәр адәм баласы үз ләззәте өчен башкаларны кыерсытырга, аларның өлешенә керергә: алдарга, урлашырга, таларга, хәтта үтерергә әзер икән, монда ярату турында нинди сүз була ала? Ай-йолдызлардан башлап, елга-күлләр, урман-кырлар, кешеләр, барлык җан ияләре, хәтта кечкенә бөҗәкләр дә – синең тормышыңның бер өлеше бит. Ул тормышны матурлау өчен – сәнгать өлгеләре, җиңеләйтү өчен адәм акылы уйлап тапкан казанышлар да бар әле. Әгәр адәм баласы үзенә рәхәтлек тудыручыларның кадерен белми башлый икән, бу инде тормышны ярату түгел, бу аны куллану. Бу – аны көчләү.

Чиксез ләззәт артыннан куып исергән, күзләре маңгаена менгән кешелекне айнытып җибәрер өчен бәлки менә шушындый тетрәнүләр дә кирәктер. Ходай бәлки шуның өчен барысына да ирек куядыр. Үз хаталарыбыз, гөнаһларыбыз өчен түләүдер бу бәлки. Бер гөнаһсыз кешеләрнең фаҗигагә тарулары гына кызганыч. Хәер, монысына да гаҗәпләнергә кирәкмидер. Кеше, Җирдәге тормышның хәлиткеч бер өлеше буларак, беркайчан да фәкать үзе өчен генә җавап тотмый. Җәмгыятьнең хаталары өчен һәрвакыт кешеләр түли. Шәхесләр күбесенчә. Гөнаһсызлары бигрәк тә. Чөнки алар үз-үзләрен яклый белми, яклаучылары да булмый. Яклый алучылар мондый чакта алардан йөз чөерә, ташбака сыман үз кабыкларына кереп бикләнә.

Башта бик хәтәр көчле кебек тоелса да, тора-бара Айгөлнең бу уйлары да мәгънәсен җуйды. Дөрес түгел бугай алар. Бу дөньяда бер нәрсә дә дөрес түгел. Ялган белән Дөреслек игезәкләр кебек монда. Сиам игезәкләре кебек.

Хәлсезләнеп, ярга сарылган дулкын шикелле Айгөлнең уйлары да, хисләре дә тынып калды. Үткенлеген җуеп, нindидер калыплардан ерак китә алмый салулап яткан уй-тойгыларның тынып калуы яхшырак та иде бугай. Тик алар тынмады. Алар авырту-сулкылдауга әверелеп, акрын гына көчәя барды, бераздан кыя ташны җимерердәй булып үрә баскан гайрәтле дулкыннар сыман башының әле бер, әле икенче ягына килеп бәрелде. Баш сызлауның нәрсә икәнен яхшы белә Айгөл, әмма моның кадәр интектергән авыртуны әлегә кадәр белми иде. Бераздан сызлану дулкыннары күкрәгенең һәм аркасының өске өлешенә агып төште дә читлеккә эләккән гайрәтле аждаһага әверелеп чәбәләнергә тотынды. Айгөлнең сулышы кысылды. Тын

алырга дип көчәнсә, күкрәк читлегендәге аждаһа, котырынып, ут сиптерде. Тын алалмау да, суларга тырышу да газап, бу газаптан котылу юлы да юк иде. Айгөл үз-үзен белештермичә тартышырга, ыңгырашырга тотынды.

– Нәрсә булды, Айгөл? – Глүсә шәфкать туташын чакыру төймәсенә басты да, аның караватына килеп утырып, башыннан сыйпарга тотынды. – Түз инде аз гына, аппагым. Бирешмә инде. Барысы да синнән тора. Түз алтыным, түз. Хәзер табиблар килер.

Ничек кенә сәер тоелмасын, Глүсәнең шулай башыннан сыйпавы җиңеллек биргәндәй булды, ә аның чиксез ягымлылык белән әйтелгән сүзләре күңелне кузгатты. Битарафлык, гамьсезлек белән дөнья тулган кебек тоелса да, кешелеклелек, ягымлылык, наз бар бу дөньяда. Иң өметсез кебек тоелган вакытларда әнә шулар ярдәм итә. Яктылыкка ышанырга кирәк. Ышанырга. Бәлки аны хасил итүче һәм яшәтүче көч нәкъ менә безнең ышанычтыр? Яктылык безнең өмет-ышанычлардан барлыкка килә дә шатлык-куанычлар белән тукланып яшидер. Күңелне төшерергә ярамый. Ышанырга кирәк. Ышанырга...

Береаздан палатага шәфкать туташы килеп керде. Ул Айгөлне күрү белән кабат чыгып китте дә коридорга сөрән салды:

– Уникенче палатага! Пациентның хәле начарланды.

Айгөл боларны күрмәде. Ул һушын җуйган иде.

**10**

Айгөл уянып китте. Тынлык. Палатадашларының тавышын ишетергә тырышып, бераз ятты да күзләрен ачты. Берни дә ишетелмәгәч, башын күтәреп карады. Беркем дә юк иде, ул берүзе бер палатада. Көч-хәл белән торып утырды. Караватыннан дүрт-биш адым ераклыгында гына урнашкан ванна ишегенә күз салды. Бәдрәфкә барып килгәндә, яхшы булыр иде дә... Теге палатада мондый четерекле йомышларны үтәргә Глүсә ярдәм итә иде. Ешрак барырга туры килгәндә дә күпсенеп тормый: «Глүсә, тагын урап килик инде тегеннән», – диюгә выжт итеп килеп җитә. Бәдрәф еракта булмаса да, ике яклап та яртылаш зарарланган үпкә белән анда барып җитү җиңел түгел, сулыш кысыла, баш әйләнә, аяк-куллар йомшара. Ә барып җиткәч, унитазга утыру үзе бер мәшәкать булып тоела. Өстәвенә, үзеңнең шушы халәтеңнән үртәлергә мәҗбүр буласың. Алма кебек тупылдап торган хатын, менә бит нинди хәлгә төштең, хәтта хаҗәтеңне дә үзаллы үти алмыйсың. Мондый халәттән күңел тула, бугазга төер утыра, күзләргә яшь тыгыла.

– Ярый, син артык өзгәләнмә, барысы да уза аның, – дип юата мондый чакларда Глүсә. – Без барыбыз да шуның аша үттек инде.

Аның сүзләреннән күңелгә җылы йөгерә. Бөтен кеше башына да төшкән бәла ул һәрвакыт кечкенәрәк булып тоела. «Башкалар түзгән, җиңеп чыккан бит, әллә мин алардан кимме?» дип уйларга мәҗбүр итә.

Бу юлы палатада ул ялгызы иде. Ярдәмгә килерлек берәү дә юк. Караватастына «утка» дип атала торган нәрсә куеп киткәннәр китүен. Тик аны алып, җайлап урнаштыру үзе үк олы мәшәкать шикелле. Андый нәрсәгә өйрәнмәгәч, сәер дә, гарьлек тә кебек.

Айгөл көч-хәл белән аякларына басты. Шул көчәнүгә дә сулышы купкандай тоелды. Караватка тотынып, акрын гына аягын шуыштырды,

аннан икенчесен. Шул рәвешле караваt буйлап, аннан соң стенага таянып барды. Аяклары камырга әйләнсә дә, ныклыгын сакларга тырышты, берничә адымнан соң башы әйләнүен сизеп туктап калды, тирән сулыш алырга тырышып, хәл җыеп торды, аннан тагын дәвам итте. Ишек төбенә җитүгә күңеле болгана башлады, укшып-укшып куйды. Тик тукталып тормады. Косып, дөнья пычратырмын дип куркып, бүлмә эченә ашыкты. Нәкъ шул вакытта шәфкать туташы килеп керде.

– Әй Аллакаем! – дип, Айгөлгә ярдәмгә ашыкты ул. – Нигә чакыру төймәсенә генә басмадыгыз? Сезгә болай йөрергә ярамый бит...

Аннары, Айгөлне култыклап алып, караватына яткырды да укол ясады.

– Бүтән вакытта болай итмәгез, – дип кисәтте аннан соң. – Нинди генә ярдәм кирәк булса да, менә бу төймәгә басыгыз. Сезнең хәлегез алай итеп йөрерлек түгел. Аңлашылдымы?

Айгөл баш какты.

– Хәзер сезнең янга табиб үзе керер, – шәфкать туташының тавышындагы баягы кырыс таләпчәнлекне якты ягымлылык алыштырды. – Ул сезнең белән бик җитди темага сөйләшергә тели. Ә хәзергә бераз ял итегез. Һәм чакыру төймәсе турында беркайчан да онытмагыз.

Ул чыгып киткәч, Айгөл телефонын кулына алды. Ире белән дә күптән әйбәтләп аралаша алганнары юк, берсе шалтыратканда, икенчесе сөйләшә алмый. Язышу да ара-тирә генә, һәм ул «хәлләр әйбәтләнә, үзең ничек?» кебек сүзләрдән артмый. Шулай булырга тиештер дә инде мондый вакытта. Беренчедән, начар булса да, бик сиздермәскә тырышасың, яраткан кешеңнең күңелен яралыйсы килми. Икенчедән, барысын да тәфсилләп язарга хәл дә юк, баш та бик эшләп бетми. Илдарның да хәле шул чамадыр инде. Телефоннан ул ике тапкыр шалтыраткан, кыска гына дүрт хәбәр җибәргән. Шул ук сүзләр. Бернинди үзгәреш тә юк. Димәк, аның да хәле бик мактанырлык түгел. Тагын әллә кемнәрдән хат-хәбәрләр килгән. Ярый, аларын соңрак, арулангачрак карап чыгар.

Телефонын куюга палатага доктор килеп керде. Уртача гәүдәле, чәчен-битен каплаган. Башка вакытта урамда күрсәң дә, танырлык түгел. Тавышыннан чамаласаң гына инде. Әлегә Айгөл аның табиб икәнен ак халатына карап белде. Алар гел актан йөри, шәфкать туташлары яшелдән, хезмәт күсәтүче персонал – зәңгәрсу киемнән. Табибның медицина терминнарын сиптерүеннән Айгөл берни дә аңлый алмады. Доктор да моны сизде бугай, күзләрен тәгәрәтеп, бер хәрәкәтсез карап торган хатынга караш ташлап алды да адәм теленә күчте:

– Гади генә әйтсәк, болайрак була. Вирус үзе җиңелмәс чир түгел, әмма аның бик мәкерле үзенчәлеге бар: кешенең моңа кадәр булган бөтен авыруларын көчәйтеп җибәрә. Сезнең буыннарда, кан тамырларында чирегез бар. Авырлы хатынга бу бик куркыныч. Беренчедән, аның үзе өчен куркыныч тудыра, икенчедән, карындагы баланың гомере өчен. Без, әлбәттә, сезнең дә, баланың да гомерен саклап калу өчен барысын да эшлибез. Әмма килеп туган хәлдә без сайлау алдында калырга мөмкинбез. Икегезнең дә гомерен саклау мөмкинлеге өзелгән очракта, без яки балага, яки сезгә өстенлек бирергә тиеш булачакбыз.

Аның тавышыннан ук Айгөл хәлләрнең бик мөшкеллеген чамалап

өлгергән иде, сүзләрен тыңлаган саен сиземләве көчәя барды, күңеленә шом йөгерде. Ә икенең берсен сайлау мөмкинлеге турында ишетүгә, арка үзәге буйлап салкын йөгерде.

– Димәк, икенең бере: яки бала, яки мин?

Доктор көрсенеп, баш какты:

– Шулайрак килеп чыгарга мөмкин.

Айгөл күзләрен йомды. Бер гаепсез кешегә шулкадәр мәрхәмәтсез булган дөньяны күрәсе килми иде. Күзләрен йомуга ук әллә кайдан саркылып чыккан яшь тамчылары керфек очларында калтыранды. Тамагындагы төерне йотарга тырышты. Нәрсәдер әйтергә дип авызын ачты, әмма тавышының еламсырауга әйләнүен тоеп туктап калды. Тынычланырга кирәк. Төшенкелеккә бирелергә ярамый. Төшенкелеккә бирелү – үзе үк... Тик мондый вакытта, шушындый җанөзгеч сынау алдында төшенкелеккә бирелмичә кара син! Чит кеше башына төшкән кайгы турында фәлсәфәгә бирелергә, сәгатьләр буе бәхәсләшергә, әллә нинди фикерләр әйтеп бетерергә мөмкин. Ә үз башыңа төшсә, берни дә әйтәсе килми. Уйлыйсы да килми. Бар булмышыңны ачы нәфрәт, аяусыз тойгылар күмеп китә.

Кинәт Ходай тел ачкычы бирде бугай. Айгөл газапларын артта калдырып, табибка текәлде:

– Өченче юл юкмыни соң?

– Дүрт юл бар, – диде табиб үз көчсезлегеннән үзе кыенсынган шикелле. – Яки икегез дә исән каласыз. Мин бөтен күңелем белән шулай булуын телим һәм моның өчен кулымнан килгәннең барысын да эшләячәкмен. Балага яки үзегезгә...

Монысын Айгөл белә иде инде, кабаттан ишетәсе килмәде һәм ул бүлдерде:

– Ә дүртенчесе?

– Анысы иң хәтәр очрак. Икегезне дә коткара алмаска мөмкинбез. – Ул тирән көрсенеп өстәп куйды. – Алай да булырга мөмкин.

Тынлык урнашты. Әллә нинди салкын, караңгы тынлык иде бу. Дөньяда барлык җан иясе үлеп беткән дә бөтен нәрсә тынып калган шикелле.

– Бу хакта, бәлки, мин болай ачыктан-ачык әйтергә дә тиеш түгелмендер. Тик сез белеп торырга тиеш. Көч тупларга. Чир белән көрәшергә әзер торырга. Әгәр сезне коткару өчен берни дә эшләмибез икән, нәтиҗәсе билгеле. Соңгы чарага тотынабыз икән, төрлечә килеп чыгарга мөмкин.

Айгөл, бер ноктага текәлеп, озак кына утырды да күзләрен табибка күтәрде.

– Нәрсәдер эшләп карарга кирәк.

Доктор аңа төбәлде:

– Сез, чынлап та, шуны телисезме?

– Әлбәттә!

Доктор зәңгәр папкасыннан ике кәгазь алып, Айгөлгә сузды:

– Алайса, менә бу кәгазьләрне укып чыгыгыз да кул куегыз. Бу дәвалау чаралары белән килешүегез турында...

Айгөл аңлый иде. Соңгы вакытта суд юлында сөйрәлүләрдән куркыпмы, хәтта гади генә дарулар эчәр алдыннан да шундый килешү төзи башладылар. Ул кәгазьләргә күз йөгертеп кенә алды да, билгеләнгән урыннарга култамгасын куеп, табибка сузды:

– Доктор...

Табиб кәгазьләрен папкасына салгач, дикъкать белән аңа төбәлде.

– Доктор, үтенәм... Әгәр шундый сайлау алдыгызга басса... Әгәр икенең берен сайларга туры килсә... Зинһар өчен... Алла хакы өчен дип сорыйм... Баламны сакларга тырышыгыз. Ул исән-сау туарга тиеш. Доктор, сез мине ишетәсезме?

Доктор бераз дымлана төшкән керфекләрен ачып-ябып алды.

– Яхшы, Айгөл ханым, – диде ул ышанычлы тавыш белән. – Беренче чиратта – бала. Тик без сезнең икегезне дә алып калырга тырышачакбыз. Барысы да уңышлы булачак. Сез дә шуңа ышаныгыз.

Доктор этиләрчә итеп хатынның аркасыннан сөйде дә урыныннан кузгалды. Баш кагып кына саубуллашып, ишеккә атлады. Ул чыгып киткәч, Айгөл бер ноктага төбәлеп, озак кына утырды да үзе дә көтмәстән кычкырып елап җибәрде.

**11**

Беркадәр тынычлангандай булып, күз яшьләрен сөртеп маташканда, телефоны шалтырады. Илдар! Ватсап аша! Видеосөйләшүдән. Моңа кадәр юньләп сөйләшә алганнары юк иде, йә Айгөлнең хәле булмый, йә Илдарның телефоны дәшми. Язышканда икесе дә артык чишелеп бармый, «әйбәтләнә» дию белән генә чикләнәләр. Бер-берсенең хәлләре бик үк әйбәт түгеллеген икесе дә чамалап торса да, зарлану якынының күңелен яралау булып тоела.

Тик бу юлы Айгөл бер нәрсәне дә яшереп кала алмый иде. Илдар беразябыга төшкән, сөйләшү рәвеше дә акрынайган, тавышы сүлпәнләнгән. Шулай да сер бирмәскә тырыша. Исәнлек-саулык сорашкан арада ук Айгөл моны сизеп өлгерде. Үзенең дә кыяфәте бик әллә ни түгелдер инде, Илдарның карашларында ярату, сагыну белән бергә кызгануга тартым хисләр дә чагылгандай булды. Ләкин иң мөһим хәбәрне әйтеп өлгерергә кирәк. Бу хакта уйлауга ук Айгөлнең иреннәре дерелдәп алды, авызын ачса, тавышы калтыраныр, елап җибәрер кебек тоелды. Тик әйтергә кирәк иде.

– Илдар... – Хатынының тавышында ниндидер сәерлек тоеп, ир тынып калды, игътибар белән тыңлыйм сине дигән карашларын аңа төбәде, Айгөл тамак кыргандай итте дә сөйли башлады: – Безнең хәлләр бик әйбәт түгел ул, Илдар. Мине икенче палатага күчерделәр, ялгызым гына монда. Әле генә доктор кереп чыкты. Беләсеңме, ул нәрсә диде?

– Нәрсә диде? – Бу сүзләрне ишетүгә үк Илдарның йөзенә болыт йөгерде, газап катыш сагаюлы карашларын телефон экраныннан аера алмый торды. Тавышы да дулкынланулы иде. Хатыны фикерен туплап торган арада, ул тагын хәлсез ашкыну белән кабатлады: – Доктор нәрсә диде?

– Сабыр ит... – Айгөл тирән-тирән сулыш алып, бераз хәл җыйгандай итеп торды. Аннан соң акрын гына барсын да сөйләп бирде. Сулышын сулышка ялгап, сүзләрен өзә-өзә... тавышы кайчак тигез генә ишетелде, кайвакыт калтыранып, менә-менә елауга әверелеп китәрдәй тоелды. Хәбәр бик хәтәр булса да, хатынының хәлен аңлап, Илдар бүлдермичә тыңлады. Аннан соң бөтен әрнү-газапларын бер сүзгә сыйдырырга теләгәндәй, авыр сулап куйды:

– Йа Ходай!..

Авыр тынлык урнашты. Айгөл дерелдәгән иреннәрен кысып, челт-челт

килгән керфекләрен экранга төбәп, иреннән җавап көтте. Бер ноктага төбәлеп, тын калган Илдар дәшмәде. Ул хәтта селкенеп тә карамады, сулыш та алмады бугай, торaташка әйләнгәндер шикелле иде. Озак кына шулай торгач, иреннәрен кысты. Тирән сулап куйды. Карашларында боз булып катып калган хәсрәтне эретергә теләгәндәй, күзләрен ачып-йомып алды. Нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачты, әмма тавышы чыкмады. Тамак кырып куйды.

– Айгөл... – Ниһаять, аның карлыккан авазы ишетелде. – Айгөл...

Илдар бераз тынычлана төшкәндәй булды, әмма йөзендә киеренкелек көчәя генә барды. Айгөл аның компьютер артында нәрсәдер язып утырган чагын хәтерләде. Әле дә Илдар тирән уйда, нәрсәдер эзли иде бугай. Айгөл аны бүлдерергә базнат итмәде, сабыр гына көтте. Ниһаять, ир телгә килде:

– Докторлар да барысын да белеп бетерми, Айгөл. Аның сүзләренә тулысынча ышанырга кирәкмидер. – Бу юлы аның тавышы сабыр, ышанычлы булып ишетелде. – Аннан соң яңа дәвалау ысулы билгеләр алдыннан алар гел шулай итә. Аның нинди нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген аңлатып, пациенттан култамга алалар. Мин дә андый килешүгә кул куйдым. Бу аларга дәвалау уңышсыз чыккан очракта суд юлында йөрмәс өчен кирәк бугай. Шуңа күрә син барысын да күңеленә якын алмаска тырыш. Безнең хәлдә хәзер иң мөһиме – төшенкелеккә бирелмәү. Өметне өзү гомерне өзүгә тиң.

Иренең сүзләреннән Айгөлнең күңеленә җылы йөгерде. Сулышын авырлык белән генә алып, сүзләрен кыенлык белән әйтсә дә, тавышында күңел түреннән чыккан какшамас ышаныч бар иде. Бу хәтта бер мизгелдә бөтен нәрсәсен югалтып, соңгы чиккә китереп терәлгән кешенең коточкыч дошман белән хәлиткеч көрәше булып тоелды. Яшәүгә омтылышы, рухи гайрәте шушы дәрәҗәдә булганда, ул хәлсез көенә дә барысын да җиңеп чыга алыр шикелле иде. Айгөлнең күзләренә нур кайтты. Аның үзгәрешен күрүдән Илдар да балкып киткәндәй булды.

Ире, чынлап та, хаклы иде бит. Хастаханәнең кайсына барып эләксәң дә, хәзер шулайрак итәләр. Хәтта кайчак яңарак дару бирсәләр дә, «Пациентның үз теләге буенча» дип кул куйдырталар.

Тик хатынның күңелендәге курку хисе тулысынча юкка чыкмаган иде әле.

– Илдар, – дип пышылдады ул, шул тойгыдан арына алмыйча. – Әгәр... Әгәр икенең берсен сайларга туры килсә?

Һәм үзенең ни өчен болай диюенә үзе дә аптырап куйды. Иренең фикерен белергә теләдеме, аның хуплавын, мәхәббәт белдерүен өмет иттеме, аңларлык түгел. Югыйсә ул үз сүзен докторга бая ук әйткән иде бит инде. Айгөл үз юлын сайлаган иде.

– Теләсә-нәрсә белән аңыңны чүпләмә, Айгөл, – дип кырт кисте Илдар. – Монда әллә ничә төрле юл юк. Юл бары тик берәү генә – барысы да уңышлы булачак. Максат – шушы. Шуңа омтылырга кирәк.

Ләкин Айгөл аның җавабын ишетергә тели иде.

– Аңлыйм, Илдар... Тик шулай да...

Ир бер мәлгә тынып калды. Айгөлнең тавышы хәлсез булса да, таләбе катгый иде. Аңа җавап бирми мөмкин түгел.

– Мин синең сайлавыңны аңлыйм, җаным, – диде аннан соң. – Һәрбер ана үз баласы өчен тамугка да керергә әзер. Ә синең кебек шәхес – бигрәк

тә. Балабызның дөньяга килүен, аның шат-бәхетле булып гомер итүен мин дә бик телим. Ләкин минем сине югалтасым килми. Синсез калсам, тормышымның бар яме, мәгънәсе бетәчәк. Син дә мине аңларга тырыш...

– Илдар!.. – Айгөлнең тавышында яшеннәр кискенлеге дә, тетрәнүләрдән торган күкрәү лә яңгырап киткәндәй булды. – Илдар...

Ир, күзләрен хатынынннан алмыйча гына, иреннәрен кысып, көрсенеп куйды да дәвам итте:

– Тыңлап бетер, Айгөл... Баласы үле туган аналар да, авырлары төшкәннәр дә, үзләре үк аборт ясатучылар да бар. Бу, әлбәттә, фаҗига. Гомерлек газап. Ләкин һәлакәт түгел. Әгәр без икебез дә исән калсак, әле тагын балалар табып үстерергә мөмкинбез. Бәлки, ул сабыйга шушы ук баланың җаны күчкән булыр.

– Димәк, син... – Айгөлнең тавышы күз яшьләре аралаш иде һәм ул моны яшереп тә тормады. – Син баланың тууын теләмисең!

– Телим, Айгөл. Ләкин мин сине югалтырга теләмим.

– Ә баланы?

– Айгөл, мин сезнең икегезнең дә исән-сау булуыгызны телим. Һәм, шуны сорап, көне-төне Ходайга ялварачакмын. Моның өчен мин хәтта үз гомеремне бирергә дә риза. Минем берегезне дә югалтасым килми.

Айгөл хәлсезләнүен тойды. Иреннән ул мондый сүзләр ишетергә теләми иде бугай. Айгөлнең сайлавын бәяли алуын, эченнән генә соклануын көткән иде бугай ул Илдарның. Баласының тууы хакына үз гомерен корбан иткән ана соклануга да, яратуга да лаек. Ул – чын ана. Ләкин Илдар бөтенләй башка нәрсә сөйләде... Үз карынында тыпырчынмагач, күзенә күренмәгәч, бала кадерен бик аңлап та бетерә алмыйдыр инде ир кеше. Моны, бәлки, кичереп, гафу итеп тә була торгандыр. Айгөл, бәлки, берәр кайчан кичерер дә. Тик әле аның сүзләре рәнҗетте. Нык итеп. Хәтта ике араны суытырлык дәрәҗәдә. Хатын иренең соңгы сүзләрен тешләрен кысып кына тыңлады да:

– Син инде кемнедер югалттың бугай, – дип, трубканы ташлады.

Бер мизгелгә бөтен булмышын нәфрәт ялкыны чорнап алды. Аны шундук диярлек кайдандыр килеп чыккан күз яшьләре давылы күмеп китте. Айгөл корсагында хәлсез тартышкан баланы кочаклап үксеп еларга тотынды.

## 12

Сулкылдаган саен сулышы кысылды, үпкәсе күкрәгеннән кубып, тамагына килгәндәй тоелды. Айгөл тынычланырга тырышты, ләкин күңелендә котырынган давыл юл куймады, ул инде хатынның теләгенә буйсынырлык дәрәҗәдән узган иде. Күзләрен яшь томалады, уйларын нәфрәт богаулады, үпкәләрен, бөтен тәнен сызлану йолыккалады. Күзгә ак-кара да күренерлек түгел. Шулай да Айгөл, мизгелнең бер өлешендә һушын җыеп, табибларны чакыру төймәсенә басты. Бәхетенә каршы, шәфкать туташы шундук атылып килеп керде дә, эшнең нидә икәнлеген аңлагач, укол ясап чыгып китте, ә бераздан, система кую әсбапларын күтәреп, кабат керде.

– Сез, зинһар өчен, тынычланыгыз, – диде ул, хатынның иңеннән сөеп. – Хәзер барысы да җиңелрәк булып калыр.

Айгөл тынычланырга тырышты. Шулай кирәк. Югыйсә бу дәрәҗәдәге сулкылдау-сызланулар белән балаңны харап итүең дә бар. Алла сакласын.

Уколдан соң хәле бераз җиңеләебрәк калгандай тоелды, ә акрын гына тамган система тамчылары тәэсирендә бөтен тәне йомшарып китте, күзләренә йокы тыгылды. Бу халәте күңелендәге давылны да юкка чыгарды, әллә кайдан кинәт баш калкыткан газаплы тойгылар кабат үз өненә кереп бикләнделәр.

Илдарны гаепләп, нәфрәтләнеп маташасы юк иде. Дөрес эшләмәде Айгөл. Әгәр икенең берен сайларга туры килсә, имеш... Бу берничек тә дөрес җавап бирә алырлык сорау түгел иде. Мондый сорауны бирергә ярамый иде. Ире үзе дә әйтеп торды бит, юк-бар белән башыңны катырма дип. Бу гадел сайлау түгел. Ике явызлыкның кечерәген сайларга кушалар. Тик монда берсе дә кече түгел. Әгәр Айгөлнең үзеннән ире: «Минем исән калуымны телисеңме, әллә баланың тууынмы?» – дип сораса... Бу очракта нәрсә дип җавап биреп була да аның кайсы дөрес килеп чыга? Берсе дә түгел! «Баламның исәнлеген телим» дип әйтү үзе үк «Синең үлемеңне сайлыйм» дигән шикелле яңгырый бит. Мондый сүзне сөйгән кешеңә әйтеп буламыни?

Илдар да алай дип әйтә алмады. Бәлки, күңеленнән ул баласының исән калуын теләгәндер. Тик бу бит тел белән әйтелерлек сүз түгел. Асылда, Илдар икесенең дә исән-сау булуын тели. Аңа бәйләнерлек бер сәбәп тә юк. Тик... Тик аның абортлар, баланың үле туулары турындагы сүзе... Хәер... Бер карасаң, ул да хаклы бит инде. Балаң төшсә дә, үле туса да, аның артыннан башыңны кабергә тыга алмыйсың, кайгыларыңны эчеңә йотып яшәргә мәҗбүр буласың. Бернәрсә дә эшләп булмый.

Ә яшисе килә иде. Тормыш авыр дип, ничек кенә зарлансаң да, яшь кенә көеңә бу дөньядан китәсе килми. Чир-чорлар да, сызланулар да, эпидемияләр дә узар ул бер. Акрын гына барысы да үз урынына кайтыр. Тормышның матурлыгы күзгә күренә башлар. Үз өеңдә, сөйгән кешең янында, үз балаңны күкрәгеңә кысып... Әрнү-сызланулардан, кайгы-хәсрәтләрдән азат булып, күңел тынычлыгында һәм мәхәббәт дулкынында яшәү үзе үк оҗмах кебек ләбаса. Мондый җәннәттән беркемнең дә баш тартасы килерлек түгел. Айгөлнең дә яшисе, тормыш матурлыкларын күреп хозурланасы, рәхәтлекләрен тоеп ләззәтләнәсе килә иде.

Үләсе килми. Үлемнән курку дигән нәрсә бар. Ул бөтен кешедә дә була торган табигый тойгы диләр. Тик Айгөл үлемнән курыкмый, ул теге дөньяда нәрсәләр көткәнлеген уйлап мазасызланмый, ул бу дөньядагы иң кадерле, иң якын кешеләрен калдырудан курка, алардан аерылырга теләми иде.

Бу бер дә начар нәрсә түгел, әмма икенче ягы бар, һәм анысы Айгөлне шомга сала, куркуга төшерә. Алдында икенең берсен сайлау ихтыяҗы калкып чыккач, нәкъ менә шушы яшәү теләге аны дөрес юлдан аерырга мөмкин иде. Табибка: «Иң мөһиме – баланың исән калуы», – дип әйтсә дә, хәлиткеч бер мизгелдә аның карары үзгәрергә һәм хатын, үзе дә искәрмәстән баласы турында онытып, үз гомере өчен көрәшә башларга мөмкин. Мондый хәлнең хәтта ихтыярсыз рәвештә килеп чыгуы да бар. Табиблар гына түгел бит әле монда, организм дигән нәрсә дә хәлиткеч көч булып тора. Организмның үз-үзен саклау инстинкты бар бит әле. Әгәр менә шундый хәлиткеч сынау вакытында Айгөл үзенең бөтен көчен баласының исән калуы өчен биреп бетерә алмаса? Иң куркынычы шушы иде.

## 13

Баштагы хәлсез ухылдаулары җан авазына әйләнде. Авыртуга чыдап булырлык түгел. Аның кайсыдыр җире генә авыртмый, ә бөтен булмышы чамасыз сызлануга әверелгән шикелле иде. Әйтерсең дөньяның бөтен кара көчләре зур бер гаскәр булып тупланган да, адәм күзе күрмәслек дәрәҗәдә кечерәеп, Айгөлнең бар гәүдәсе буйлап таралган һәм аяусыз сугыш ачкан. Тәненең тиресенә кадәр ут булып яна. Кояшта чамасыз кызынганнан соң эссе мунчага кергән шикелле әрни. Хәтта күлмәге тәненә ышкылып китсә дә, бу әрнү йөзләтә көчәя. Ә газап эчендә чәбәләнгәндә, тыныч кына ятып булмый, әле кул-аяклары, әле бөтен тәне тартышып куя, йә уңга, йә сулга әйләнеп ятарга мәҗбүр итә. Аның саен тәне ышкыла һәм утлы пычак белән тиресен тунаган тәэсир калдыра. Буыннары сызлый. Иңнәре, терсәкләре, бармак чуклары ата салкында боз булып туңганнан соң эри башлаган кебек әрни. Аяк буыннары да шул ук хәлдә. Аякларында боз шикелле туң авырту, алар инде йөрми дә, бөгелми дә, авыртудан башка нәрсәгә яраклы түгелдер кебек. Алар шушы салкыннан һәм сызланудан котылырга теләгәндәй тартышып-тартышып куя, хәрәкәтләнгән саен сөякләре бер-берсенә ышкылып ашалган сыман була. Уалган сөякләрнең валчыклары итләренә, кан тамырларына кадала. Эчендә дә бернинди тынгылык юк, бер ризык капканы булмаса да, ашказаны таш тутырган капчык сыман тыгылып каткан, эчәкләрендә галәмәт зур утлы елан анда-монда шуышып йөргән кебек. Корсагының әле бер, әле икенче тарафына ут ягалар, бөтен булмышыңны көйдергән ялкын бер генә мизгелгә сүрелгәндәй була да кабаттан дөрләп китә. Кара көчләрнең сансыз гаскәре аяусыз үҗәтлек белән аның карынындагы иң изге урынны, туачак баласы яткан карынын ертып керергә тели. Хатын моңа җаны-тәне белән каршы тора. Тик аның җаны да инде челтәр кебек телгәләнеп беткән, озак карышырлык гайрәте юк... Аңа ярдәмгә килеп, һөҗүм итүче дошманнарны бәреп җибәрергә теләгәндәй, карынындагы бала тыпырчынып-тыпырчынып куя. Ул да хәлсезләнгән. Бу җитди каршылык булудан бигрәк, канәгатьсезлек белдерү кебек кенә. Тик ул хатынның күңеленә җылы өрә, ялгыз түгелмен бит әле, минем көрәштәшем бар, бу мәхшәрне бергәләшеп, ничек тә җиңеп чыгарбыз дип уйлау мөмкинлеге бирә.

Кинәт нәрсәдер булды.

Камауда калган кальганы коткарырга килгән гаскәрләр шикелле көтмәгәндә, ниндидер көчләр пәйда булды да Айгөлнең әрнү-сызлануларын бер-бер артлы кыйратырга кереште. Хатынның хәле җиңеләйгәннән-җиңеләя барды. Аңа ярдәмгә килүчеләрнең үзара шаулашуы арасыннан өзек-ертык сүзләре ишетелеп китте:

– Тиз булыгыз!

– Ашыгырга кирәк...

– Баланы коткарырга...

«Баланы коткарырга!» – дип кабатлады хатын, аларга ияреп. Баланы коткарырга... Балакаемны! Аның уйларын, әлбәттә, беркем дә ишетмәде. Зыр китереп, каядыр алып киттеләр дә, зәңгәрсу-яшькелт яктылык сибүче кояш дөньясына кергәч, ашыгып-ашыгып, нәрсәдер эшләргә тотындылар.

Айгөл баш очындагы яшькелт-зәңгәр утлар сибеп янган шул кояшка карап ятты. Ул якында гына кебек иде. Кояш түгелдер инде түгелен. Әмма нурлары шундый рәхәт иде, күзне чагылдырса да, күңелне иркәли. Шул

кояш астыннан Айгөлгә иелгән ак сыннар, бедер-бедер килеп, нәрсәләрдер сөйләшә, тик хатын аларның сүзләрен аңламый. Бераздан алар да томанга әйләнеп юкка чыкты, тирә-якта бушлык кына калды. Хатын үзен ниндидер капкынга эләккәндәй тойды. Авыртулары күпкә азайса да, ул бу халәтеннән беркая да китә алмый, үзенең кайдан килгәнен дә, кая барырга тиешлеген дә белми. Керү юллары да, чыгу юллары да юк. Шуңа да үзенең хәле котылгысыз булып тоела, сызланулары таралса да, күңелен әллә нинди сәер, томан сыман сыек газап талаган шикелле була. Хатын, бөтен көчен биреп, шушы хәленнән котылырга, үз-үзен бәяли алырлык яссылыкка чыгарга тырыша, әмма берничек тә булдыра алмый.

Бераздан ул бөтен газаплардан тулысынча азат булып, рәхәт яктылыкка атылып чыкты. Җилдә очкан тасма җиңеллеге белән караватына торып утырды, аягына басты һәм бүлмә буйлап атлап китте. Атлап түгел, йөзеп... Һәм, үзенең йөзә алуына гаҗәпләнеп, тирә-якка күз салды.

Ул операция бүлмәсендә икән. Айгөлнең сукыр эчәгенә операция ясатканы бар, шуңа үзенең кайда эләгүен тиз аңлады. Түшәмгә эленгән прожекторлардан төшкән яшькелт-зәңгәрсу яктылык та аңа яхшы таныш. Ул, гадәттә, операция өстәле өстендә була. Монда да өстәл тирәли ак халатлылар тезелешеп баскан, ара-тирә сүз әйтешеп алалар, күнегелгән төгәл хәрәкәтләр белән нәрсәдер эшлиләр. Өстәлдә яткан кешенең йөзе каплаулы, пөхтә итеп җыеп куелса да, озынлыгы беленеп торган куе чәчләре генә аның хатын-кыз икәнен чамалау мөмкинлеге бирә. Кем ул? Ниндидер таныш чалымнары бар кебек тә тоела, шул ук вакытта кемлеген төгәл генә билгеләп тә булмый. Табиблар соклангыч бер ярашканлык белән хәрәкәт итәләр. Читтән караганда, аларның бу хәрәкәте биюне дә хәтерләткән кебек.

Монда ничек килеп эләкте соң хатын? Гадәттә, операция бүлмәсенә чит кешеләрне кертмиләр бит. Димәк, ул чит түгел. Операция өстәлендә ятучы хатын аның берәр туганы микәнни? Әнисеме? Юктыр... Әнисе инде күптән гүр иясе, үзенең дә, иренең дә кыз туганнары булмады... Хәтта андый якыннары булган хәлдә дә, аны операция бүлмәсенә кертмәсләр иде. Ничек килеп эләкте соң әле...

– Гафу итегез... – Айгөл үз тавышыннан үзе сискәнеп китте. Итагатьле итеп, йомшак кына сорарга теләгән иде. Тавышы бик көчле килеп чыкты. Ул тамак кырып алды да тагын кабатлады: – Гафу итегез, мин ничек...

Һәм көтмәгәндә башына суккан уйдан һушына килеп туктап калды. Монда нәрсәдер дөрес түгел иде. Аның бая гына хәтта үзен сискәндерерлек дәрәҗәдә кычкырып әйткән сүзен беркем дә ишетмәде. Хәтта бөтен игътибарларын авыруга юнәлткән хәлдә дә аның тавышы эзсез үтәргә тиеш түгел иде. Бер тын уйланып торды да табиблар янынарак үтте. «Якынрак килеп карасам, бәлки өстәлдә ятучының кем икәнен дә чамалап булыр...» – дип уйлады ул. Түргә узганда, стенадагы көзгегә күзе төште дә тагын туктап калды. Керфекләрен ачып-йомып алды. Ләкин күренеш үзгәрмәде. Ул көзгедә күренми иде.

– Минсиңайти-и-им! – дип, күзләрен шарландырды ул бу көтелмәгән хәлдән. – Нәрсә соң бу? Төш кенәдер бәлки.

Нәрсә генә булса да, бу чынбарлык түгел инде. Кычкырып әйтелгән тавышыңны да ишетмәсеннәр, көзгедә үзеңне үзең дә күрә алма... Могҗиза бу ниндидер.

Ул арада ак халатлыларны хәрәкәте җанланыбрак китте. Табибларның

берсе өстәлдәге хатын эченнән нәрсәдер тартып алып өскәрәк күтәрде. Сабый бала! Табиблар бер мизгелгә, карашларын шунда төбәп катып калды. Кинәт аларның өстеннән күзгә күренмәс бер көч узды да барысының да күзләрен моңсулыкка манды, йөзләренә сагыш, хәрәкәтләренә сүлпәнлек өстәде.

– Ул җансыз, – дип пышылдады сабыйны күтәргән табиб һәм аны якындагы өстәлләрнең берсенә салды. – Аппаратны тоташтырыгыз...

Берничә табиб сабый яткан өстәл янына күчте. Берсе балага кислород битлеге кидерде, икенчесе, кулларын капшап, укол ясарга җыена башлады, өченчесе күкрәгенә кечкенә тәлинкә сыман нәрсә куйды. Ул арада күрше өстәлдә яткан хатынның битен каплап торган челтәрсыман япма бераз ачылып китте. Айгөл аны күреп катып калды. Операция өстәлендә яткан хатын Айгөл үзе иде. Моңа хатын артык гаҗәпләнмәде, үзе бик ышанырга теләмәсә дә, күңеленеңме-аңыныңмы кайсыдыр өлеше белән ул хәлләрнең нәкъ шулай булырга тиешлеген сизенгән иде бугай. Бәлки, гаҗәпләнерлек вакыты да булмагандыр. Бала дөньяга күренү белән ак халатлылар ояларына таяк тыгылган кырмыскалар хәленә килеп кайнашырга тотынды. Аларның бер өлеше сабый яткан өстәлдә мәш килсә, икенчеләре Айгөлнең гәүдәсенә ябыштылар.

Ә бала... Аның баласы... Бу хакта уйлау белән ниндидер сәер тойгы уянды. Үкенүме соң инде ул, әрнүме, газапмы... Алай да түгел бугай. Ни икәнен дә аңлап булмый торган бер халәт инде шунда, авыр, караңгы халәт. Яктылык, нур белән тулган дөньяны буа, томалый торган. Әмма моның ни икәнен ачыклап өлгерә алмады, ниндидер зур якты йомгак пәйда булды да Айгөлне ияртеп алып китте. Аңа берничек тә карышырлык түгел иде.

## 14

Айгөл, уянгач та, күзләрен ачарга куркып ятты. Ул үзенең палатада ялгыз үрсәләнеп яткан вакытын да, операция бүлмәсендәге сәяхәтен дә хәтерли, әмма аларның кайсы – төш, ә кайсы өн икәнен аера алмый һәм нинди чынбарлыкта уянып китәчәген белми иде. Тик болай яту берни дә бирмәде: башы юньләп эшләми, ә тирә-якта – шома тынлык, уйлары эләгеп тернәкләнеп китәрлек бернәрсә дә юк иде. Ул күзләрен ачты. Хастаханә палатасының ак түшәмен күрүгә, борынына дару исе килеп бәрелгәндәй булды. Караватт янындагы урындыкта утырган ак халатлы ханым торып басты да Айгөлнең иреннәрен юеш марля белән чылатып алды. Айгөл иреннәрен ялап куйды. Тамагы бик кипкән икән, йотлыгып-йотлыгып су эчәсе килә. Әмма ак халатлы ханым калаклап кына бирде.

– Әлегә җитеп торыр, – диде ул елмаюлы тавыш белән. – Бераздан тагын эчәрсең.

Айгөл баш какты. Түшәмгә текәлеп, уйларын тәртипкә китерергә тырышты. Хастаханә... Авыртуга түзәлмичә бәргәләнү... Операция бүлмәсе... Өстәлдә яткан хатын... Кинәт ул, нәрсәнедер исенә төшереп, ике кулы белән эчен капшап карарга теләде. Тик берни дә килеп чыкмады, куллары бәйле иде. Ычкынырга теләп тартышканда, аякларының да бәйдә икәнен аңлады, аларны азат итәргә теләп тыпырчынудан эчендә тупас авырту хасил булды.

– Тынычлан, кызым, тынычлан... – дип, аның иңенә кагылды ак халатлы ханым. – Тулысынча айнып җиткәч, аяк-кулларыңны чишәрләр.

Айгөл шикле карашын аңа төбәде. Күз төбендәге җыерчыкларга, чигә чәчләренең аклыгына караганда, бу ханым чынлап та өлкән яшьтә һәм Айгөлгә «балам» дип әйтерлеге бар иде. Зәңгәрсу күзләрендә дәү әниләрнекендәгечә кайгыртучанлык, назлы якты нур. Әнә шул карашлар хатынны беркадәр тынычландыргандай булды, тик шундук диярлек ул башын күтәреп, күзләрен аска төбәде. Бер мизгелгә катып калды. Агарынып китте. Күзләрендә ачы газап катыш чиксез нәфрәт пәйда булды. Йөзләре тартышты. Һәм хатын җанөзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Балам!

Аның тавышы тәрәзә пыялаларын зыңлатып торды, кечкенә күзәнәкләргә әверелеп, стеналарны тишеп чыкты һәм бөтен җир өстенә таралды, күкләргә күтәрелде, йолдызларны сискәндереп, дерт-мерт килеп җемелдәргә мәҗбүр итеп, бөтен галәмгә таралды:

– Кайда минем балам! Балам кайда?

Барлык галәм бер мизгелгә калтыранып куйды, бөтен дөньяны телеп, әрнү дулкыны узды. Күкләр күкрәде, җирләр тетрәде, дулкыннар аягүрә басты. Һәм баласын җуйган ананың иңрәү авазы ишетелде:

– Кайда минем балам? Кемнәр алды?

Күкләрдән җавап булмады. Кояш болыт арасына качты, йолдызлар күзен яшерде. Яшеннәр ялгыз аккош сыман җиргә ташландылар. Ачы җилләр кыяларга бәрелеп шуып төште. Баласын җуйган ана авазы бар галәмне тетрәндереп тибрәнде дә, хәлсезләнеп калган дулкын сыман, үз ярларына барып егылды һәм күз яшьләре сыман тын һәм ачы агым булып кабатланды:

– Балам?

Бу инде баягыдай гайрәтле дулкын түгел иде. Анда сабыйларча гаҗәпләнү, аптырау һәм язмышның шундый гаделсез була алуына ышанырга теләмәү тойгылары чагылды. Ничек шулай мөмкин инде? Әле генә карынында тибенеп яткан сабый дөньяга туарга да өлгермичә юкка чыгарга тиешмени? Тудырганчы ук тартып алырлык булгач, ник яралттың да ник аның назлы хәрәкәтләрен карында тою мөмкинлеге бирдең?

– Түз инде, кызым... Түз... – дип кытыршы бармаклары белән Айгөлнең маңгаеннан сыйпады ак халатлы ханым. – Безгә сабырлыктан башка чара юктыр инде. Түз, балакаем... Ела да түз...

Аның үзенең дә куллары калтырана, дерелдәп торган керфек очларыннан агып төшкән тасмалар яңаклары буйлап агып төшкән иде. Юеш эзләр хәтта битлек аша да күренеп тора. Хәер, күз яшьләрен битлек кенә каплый аламыни инде.

– Түз инде, балакаем... – дип такмаклады ул, пышылдауга күчеп. – Сабыр булырга тырыш. Исән-имин терел. Аякка бас... Вакыт барысын да бераз дәвалый ул. Күңел сызлануларын баса. Баса...

Карчыкның тавышы калтыранып китте. Ул бер мәлгә тынып торды да, тамагындагы төерне йотып куйгач, дәвам итте:

– Әрнүләре үтмәсләнсә дә, җөе кала инде аның... Күзне каплаган яра кебек булып кала. Кайда гына карасаң да, шул яра аша карыйсың. Шул яра аша күрәсең.

Ул авыр сулап куйды.

– Минем кызымның авыры да нәкъ синеке кебек иде. Нәкъ синең кебек,

балам. Әмма аның хәле аз гына башкачарак булып чыкты... Сабыйны саклап алып калдылар, кызымны коткара алмадылар. Оныгыбыз ятим булып туды...

Карчык дымлы керфекләрен кул аркасы белән сөртеп алды да дәвам итте:

– Кызыбыз өчен кайгырсак та, оныгыбыз өчен шатланган булдык инде. Аның дәвамы кала дип юандык. Тик алты ай да узмады, сабый чиргә уралды. Елый да елый. Сызлана. Тынгылык тапмый, бәләкәчем. Табиблар күпме генә тикшерсәләр дә, чирен ачыклый алмадылар. Бер дәва да ярдәм итмәде. Тагы шулай алты ай чамасы тәмуг эчендә яшәде сабый. Аннан җан бирде.

Карчык тагын тынып калды. Күзләрен сөртеп алды. Битлеген төзәтеп куйды.

– Бу зәхмәтле чир эчендә туган балаларның бик күбесе шундый хәлгә юлыга икән. Монысын соңыннан белдек. Шуңа күрә... Ходайның ниятләрен адәми зат аңламый да кала күп вакытта. Син дә, балам, артык бетеренмә. Үзеңне сакла. Исән-сау котылсаң, барысы да булыр әле. Синең әле барысы да алда.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, ул Айгөлнең авызына калаклап кына су каптырды. Аннан соң чынаяклап эчерде. Айгөл елавыннан туктады. Карашларын палатаның ак түшәменә төбәп тынып калды. Ак халатлы ханым аны бераз күзәтеп торды да кул-аякларын бәйдән ычкындырды.

– Кисәк хәрәкәтләр ясамаска тырыш, балам, – диде ул, дәү әниләрчә итеп. – Карыныңда яра бар. Ертылып китмәсен.

Айгөл аңа карап баш какты.

– Рәхмәт сезгә, апа! – Хатын аның учларын үз учларына йомды. – Рәхәт сезнең белән...

Карчык аның учларын назлы гына кысып алды да:

– Рәхмәт, балам, үзеңә дә. Миңа да рәхәт синең яныңда, – дип елмайды һәм җитдиләнеп дәвам итте: – Шулай булырга тиештер дә ул. Кешеләргә бер-берсе белән һәрвакыт рәхәт булырга тиештер. Әнә шул хис кешелекнең тарту көчен арттырадыр. Югыйсә тормышның тигезлеге югала бит, һәркем үз эченә бикләнә, үзе бер дөнья кебек яши башлый. Әгәр шулай кирәк булса, Ходай бәндәләрне ташбака кыяфәтендә итеп яралткан булыр иде. Һәрберсе үз кабыгына бикләнеп яшәсен өчен.

Ташбака кыяфәтендәге кешеләрне күз алдына китерүдән Айгөл елмаеп куйды. Бу аның соңгы араларда беренче елмаюы иде. Баласын югалткач... Баласын югалткан ана елмаерга тиеш түгел... Айгөл үз елмаюыннан кыенсынып куйды.

– Газапларын да бирә шул...

Карчык иңнәрен сикертте:

– Кем белә инде, балам... Бәлки, бу бер газапны икенчесе белән алыштыру гынадыр. Кызымның сабыен... Оныгымның ничек интегүләрен сөйләдем бит әле. Сүздә генә аңлатып булмый инде аны. Үзе кичергән кеше генә белә. Сабый елавы иң авыр чир шикелле бит ул, җаныңның бөтен сызлануларын актарып чыгара...

Ул бер мизгелгә тукталып торды. Тирән сулап куйды. Айгөлгә күз салып торды һәм, хатынның сүз йомгагын көтүен күреп, дәвам итте:

– Менә син баламны югалттым дип кайгырасың. Газапланасың. Бәлки Ходай аны бу дөньяда күрергә тиешле газапларыннан коткаргандыр. Аны

минем оныгым кебек интегүләрдән саклап калгандыр ул бәлки. Шул газапларның бер өлешен алып, сиңа биргәндер. Шул хакта да уйлап кара әле син.

Айгөл ни дип җавап бирергә дә белмәде, көрсенеп кенә куйды:

– И апа...

Карчык аның учын сыпырды:

– Ничек кенә авыр тоелмасын, киткән артыннан китә алмыйсың икән. Алай ярамый да. Үзе биргән Ходай гомерне, үзе ала. Шул гомерне өзәргә омтылу да, кара кайгыга батыру да гөнаһ булыр иде. Хәтта канәгатьсезлек белдерү дә гөнаһ. Ходай биргән бүләктән йөз чөергән сыман. Фетнә!

Карчыкның бу сүзләрен тыңлаганда, Айгөл ни өчендер Глүсәне исенә төшерде. Ул да баласын югалткан бит инде. Тик ул рух ныклыгын һәм өметен, димәк, киләчәген югалтмаган. Һәм ул, үзе дә сизмәстән карчыкның кулларын кысып, теге сүзне пышылдады:

– Төшенкелеккә бирелергә ярамый... Бирелергә ярамый...

**15**

Карчык белән аралашып, бераз һушына килгәч, доктор керде. Ул ярыйсы ук йончу иде, гәүдәсе дә тишелеп, тыны чыккан туп шикелле хәлсезләнеп калган, күзләрендә тирән сагыш, үкенү. Айгөл, аның операция бүлмәсендәге вакытын искә төшереп, кызганып куйды. Югалтуны табиблар да авыр кичерә торгандыр инде. Аларга да җиңел түгелдер.

– Авырткан җирегез юкмы? – диде табиб, хатынның күзләренә туры карамаска тырышып. – Үзегезне ничек хис итәсез?

Акылы белән барысын да аңлап торса да, Айгөлнең күңелендә бер мизгелгә давыл купты. Үзегезне ничек хис итәсез, имеш... Ә баласын җуйган ана үзен ничек тоярга тиеш? Ул хисләрен йөгәнләргә тырышты.

– Ә сез... – Сүзләре барыбер гаепләү карары сыман теш арасыннан сыгылып чыкты. – Сез үзегезне ничек хис итәсез?

Тынычланырга кирәк. Үз баласын коткарып калырга теләгәндәй, җан аямый тырышты бит инде табиб. Хәтта сабыйның үле туганын белгән килеш тә аңа җан кертергә тырышып маташтылар. Алар шулай көч түкмәсә, бәлки, Айгөл үзе дә исән кала алмас иде. Теге дөньяга китеп беткән иде бит, шушы кешеләр аны кире кайтарды.

– Кызганыч... – Табиб ни әйтергә теләгәнен оныткандай тотлыгып калды. – Баланы без...

– Кирәкми. Сөйләмәгез! – дип кырт кисте Айгөл һәм, үз тавышының рәхимсезлеген тоеп, тын калды. Хисләрен йөгәнләргә тырышты. Киеренкелекне киметергә теләгәндәй, тамагын кырып куйды. – Мин беләм. Барысын да күреп тордым.

Табиб аңа аптыраулы караш ташлады:

– Нәрсә?

– Барысын да күрдем, – дип дәвам итте хатын, беркадәр тынычланып. – Сабыйны алганда, йөземне каплаган челтәрсыман япманың шуып төшүен дә... Баланы аерым өстәлгә салып, җан өрергә тырышуыгызны да... Барысын да.

Гаҗәпләнүдән табибның күзләре түгәрәкләнгәндәй булды:

– Ничек?

– Мин шунда идем, – дип дәвам итте Айгөл. – Шунда, аңлыйсызмы?

Доктор ишеткәннәрен аңына сеңдерә алмыйча, беркадәр исәнгерәп торды да башын кагып куйды:

– Ярый... Ярый, димәк, сез беләсез... – Ул авыр сулады. – Үзегезнең хәлегез... Бүген сезнең гомерегезгә куркыныч янамый дип әйтергә мөмкин. Анализларыгыз начар түгел. Тиздән аякка басачаксыз.

Айгөл башкача берни дә дәшмәде. Баш кагып кына торды. Авызын ачса, хисләренә ирек куяр да табибны рәнҗетер шикелле тоелды. Доктор да дулкынлана иде, артыгын сөйләнеп тормады, берничә соравына җавап алды да чыгып китте.

Аннан соң хатын телефонын алып, Илдарның номерын җыйды. Башта видеосөйләшүдән чакырды. Ирен күрү теләге зур иде. Күрү генә түгел, иңнәренә башын салып йә күкрәгенә капланып үксеп-үксеп елау теләге... Тик җавап бирүче булмады. Аудиочакыруга да җавап бирмәделәр. Башта бераз үртәлсә дә, Айгөл ахырда моңа сөенеп кенә куйды. Ни генә әйтсәң дә, Илдар ял йортында түгел, диңгез буенда кызынып ятмый. Авыру иреңнең күзләренә карап, авыр хәбәр җиткерү бик газап булыр иде.

Беркадәр уйланып торды да ул ватсап аша хат кына язып салды:

«Илдар, бәгърем... Кайгылы хәбәрем өчен, зинһар, ачуланма. Үз хәлең авыр вакытта мондый хәбәрне ишетү җиңел булмаячагын белсәм дә, әйтмичә кала алмыйм. Тик син нык булырга тырыш. Төшенкелеккә бирелмә. Бер-беребезгә таяныч булып яшик. Хәзер без икәү генә калдык бит. Улыбыз үле туды».

Илдардан җавап килмәсме дип, әледән-әле телефонына күз салып торса да, бер хәбәр дә булмады. Бу халәт бераздан Айгөлнең күңелендә шик уята башлады. Ире баланың үлемендә аны гаеплидер кебек тоелды. Теге вакытта иkenең берсен сайлау турында әйткән иде шул. Әйтәсе калмаган икән. Хәзер ул «Үзе исән калыр өчен балабызны корбан иткән» дип уйларга да мөмкин бит. Их...

Бер яклап, шулай борчылса, икенчедән, иренең сәламәтлеге начараеп китүдән курыкты. Хәтта ачуланса да, нәфрәтеннән кара көйсә дә, дәшмичә калмас иде ул. Шалтыратыр, тиргәр, бөтен ярсуын чыгарыр иде. Илдар, әлбәттә, ярсыдым дип, әллә ниләр әйтә торган кеше түгел. Ләкин ул дәшмичә калмас иде. Димәк, хәле бик яхшыдан түгел. Исән генә булсын инде берүк. Исән генә булсын. Аны да югалтса, Айгөл ничек яшәр... Алла гына сакласын. Берүк сакласын гына...

Төрле уйлар арасында бәргәләнү җиңел түгел иде. Ярый әле, чире бераз тынычланып калган кебек булды. Сызланулар да изсә, авыр тойгылар да җаныңны таласа, барсына берьюлы чыдау бик авырга төшәр иде. Әле дә Айгөл үз-үзенә урын табалмады. Шул рәвешле хәтсез генә бәргәләнгәч, ниһаять, Илдардан хат килеп төште.

«Айгөл, җаным, безнең өчен зур кайгы инде бу. Авыр югалту. Тиз генә җавап та яза алмадым, ни генә дип әйтсәм дә, ялгыш булыр төсле тоелды. Бу кайгыга без барыбер түзәргә тиеш инде. Бала кайгысы, ул үле туса да, тугач үлсә дә, бер ата-анага да җиңел түгел. Киткән артыннан китеп булмый. Бирешмик, җаным. Син дә төшенкелеккә бирелмәскә, нык булырга

тырыш. Үзеңне сакла. Мин сине яратам. Син – минем бердәнберем. Без әлегә икәү генә. Бер-беребезгә таяныч булыйк. Савыгып чыккач, чын тормыш башланыр. Без анда бер-беребезнең дә, тормышның да кадерен белеп яшәрбез. Безнең әле барысы да алда».

Бу сүзләрне Айгөл кабат-кабат укыды. Ул инде үз-үзен гаепләп, иренә ышанычын югалта башлаган иде. Әле күзләре яшьләнде, үзен иренә дә, дөньяга да кирәкле зат итеп тойды. Илдар аның җан яры да, җил-яңгырлардан саклар кальгасы да. Шундый кешең барында тормыштан өмет өзәргә, төшенкелеккә бирелергә ярамый. Бер-береңнең һәм һәр мизгелнең кадерен белеп яшәргә дә яшәргә әле. Ә күңел газаплары, тән сызланулары – барысы да вакытлыча. Алар бер узачак.

Беркадәр вакыттан соң Илдар тагын бер хәбәр җибәрде. «Җаным, мине хәзер нык итеп дәвалый башладылар. Процедуралар бик күп. Телефонны гел үзем белән йөртә алмыйм. Җавап килми торса, борчылма. Үзем хәбәр бирермен. Мин сине яратам!»

Болай дип алдан кисәтеп куюы әйбәт булды. Югыйсә Айгөл борчылып торыр, төрле шикләргә төшәр, авыр уйларга бирелер иде. Иреннән ни өчен хәбәр юк икәнен алдан белеп торгач, борчулары бөтенләй үк юкка чыкмаса да, Айгөл тынычлыгын җуймады.

Үзенең дә буш вакытын бик калдырмадылар. Әле анда, әле монда йөртеп дәваладылар. Торым-торымга уколлар кадап, система куеп тордылар. Шулар тәэсире булдымы, авыртулары бераз басылгандай тоелды. Әледән-әле йокы басты. Уйлары да, хисләре дә ялкаулаңыбрак калгандай итте. Кайчакларда үзенең бу халәте беркадәр сагайтса да, әрнү-сызланулардан котыла баруын тою җиңеллек бирә иде. Ә бу бик мөһим – киләчәгеңә өмет белән карарга булышлык итә, менә шушы авырлыкларны җиңеп чыккач, адәмчә тормыш башланырын вәгъдә итә, яшәү көче бирә.

## 16

Баласын югалтканнан соң, Айгөлгә тынычландыра торган уколлар ясый башладылар бугай. Сызланулары басылды, күңеле дә җилсез көндәге тирән күл сыман тынып калды. Уйлары сүлпәнләнде, ул үткәннәрендә казынмады, киләчәкне колачларга тырышып та чәбәләнмәде. Хатын тынычлык дөньясында тибрәнде. Хәтта телефонын да актарып карамады. Кемгәдер шалтыратырга яки язышырга да теләге булмады. Үзен кызыксындырган шикелле тоелган язмаларны укый башласа, берничә минуттан ук күзләре йомылды, йокы басты. Китап, гәзит-журналлар да гел йоклата торганга әйләнде. Айгөл тулысы белән диярлек йокы патшалыгында иде.

Хәтта үпкәсен җилләткән вакытларда да артык авырту тоймады. Югыйсә элек бу процедура бик газаплы тоела, үпкәсе эчендә ниндидер күзгә күренмәс кеше тын юлларын каты себерке белән себереп йөридер кебек була иде. Зур гәүдәле, көчле һәм тупас кеше. Хәтта кеше дә түгел, ә дию пәрие. Башта себеркесе белән бөтен дөньяңны тигезләп, Убырлы карчык үтә, аның артыннан стеналарга ут сиптерә-сиптерә, Дию уза. Хәтта алар эшен бетереп юкка чыкканнан соң да тын юлларындагы утлы әрнү озак дәвам итә. Сулыш алган саен ялкыннары яңа көч белән дөрләп киткәндәй була. Әрнетә.

Хәзер алай булмады. Авырту-сызланулар кайдадыр еракта,

тынычландыручы дарулар артында калды. Шул дарулар аша үтеп керә алмагач, алар Айгөлне бик интектермәде. Кемнеңдер ихата чистартканын тәрәзә аша карап торган сыман гына иде.

Гомумән, Айгөлнең бөтен тормышы тәрәзә аша күзәтү кебек булды. Ул бернигә дә катнашмады, берни дә эшләмәде, бары тик тормыш агышын күзәтеп кенә торды. Бу күңелсез һәм ялыктыргыч гамәлдән тиз арып, йокыга талды. Бераздан уянды да тагын күзәтергә тотынды. Бернинди үзгәреш тә юк, уйларың-хисләрең эләгеп китәрлек бер күренеш тә табылмый. Ә бертөрлелек тагын арыта һәм йокы куенына этәрә...

Кабат үз палатасына кайткач та, әллә ни үзгәреш булмады. Элекке танышлары инде чыгып киткәнме, башка җиргә күчерелгәнме, алар юк иде. Айгөл сорашмады. Яңа килгән авырулар белән танышты бугай инде ул. Тик исемнәрен шундук онытты, кабаттан сорарга кыенсынды. Йокы илендә һәм яңа күршеләренең хәле дә, үзләре дә, сүзләре дә кызык түгел иде. Бу зәхмәтле чир кешенең ис сизү, тәм тою кебек сәләтләрен ала. Айгөл дә кичерде андый халәтне. Ә менә хәзер аның авыруы тирәнгәрәк керде дә тормыш тәмен тою сәләтен тартып алды. Аның өчен бернәрсә дә кызык түгел иде. Хатын моңа артык борчылмады. Бары тик авырту-сызланулар һәм күңел газаплары гына кире кайтмасын. Иң куркытканы менә шулар иде.

Хәле арулана барды. Бераздан аның үпкәсен җилләтүдән туктадылар. Кислород битлеген генә салмаска куштылар. Монысы инде күнегелгән нәрсә, бер кыенлыгы да юк иде. Тагын күпмедер вакыттан соң, битлек киюне дә үз иркенә куйдылар. Эчендәге операция эзе дә төзәлә бара иде бугай, һәрхәлдә авыртуы артык сизелмәде. Менә шулай әкеренләп кенә ул тормышка кайта башлады. Сулыш алу күнегүләре ясарга өйрәттеләр. Айгөл аны җиренә җиткерергә тырышып, көненә әллә ничәшәр тапкыр ясады. Бераздан тын юллары ачылуын үзе үк тоя башлады.

Аңын һәм хисләрен томалаучы даруларны да азайттылар бугай. Хәзер инде авыр процедуралар артта калды һәм андый нәрсәләргә мохтаҗлыгы бетте. Шулай да аңы тулысынча ачылып җитмәде бугай. Бу хакта сорашкач, табиб:

– Борчылмагыз, акрынлап кына, барысы да үз җаена кайтыр, – дип тынычландырды. – Тиз генә булмас, әлбәттә. Ләкин атна-ун көннән барысы да җайлана төшәр. Әлегә түзәргә һәм тынычлыкны югалтмаска гына кирәк.

Айгөл аңа ышанды. Сызланулардан, сулыш ала алмыйча интегүләрдән, күңел газапларыннан котылу үзе дә бик зур нәрсә иде.

Фикер таркаулыгы көчле иде. Хәтта Илдарны да онытып җибәрде ул. Бөтенләй үк онытмады инде, тик аның өчен борчылулары, хәлен белешү, аралашу теләге әллә кая еракка качты. Бары тик хастаханәдән чыгасы көнне генә аңа шалтыратты. Тик трубканы алучы булмады. Хәлен белешеп, хат язып җибәрде. Берничә сәгать буена көтсә дә, җавап килмәде. Кайдадыр еракта, күңеленең хисләр барып җитәлмәслек урынында давыл уйнаганы сизелде, әмма ерактагы ул давыл хатынның җанын өзгәли алмады. Чыгаралар бит хастаханәдән. Йә үзе Илдар янына барып килер, янына кертмәсәләр, табибын күреп сөйләшер. Хәзер ул чирдән котылган, сәламәтләнеп килүче кеше, иренең хәлен яхшыртуның берәр әмәлен тапмыйча калмас.

Якыннарының барысы да диярлек буш түгел иде. Кайсылары эштә йөри, кайсылары шушы чир белән хастаханәдә ята. Шуңа Айгөл аларның берсен

дә борчырга теләмәде. Хәзер барысы да җайлы. Такси чакыртасың да, ул сине кая кирәк, шунда илтеп куя. Бернинди мәшәкате юк. Айгөл дә өенә таксида гына кайтты. Әйберләре хәтсез генә җыелган, сумкалары авыр гына. Ләкин подъезд төбеннән лифтка кадәр ара якын иде. Шулай да хатын, машинадан төшкәч, бераз югалып калгандай булды. Саф һава! Аның инде ничә көннәр буена урам һавасын сулаганы юк икән бит. Бу үзе үк дәваның бер төре шикелле иде. Айгөл ләззәтләнеп, күкрәк тутырып, сулыш алды. Тын юллары өчен күнегүләр ясады. Тәннәре җиңеләеп, зиһене ачылып киткәндәй булды. Күзләрне камаштырырлык аклык. Хастаханәнең саргылт төстәге таш стеналарына озак вакытлар буе карап ятканнан соң урамдагы төсләр үзе бер тылсым шикелле була икән. Иркенлек. Айгөл хәзер кая теләсә, шунда бара ала, дүрт ягы – кыйбла. Ул ирекле.

Сумкаларының авырлыгын да онытып, озак кына шулай басып торды да ишеккә атлады. Больница коридорларында йөргәндә, адымнары ныклы шикелле иде, әле менә буыннарының йомшап китүен, аякларының чалшаеп-чалшаеп алуын тойды. Ярар, ныгыр әле. Хастаханәдән чыкканда, шулай була инде ул. Айгөл дә бераздан, җир хуҗасы булып, каты басып йөри башлар.

Фатирына кергәч, сумкаларын идәнгә куйды да ишек төбендә туктап калды. Бәлки Илдар кайткандыр инде дигән өмете бар иде. Аны чәй куеп, тәм-томнар әзерләп көтеп торадыр. Хатыны ишектән керү белән колачларын җәеп килер дә: «Бердәнберем минем, кайттыңмы?» – дип кочаклап алыр. Мондый хәлнең булуы мөмкин түгеллеген акылы белән аңласа да, күңеле нидер көтә иде. Әмма аны тынлыкка чумган фатир каршылады. Салкын, шомлы тынлык иде бу. Колакларны чыңлатып, сөякләреңә кадәр үтеп керә торган әрсез һәм аяусыз тынлык. Башка вакытларда бер дә болай булмый торган иде. Фатирына кайтып керү белән ниндидер якты нур, җылылык чолгап ала. Әниләр куенындай назлы ягымлылык күңеләңне иркәли. Үзеңне хәвефсез тоясың, иң ышанычлы җирдә икәнеңне тоюдан җаның ирекә чыга, иркәләнә. Ә бүген... Бу да бәлки теге зәхмәтле чирнең бер гыйлләседер. Әллә дарулар белән томаланган аңның тупасланып калуы сәбәпчеме? Ни генә булса да, бу күңелгә шом өсти торган күренеш иде. Шуңа да Айгөлнең беренче уе фатирдан чыгып качу булды. Әле монда туганнары бар. Аларга барып торырга була. Ләкин ишек тоткасына үрелгәч, ниндидер тойгы кире борылырга мәҗбүр итте. Бала-чага кебек болай кыланырга ярамый. Бу хакта берәрсе белсә, акылыннан шашкан икән дип уйларга да мөмкин. Алла сакласын.

Айгөл өске киемнәрен салып, шкафка элде дә кухняга узды. Бүлмәдә тәртип булса да, бер нәрсә дә ул калдырып киткәнчә түгел иде. Монда кемдер булган, аш-су әзерләгән һәм барысын да үз тәртибе белән җыештырып куйган. Йә хәйран... Хәтта тәрәзә пәрдәләре дә бүтәнчә эленгән. Ир-ат болай кыланып йөри белми инде. Хатын-кыз кулы сизелә монда. Айгөл чәйнекне чайкатып, су җыйды да плитә өстенә куеп кабызып җибәрде. Аннан соң залга узды. Монда да ишек төбендә үк тукталып калды. Бөтен нәрсә үзгәргән, диван җәймәләрен дә, тәрәзә пәрдәләрен дә, башка чүпрәк-чапракны да алыштырганнар. Димәк, аның пәрдәдер, җәймәдер саклый торган шкафында да актарынганнар булып чыга. Йокы бүлмәсе дә танырлык түгел иде. Айгөл хәтта үзгәрешләрне барлап та тормады, күз генә салды да, ишекне ябып, кабат залга узды.

Илдарга шалттыратты. Ниләр булганын белсә, тик ул гына белергә мөмкин иде. Тик ире трубканы алмады. Чакыруны тыңлап, җавап көтеп торганда, Айгөл ниндидер ят тавышка игътибар итте. Пыяла арасына эләгеп бәргәләнгән чебен кебек зерелди торган тавыш иде бу. Шкаф ягыннан килә. Айгөл урыныннан торып, шул якка атлады. Кинәт тавыш тынып калды. Айгөл дә туктады. Иренең телефонын кабат җыйды. Бераздан теге тавыш тагын ишетелде. Бу юлы Айгөл эшнең нидә икәнен шундук аңлады һәм дулкынланудан, гаҗәпләнүдән күзләре акаеп чыкты, йөрәк тибеше ешаеп китте.

Шкафның шүрлегендә Илдарның телефоны ята иде. Айгөл шалтыраткач, ул, дерелдәп, шундый тавыш чыгара. Тукта! Нишләп аның телефоны монда булырга тиеш соң әле? Димәк, ул хастаханәдән чыккан. Терелеп чыккан. Тик нигә ул Айгөл янына килмәгән соң? Берәр кәнфит алып килсә дә: «Ирең килде, сиңа сәлам әйтте», – дип, Айгөлгә тапшырырлар иде бит. Ә ул... Ул хәтта шалтыратмады да. Язмады да. Хәтта Айгөлнең хәбәренә дә җавап бирмәде. Димәк, ул Айгөлгә нык рәнҗегән. Баласын саклый алмаган өчен...

Һәм кинәт Айгөл фатирның үзгәрүен, анда хатын-кыз кулы сизелүен исенә төшерде дә дертләп китте. Хатыны хастаханәдә ятканда ул, бәлки монда бүтән хатын-кыз алып кайткандыр. Югыйсә мондый үзгәрешләрне ничек аңлатырга була? Ирләргә ышанырга ярамый дигән сүзләрне ахирәтләреннән еш ишеткәне бар. Хәзерге хәл менә шул сүзләрнең дөреслеген дәлилләгән кебек тоелды.

Тик Айгөл бу уйларының дөреслектән ерак икәнен сизә иде. Илдар андый түгел. Хәтта Айгөлгә ачуланып аерылышырга яки бүтән хатын-кызга өйләнергә теләсә дә, ул болай итмәс иде. Башкача эшләр иде ул. Айгөле тулысынча савыгып аякка басканчы бернәрсә дә сиздермәс иде хәтта. Юк, болай дию дә дөрес түгел. Аның Илдары беркайчан да башкаларга күз салмас, хатынының хәлен аңлар һәм аңа таяныч булырга тырышыр иде. Илдар аңа беркайчан да хыянәт итмәс иде. Ире бу хакта теле белән сирәк әйтсә дә, Айгөл аның мәхәббәтен тоя, ул сөюнең сафлыгына тулысынча ышана. Нәрсәдер булган. Тик нәрсә?

Туганнарның берәрсенә шалтыратып, хәлне сорашырга кирәк иде. Айгөл аларны күңеленнән генә барлап чыкты да Илдарның сеңлесенә эндәшергә булды. Зәлифә ничектер якынрак иде. Ешрак та аралашалар, үзе дә абый да җиңги дип кенә тора. Эштәдер инде ул, тик барыбер хастаханәдән чыккан җиңгәсе белән сөйләшергә өч минут кына вакыт таба алыр әле. Бәлки Илдарның телефоныннан шалтыратыргадыр? Юк инде... Ләкин шкаф шүрлегендә яткан телефон аны ничектер үзенә тарта иде. Айгөл аны кулына алырга, тотып карарга берничә тапкыр укталып куйды да тыелып калды, йә уйлары башка нәрсәгә юнәлде. Менә хәзер тыелгысыз көч аны аркасыннан этәреп дигәндәй, телефон янына алып килде. Тотып кына түгел, актарынып карарга кирәк. Бәлки Илдар кемнәр беләндер язышкандыр, Айгөлнең сорауларына җаваплар шушы телефондадыр кебек тоелды.

Хатын телефонны шудыруга аның астындагы бер бит кәгазь идәнгә төшеп китте. Телефон төймәләренә баскалый башлауга теге кәгазь игътибарын тартты. Хатын-кыз кызыксынуы тыелгысыз көч икән, аны берничек тә туктатып булмый. Ләкин Айгөл үзен җиңәргә тырышты. Менә Илдарның Зәлифә белән ватсап аша язышкан бүлеге. Кыска-кыска язулар...

Айгөл сүзләр күбрәк булганына тукталды. Укый башлады.

«Хәлем начарлана, сеңлем. Ничек булып бетәрен төгәл генә әйтә алмыйм. Әгәр бер-бер хәвефле хәл булса, зинһар, бу хакта Айгөлгә әйтмәгез. Борчылмасын. Савыгып чыккач кына әйтерсез. Тик аңа кадәр берни дә сиздермәгез».

Айгөл үзе дә сизмәстән, идәндәге кәгазьгә карап алды. Иелергә омтылды. Ләкин күзләре кабат экрандагы хәрефләргә кайтты. Зәлифә аңа җавап итеп юату сүзләре язган. Тора-бара Илдар үзе дә уңай кәефкә күчкән... Ә идәндәге кәгазьнең язулары өске якта... Аз гына чүгәләсәң, укырга мөмкин бугай... Ә менә монысы Илдарныкы...

«Мин барыбер әйбәткә өметләнәм. Бер-бер хәл булса дип кисәтүем генә. Мин Айгөлнең ничек газаплануын аңлап торам, ә минем хакта начар хәбәр аны бу хәлендә аяктан егачак. Шуңа кисәтәм. Тик без яхшыга өметләник. Тормышта могҗизалар булып кына тора бит. Монда да миннән дә авыррак хәлдәгеләр дә аякка баса. Барысы да яхшы булыр әле, Зәлифә. Вакыты җиткәч, без әлеге хәлләр турында көлешеп кенә искә алырбыз».

Нинди кәгазь икән соң бу? Хатын, телефон төймәләренә баскалаудан туктап, идәнгә иелде. Кәгазьне үрелеп алды да язуларга күз салу белән катып калды. Йөзендә чиксез гаҗәпләнү пәйда булды. Бераздан бөтен булмышын чиксез караңгылык чорнады. Күзләрендә кара кайгы төсмерләре, йөзендә җыерчыклар пәйда булды. Иреннәре калтыранды. Шул калтыранган иреннәре аша үзәк өзгеч бер ыңгырашу авазы сыгылып чыкты:

– Илдар! Җаныкаем...

Кулларында дерелдәгән кәгазьнең иң башында торган язуны кемдер кычкырып укыгандай тоелды. Укучының тавышы әллә кайдан, бик еректан, галәмнәр төпкеленнән ишетелгәндәй иде.

– Үлем турында таныклык.

Һәм тавыш Илдарның хастаханәдә зәхмәтле чирдән үлүе турындагы хәбәрне таратты. Айгөлнең колакларында өзек-ертык авазлар гына яңгырап торды.

– Илдар... Үлеме турында... Илдар. Илдар...

Хәзер инде Айгөлгә барысы да ачык иде. Ни өчен өйдәге җиһазларның алыштырылуы да, телефонның монда булуы да... Барысы да... Хәтта Илдарның үлеме турында ни өчен хатынына хәбәр итмәүләренең сәбәбе дә.

Их, Илдар...



Рифә
Рахман

# ГАШЫЙК БУЛГАН КӨННӘР...

## Кояш исе

Кояш исе килә җәйдән, тузан исе, үлән.
Үләннәрне үбәм, димен, чында җәйне үбәм.

Сөям аны егетләрне сөйгән кебек – янып.
Чөя башын – китә горур, булмый бергә калып.

Берсе китсә, икенчесе чират көтә тора.
Җәйнең төсен сагынуда гомер үтә тора.

Кояш исе килә җәйдән, болын исе, урман.
Һәр исенә китә исем, һәм мин гашыйк булам.

Ничә кабат гашыйклыгың сөйли яшең санын.
Көзне, кышны, язны кичим, сөяр өчен тагын!

## Җилдән туган

Куркабыз без ялгыш туган хыяллардан,
Күңелгә яз килер төсле куркабыз без:
Тел очында торса тәме алмасының
Мәхәббәтнең, сүзебезне йотабыз без.

Саклыйбыз без җаныбызда сабый хисне –
Ул үсәр дә, хыял бүртер кебек артык.
Куркабыз без ялгыш туган һәр нәрсәдән,
Әйтерсең лә хәтта хисне җилдән таптык.

---

Рифә РАХМАН (1962) – *шагыйрә, прозаик, галимә; «Онытырмын димә», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» һ.б. исемдәге күпсанлы китаплар авторы. С.Сөләйманова, Ф.Хөсни, Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

* * *

Мин беркайчан яратмаганмындыр
Тормышымны шулай – яшим (!) диеп.
Ясыйм-бозам, кадак кагам, кисәм...
Һәм йокыга китәм сине сөеп.

Мин беркайчан яратмаганмындыр
Беркемне дә, болай нидер көтеп.
Ясыйм-бозам синле киләчәкне,
Өметсезлек белән җимердертеп.

Мин беркайчан сине очратмаган,
Шуңа сине һичбер уйламаган.
Тормышымның биргән сулышларын
Синең өчен диеп суламаган...

Бәялим мин һәрбер гыйшыклыкны
Миңа кирәк булмаган ул диеп
Хәзер генә, менә хәзер генә!
Кайда йөргән ихлас сөю элек?

Мин беркайчан яратмаганмындыр,
Мин беркайчан яшәмәгәнмендер...
Ясыйм-бозам синле киләчәкне.
Буяуларны күтәрмәслек киндер...

Мин беркайчан сине уйламаган:
Мин беркайчан сине очратмаган.
Сөюле хис йомган керфегемне,
Төрле шикләр төртеп уятмаган.

## Көлүем сәбәбе

Андый көчләр сиңа бирелгәнме,
Андый сәләт синдә бармы соң?
Мин бит көлеп торган кебек кенә...
Син – сөйдерә алыр ярмы соң?

Алырсыңмы мине яраттыра,
Алырсыңмы кулга төшерә?
Мин бит көлеп карап торган булам
Әле сөймәгән дә кешегә.

Әле күзем төшкән генә чакта,
Әле хисем йокы бүскәндә,
Әле ул һич минем кермәгәндә
Ярымуяу күргән төшләргә.

Матур сүзләр белән эретеп тик,
Алырсыңмы мине караттыра?
Ә хәзергә сиңа көлгән булам.
Бу этапта көлү ярап тора.

* * *

Болыннарда исә җилләр.
Куеныма керә.
Тупас ирдәй әрсез алар:
Керә көлә-көлә.

Агымсуда дулкын уйный.
Төптән куба ташлар.

Исәр дүңгәләктәй йөртә
Кайчак гашыйк башлар.

Илтә ярың алларына
Әрсез итеп, юләр.
Әдәбемне читкә куеп,
Гашыйк булган көннәр...

## Теләк

Яз күрүдән гомер курыктым мин
Басуларда яшен уйнаганны,
Курыктым мин утлар кыйнавыннан
Серкә очырганда бодайларны.

Һәм җәйләрен көн яшенле чакта,
Төн яшенле чакта бөркәнеп
Юрганыма, яттым караватта,
Сабырларым тәмам төкәнеп.

Аҗаганнар уйный икән кыш та:
Уйный икән синең куеныңда.
Юрган асларына яшен үткән!
Ут яндырмыйк, яме, ай буена...

* * *

Язар кебек идем ай буена
Синең хакта затлы шигырьләр.
Укымас та дигән бер уй килде,
Аның өчен татлы шөгыль бар.

Аның өчен чибәр ханымнар бар,
Елык-елык килгән шәраблар,
Әле синең белән танышканчы
Яшәвенә узган гадәтләр...

Язар кебек идем ай буена,
Кара эчеп – сәрхуш каләм күк,
Кипте күңел – каләм баш тыкмаган
Кара савытыдай калган күк.

* * *

Сөюнең бар башы:
Бар кайнар көннәре.
Бар төне – юксынып
Чылаткан мендәрне.

Сөюнең бар чиге:
Бар яшәү, бар үлем.
Сөюнең кай төше –
Елмайган бу көнем?

Күңелне тутырган
Уртасы мәллә ул?
Танышкан мизгелдән
Гел минем гамьдә ул.

Сөюнең бар башы,
Сөюнең бар чиге.
Турый ул кисәкләп
Бербөтен гомерне.

* * *

Күңел төште. Болыт арасында
Аны күтәрерлек юк якты.
Нигә сиңа бик тиз гашыйк булдым,
Һәм гашыйклык шулай тиз кайтты?

Казан урамнары ак кар гына.
Илтә алар сине еракка.
Их, аларны булмый алып калып
Һәм саф килеш кенә саклап та.

Машинаңның шома тәгәрмәче
Ак карларны таптап үттеме?
Ул аларны син аркылы узган
Минем күңел кебек иттеме?

Ашыкты ул кая, тукталды ул
Кайсы өйдә, кайсы тарафта?
Төште күңел, күтәрерлек түгел,
Юатып та аны, алдап та.

Бик тиз гашыйк булдым һәм... оныта
Алмый йөрим урам буйлап мин.
Кайтты күңел, арыттым шул аны,
Бары сине генә уйлап мин.

## Көнләү

Көнлим сине, көнлим сөяркәңә,
Булганына, тиздән булырына.
Мин күргәнче нигә алар таба?
Сайлап ала сине кем урынына?

Көнлим сине, көнлим бар нәрсәгә,
Белгәненә, белми яшәгәнгә,
Көнли алырмын мин, эчә калсаң,
Үз күземнән аккан яшьләрдән дә.

Көнләрмен мин, сөртсәң аларны син,
Сайлап йомшак, ефәк кулъяулыклар, –
Шул яшьләрне, һай, кадерли диеп...
Көндәшләргә минем уяулык бар!

## Магнит давылында

Җил миңа сәлам китерде Кояштан.
Һәм башны авырттырды яңабаштан.
Сөйлиләр, магнит дулыйдыр дип Җирдә.
Магнитсыз урын калды микән Илдә?
Ә ничек Кояш минем барны белгән?
Бу давыл чыга мәллә соң үземнән?
Уятамы, уйнатамы аны җил?
Җибәргәнме Кояш дип: хәлләрен бел.
Ул гашыйкмы рухы сынмас кызларга?
Ярату көче юкмы йолдызларда?
Ул гашыйкмы кызлардан да тик миңа?
Исәрлектән саклыйдыр йоклау гына.
Кирәкми яратуы һич Кояшның.
Сөюләргә түзәрлек итми яшем.
Яратудан мин болай да таушалган:
Йөрәгемә никадәр ядрә алган.
Яргандыр аны ярның шәп камчысы.
Булмаганмын шигырьлек илһамчысы.
Инде дә кирәк миңа тыныч гомер.
Калдырыр Кояш, сөйсә, кара күмер!
Ник сәлам юллыйдыр ул миңа гелән?
Ятамын каплап башны мендәр белән.
Сөйлиләр магнит дулыйдыр дип Җирдә.
Магнитсыз берәр урын бармы Илдә?

## Әйләнеш

Томырылып карый миңа яшел күзләр,
Курыкма һич, дерелдәмә, китап бите.
Сусыл җәйне хәтерләтә көзен миңа
Сиңа ятып кипкән яфрак силуэты.

Өзеләм бит диеп тора аздан гына:
Җәйнең күзе – яшел килеш корыган яфрак.
Ә җәй үзе инде күптән саубуллашты.
Хушлашты ул, туры минем күзгә карап.

Тамам-тамам диеп тора мөлдерәмә.
Агачларда көзнең күзе – сары яфрак.
Ә көз үзе инде күптән китеп барды,
Хушлашты ул минем белән кыймыйчарак.

Яфрагы һич коелмаган агачлар бар.
Кышның ап-ак кары яткан ябалдашка.
Карда туңган күзләр очмый, төшә җиргә.
Алар минем күңелем күк чирле, хаста.

Утырам мин китап укып балконымда.
Дымлы идән, дымлы урын, китап бите...
Миңа көзем үпкәләп үк киттемени? –
Тышлыгында аның таркау силуэты.

...Таңда бәсе коелмаган агачларга
Кара карга килеп кунды – яз да җитте.
Үлек кергән өй күк иде кышын балкон...
Ярый әле, иртә килгән яз терелтте.

Чирләремнән арындырды, хисләремнең
Очырды ул ямьсезләрен, авырларын.
Инде тышта китап укып утырам мин.
Яланөс үк – иртә яздан җылынганмын.

Ботак тулы яшел күзләр, өзелсәләр,
Битләреңә яткыр берсен, китап бите.
Сусыл җәйне хәтерләтсен көзен, кышын
Сиңа ятып кипкән яфрак силуэты...

Әлфис
Гаязов

# КАЙСЫ ЯКТАН ЧЫГА СОҢ БУ КОЯШ?

РОМАН

**20**

Искиткеч уңган буламы икәнни кеше? Шәйхеләхияр улы Ризванны күргән һәр кеше шулай уйлый торган иде. Утыздан чак кына өстә булуына карамастан, аның Казанлыдан башка ике авылда бөтен нәрсәсе әзер ике өе бар, кер дә яши башла! Хуҗалыкта җилгәргечләр, молотилка булуы күп эшне сезон саен ялланучылар башкарган дигәнне аңлата.

Чынлап та, аның өе Казанлының Елгабаш дигән очында әллә кайдан күренеп тора. Ул мондагы тәртип буенча эшләнмәгән, әллә нинди кала проекты белән салынган, андагы уңайлыклар турында хыялланырга гына була. Берничә бүлмә ирләр, хатын-кызлар һәм кунаклар өчен. Зур тәрәзәләр аша үткән яктылык өйне икенче төрле итеп яктырта, шуңа да ул елмаеп утырган кебек күренә. Идән-түшәмнәр бүрәнәне икегә ярып кына эшләнгән, шул тиклем әйбәт шомартылган, иләк аша чыгарылган көл белән юылган – төсе дә чын гәрәбә төсен саклый. Йорт-кура тәртиптә, шул ук уртага ярылган бүрәнә белән уратып алынган, әвеннәр, мунча, абзарлар бердәм хуҗалык барлыкка китерә. Һәр бүлмәнең диварында ау мылтыклары эленеп тора – бусы инде хуҗаның оста сунарчы булуын күрсәтә.

Ризван иртән иртүк йә атка атланып, йә аны җигеп чыгып китә, кичкелеккә нидер төяп, ауда атып алган киекләр салып кайтып керә. Шул арада үзенең җирләрен дә карап өлгерә, балаларга һәм тормыш иптәшенә зур игътибар күрсәтергә җитешә.

Менә бүген дә юлга чыгуның максатларын сөйләп тормыйча, гаиләсен төяде дә Яхшы чишмә ягына кузгалды. Арбада яшел печән, балта, чалгы, ашамлыклар, чәйказан һәм кирәкле савыт-саба. Җигүле ат түземсезләнеп биеп тора.

Иртә уянган балалар арбада йокыларын дәвам итте.

– Гыйльминур, Яхшы чишмәгә сигез чакрым, аннан бер җиргә барып киләбез – бусы алты чакрым. Көн буена барысы утыз чакрым тирәсе йөреп кайтабыз. Хәтереңдәме, елына бер булса да Изге чишмәгә барырга кирәк дип сөйләшкән идек, бу сүзне һич үтәп булмый. Без синең белән ел

*Дәвамы. Башы узган санда.*

буена бер көн дә ял итмәдек, эшләдек тә эшләдек. Шулай булгач, бүген ял, андый яллар безгә дә тиештер Аллаһы Тәгаләдән! – Монысын инде Ризван хатынына, Чияле тавына менеп, тузанлы ат юлы белән Яңа Казанлы авылына табан барганда сөйләде.

Гыйльминур риза иде ул әйткәннәр белән. Ул да сәхрәне ярата, ул да, урман-кырга чыгып, бераз ял итеп кайтуны иң яхшы яллардан саный. Гомумән алганда, Ризван кая бара, ул шунда барырга әзер, аның белән генә, ул янында булганда гына, үзен чиксез бәхетле итеп исәпли.

– Арттан куучы юк, ашыкмыйбыз, теләгән урында туктыйбыз, теләгән урында йоклыйбыз, кайчан телибез, шунда өйгә кайтабыз, менә ни эшлибез без сезнең белән, кызлар! – Ризванның күңеле күтәренке, тавышы көр, шатлыгы эченә сыймый. Ул әле барысын да әйтеп тә бетермәде Гыйльминурга. Барып җиткәч, әзерләгән бүләген күрсәткәндә әйтермен дип, серен эченә бикләп куйды.

Ат ашыкмый гына атлый, тирә-якта ашлыгы җыеп алынган басулар ята, анда ниндидер кошлар коелган ашлык бөртекләрен чүпли, алар Көтмәс буен – дымлы урынны үз иткән. Торналар озын аяклары белән түмгәктән түмгәккә сак кына атлыйлар, сирәк кенә, сагышлы тавыш белән кычкырып, көзнең сары кояшына ниндидер хәбәр бирәләр кебек.

Менә бит, үзенең мәшәкатьләре белән тагын көзләр килеп җитте, ә җәй китәргә ашыкмый да, уйламый да. Кеше аптыратырлык җылы, кояшта ялтыраган бәллүр кебек көннәр, урман-яланнардагы көзге сары сагыш. Тынлык якынаеп килгән кышына табан атлаган табигатьне моның белән килешергә чакыра.

Кич-иртәләрен салкын, көндезләрен дә инде җәйге кебек эссе түгел, һәм бу тынлыкта камыл астындагы тук тычканнарның йөгерүе дә ишетелә. Чак кына искән җилдә үрмәкүчләр һавага күтәрелә, бөтен ялан аларның көмештәй пәрәвезе белән тула. Кызык, кем һәм кайчан бу йомгакны сүтеп-таратып җибәргән икән?

Арыган җир ялга әзерләнә. Саф, чиста күк гөмбәзе еракларга, биеккә күтәрелә. Бу чисталыкта Казанлының югарырак бер читеннән Николаевка чиркәвенең кадак кебек очы тагын да очлырак булып күренә. Чиркәүнең кызыл кирпечләре, аның кырында үскән чыршыларның яшеллеге, кайчакта ялтырап алган гөмбәзендәге алтынсу калае бербөтен тәшкил итеп, мәңгелек турында сөйли, изге дога укыган төсле иде.

Ә сентябрь кояшы кыздыруын дәвам итә. Зәп-зәңгәр һавада бер болыт әсәре юк, шул зур киңлектә кояш берүзе бер яктан икенче якка тәгәри, эсселектән кибеп кызган, ярылган юлларда тапталып, онга әйләнгән тузан ята.

Йомшак та соң шул тузаннан арбада баруы. Ат та үз иркенә куелган, теләсә – чаба, теләсә – атлап бара, барышлый өзеп үлән каба, ә арбада яткан үлән инде, кибеп, печәнгә әйләнә башлаган.

Ризван, балаларның уянуын күреп, кулларын авызына китереп, боерык бирде:

– Бераздан Көтмәс елгасы аша күпергә җитәбез. Шунда ялга туктап, чәй кайнатып, ашап-эчеп, ял итеп алырга, яшел үлән чабып, атны ашатырга, азрак җирдә аунарга боерык бирәм!

Кызлар чәчләренә кунган печән сабакларын сыпырып төшерделәр, шаярып көлештеләр, арбада үзләренә ошаган урынны сайлый башладылар. Ә менә монысы инде тыныч кына үтмәде – китте тавыш, китте этеш-төртеш, китте бәхәсләшү! Елга янына барып туктаганчы шауладылар, бары тик чәй-казанда кайнаган үләнле чәй генә аларның урын бүлешүен оныттырды.

Ризван атны тугарып, тәртәләрне өскә каратып бәйләп куйды, аларга чыпталар ташлап, утырган урынга күләгә ясады, учак әзерләп, чәй кайнатты, балаларны елга буенда чиратка бастырып, битләрен юды. Шул арада тәртәләр астында Гыйльминур оештырган менә дигән кыр өстәле барлыкка килде.

Бардыр, бардыр кичә генә пешкән арыш икмәгенә өр-яңа каймак ягып, өстенә кайнатма тамызып ашаган кешеләр... Әле дә телләрен йотып искә алалардыр аны! Балачакның онытылмас хатирәләре булып уелып калган истәлекләр туган ил, туган тел, әти-әни, тормыш-көнкүреш ваклыклары белән бәйләнгән, әнә шулар кешенең эчке бер нигезенә, иң мөһим умыртка сөякләренә берегеп, эчке торышын сыйфатлыйлар. Шул түгелме икән туган илгә булган мәхәббәтнең өзелмәслек иң киң, иң нык нигезе, төбе?

Чәй эчелде, алга барырга әзерлек башланды. Монысын да Ризван шаярып, боерык формасында бирде:

– Кызларга арбада урын алырга, икенче тукталыш Мартыш тегермәнендә, буа буенда. Өч-дүрт чакрым юл!

Киттеләр. Кызлар елап та алды – чапкан үлән арасына зәһәр кычыткан яфрагы эләккән. Аннан котылгач, тагын китте шау-шу, көлеш.

Урман юлы тар гына, бары тик ат арбасы салган эзләр буйлап кына бара. Тирә-якта күккә ашкан наратлар, карагайлар зәңгәр биеклекне җир белән тоташтырып тора, печәне чабып алынган болыннар япа-ялан булып ята, дымсу җирдән җылы һава күтәрелә. Шунда кызларның берсе: «Сыер, сыер!» – дип кычкырды. Олылар, көлеп, моның сыер түгел, ә поши икәнен аңлаттылар.

Җыр килә күңелгә, моң килә. Сөйләшергә якыннарың бар, сөйләшеп бетмәслек сүзләрең бар, ә җырлыйсы килә! Ризван акрын гына көйли дә башлады, аңа Гыйльминур да кушылды. Аның нинди җыр ратканын белә Гыйльминур: соңгы вакытта бик киң таралган «Хәмдия» иде ул җыр...

Кычкырма ла, кәккүк, ай каршымда,
Кычкырсана агач башында.
Талдин талга тал тибрәтеп
Сайрый сары сандугач.
Җырлау түгел, еларсың да
Өзелеп-өзелеп сагынгач...

Җырга кызлар да кушылды. Аларның бик матур нечкә тавышы җырны баетып җибәрде, аңа ниндидер танымаслык та, таныrлык та төс һәм аһәң бирде. Бер мизгелдән Ризван бөтенләй икенче кеше иде:

– Ә хәзер мин сезгә аю күрсәтәм!

Кызлар куркып чырылдап җибәрделәр, Ризван атын текә тау буендагы ташлар өеме янына алып килде.

– Кем аюны беренче булып күрә, шуңа бүләк!

Арбадан төшеп тә эзләделәр балалар, үрелеп-сузылып карап та эзләделәр, ләкин аюны тапмадылар. Гыйльминур да кушылды, ул да табарга тырышып карады, тик аю юк иде!

Менә таптылар, таптылар! Ташлар артында качып-посып утыра икән бит ул! Ходай рәхмәте, бар җире дә килгән, тырнакларына тикле таштан ясалган аю булып чыкты ул. Аюны тапкач, бар да бүләк көттеләр. Кызыл билле прәннек булды кызларга бүләккә.

Бу урында, тау-таш арасында еланнар күп булып чыкты. Ризван балаларын алдан ук кисәтеп куйган иде, барысы да бик сак булдылар. Еланнар турында көне буе сөйләргә әзер Ризван, ул аларның телен белә, ахры. Аның елан белән дуслашуы дошманлыктан башланып китә. Яз көнендә, еланнарның язгы куышуы вакытында Ризван аларның йомгагына ата – монысы инде бер дә алай эшләргә ярамый торган адым була. Моңа җавап итеп, еланнар Ризванны куа башлыйлар. Бары тик яхшы ат кына коткарып кала аны бу бәйгедә. Әллә шулай булган, әллә булмаган, моны Ризван үзе дә бик сөйләми, бары нииндидер яхшылык күрсәтеп кенә, еланнар патшасының ышанычын кирегә кайтара алган ул. Бу хәлләрдән соң халык «Елан Ризванга мөгезен бүләк иткән» дип тә сөйләде. Елан, имеш, кешегә рәхмәт әйтәсе килсә, аның артыннан бер адымга да калмый йөри башлый. Кеше, моны аңлап, берәр әйберен ташлый аның алдына. Елан шул әйбер эченә үзенең кабыгын сала, әгәр инде меңнән сайлап алынган кешесе булса, ул кабыкта мөгезен дә калдыра. Андый кеше бәхетле дә, кодрәтле дә була, ди. Ризван, бу хакта сүз чыкса, берни әйтми, бары тик елмаеп кына тыңлый.

Еланлы ташлыкны хәвеф-хәтәрсез генә узып киттеләр. Ерактан су тавышы ишетелә башлады – Мартыш тегермәне якынайды. Чиста сулы Көтмәс, тегермәннең су тәгәрмәчләре аша күз иярмәслек тизлектә үтеп, чак кына басылып агып ята. Ризван балаларга карап эндәште:

– Ә сезнең балык тотасыгыз килмиме? Менә бу борылышның алдында минем ау салынган. Менә хәзер шуны алабыз, балыкларын җыябыз, чистартабыз, табада кыздырабыз. Бәлки ашын да пешереп җибәрербез! Бусы инде балык эләгү-эләкмәүдән тора, карап карарбыз!

Аһ, Ризван, Ризван! Кай арада ауны китереп салып киткән? Кем генә моны белә, кем генә моны, Ризваннан башка, шулай оста итеп уйната алган? Йа Ходай, ипле кеше генә түгел, күңеле тулы иҗат булган кеше бит бу! Хәтта Гыйльминур да аптырады бу эшләргә.

Тиз арада ауны таптылар, ул чыннан да тулы иде. Вак-төяген җибәрделәр, ә көмештәй ялтырап яткан ару гына чабакларны, бәртәсләрне, алабугаларны, тагын әллә нинди балыкларны җыеп алдылар. Ауны кайтканда алырбыз, салкында торсын, бәлки балык та өстәлер дип, кабаттан елгага ташлады Ризван.

Мартыш тегермәне өстендә акчарлаклар уйный, буаның икенче башында җылы якларга җыенучы үрдәк-казлар шаулый. Агач төбендә баягыча урын әзерләнде, ә балык күп булгач, ашы да куелды, кыздырырга да өлеш чыкты.

Олы кызы «Нигә тегермән Мартыш дип атала?» дигән сорау бирде. Ризван аңлатырга тырышты. Мартышның маймыл, йонлы кеше сыйфатындагы хайван икәнен сөйләде. «Тегермәннән ерак түгел генә шундый ук исемле чишмәсе дә бар», – диде. Тик сорауның икенче яртысына – кызның «Ул

йонлы кешеләр монда яшиме?» дигәненә җавап юк иде шул. Чынлап та, кем генә белсен, каян чыгып бирелгән ул исем тегермәнгә, Маймылы монда яшәмәгәч? Маймылны күргән кешеләр аз түгелдер ул – хаҗга баручыларның бу турыда сөйләгәннәре бар. Әллә инде берәр урында шул маймылга охшаган таш сыны да бармы? Менә шулай аңлатырга тырышты ул бу сорауга җавапны.

Аптырап та, сокланып та бетә алмый Гыйльминур Ризванга. Бер караганда, салмак фигыльле олы кеше, бер караганда, шук, шаталак егет, бер караганда, күзләре утлы куздай янып торган мут малай. Каян килә бер кешедә шул тиклем аң-белем, зиһен? Уңганлык, шаянлык?

Өйләнгән чаклары гел искә төшә. Уналтысы да тулмаганда урлап алып китте аны Ризван күченеп килүчеләр салган бәләкәй генә авылдан. Авыр иде Гыйльминурга үги әни белән: бернигә өйрәтү юк, көн саен битәрләү аны кешеләрдән биздерде. Шул чакта Ризванның атылган йолдыз булып килеп чыгуы аны саклап алып калды. Ярата иде дә соң әтисе, тик кыз бала көннәрен аның белән үткәрәмени? Сөйләшенгәнчә, Ризваннықылар суга барган кызны, эләктереп, чанага утырталар, шартлатып, мылтыклар аталар, авызларына Өреш аракысы салган атлар, дулап, Казанлыга чаба...

Икенче көнне килә әтисе елап. Киселгән икмәк ябышмый, моны аңлый, тик кызының адымын хупларлык әйбәт сүзләр таба алмый ул...

Арбада барганда, бөтен тирә-як хәрәкәттә, бар дөнья каядыр ашыга. Тора-бара арба алга түгел, тирә-юнь артка табан киткән кебек тоела башлый. Балалар, моны сизеп, инде күптән арбаның йә алдына килеп яталар, йә арткарак барып утыралар, әниләренә тотынып басып торалар, җигелгән атның куе кыллы койрыгы белән чебен-кигәвен куганын күзәтәләр. Усал кигәвеннәр кайчак кызларга да тынгылык бирми, шуңа Гыйльминур аларның һәрберсенә яфраклы чыбык тоттырды.

– Инде туктап тормыйбыз, – диде Ризван. – Яхшы чишмәгә биш чакрым юл калды. Менә анда туктыйбыз, юынабыз, агач мичкәләргә су алабыз, ял итәбез һәм тагын бер җиргә барып киләбез.

«Бер җир» дигәне шул тиклем кызыксындыра, тик Ризван кая барасын әйтми. Гыйльминур, хәйләләп, балалардан да соратып карады – кая ул! Мыек астыннан гына елмаеп, арбага аякларын сузып салып эндәшми утыра, сүзне читкә бора, серне сөйләргә уйламый да! Тиз арада ат җигелде, әйберләр җыелды, тагын алга атладылар, кирәк чакта юырттылыр, чаптылар.

Чишмә яланында, елның, көннең нинди мизгеле булуына карамастан, Сабан туендагы кебек халык. Кызык, төрле милләт халкы җыелган, барысы да монда күмелгән изгене үз динендәге кеше дип исбатлый. Куак төпләрендә сәҗдәгә киткән мөселманнар, агачка эленгән тәреләргә багучы рус кешеләре, ниндидер ташлар, чүпрәкләр тотып утырган мәҗүсиләр – барысы да бу җирнең изге булуына мөкиббән китеп ышыналар, ышанырга телиләр.

Яхшы чишмә кирәкмәгән кешеләрне кабул итми дип сөйлиләр бу якта. Андыйлар килгәндә, ачуланып, кара болытлар белән каршылаганы да бар диләр. Шуңа күрә элек-электән матур гына, ипле генә килеп туктыйлар, изге сүзләрне кабатлаганнан соң, читкә китеп юыналар, дога укыйлар. Хәер, болары инде элек-электән килгән гадәт. Хәзер иң мөһиме – чишмәнең саф,

таза булуы, аның дәвасы, файдасы, бу урынның табынылган булуы. Һәм бу табынуның йөзләрчә ел дәвам итүе. Берничә чакрымга сузылган түгәрәктә чишмәләрнең күплеге, күзләрне терелткәне дә, ашказаны чирләрен юып төшергәне дә, күкерт агып чыккан исле сары чишмәләре дә, сазындагы файдалы ләме дә, кешеләр өчен тагын әллә нинди файдалы үзлекләре бар. Шуңа да бирегә киләләр, дәваланалар, шифалы суын алып кайтып китәләр.

Зур гына яланның көньягында тирән, ләкин төбе күренеп торган Төлгеҗ елгасы ага. Яхшы чишмә суын алырга җайлы булсын дип казып куелган урыны да бар, шунда чишмәнең зур күзәнәкләре аша чыккан салкын су өскә ыргыла, таш белән әйләндерелгән казылган җирне тутыра, гөрләп, улактан агып чыга да Төлгеҗгә агып төшә.

Бөтенләй икенче кешегә, серле кешегә әйләнде дә китте Ризван. Бигрәк җитди итеп юынды, догаларын укыды, чишмә суын кайнатып, чәй дә эчеп өлгерделәр. Тагын ат җигелде; арбага утыргач, Ризван азрак серен ачты.

– Хәзер без Олы елга дигән авылга барып киләбез, ерак түгел, бары җиде-сигез чакрым гына.

Һәркем үз эше белән мәшгуль булды. Гыйльминур юылган табак-савытларны сөртеп, туздан ясалган тырыска тутырды, салкын сулы мичкәләр янына май һәм эремчекне, юлга пешереп алып чыккан ит кисәкләрен урнаштырды. Иң бәләкәй балалары үзенә игътибар таләп итә, арбада аңа, кояштан каплатып, йомшак урын әзерләнгән, ул беразга изрәп йоклап китте. Ә кызлар җыелган чәчкәләрдән такыялар үрә башлады. Күп тә үтмәде, арбаны ямьләп такыялы дүрт баш күренде. Монда да иҗадилык кайнап чыккан: такыяларның нинди генә юк!

Атны чаптырып, авыл урамына килеп керделәр. Олы елга дигәне урман эчендәге бер урамнан торган бәләкәй генә авыл икән, урманда утрау булып урнашкан өйләре дә күренә, бары авылдагы тынлыкка игътибар иттеләр – монда эт өргән тавыш та ишетелми иде. Ризван авыл уртасындарак атын бер яңа төзелгән йортка юнәлтте. Ырыс капкалы, биек коймалы, матур итеп такта белән ябылган түбәле, биек, зур тәрәзәле өй аларны елмаеп каршы алды. Ризван, ат туктап өлгергәнче сикереп төшеп, капканы ачты, ишегалдына уздылар. Өр-яңа абзар, мунча, хуҗалык йорты, әлегә бәрәңгесе алынмаган бакча, казылып яткан кое – монда яши башларга бөтен шартлар да бар иде. Ризван, кайдандыр ачкыч табып, ишеккә эленгән зур богау йозакка төртте. Шуннан ишекне ачып, кызларын өйгә чакырды. Ап-ак өй үзенең чисталыгы, тәмле агач исе белән таң калдырды. Көне буе тар арбада утырып, хәрәкәтне сагынган балалар өйнең астын-өстенә китереп йөгерә дә башладылар. Ризван белән Гыйльминур өстәл артына килеп утырдылар. Гыйльминурның күзләрендәге сораулар Ризванга күчте.

– Гыйльминур, син беләсең минем тик тормаганны. Дөньялар бозыла дигәч, мин Казанлыдан башка ике авылда өй төзеп куйдым. Кем белә, кайсысында тынычлык таба алырбыз, әгәр булса инде ул тынычлык... Менә бу йорт – шуларның берсе. Әгәр сиңа ошаса, бүгеннән монда яши башлыйбыз, ошамаса – башка җаен табарбыз. Мин нинди карарыңа да риза, синнән – теләгеңне әйтү. Әйт, бер җавапка да ачуланмыйм, барысын да кабул итәм!

Урамда да, өйдә дә колакны тондырырлык тынлык, биек тәрәзәләрдә

кояш уйный, яңа гына чыгарылган, инде сылап агартылган ак мичтән балчык һәм ат тизәге исе килеп борынны кытыклый. Мич алдындагы иң кирәкле әйберләр – кыскыч, ипи көрәге, кисәү, табагач, күмер чүлмәге Ризванның шул тиклем игътибарлы булуы турында сөйли иде. Гыйльминур, идән буйлап йөгергән балаларга карап, озак кына эндәшми утырды.

– Ризван, ачуланмасаң, әйтәм. Син беләсең бит минем бәләкәй генә авылда үскәнне. Ни күрдем инде мин? Берни дә күрмәдем... Менә бу биш баланы да шул язмышка дучар итикме инде? Бу авылда бит әллә балалар да юк?! Өй матур, һичшиксез! Тик безнең Казанлыдагы йорт та менә дигән!

Чынлап та, авылда бер тавыш ишетелмәде. Гыйльминур дәвам итте:

– Рәхмәт сиңа минем өчен җан бирергә әзер торуыңа, минем эшемне җиңеләйтергә тырышуыңа, балалар дип өзгәләнүеңә. Мин игътибар иттем инде, монда яшәү өчен бар нәрсә дә бар. Әнә, хәтта күмер чүлмәге дә. Рәхмәт шундый хәстәрле булуыңа. Чын хуҗа син! – Гыйльминур туктап калды. – Тик... Тик килеп яши башлау үзебезнең аяк-кулны бәйләп, колак-борынны кисеп, җаннарыбызны-тәннәребезне монда беректерергә тырышу булыр дип уйлыйм мин. Барып чыгармы? Юктыр, Ризван!

Ризван да бик күп уйлады бу хакта. Тик, Гыйльминурны монда алып килеп, хуҗалыкны күрсәтми торып, бернинди карарга килеп булмаганын да ул яхшы аңлый иде. Аның шатланып риза булмаячагын да белә иде ул. Менә – бөтен шарты инде килде, җавап бар, хәзер алга, икенче юллар эзләргә, табарга, яшәргә. Тормыш дәвам итә бит!

– Аңладым, туры җавабыңа рәхмәт, Гыйльминур! Мин сине шулайрак әйтерсең дип тә уйлаган идем, үзем дә шундый җавап тирәсендә әйләнәм. Дөресен әйтәм, башта азрак куркыбрак та тордым – көтмәгәндә син ризалашырсың дип. Хәзер куллар баудан ычкынды, мин үземнең карарымда азат. Алга барабыз, Гыйльминур! Яшибез, Алла гына бирсен, Гыйльминур!

Балалар да тынып калды, ул бу сүзләрне әйткәндә.

– Ә хәзер болай итәбез. Бераз кунак булабыз монда, ял итеп алабыз, көн кызуын уздырабыз да, кичкә авышкач, үзебезнең Казанлыга кайтабыз. Ризамы сез, җанкисәкләрем?

– Ярый, ризабыз, җанкисәгем!

Кызлар: «Риза-а-а!» – дип кычкырып, баш кактылар.

Ризван, арбадан йөгертеп, самавыр белән торбасын алып керде, мич башыннан чыра агачын тартып төшерде, кайдандыр калын пычак табып, чыра телде, самавырга ут салды. Боларны карап торган Гыйльминур сокланып туктый алмады Ризванның уңганлыгына: ничек итеп барысын да алдан уйлый, күрә белә, барысын күз уңында тота, һәрбер вак-төякне алдан ук исәпкә ала? Әйе, бар икән андый кешеләр, һәм шуларның берсе – Ризван – Гыйльминур бәхетенә!

Без, бүгенге көн кешеләре, үзебезне акыллы да, алдан күрә белүче дә, бу сәхифәләрдән күпкә югары торучы дип хис иткән булабыз. Кирәкми андый тырышулар, кирәкми! Бары кешеләр өстеннән түгел, сәхифәләр өстеннән күтәрелеп карыйк булган хәлләргә. Тормышка шул вакытта яшәгән кешеләр күзлегеннән чыгып карыйк: алар да шулай берсен-берсе яраткан, туганлашканнар, балалар көтеп алганнар, шатланганнар. Алар

да безнең кебек шатлана да, хафалана да белгәннәр, яратканнары өчен тау булып баса алганнар, бергәләп тормыш корганнар һәм җирдә тормышның дәвамы булганнар. Менә шулар түгелме кешеләрне бергә тоташтыручы барлык кешелек өчен уртак булган кыйммәтләр? Бар алар, бар! Аларга тотынып, халык яши, милләт чәчкә ата, аларга ил сыенган!

Бер-ике сәгатьләп ял итеп алган тук ат, матур гына юыртып, Олы елга белән Казанлы арасын якынайта, ә арбада барганнар, җиде тавышка сузып, баягы «Хәмдия» җырын җырлый иде.

**21**

Старшина Ибраһим үзенең юлбасарларын, андый-мондый хәлләр булмасын дип, ике-өч атнадан артык якын китерми тотты. Шул арада ул тагын нәрсә эшләргә кирәклеге турында уйлады, Матусовның эшен туктатыр юллар табарга тырышты. Йөри торгач тапты ул юлларны. Тик аны тапканчы, өязгә барып кайтырга туры килде.

Бөре өязе сугыш башланган елларда дистәләгән волостьны үз эченә алган административ берәмлек булып танылган өязләрнең берсе булып үсеп китә. Географик яктан бик уңайлы урнашуы, күп сулы Агыйдел елгасының, кирәксә, диңгез белән тоташтыруы, тирә-якта даны чыккан төрмәсе булуы, сәяси эшләрнең үзәге булып китүе дә аңа файда өсти, аның данын башкалардан биегрәк итеп күтәрә иде.

Ничек кенә булмасын, соңгы айларның сәяси яктан да, икътисади яктан да тотрыксызлыгы кеше нервыларын гына җеп итеп сузмый, административ җепләрне дә чыңлата, анда эшләгән кешеләрне кычкыртып елата.

Ярдәмчеләре, кереп, шәүлә булып утырдылар. Ибраһим алардан берәр төрле яңалык, тәкъдимнәр көтә иде. Ә болар телләрен йотканнармыни, бер сүз дәшмиләр!

– Йә, нинди тәкъдимнәр бар? Туктатмыйбыздыр бер башлаган эшне? Тамырбулат абзый, ни уйлыйсың?

– Теге... ни... бик кайгылы чагы, бераз түзеп тормыйбызмы дим?

– Син дәме? – Ибраһим Ярмигә борылды. Тегесе тамагын кырып, төссез күзләре белән стенадагы чебенне күзәтеп, өметсез генә җавап бирде:

– Соң, чынлап та бик каты килеп чыкты, түзик бераз...

– Вәт диваналар, шыр диваналар! Изгеләр җыены! Сезгә ышанып, мин эш башладым, дивана инде мин дә, Ходай! Туктау юк. Уйламыйсыз, туң башлар! Сез бит берничә фикер әзерләп килергә тиеш идегез! – Ибраһим кызганнан-кыза барды. – Болай итәбез. Матусовның Чулманга тикле җиде пристане бар. Шуларны яндырырга кирәк. Җае чыгып тора. Якын көндә рекрутлар озатабыз, сез, эчкән булып, төшкә тикле кеше арасында йөрисез. Шуннан юкка чыгып, бу эшне башкарасыз. Кәрәчин миннән, шешәләргә салып куелган. Кичкә кайтып җитеп, әпәт кеше арасында булырга тиешсез. Аңлашылдымы?

Тамырбулат Ибраһимны аңларга бик тырышса да, берничек тә тел төбен чамалый алмады. Шуңа соравын бирде:

– Ничек инде бер кичтә Чулманга тикле барып әйләнергә?

– Ә-ә-й, ләгънәт төшкере! Чулманга түгел инде, бер-икесен,

якыннарын! Ташкүр кырындагыны, Борай янындагысын. Боларына бит җитешеп була!

Ибраһим аларны эчтән генә, «Аңгыралар!» дип атап, бик озак башын кагып торды. Тегеләр кая килеп капканнарын аңлый башладылар, ахры, берсүзсез күтәрелеп, аягүрә бастылар да чыгарга юнәлделәр.

– Шул! Башка фикер юк!

* * *

Ике кара бәндә чыгып китте. Ибраһим, бүлмәдә калган улына бик озак карап торгач, йомшак кына дәште:

– Сәйфетдин улым, тыңла әле. Дөньяның артына тибеп яшәү өчен көч-гайрәт, власть кирәген син аңладың инде. Тик власть, үзе килеп, итәккә төшми, аны алыр өчен башта кемдер булырга кирәк.

– Хәтта байлык та ярдәм итмиме?

– Байлык та. – Ибраһим төп сүзенә күчте. – Улым, сиңа әфисәр булырга кирәк, менә нәрсә. Әнә кара әле, староста Хәмитнең олы улы Салих хәзер штабс-капитан! Аннан, кара әнә Дедухинныкыларны. Ике улы да поручик. Әфисәрлек бервакытта да юкка чыкмый, аны һәр власть ихтирам итә, алга этә, сайлап ала, ашата-киендерә, акчасын каерып түли.

– Әти, мин әзер дә ул. Тик мине кем алсын инде? Белемем юк, булганы да мәдрәсә генә.

– Анысы минем эш! Җаен таптым инде Бөредә. – Ибраһим канәгать елмайды. – Шуннан, син мәдрәсәдә генә укымадың, земство мәктәбендә укыдың. Иң мөһиме – русча матур сөйләшәсең! Ярар, бу турыда соңыннан. Тик башкалар белән армиягә китәргә кирәк булыр сиңа. Армиягә алу буенча фәрманны безгә Бөредә җиткерделәр дә инде.

Менә бу урында кычкыру, каршылык көткән иде Ибраһим. Алар булмады. Ул, эчтән генә шатланып, «Сөбханаллаһ, шәп егет тәрбиялим икән бит!» дип тә уйлап куйды.

– Синең белән сөйләшми торып, халыкка армиягә алу турында белдерү ясамый торган идем. Болай булгач, иртәгә Аллага тапшырабыз. Хәзер син мин әйткәннәрне ятлап ал да онытып тор. Берсекөнгә волость бинасында рекрутларны карау үткәрәбез. Син тып-тын гына башкалар кебек йөреп торасың. Ике көннән сезне Казанцево аша, пароходка төяп, Бөрегә алып китәләр. Анда барып җиткәч, синең янга Тукмаков дигән бер Ходай бәндәсе килер һәм сине башкалардан аерып алып китәр. Калганы, улым, синнән: укы, тырыш, алдаш, урлаш кирәгенчә, сат, сатып ал, кирәк булса, акча төрт, тик әфисәр генә бул! Аңлашыламы?

– Аңладым барысын да, әти. Ятладым һәм оныттым әлегә!

– Ярар.

– Бөтен тырышлык – әфисәр булу. Аннан күз күрер, эше дә булыр, ашы да, Алла боерса! Кирәк булса, малын да жәлләмибез, акчасын да. Малай кеше гаиләнең терәге, ул көчле булса, гаилә дә, зат та, исем дә көчле була. Менә шуңа тырышабыз, улым!

– Ярар, әти, мин тырышырмын!

– Син үзең дә бик килешле, коеп куйган әфисәр. Әтисе кем дип

сорасалар, аның җавабы да бер дигән: этисе – волость старшинасы! Бу бит һәркемгә дә тәтеми! – Әйткәнен Ибраһим зур канәгатьлек белән, битен-сакалын сыпырып тәмамлады. – Тик боларны кешегә, хәтта әниеңә дә әйтергә ярамый – монысын да аңлагансыңдыр бит?

– Аңладым, эти!

Һәрберсе алдагы тормышны күзаллый иде бу мизгелдә. Сәйфетдин үзен, атка атланып, күп солдатлар катнашкан бәрелеш-алышны карап торган зур хәрби башлык итеп күрде. Башкалар аның янына берәм-берәм йөгереп килеп язу тапшыралар да йөгереп чыгып китәләр. Кирәксә, Сәйфи аларны туктата, тиргәп-кыздырып ташлый, акыл өйрәтә, бармак белән яный. Ибраһим исә алтын погонлы әфисәрләр арасында утырган Сәйфине күрде, шунда үзен башкалар белән бер тиңдә ризалык белән йөреп яткан карт итеп хис итте, үзенә булган ихтирам яңгырында коенды. Колагына башка әфисәрләр әйткән сүзләр дә ишетелеп кала иде: «Ул бит полковник Ибраһимовның, юк, генерал Ибраһимовның атасы, аның тирәсендә бик буталып йөрмәгез! Йөрсәгез, тын гына, аяк очына гына басып! Аның башын катырмагыз!»

Киләчәк бик матур, өметле булып күренә иде ерактан.

## 22

Маңгаенда матур кашка йолдызы булган аты Гәрәйнең килгәнен акрын гына пошкырып каршы алды. Ә ул сикереп менеп атлангач, шунда ук юыртып та китте. Тик Гәрәй, тезгенен кысып тотып, аны тынычландырды. Ат, моңа үзенең ризасызлыгын белдереп, башын дугалатты, тимер авызлыгын теш арасында йөртеп күрсәтте.

Гәрәй атны тыебрак килде. Соңгы көннәрдә булган хәлләр аны шатландыра да, бер үк вакытта чиксез дулкынландыра да иде. Уйлар диңгезе шулай ук тирән, шулай ук төпсез. Ничек кенә булмасын, Гәрәй үзен иң бәхетле кеше итеп тоя иде хәзер. «Нина, Нина!» – дип, җырга салып суза ул кадерле исемне. Әле күптәнме ул аны бер күрергә зар-интизар булып йөрде? Бер күрергә, башкасы – бер-ике сүз алышырга, күзләренә карарга – болары тормышка ашмаслык хыял иленнән. Печән вакытлары, Таныпп, үзенең малайларча шаянлыгы, этисе белән Степан арасында бер дә юктан килеп чыккан ызгыш... Боларның кайсылары шул тиклем кирәк булды икән? Ә бүген? Бүгенгене уйлаганда, аның тәне буйлап, башларын әйләндереп, бер эсселек үтеп китә, үткәннең һәрбер мизгеле күз алдыннан китми шатландыра, өмет бирә.

Бүген ул Нинаны күреп кенә калмады, аны бер мизгелдә кочагында да тота алды. Шул вакытта аның нихәтле якын да, кадерле дә булуын аңлады Гәрәй. Моңа хәтле Нина аңа әллә нинди тотып ала алмаслык, һәрвакыт күз алдыннан китмәгән ай һәм кояш нурыннан үрелгән ерак бер хыял булып кына тоела иде.

Тормышка ашуына бер тамчы ышаныч та булмаган хыял бүген Гәрәйгә тагын бер мизгелен бүләк итте дә юкка чыкты. Килде, өмет өстәде, канатларны үстерде дә очты. Башка берни турында да уйлыйсы килми: этисенең Степан белән дошманлашуы турында да – Гәрәй аңлый бу

хәлләрнең аңа бик нык комачау итәсен, авыл кешеләренең аннан үч алырга теләве турында да, мобилизациянең алдагы дулкыны турында да, үзенең сугышка китеп барачагы турында да...

Юк, болары түгел, башка уйлар биләп алды Гәрәйне. Нина, бары Нина белән тулды аның моңлы дөньясы, бер Нина тал чыбыгы кебек нечкә буйлары белән бөтен дөньяны каплады, бер Нина үзе белән алмаштырды да куйды чиксез зур галәмне...

Көзнең беренче салкыннары кочагында яткан агачлар, басу читендә үскән озын үләннәр талгын җилдә тибрәләләр. Урман юлы, кара җәймә булып, артта калып, ашыкмый гына ялгыз юлчыга ияреп баруын дәвам итте. Шул тиклем сихри тынлык бар иде бу табигатьтә, һәм бу тынлыкта атның тузанлы юлга баскан аяк тавышы да, ниндидер кошларның сайравы да, таңга авышкан кичнең яктылыгы да үзенә күрә бер җанлылык бирә иде.

Гәрәй, атның тезгенен ияргә бәйләп куеп, аңа ирек бирде, һәм ат үзе белгән сизем белән юлны табып, авылга табан атлады. Атта атланып килү, иярдә бер ритмда тибрәлү, атның жылысын тою, татлы уйларда йөзү – бу кичнең азагы булмасын иде дигән теләк уятты Гәрәйдә.

Югарыда, Киек Каз Юлының сөтле яланында уйнаган меңләгән йолдызлар Гәрәйгә яратып карый, шаянланып, без синең сереңне беләбез дип, аңа күз кысалар, утлы эзләр калдырып, очкыннар чәчеп, җиргә атылып төшәләр.

Инде ашлыгы сугып алынган яланнар да артта калды, биек агачлы авыл зиратын узып киттеләр, ат акрын гына авыл урамыннан атлады да таныш капка алдына килеп туктады. Тын урамның икенче башында төнге каравылдагыларның тукмак тавышы бер ишетелә, бер юкка чыга.

Гәрәй тиз генә сикереп төште дә, атны лапас астына кертеп, алдына бер кочак печән ташлады. Аңлый хуҗасының хәлләрен ат та: йомшак, җылы иреннәре белән Гәрәйнең битеннән үтте, тирән итеп тын алып көрсенеп куйды. Гәрәй аның тирле муеныннан кочаклады, каты ялына йөзен яшерде һәм күзеннән яшьләр акканын сизде. Бу мизгелдә берни кирәк түгел иде бу дөньяда, беркем дә бу чакның рәхәт минутларын бүлешә алмый иде. Озак елады Гәрәй атның муенын кочаклап, бәхеттән, өметләр чәчкә атуыннан. Шушы йомшаклык өчен чак кына оят та, кыен да иде; тозлы яшьләрнең әчелеге аңлатып бирә алмаслык хәлләрне җинеләйтә төште. Аты да аңлый кебек иде Гәрәйне: гаепле сыман башын иеп, дымлы иреннәре белән аның битенә, кулларына, муенына төртелде, тавышлы һәм йомшак итеп жылы тыны белән Гәрәйнең колагына, күзләренә өрде. Гәрәйнең башыннан малайларча шук уй үтеп китте: ат аңа, кайгырма, мин сине тагын очраштырам барыбер Нина белән дия кебек иде... Булырмы икән? Ай-һай... Степан хәзер бикләп куячак бит аны! Гәрәйнең әтисе дә беләчәк Михайловкага барганны, үзенә дә эләгәчәк. Тик монысы мөһим түгел. Ни булса, шул булыр. Атны кочагыннан ычкындырып, Гәрәй печән өстенә ятты, үлән кыягын кабып, аның баллы тәмен тойды, ә узган төндә калган йокы үзенекен итте, йокларга чакырды.

Инде йоклап китеп барган чакта да Гәрәйнең уенда бер Нина иде, һәм башка уйларны ул башыннан куды.

* * *

Хәмит үзенең дистә еллар буе килгән гадәтен бозмыйча, йокыдан иртүк торды. Гәрәйне урынында тапмый көлеп куйды – монысы инде үзенең егет чагын искә төшерү иде. Бүгенгә планнар зур – Степан белән бүлешә алмаган болын печәнен кайтарып өеп кую, бакчаны язга әзерләү, мал абзарының түбәсен караштыру. Авыл кешесенең эшен тавык та чүпләп бетермәс, монысы хак.

Карап тормасаң, эшләре бер дә бармый бу ялланган кешеләрнең. Ничек итеп шулай эленке-салынкы эшләп була икән, хезмәтенә күрә хакы да бар бит! Моңа аптырап, Хәмитнең җаны көя. Бу кешеләрнең бер аягын алганчы, икенчесен эт ашый бит! Менә бүген дә кушкан эшнең яртысын да эшләмәгәннәр, ә кояш кичкә табан авышты. Ни эшләтәсең инде ялкауны? Барып, сүз әйтсәң, кырык сылтау табалар. Бер дә юкка гына, ялкауга эш кушсаң, киңәш бирә дип әйтмиләр шул!

Авылның баерак кешеләре күптән инде тәмамлап куйдылар эшләрен, әнә хәзер җырлап йөриләр. Ә Хәмитнең эшен тавык та чүпләп бетермәс. Бер карап торып эшләтүче кирәк, тик тотмый торган кеше кирәк... Тик кайдан аласың аны? Бар да үз эшендә.

Кайдандыр, тузанын кага-кага, Сәрия килеп чыкты, аның алдыннан болыт булып, төтен исе йөгерә иде. Хәмит үзен урап үтүче кызны туктатты:

– Сәрия, чакыр әле әниеңне!

– Хәзер! – Сәрия шунда ук юкка чыкты, ул Хәмитнең кан тамырлары шартлаган кызыл күзләренә карарга да курка иде.

Хәмит эшчеләрне кугалаганчы, алъяпкычын төзәткәләп, Нәгыймә дә кереп җитте.

– Эшләр ничек, килен? Ильяс ни хәлдә?

– Рәхмәт, Хәмит ага. Рәхмәт яугыры, Прохор килеп киткәннән соң, аякка басты, күзләр генә тимәсен. Инде ашый башлады акрын гына, тотлыгып җәфаланган иде бит – анысы да үтеп бара, иншалла! Берни эшләтмим, кайткач та, үзе теләп эшли башлаган иде йорт-курада, әнә бит нинди хәлләр була язды. Өй эшенең беткәне бармы? Безнең ашлык күп тә түгел бит!

– Нәгыймә, безнең эш бармый әле бер дә. Бәлки, ярдәмләшерсең? Онытмам. Язмы, кышмы, мин дә ярдәм кулын сузармын, ә?

Бер мизгелгә уйга калды Нәгыймә. Аның Хәмиткә ярдәме беренче генә түгел.

– Ярар, мин риза. Өйгә кайтып килим инде, балаларга ни эшләргә кирәклеген әйтеп.

– Бар, бар, килен! Изгелек җирдә ятмый ул! Син элеккечә менә бу ялкауларны да кара инде, бөтенләй эшләмиләр!

Тагын кеше эше, башы да, азагы да юк бу кеше эшенең. Үзендә очы-кырые юк, ташла да башканың эшенә чум ди. Нишлисең, башка юлы юк шул!

Башын иеп, шундый уйлар белән Нәгыймә Хәмитнең бетмәс эшләренә тотынды.

Башка уйлар да борчый Хәмитне. Ике ай инде Салихтан кош теледәй дә хат-хәбәр юк. Ике ай элек язган иде Мәскәүдә торулары, пайтәхеттә тәртип саклаулары турында. Бу инде әйбәт эш, сакласыннар тәртипне.

Тәртипне бар да ярата, бигрәк тә Хәмит, япон сугышын үткән кеше, нинди бай авылның старостасы. Бишенче елда тәртипне югалттык. Ә нәрсә белән тәмамланды ул елларның азып-тузуы? Бернинди әйбәт нәрсә булмады, дөньяны утын ваклаган кебек тураклап ташладылар, әллә нинди кешеләр патшаны тиргәп йөрделәр... Азагы ни инде? Кирәк, кирәк Рәсәй халкына мичкәне кыскан кыршау кебек тәртип. Берсе дә чыга алмаслык кыршау кирәк! Шул чакта гына дәүләт яши, шул чакта гына Хәмит ихтирамлы староста булачак. Ә башкача ничек булсын? Менә, мисал өчен күрше – этисе әйбәт кеше иде, урыны оҗмахта булсын! – аның алдында баш киемен салмаса, нинди тәртип, нинди ихтирам булсын бу дәүләткә? Ихтирам кирәк властька, ихтирам кирәк власть кешеләренә. Һәм ул ихтирам ярлылырдан гына түгел, барысыннан да, байларыннан да. Моны волостьта гына түгел, өяздә дә беләләрдер!

Ихтирам, курку – менә властьның нигезе. Хәмит моны яхшы белә. Әнә язын Гәрәйне армиядән алып кала алды бит, калды! Аллага шөкер, ул янда, исән-сау, кул арасына кергән үз кеше. Әгәр этисе кирәк кешеләрне тапмаса, алар белән сөйләшмәсә, икенче улы да соры шинельдә йөреп ятар иде. Бирсен Ходай, шулай тын гына үтеп китсен, Аллаһы Тәгалә коткарсын андый кирәкмәгән юллардан. Борчыган икенче мәшәкать тә бар: кыз буй җиткән, әнисен кисәтеп кую кирәк, күз-колак булсын! Кыз бирәү генә, кем кызы бит әле – староста Хәмит кызы! Әйтәләр бит: кыз бала бит ул изге әманәт, аны вакытында тиешле кешесенә илтеп тапшыру – ата-ананың изге бурычы. Бернигә карамый илтеп тапшырырга. Староста булып эшләү дәверендә дошманнары да күбәйде, монысы инде була торган хәл. Шуңа кызны матур итеп, бөтен йолаларны үтәп, туйлар үткәреп, яңа кешеләр белән туганлашып, кияүгә бирергә кирәк. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Ә дошманнар... Алары да кирәктер тормыш иткәндә: йокламаска, артта калмаска, күпне белергә, дус-ишләр, туганнар белән әйбәт яшәргә, җитешсезлекләргә каршы торырга.

Озакламый, Алла боерса, Салих та кайтыр. Менә бит, Ходай биргәч, гап-гади авыл кешесенең улы да әфисәр булып китте. Ничек инде аның белән горурланмаска? Хәмит тә вакытында дөньяның агышын дөрес аңлады, тиешле белемен, шәһәр тәрбиясен бирде, елата-елата, бот буе гына баланы Ырынбурның Неплюев кадет корпусына илтеп урнаштыра алды.

Тик менә бәләкәен, Гәрәйне, кысып тотарга кирәк, чиктән чыгып азып бара бугай. Кулдан ычкынды! Аллам сакласын, Михайловкага, Степан кызы янына йөри диләр. Йа Ходай! Булмас, булмас, динле кеше, яхшы ата баласы алай итмәс! Әстәгъфирулла, тәүбә, тәүбә! Аллам, үзең сакла, бәхетле озын гомер бир миңа һәм балаларга!

Кичә килеп киткән Сафа мулла белән сөйләшү әле дә күз алдында. Наган таккан мулла староста белән ипле генә сөйләште сөйләшүен, тик эчендә ни янганы күренеп тора. Сөйләшүнең азагы шул: малайны марҗадан аерырга, тыярга, тыймасаң, икенче юллар табарбыз. Монысын инде янау дип кабул итәргә кирәктер, ә ничек башкача? Янау инде. Син болай ит, син тегеләй ит, имеш. Матур гына башлап сүзне, әнә, ничек итеп тәмам итте. Онытты барын да: староста белән сөйләшүен дә, үзенең дин кешесе булуын да, мондый дорфа итеп сөйләшергә бер нинди вәкаләтләре булмавын да.

Әлеге сөйләшү, Хәмитнең канын кыздырып, тагын күз алдыннан үтте. Ярым дин кешеләренчә, ярым авылча киенеп килеп керде Сафа Хәмиткә итекләрен ялтыратып.

– Әссәләмегаләйкүм, Хәмит ага!

– Вәгаләйкүмәссәләм!

Дога кылдылар. Сафа шунда ук үз йомышына күчте.

– Kһем-kһем! Хәмит кордаш, мин бик авыр хәбәр ишеттем. Синең кече малаең Михайловкага Степан кызы кырына йөри диләр. Син беләсеңдер инде бу эшләрне? Бәднам, яманатың чыга бит!

Хәмит тын калды. Ишеткәне бар, тик мондый ук дәрәҗәгә барып җитүе!

– Буш сүз, хәзрәт, буш сүз бу! Нинди марҗа булсын ди саф мөселман гаиләсендә?

– Ә минем белүемчә, буш түгел. Ярар, тел чарлап торырга вакытым юк. Кордаш, туктат малаеңны бу шайтан котырткан эшләрдән. Нинди үрнәк бирәсең син башкаларга, ә? Kһем-kһем! Үзең булдыра алмасаң инде, без табарбыз җаен да, ысулын да.

Сафа, Хәмитнең җавабын көтеп тә тормыйча, итеген шырт-шырт итеп, чыгып та китте. Мондый оятны Хәмитнең шушы яшькә җиткәнче күргәне дә, ишеткәне дә юк иде.

Торып тор, ашыкма, мулла азгыны, менә озакламый Салих кайта, карап карарбыз, кем кемгә янар.

Тик, ничек кенә булмасын, дөрес сөйли Сафа мулла. Ничек инде гасырлар буена тупланган гореф-гадәткә каршы чыгып була? Башкалар юлны тапканчы, Хәмитнең үзенә иң туры юлны табарга кирәк тизрәк бу мәшәкатьтә.

Әнисенә дә ныгытып әйтеп куярга кирәк, карасын. Авылларда бу турыда күп сөйлиләр, имеш. Кеше сөйләвен дә тыярга кирәк, алайса әлеге дә баягы дошманнарга таратырга бик уңай бер гайбәт булыр. Шушы малай актыгы аркасында ихтирам да кими бит старостага.

Менә сиңа мөселман! Аз тырыштымы Хәмит аны рухлы итеп тәрбияләргә? Ә ул? Марҗа кирәк булган дисең инде, ә? Нәрсә белә ул, юеш борын? Марҗа... Батыр үлеме марҗадан, ди халык.

Соң, үзебездә ошаганы булмаса, башка авыллар бар, кирәк икән, шәһәренә алып чыга алам. Тирә-якның һәрбер кешесе туганлашырга тора, кызына өстәп байлыгын бирергә әзер. Ата-бабасын хурлыкка калдырып... Вәт селәгәй! Күптән минем кулның катылыгын татыганың юк шул! Татырсың хәзер! Тыңламасаң – каргыйм, ыштансыз-күлмәксез калдырам! Ата фатихасыннан башка ерак китә алмассың.

Йә булмаса армиягә җибәрәм. Ә нигә, бу яшьләрне аерып булмастай була калса, армия – бердәнбер чара. Аерып җибәрү, тәҗрибәдән чыгып әйтү бусы, була торган эшкә охшамаган. Барсын, йөреп кайтсын. Кайчандар бу сугыш бетәр бит?

Булды. Карар үзеннән үзе килеп чыкты, үзеннән үзе кабул ителде. Армия! Анда барганнар бар да сугышка эләгә дигән сүз түгел әле, Алла кушканны үтәрбез.

Кем кызы бит әле! Дошманнарның дошманы булган Степан кызы! Башкасы булса, бәлки, гафу да итәр идем, яшь чакта ниләр булмый, гафу

ит бу сүзләр өчен, Ходаем! Бу Степан кызы белән – беркайчан да гафу итү юк! Минем соңгы сүзем шул бу хәлдә. Бүген үк сөйләшергә, кирәксә, үгетләп карарга, аңлатырга. Ташласын ул бу эшен.

Шундый уйларга бирелде Хәмит намазлык өстендә. Дога укуны тәмамлап, соңгы тапкыр Алла исемен әйткәндә, куллары күтәрелгән килеш эленеп калды. Шул вакытта гына ул, башка уйлар белән мавыгып, намазны тәһарәтсез башкарганын аңлады...

Тирән ыңгырашу тавышыннан өйнең буралары селкенгән сыман булды.

Йортка йөгереп чыгып, ул тыныч кына йоклап яткан Гәрәйне тапты. Стенада эленеп торган тезгенне алып, бар көченә Гәрәйнең аркасына берне сыптыртты. Гәрәй эссе су сипкәндәй сикереп торды, йокыдан айнымаган зур итеп ачылган күзләре белән әтисенә карап, бер үк сүзләрне кабатлады:

– Әти? Нишлисең? Нәрсә булды?

– Эт баласы, синең аркада, синең аркада!..

Куллары белән битен каплап, бер сүз әйтми тик кенә басып торган Гәрәйгә Хәмит тезген белән суктыруын белде.

– Монысы миңа төшкән оят өчен! Монысы шушы яшемдә, халык көлеп, исемемне чәйнәгән өчен! Монысы Степан кызы өчен! Монысы гореф-гадәтне санга сукмаган өчен! Монысы маржа өчен!

**23**

Пётр Алексеевич Ташкинов белән Пётр Васильевич бик озак сөйләшеп утырдылар. Күз алдында дөнья җимерелә, чиктән чыгып, бушка әйләнгән су тәгәрмәче буаны, тегермәнне җимерүгә алып барган кебек, аны һәлакәткә илтә. Әле туктатып та буладыр, ә бераздан инде, кире кайтара алмаслык тизлек җыеп, дөньяның астын өскә китерәчәк идарәсен югалткан тормыш.

Алар икесе дә бер уйда иде. Матусовның хәле авыр, аңарда әле дөнья кайгысы бөтенләй юк, кем белә, кайчан ул элеккеге торышына кайта алыр?.. Бүген властька бернинди дә ышаныч юк, беркем берни эзләмәячәк. Кызганычка каршы, беркемгә бернәрсә дә кирәк түгел. Сүзне шуннан башладылар да алар: тикшерүгә үзләре тотыналар, җай гына, тыныч кына, ипле генә. Алдан ук сүз биреп куйдылар – үч алу каты булачак, елгачыларның язылмаган кодексын әле беркем дә кире какмаган.

Ташкинов беренче булып сүз башлады:

– Петя, мин такелажны тикшерттем. Аларның бәйләнгәне бәйләнгән, бер өлеше балта белән чабылган. Ул баркада бар да бик йомшак бәйләнгән. Башкалары Әстерханга китте бит инде, аларда ничектер, белмим. Ә монда...

Пётр Васильевич урынында сикереп куйды, авызыннан ямьсез сүзләр дә чыгып ычкынды:

– Мин шулайдыр дип уйлаган идем дә! Нәрсә эшлибез?

– Безнең хуҗада дөнья кайгысы бетте. Тик бу хәлне тикшерергә кирәк, гаеплеләр тиешле җәзасын алырга тиеш.

– Риза! Бүгеннән. Мондый оятсызлыкның бездә булганы юк иде әлегә. Шуңа күрә барлык әйткән сүзләрең белән килешәм. Әлениләр эшли алдың соң?

– Башкалар өчен урманга җибәрдек дигән сәбәп белән каравылчыны, бәйләүчеләрне бикләп куйдым. Беркем белми аларның бикле икәнен. Әйдә, барып сорау алабыз!

Пётр Васильевич тешләрен шыгырдатты:

– Әйдә, тик мин аларны үтереп куярмын дип куркам.

– Монысы әлегә кирәкмәс. Кушучыларын, башкаручыларын белик башта, аннан соң елгачыларның йоласын үтәрбез. Ух! Нинди җәза һәм ничек үтәлә, сиңа сөйләп торасы юк!

– Юк, юк! Тик белергә генә кирәк кемнәр икәнен!

Йөгереп диярлек бардылар Аккош күле янындагы аерым торган мал караучылар йортына. Җәен ул йорт буш тора, маллар яланда, каравылчылар анда кереп тормыйча гына кайтып-китеп йөриләр, көтүчеләр турыга көтүгә чыгалар иде.

Пётр Васильевич ишекне каерып ачты да каравылчыны, якасыннан өстерәп, йортка алып чыкты:

– Әйдә, Сафарка, сөйлә, кем такелажны балта белән тураклады? Смотри, если әйтмәсәң йә алдасаң, сразу Танып төбенә китәсең.

Сафарка дигән абзый куркуыннан калтырана ук башлады.

– Туктап тор, Пётр, сорау бирергә кирәк, и җавап көтәргә. Сафар, скажи, ят кешеләр килгәне булмадымы Гәвенгә бу айда?

Абзый уйга калды. Күренеп тора, ул, календарь актаргандай, хәтерендәге көннәрне артка табан ташлый иде. Менә ул туктап калды:

– Сентябь башында Казанлыдан бер мужик үтеп китте. Шунда барка читенә утырып, тәмәке тартты, тирә-якка карап утырды. Мин ут чыгарырсың дип, баркадан куып төшергәч, авылга кайтып китте.

– Кем ул? Исеме? – Пётр Васильевич, каравылчыны тагын куркытып, кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

– Күзенә ак төшкән... Я... Я... Ярми!

Ике Петя бер-берсенә карадылар. Боларның берсен тапкач, икенчесен табу зур эш түгел. Каравылчы белән нишләргә? Гаебе юк, тик телен тыеп йөри алырмы?

Пётр Алексеевич, зирәк, акыллы кеше буларак, аңа табан борылды.

– Менә нәрсә, Сафар! Синең берсеннән-берсе бәләкәй биш балаң бар, әниең олы яшьтә, караватта синең күзгә карап ята. Алай-болай... – кабатлыйм, алай-болай без синнән сораганны берәр кеше ишетсә, смотри: өеңне балаларың белән яндырам, үзеңне – Танып төбенә. Ышанасыңмы?

Абзый куркып, бу сүзне кабатлады да кабатлады:

– Ышанасыңмы? Ышанасыңмы? Ышанасыңмы!

– Ярар, бар әлегә!

Каравылчы, баш киемен култык астына кыстырып, тирә-ягына карана-карана, нидер сөйләп, авыл ягына ашыкты.

Ташкинов бераз башын чайкап утырды да Петяга эндәште.

– Монысы, Ярмине әйтәм, явно башкаручы. Аңа безнең эшләр кирәкми дә, кирәк тә булмаячак. Простой бандит, юлбасар. Чернушка юлында кеше талап йөргән качаклар командасыннан. Нигәдер утыртмадылар аны, откупился, видать.

– Бәйләүчеләр белән дә сөйләшик?

Алары икәү иде. Караңгы баздан чыккач, кояштан күзләрен кысып, хәлне аңларга тырышып, бик озак басып тордылар. Ташкинов сүз башлады:

– Сезнең аркада ике яшь баланы югалттык. Йөк бәйләнмәгән, осадканы

тикшермәгәнсез! Барканы неуправляемый ясагансыз. Елгачыларның язылмаган законнары буенча моның өчен сезне нинди җәза көткәнен беләсездер?!

Бусын әйтмәсә дә, аңлашыла иде, эшчеләр бу кәсептә беренче көн түгел. Олырагы җавабын башлады:

– Пётр Алексеевич, син безне беләсең. Мин егерме елга якын служу верой и правдой! Моңа тиклем булганы юк иде бу эшнең. Бәйләү – һәрвакыттагыча, үзем тикшереп, карап тордым. Ул барка бик җиңел, бик җитез, кош кебек. Шуңа азрак канатларын чыгарып төядек – монысы минем уйлап тапкан ысул, моны да беләсең.

– Беләм монысын!

– Кичә Гәвенгә китереп ташлаган барканы тагын бер кат карап әйләндем. Бер төене дә минекечә бәйләнмәгән, миндә бит япон сугышыннан алып кайткан диңгез төене. Моны да беләсең. Димәк, без тиешенчә эшләгәнбез, безнең арттан иртәнге якта төеннәрне кемдер сүтеп, яңадан бәйләп чыккан, сүтә алмаганын балта белән чапкан. Алла каршындагы кебек ант итәм! Без гаепле түгел монда!

Ташкинов бәйләүченең бөтен алымнарын да белә, шуңа ул аңа ышана иде. Егерме ел бергә эшләве дә бар. Шулай да ул сорауларын бирә торды:

– Без белмәгән, чит-ят кешеләр йөрмәделәрме ул көннәрдә? Бәлки, терекөмеш турында берәр нәрсә ишеткәнсездер?

– Ят кешеләр булмады. Казанлыдан килеп йөрделәр. Тик алар ятмыни инде?

– Кем? Кем ул? Исеме? – Пётр Васильевич тагын түзмәде, ыргылып торды урыныннан.

– Ә ул адәм Казанлыдан, шадра битле!

Пётр Васильевич бу юлы тагын кычкырып җибәрде

– Тамырбулат!

– Ну да, ул.

Әлегә ике кеше җәтмәгә эләкте. Тик анда эләгү алар гаепле дигән сүз түгел. Гәвен дә, су тегермәне дә кешеләр өчен ябык урын түгел, алар килә дә, китә дә алалар, шуңа боларны күреп, усал итеп сөйләшергә кирәк әле башта.

Бәйләүчеләрне, бик нык кисәтеп, өйгә кайтарып җибәрделәр.

– Лексеич, әйтергә дә куркам. Кушучы безнең күптәнге таныш түгелме икән? Тын гына арага керергә маташып карады бит ул ничә тапкыр. Барып чыкмады. Әле самый дөнья буталган чак, ул сәясәтнең кая барганыннан яхшы хәбәрдар...

– Син... син теге аксакны әйтәсеңме? Минем башны да бораулый шул борау әллә кайчаннан бирле бит... Неужели?

– Булмас димә...

– Ярар, тикшерик әле дальше. Ничек кенә йомгакны урама, очы бер килеп чыга аның! Әгәр без уйлаганча булса, эшләр хәтәр. Сак булырга кирәк. Бу гади дошман гына түгел, дошманның да иң явызы! Иң хәллесе!

Хәзер алда ни эшлисен ныклап уйларга кирәк иде. Шунда ук Пётр Васильевич үз фикерен әйтте. Башта Ярмине тотып алып чыгып китәргә кирәк. Теге икенчесе – каторжан, аның белән сөйләшү авыррак булыр,

монысы гап-гади юлбасар, куркытып та була, кирәксә. Әләгер урыны була калса, тегесе дә әллә кая баралмас. Бүген халык яшьләрне армиягә озата, соң ятачаклар, шуннан файдаланып эләктерергә кирәк Ярмине.

Пётр Алексеевич:

– Ярдәмчеләр кирәкмәсме? – дип сорады үч алырга янып торган Пётр Васильевичтан. Тегесе тулысынча дәлилле кире җавап бирде:

– Юк! Без бит эшне судка илтеп җиткерергә уйламыйбыз. Безнең бурыч – аларны җәзасыз калдырмау. Бу очракта кеше күп булса, шаһитлар да күбәя. Ә безгә кирәкме бу?

Ике Петька әлегә шулай дип килештеләр.

**24**

Ильяс, акрынлап кына, тагын йөри башлады, сөйләшүе әйбәтләнде. Прохорның дәвасы, аның шифалы куллары, калдырып киткән дарумайлары ярдәм итте. Бөтен интеккәне – хәлсезлек, хәрәкәтнең чикле булуы. Монысына да түзде ул, акрынлап бусы да үтә башлады. Шул арада берничә тапкыр Никонов белән сөйләшеп утырдылар, аның биргән киңәшләрен ул хәтерендә калдырырга тырышты, дөньяда булган яңа карашлар белән танышты. Аның башында сәясәт буенча аңлаешлы, халыкка гади сүзләр белән аңлатырлык тәгълимат нигезе барлыкка килде, һәм ул шуның буенча Яков Константинович белән әллә нинди бәхәсләргә кереп бетте.

Бәхәсләрнең тирәнлеге Ильяс ягыннан әллә ни дәрәҗәдә булмаса да, Никоновның сөйләшә-аңлата белүе аңа инкыйлаб белемен күтәрергә генә түгел, ә дөньяга, кешеләргә, фиркаләргә аек фәлсәфи караш формалаштырырга мөмкинлек бирде. Бусы инде иң кирәклесе, чөнки, Никонов әйтүенчә, максатларын, шул максатларга илтә торган юлларын белми торып, инкыйлабка суга ташланган кебек ташланырга ярамый. Инкыйлаб – үз өермәсенә миллионлаган кешене тартып кертә торган ташкын, ул ташкында һәрбер язмыш әйләнә, бата, калка, юкка чыга, һәм кеше язмышы белән уйнарга беркемнең дә хакы юк. Инкыйлаб кеше өчен эшләнә, димәк, аның нәтиҗәләре дә беренче булып кеше мәнфәгатьләренә юнәлдерелгән булырга тиеш. Тик «тиеш» белән «булачак» – аралары ерак булган икесе ике нәрсә, аларны якынайту, тормышка ашыру – инкыйлабның зур бурычы.

Тагын бер шатландырган вакыйга булды – ул Казаннан хәбәр, анысын Чернушкага кайтучы кеше аша җибәргәннәр. Хатны бик тәфсилләп, озын итеп, ару-талуны белми торган Камил Якуб язган. «Мәктүбемнең иң беренче юлларында ук үзебезнең исән-сау икәнебезне белдерәм. Эреле-ваклы эшләргә чумып, алны-артны да күрмичә, дөньяны алга куабыз, Ильяс туган».

Бер мизгелгә Ильяс шаулап торган Казандагы эреле-ваклы эшләрнең нинди булуын күз алдына китерде. Булыр эреле-ваклы! Мондый егетләр тыныч кына шул эшләр арасында йөзмәс! Үзләре агымны үзгәртеп, тизләтеп, юл күрсәтеп баручылар бит алар!

«Казан кайный, Петроградта һәм Мәскәүдә булып яткан хәлләр безне дә биетә. Бүген-иртәгә яңа инкыйлаб башланырга тора, кояш бу юлы да көнбатыштан чыгачак! Яңа уйлар шул тиклем күп, планнарыбыз Рәсәйне, милләтебезне әллә нинди биеклекләргә алып менәрлек. Янабыз, көябез, йөгерәбез, чабабыз, дустым! Син дә анда йоклап ятма! Бәйнәлмиләлдә –

бөтен илләр эшчеләренең гимнында җырланганча: «Кузгал, уян, ләгънәт ителгән коллар һәм ачлар дөньясы!»

И-их, ничек аңлатырга әлегә сугыш шаукымы үзеннән җибәрмәгәнен! Бераз ятарга туры килде бит. Җавап хатында монысын да язарга кирәк, Никонов биргән дәресләр турында да бер-ике сүз кирәк. Мондагы вазгыятьнең дә гади булмавын әйтергә, эренле шешнең бүген-иртәгә тишеләчәге турында да онытмаска кирәк.

«Милләт, дигәннән. Ниһаять, ул турыда да чынлап торып уйлый башладык. Хөррият бит ул бөтен кеше өчен дә, ул милләткә карамый. Ә милләтләр тигез үсештә булырга тиешләр! «Беренче милләт» йә «Соңгы урындагы милләт» дип мөһер сугылган милләтләр юк! Шуңа күрә дә без татар милләтенең язмышы өчен кайгырабыз, башкорт дусларыбызны да онытмыйбыз. Июль аенда Беренче мөселман сугышчылары Корылтае һәм Беренче Бөтенрәсәй мөселманнарының Корылтае үтте. Аларның бергәләп үткәргән утырышында айның егерме икесендә Эчке Рәсәй һәм Себер мөселманнарының Милли-мәдәни үзаллыгы игълан ителде. Шунда ук Милли Идарә оештырылды. Кем дип уйлыйсың Идарәнең рәисен, Ильяс дустым? Безнең Садри дус Максуди! Казанга килгәч тә, мин сине аның белән таныштырырмын. Ә-ә, менә нәрсә тагын да: Максуди тәкъдиме буенча Милли Мәҗлес булдырылды. Ул Уфада урнашкан, монысы синең өчен бик уңай булачак инде. Менә шундый хәлләр, туган!»

Моңа тикле кем уйлаган милләтләрнең үсеше турында! Тигезлек бар дип әйтеп булмый шул әлегә. Кемнәрдер йөз елга артта калган, кемнәрнеңдер үсешен махсус тоткарлап та киләләр, кемнәрдер тарихның киң юлына яңа гына чыгып килә.

«Бармы сиңа табан тартылучылар? Сөйләшенгәнчә, сугыш тәҗрибәсе булган кешеләр белән мөнәсәбәттә торасыңмы? Большевиклар бармы сезнең якларда?»

Тартылучылар аз түгел, монысы шатландыра. Алар арасында сугышны үткән кешеләр дә күп. Большевикларга килгәндә инде... Болары юк Казанлы, Аскын, Балыкчы волостьларында. Хәер, бер кеше бар, диләр. Ул Гордино һәм Леун авылларында яшәүче урманчы Антипин. Хатны җибәргәнче, барып, аның белән танышып килергә кирәк.

«Дустым, синнән гәзитләргә өзелеп хәбәр көтәбез бит. Инде тирә-ягыңны әйбәт өйрәнгәнсеңдер, кемнең кем икәнен дә белгәнсеңдер. Безне кызыксындырганы – нинди каршылыклар бар бүгенге авылда. Кем белән кем арасында. Халыкның большевикларга булган мөнәсәбәте, аларның җир турындагы, тынычлык турындагы вәгъдәләренә карашы. Одним словом, русчалатып әйткәндә, яз барысын да. Югалма, дустым! Йә без алга чапкан паровоз вагонында, йә чак-чак баручы арык ат арбасында!»

Боларына инде җавап бар. Ул җавапны, берәр җаен табып, тиз генә җибәрергә кирәк!

## 25

Антипин, Леун, Гордино – бу өч исем Ильяска берничә көн тынгылык бирми иде инде. Авылларның кайдалыгын якынча белә, тик ул якларда бөтенләй йөргәне юк. Үзенең хәлен дә истә тота – берүзе бару турында

уйлау да дөрес түгел. Ә кем белән? Уйланып йөри торгач, ул Ризванны искә төшерде. Менә ул – тирә-якны уч төбедәй белгән бердәнбер кеше! Урманны да, юлларны да, юлсыз урынын да, кешеләрен дә, тагын әллә ниләр белгән кеше бу якларда бер Ризван.

Ильяс кичкә таба озын урам буйлап Казанлының түбән очыннан үрге очына Ризваннарга атлады. Урамның озынлыгын атлаган гына белә, атлый торгач, ул чак кына Елга башына тикле барып җитмәде.

Ризванның йортында эш кайный иде. Җилгәргечләр эшли, ашлык сугу машинасы гөрли, берничә ялланган кеше алар тирәсендә орчык кебек әйләнәләр. Алардан ерак түгел әвеннән, арыш саламы кылчыгына уралып, төтен исе иятреп, Ризван үзе дә килеп чыкты. Сөйләшер өчен тавышлы урыннан читкәрәк киттеләр. Ильяс шунда ук нигә килгәнен әйтеп салды, араның ераклыгына зарланды.

– Ә нигә ерак дисең син ул араны? Күпме дип уйлыйсың?

– Күпме дип... Аскынга илле булса, аннан – утыз. Менә сиңа, аз дигәндә, сиксән чакрым бер якка!

Ризван көлеп җибәрде:

– Ә хәзер кыскартабыз ул юлны. Аскын бөтенләй читтә, әллә кайда кала. Казанлы, Мута Елга, Олы күл, Төлгеж баш, Яңа Карыш, Тюйск, Леун – барлыгы алтмыш тирәсе, бәлки, азрак та. Анда урман юлы бар.

– Алай булгач, бөтенләй кыскара икән?

– Кыскара. Барышлый тагын җаен табарбыз әле. Кайчан чыга алабыз?

– Ә нәрсә көтәргә? Һава торышы әйбәт, яңгыр юк. Болай торганда, иртәгә үк. Арба беләнме, әллә иярдәме?

Ризван бик тиз җаваплады:

– Иярдә. Иртән иртүк, көтү белән. Юл уңаеннан бит, мин үзем төшеп җитәрмен сезгә.

– Ничә көнгә чамаларга инде?

– Ике. Ике көн ярым. Барысы да без уйлаганча, Алла кушканча булса.

Ильяс та, күңеле күтәрелеп, шатланып, кайтыр юлга атлады. Җыясы әйберләр бар, атны карыйсы, ашау-эчүен онытмаска...

Ильяс, иртән торып, атын иярләгәндә, Ризван, килеп, кыска гына камчы сабы белән сак кына тәрәзәгә тидереп алды. Шунда ук капка ачылды, атын җитәкләгән Ильяс та чыгып җитте.

Киттеләр.

Авылда туып үссә дә, Ильяс, юлга чыккач, бик күп нәрсәне белмәгәнен аңлады. Һәр үләннең, агачның, һәр ташның үз исеме бар, һәр урман-кыр борылышының, елгаларның, күлләрнең атамасы бар, табигатьтә һәр нәрсәнең кеше тормышында файдалану юллары бар икән! Ялан җирләрне чаптырып, урман-куаклы урыннарны тар сукмактан бер-бер артлы үттеләр. Кояш төшке аш вакытына күтәрелгәнче, авыл башында җәелеп яткан тирән Олы күлгә дә килеп җиттеләр. Ризван тагын ачып җибәрде белем сандыгын:

– Бу күлнең төпсез урыннары да бар, диләр. Берничә ел элек монда унике дилбегә төшереп карадылар, тик барыбер төбенә төшеп җитә алмадылар.

– Унике дилбегә! – Ильяс бу озынлыкны күз алдына китерде.

– Әйе! Монда берничә күл, алар барысы да тоташкан дип тә сөйлиләр.

Бер елны шулай берсендә балыкчылар көймәсе җилдә әйләнә. Кешеләр ярга йөзеп чыга алалар, ә көймәләре яз көне икенче күлдә килеп чыга.

– Икенче елда?

– Әйе!

Авыл эченнән үткәндә, Ризван урамда кеше булмавына игътибар итте. Халык эштә. Җәйнең бер көне елны туйдыра диләр. Мондый коры көз тик ятмаска куша, кышка әзерлекне баета торган көннәр икәнен истән чыгармаска чакыра.

Ризван Ильяска борылды:

– Олы күлдән соң тагын бер авыл, Төлгеж баш, аннан соң Карыш урманнары. Минем тәкъдим – аларны үткәч, ял итеп алырга. Атларны ашатырбыз, үзебез азрак язылырбыз.

Ильяс берсүзсез ризалашты, ризалашмаслык та түгел инде, Ризван белгәнне тагын кем белсен. Шатланып, узган һәр чакрым саен Ризванның табигать белән аралашуында зур өстенлек күреп ризалашты.

Алар узган авыллар төзек, салам түбәле өйләр ара-тирә генә күренә, йорт-куралар җыештырылган, җыйнак һәм каралган. Бер яктан урман терәлеп торса, икенче яктан халык тырыш, матурлыкны күрә белгән, ихтирам итә белгән, шуңа омтылган халык. Нидер эшли, тик ятмый торган халык – әнә бит әле дә авыл урамнарында уйнап мәш килүче бала-чагалардан башка беркем күренми, бар да мәшгуль.

Менә Ризван әйткән Карыш урманнарына да җиттеләр. Ильяс җавап көтмәсә дә, соравын бирде:

– Ә каян килеп чыккан монда Карыш исеме? Күрше волостьта ике авыл бар шундый исем белән. Алар монда күчеп килгәннәрме?

Ризван шунда ук җаваплады:

– Үзләре сөйләгәнчә, Яңа Карыш, чынлап та, Батырша ихтилалыннан соң урман эчендә шул яктан качып килгән халык салган авыл. Йөз иллеләп кенә кеше яши, зур түгел ул. Ә урманнары инде – андый кара урман башка җирдә юктыр да. Үтеп булмаслык!

– Кайда кунабыз? Авылны чыкканчы, бәлки, кунарга сорарбыз?

Ризван көлеп җибәрде:

– Кеше җәфалап, үзебезне уңайсыз хәлгә куеп, хәерче кебек сорашып йөрмибез. Тагын ун чакрым барабыз да урманда кунабыз. Бер мәртәбә урманда кунсаң, син моны гомергә дә онытачак түгелсең, һәрвакыт барасың килеп кенә торыр!

Ильяс каршы түгел. Сугышта окопта кунып кына түгел, яшәп өйрәнгән кешегә берни дә түгел инде ул. Атлар үз иркендә: йә чабып алалар, йә саф һавада юыртып кинәнәләр, йә ашыкмый гына атлыйлар. Көн саен ат белән бергә булган кеше өчен ул әллә нинди күңел күтәрерлек халәт бирә, тора-бара ат белән ике арада нindидер берләшү барлыкка килә, бер-берсе өчен җаваплылык, икесе бергә чакта гына була торган галәмнән килгән тигезлек хөкем сөрә. Шуңа да бу үзенә күрә бергәлек, бердәмлек дөнья тотып килергә мөмкинлек бирә, ат гаилә әгъзасы булып китә, тугрылыгы, хуҗасы өчен җанын фида итәргә әзер торуы белән үзенә карата мәхәббәт яулый.

Ризван әйткән унбиш чакрым артта калды. Тагын да барырга дәртләре бар иде барын, тик Ризван беренче көнгә җитәр дигән фикер әйтте. Ильяс

аның сынаулы караш белән карап, хәлен бәяләп торуына инде күптән игътибар итте. «Менә нинди ышанычлы кеше Ризван!» дип эчтән генә уйлап куйды ул, Ризван кебек кешеләр булуына шатланып, аның кешелеклелегенә сокланып.

Үлән эчендә күренми дә яткан чишмә янында кыска гына вакыт эчендә шалаш барлыкка килде, казан асылды, аш куелды. Шалаш эчендә чыршы ботакларыннан калын түшәк ясалды, учак өчен төн буена җитәрлек утын да әзерләнде. Балта һәрчак кул астында, тышауланган атлар күз алдында, аларның озынайтылган тезгене шалаш аша үтә. Тик бер нәрсә җанны телә – болыт кебек очып, бер мизгелгә дә тынгылык бирми торган черкиләр. Бар икән Ризванның монысына да каршы даруы – дегет исе килеп торган бер майны сөрткәч, «Яшисе килә башлады!» – дип көлде Ильяс.

Аш ашагач, чәй эчкәч, ылыс өстендә учакка карап ятып, тел төбендәге сүзен башлады Ильяс:

– Ризван, минем бу ерак авылга баруның сәбәбен син сорамадың, мин әйтмәдем. Шул турыда сөйләргә иде исәп.

– Кирәк тапсаң, әйтерсең дип уйлаган идем мин.

– Кирәктер. Сугыштан кайтканда, Казанда тукталган идем. Шунда бик ипле кешеләр белән таныштым. Алар бүгенге сәясәтнең уртасында кайный торган иптәшләр, ни буласын алдан белеп торалар. Ә алда тагын бер инкыйлаб көтелә, аның артыннан ата – улы, туган туганы белән сугыш башлаячак. Монысы инде туктатып булырлык түгел.

– Ничек инде, йә ярман белән сугыш, йә үзара? Бу дәүләтнең акылы бармы, юкмы?

– Менә шул дәүләтнең бер эшкә дә ярамый торган хөкүмәтен алыштырырга кирәк!

– Бу бит тагын инкыйлаб! Кем килә ул хөкүмәт урынына? Бармы аны алыштырырлык?

– Бар. Большевиклар.

– Кемнәр инде алар?

– Большевиклар җирне тигез итеп бүлү турында, тынычлык, сугышны туктату турында сүз алып баралар. Шуннан ярлы халык властен оештыру, байларның кеше канын эчеп җыйган байлыгын тартып алу.

– Кемгә кирәк инде җир? Әнә бездә күпме телисең! Тик күбесе кирәген генә эшкәртә. Миндә дә кешедәге кебек ун десятиннан әллә ни күп түгел, чөнки кирәге юк. Миңа җитә, гаиләне карарлык, артыгын сатам. Башкалар да шулай ди. – Ризван башын чайкады. – Ай-һай, табарлар микән большевиклар үзләре артыннан баручыларны. Бәлки, башка якларда җирнең аерым кадере бардыр, тик бездә түгел. Бездә җир кеше өчен, башка якта ул кешене кешедән аеру өчен.

– Ә байлар?

– Ә безнең Казанлыда кайда күрдең ул байлыктан шашкан, черегән байларны? Кемне генә алма, кан эчеп түгел, тир түгеп мал тапкан. Мөхәммәтҗанны ал – ялчы булып башлады эшен, Матусовны ал – әллә кайдан килеп, монда бер ат белән урман ташучы булып башлаган кеше. Башкаларын әйтеп тә тормыйм.

– Барысы да шулай булса соң? Сәләхетдинне ал! Сату эшен кеше талап башлады.

– Бер кеше. Менә мине алыйк. Әйе, ялчылар бар, җилгәргечләрне, молотилканы эшләтү бер кеше эше түгел. Әйе, тагын башка авылларда ике өем бар. Мин дә шул кан эчүчеме? Мин, гади генә итеп әйткәндә, эше пешә торган, эше уңучан кеше. Аллага шөкер! Тик тырышлыгым аркасында. Минем кебек кешеләрне «бүресе улаучан» дип тә атыйлар. Син беләсең, бүре бер дә юкка гына уламый! Бары тик кирәксә генә улый!

– Анысы шулай инде шулаен да...

– Ә нәрсәсе шулай түгел ди әле? Ул өйләрне мин бит берүзем, берүзем төзедем! Кирәге дә булмагандыр, бәлки. Тик мин яратам ул эшне! Менә килеп керделәр, ди, минем шул мөлкәтне бүләргә. Мин нишләргә тиеш?

– Алай нахакка рәнҗетүгә барып җитмәстер дип уйлыйм.

– Булмасын! Миңа тимәгез, мин дә сезгә тимим! Ә тия калсагыз, өч мылтыгым бар, патрон беткәнче атышырга булдырырмын!

– Ә тынычлык? Күпмегә сузылыр сугыш?

– Монысына да җавап бар, әле генә әйттем: өеңә, таларга дип, дошман керсә, аны чәй эчереп утырырсыңмы инде? Сугыш тәмамланырга тиеш, тик җиңү кирәк. Җиңү! Берсен җиңелеп тәмамладык, шунда ук инкыйлаб килеп чыкты. Монысында да җиңелә башладык, патшаны бәреп төшердек. Тагын җиңелсәк, менә шунда син сөйләгән хәлләр килеп чыгачак та.

Ильяс үз сүзләренең бер дә ышандырырлык булмавын аңлады. Таныш, дус кеше белән сөйләшкәндә дә, ул аны ышандыра алмады, ә ничек төрле фикерле халык төркеме белән элемтәгә керергә? Антипинга бару дөрес, сукыр бер тиенлек тә тәҗрибә юк Ильяста.

– Ярар, шулай да булсын, ди. Әгәр мин сөйләгәннәр чынга ашып, шул туганнар арасындагы сугыш чыкса?

– Минем җавап бер: миңа тимәгез, мин дә сезгә тимим! Бик кычытынсагыз, әнә, сугышыгыз, бер-берегезнең бугазын чәйнәгез! Мин катнашмыйм бу эшләрдә.

– И-их, алай гына булса ул, Ризван!

Бер мизгелгә тынлык урнашты. Шул арада әллә кайда мылтыктан аттылар, ерак паровоз гудогына охшаган тавыш та ишетелеп калды. Калган тавышлар – урман тавышы, анысы инде урман кануннары буенча бара торган тормыш тавышы иде. Ризван дәвам итте:

– Юк, мин аңлыйм барысын да, Ильяс. Урамның теге башында сугыш булганда, бу очта битараф булып, кул кушырып утырып булмый. Тик шулай да мин үз уемда.

– Гомердә булмаган хәлләр булды, булырга тора илдә. Ни булырын кем генә белә!

– Карап карарбыз! Минем таянган ноктам бер, әйттем бит инде аны – миңа тимәгез, мин дә сезгә тимим! Тимәгез кешегә! Ул ирекле булып туа!

Ризван, торып, сүнә барган учакка утын ташлады. Бер өем чаткылар караңгыланган төнне яктыртып, күккә очтылар. Шуннан ул сүзен дәвам итте:

– Кешедә кешенең кайгысы юк, һәркем үзе өчен яши, үз язмышын үзе кора. Ничек инде ул гомер буе җыйган малны тартып алу? Бу эшләрдән соң

большевиклар ихтирам казанырлармы инде? – Ризван ятарга комачаулаган ботакны астыннан тартып алып, сындырып, учакка ташлады. – Менә, кара. Безнең авылда меңләгән кеше яши. Син әйткән ярлыларның саны – бармак бөгәрлек. Нигә алар ярлы – анысын да беләбез.

– Беләбез, тик алар да әйбәт тормышка хаклы.

– Әйе, хаклы. Тик мин, көне-төне эшләгәнгә, алардан әйбәтрәк, мулрак яшим, ә ул бит мин эшләгәндә йә йоклап ята, йә эчеп йөри. Эчеп йөрсә дә, минекенме, башканыкынмы – мөлкәтен санап та йөри! Ул да көтә вакыты килеп җиткәнне! Эләктерергә бүген үк әзер!

– Эчә торганнары бик сирәк инде ул!

– Ә бар! Власть чыннан да мактарлык түгел. Димәк, кешеләрен алыштырырга кирәк – и вәссәлам! Старшина Ибраһимнан менә ни файда? Әллә староста Хәмит тырышып эшлиме?

– Эшләмиләр. Эшли алганын табарбыз, бая әйткәнчә, вакыты җиткәч!

– Шул ук большевиклларданмы? Юк бит әле алар! Мин белгәне менә син дә, икенчесе Антипиндыр инде, аңа баргач. Барып күрик әле, кемдер ул!

– Мин дә шуңа барып күрергә теләдем инде аны.

Кинәт атлар пошкырып җибәрделәр. Ильяс торып ук утырды, кырында яткан балтаны эләктерде. Ризван шалаштан башын тыгып карап торды да тыныч кына аңлатты хәлне:

– Бурсык-мазар гына, кеше түгел. Азрак йоклап алыйк булмаса, иртәгә иртәрәк торырбыз.

– Әйе, шулай кирәктер.

Учактан шалашка җылы дулкыннар керә, очкыннар чәчеп, шартлап, кайчак утын ярыла, агып яткан чишмәнең үләннән ачык өстендәге йолдызлар чагылышы күктәге бихисап күп чын йолдызлар белән ярышырга теләп җемелди. Урман үз тормышы белән яши: кайчакта сак кына атлаган җәнлекләрнең аягы астында ботак сына, төнен ауга чыккан кошлар тавышсыз гына очып үтә, йоклый алмый утырган карт агачлар ыңгырашып ала, ара-тирә ниндидер ят тавышлар ишетелеп, кешеләрне куркыта. Тыңлый белгәннәргә күпне сөйли урман, бер дә юкка урман – колак, кыр – күз дип әйтмәгәннәр халыкта.

* * *

Юлчылар бәхетенә Антипинны Леунда очрата алдылар. Ул шактый олы яшьтәге кеше булып чыкты, монысы инде Ильясның кәефен бөтенләй үк төшереп җибәрде. Башта ул килүчеләргә шикләнеп карады, таныш булган исемнәр чыга башлагач кына ачыла төште. Монысына берсе дә аптырамады. Тик сәяси хәлгә бер дә чатнап торган карашы юк иде аның. «Апрель тезисларыннан» да хәбәрдар булып чыкмады.

– Әйе, менә монда урман арасына кереп баттык инде, туган! Бөре каласыннан Пермьгә тиклем берүзем, – дип аңлатты ул үзенең хәлләрен. – Хәзер икәү булабыз, күңеллерәк булыр!

Ничек кенә булмасын, якыннан таныштылар, бергә эшләргә, бер сүздән булырга, бер-берсенә ярдәм итәргә сүз куешып аерылдылар. Фирканең билгеләнгән сызыгын бергә алып бару кирәклеген икесе дә аңлыйлар. Антипин да уянгандай булды. Ильяс үзе күптән әзер зур эшләргә кушылып

китәргә. Бер нәрсә көн кебек ачык – монда озакламый тәгълимат та кирәк булмаячак, монда беренче нәүбәткә оештыру сәләте чыгачак.

Ризван белән Ильяс кайтыр юлга чыктылар. Икенче көнне кичке ашны алар өйләрендә ашыйлар иде инде.

**26**

Гәрәй, тезгенен кулына урап тотып, атын бакча аша басу юлына алып чыкты. Алдакчы кеше күзләре белән оялып, яшел бакчаның икенче очындагы туган йортына карады, өзәңгене кулы белән капшап, ияргә сикерде.

Тавыш-тынсыз гына атлаган ат белән бергә тибрәлеп, Гәрәй тагын уйларына бирелде. Ах Нина, Нина! Кем ярдәм итәр соң безгә? Гадел түгелсең син, ахры, Ходай! Нинди гаебебез бар соң синең алда минем һәм Нинаның? Тыелган мәхәббәткә дучар иттең дә упкынга ташладың... Тыюлы, ярамый торган... Тик нәрсәсе белән тыелган, нәрсәсе белән ярамый соң ул? Кемдер Гәрәйне гаепле дип саный, тынычланмаса, әтисе өйдән дә куып чыгарырга күп сорамас. Ничек кенә булмасын, хәзер Нинасыз Гәрәй үзенең тормышын күз алдына да китерә алмый шул! Нигә дип күрде ул аны, ни дип аны яратты? Нигә ул шушы газаплы мәхәббәтне сайлап алды? Башка кызлар юкмы авылда? Юк шул, башкалар кирәкми, бары ул кирәк, Нина – коңгырт чәчле, зәңгәр күзле Степан кызы, староста Хәмитнең кичәге дусты, бүгенге дошманы Степанның бердәнбер кызы.

Кайдан шул болын бәхәсе килеп чыкты, ни дип Гәрәй Степанга йодрыкларын төйнәп ташлана язды шул чакта? Бер-ике чүмәлә печән өчен! Ничә еллар иңгә иң куеп чаптылар шул болынны уртага бүлеп...

Хәтер тагын шул көннәргә алып кайта Гәрәйне. Таныпның матур борылышындагы җирләр уртасында ызан ята, ызанның исеме дә бар – Рус граны. Гранның теге ягында битен ак яулык белән каплаган Нина печән җыя. Икесенең карашлары очрашканда, Нинаның озын керфекләре, калтырап, аска төшеп китәләр. Шул вакытта әллә нинди сихри җылылык йөгерә, әллә нинди серле, назлы уйлар үтеп китә баштан. Бары ике әни генә, бу карашларның ни икәнен йөрәкләре аша аңлап, балаларга карап, авыр сулыйлар…

Белә иде бит Гәрәй ул вакытта ук Нинаның үзенә ошаганын.

Дуслык бетте, дошманлык артты.

Берничә тапкыр барып карады Гәрәй Михайловкага. Берничә мәртәбә ару гына эләкте авыл егетләреннән. Тик күрә алмады Нинаны, ерактан гына бер күреп калды. Хәзер инде Степанның өенә алып барган һәр сукмакны белә Гәрәй, ул сукмаклар таныш кына түгел, якын да булып киттеләр.

Өйдә билгесезлектә утыра алмый Гәрәй. Башларны әйләндереп, йөрәкнең иң тирән тамырларын иркәләп яши Нина. Кызык, ул нәрсә уйлый икән Гәрәй турында? И-их, ничек күрергә тагын бер мәртәбә булса да...

Нидер уйларга кирәк. Монда килүнең һәрберсе соңгысы булуы мөмкин – Степан болай гына бирешмәс. Ә... Әгәр урлап алып киткәндә? Зимагурлар булып? Уралга, берәр заводка? Каргыш сүзләре? Анысыннан курыкмый Гәрәй, Гәрәйнең андый тыюдан азат булып яшисе килә.

Тик бүген нәрсә булыр? Соңгы ун көндә бу бишенче бару уңышлы булыр дигән өмет тә, ышаныч та юк.

Гәрәй Йолдызны урман авызындагы карт чыршы астына кертеп бәйләде. Урын тыныч, өч яктан да куаклар, бер яктан чишмә агып ята. Ул акрын гына, һәр тавышка игътибар итеп, Михайловка урамына атлады. Авылның бу ягы тынычрак иде. Урам буйлап атлаган агачлар тын гына утыралар, күктә эре йолдызлар җемелди, көнбатыш ягында ай урагы юкка чыгып бара.

Төн кочагындагы караңгы өйләр йокыга китә алмый газаплана: өйләрдә бала-чага тавышы ишетелеп кала, аларга акрын гына эндәшкән әниләр кисәтүе ишетелә. Йортларда ярым йокылы этләр тавыш бирешә, ара-тирә тук мал-туарның тирән итеп тын алганы ишетелеп кала. Төннең яртысы узып та бара иде инде.

Әллә ничек куркыныч та, хәвефле дә урамда кешеләрдән качып атлау. Һәр мизгелдә тавыш, сугыш көтү, үзеңә генә ышану. Авылларда гайбәт таралганын Гәрәй белә. Әтисе дә тирги, Степан да яный, авыл егетләре сагалый. Бигрәк тә зур борчу салганы – Степанның Нинаны беренче сораган тиле-милегә бирәм, әгәр Гәрәй яңадан күренсә – сәнәккә күтәрәм дип әйтүе. Сәнәккә – ай-һай, булырмы, ә менә Нинаны кияүгә бирүе бик мөмкин... Шул сүзләрдән соң авыл егетләре азганнан-азды, берсен-берсе уздырып, Степан алдында эш күрсәтәләр, һәр көн саен Гәрәйне сагалап көтеп утыралар. Нинаны бер җиргә дә чыгармыйлар, Егорьевнага аның һәрбер адымын Степанга җиткереп торырга кушылды.

Башка төрле ямьсез уйлар килә, кечкенә Орыкты елгасы буеннан иserek тавышлар, гармун елаганы ишетелеп кала.

Ничәнче кат сак кына килә икән ул капкачлары акка буялган тәрәзәле өй янына? Нинаның күренгәнен көтә, көтеп-көтеп тә күрә алмый акрын гына кирегә китә. Йә үзе китә, йә, бер көтү авыл егетләреннән качканда, бакчалар аша юлын таба. Барыбер тарта аны шушы өй, анда яшәгән чибәр кыз тарта Гәрәйне. Күреп булырмы бүген Нинаны? И-их, чыксын иде ул болдырга, бер-ике сүз алышсыннар иде – тагын ни кирәк Гәрәйгә? Иң бәхетле кеше булып кайтып китәр иде ул Казанлыга! Атлап түгел, сөю канатларында очып кайтыр иде! Качып-посып йөрүләре кыен, үзеңнең горурлыгыңны ватып-кырып, төнен карак кебек йөрү авыр. Белә микән, аңлый микән моны Нина?

Гәрәйнең йөрәге чыгардай булып тибә, чигәләрдә тимерче чүкечләре уйный, тәне калтырый. Үч иткәндәй, өйдән тәкәббер атлап, Степан чыкты. Гәрәй тыңлаусызга әйләнгән тәнен өй алдындагы карт имән артына яшереп өлгерде. Степан йортны карап әйләнде, капканы ачып, бик озак урамга карап торды, шуннан капканың биген эләктереп, өйгә кереп китте.

Көтүнең файдасы юк иде инде. Тик Гәрәйнең аяклары җиргә ябышкандай, ул бер адым да атлый алмый, имән артында баскан урынында катып калды. Нишләргә? Степанны күрер өчен килдемени ул? Тагын Нинаны күрми кайтып китәргәме?

Тукта! Ишек шыгырдыймы? Әллә шулай тоелдымы? Юк! Сак кына атлап, болдырга Нина чыкты! Ишек тоткасын ычкындырмыйча, ул борчулы карашын урамга юнәлткән иде.

Гәрәй, тавыш-тынсыз атлап, йортка үтеп, болдырга якынлашты, кипкән иреннәре пышылдап, кадерле исемне атады:

– Нина!

Кыз куркып, ишеккә тайпылды. Тик Гәрәйне танып, торган урынында басып калды. Гәрәйне, көн саен бер мизгелгә туктамыйча уйлаган кешесен, төнен төшләрдә күргән якынын, күз яшьләрен түгеп, иминлек теләгән, аның өчен бөтен белгән догаларын укыган яратканын, ансыз күз алдына да китерә алмаган бәхетен үз янында күреп, туктап калды Нина.

– Гәрәй! Нигә килдең тагын? Кит тизрәк, тотсалар, тагын кыйныйлар бит! Алар... алар үтерергә дә булдырырлар! Кит, бар кит, минем яратканым! Синең белән ул-бу була калса, мин нишләрмен?

Барысын да аңлады Гәрәй: бу сүзләрдә борчылу да, йөрәктәге әрнүләр ачысы да, кызның саф мәхәббәте дә бар иде. Аңлады Гәрәй, ничә тапкыр монда килүе бер дә юкка түгел, кыйналып-тукмалып кайтып китүләре бушка булмаган...

– Нина, Нина, мин хәзер, хәзер китәм!

Сүзләр юкка чыкты, телләр аңкауга ябышты. Барысы да төштәге кебек, бәхет мизгеле бөтен галәмне тутырды, шул галәмдә алар икәү, һәм башка берни дә кирәкми иде аларга. Бу галәмдә борчылулар да, сагышлар да, аерылышулар да юк, Степанның янаулары да, исерек егетләрнең куян кугандагы кебек сызгырулары да, Хәмитнең куркытулары да юк иде, бу җиһан якты, биек, җылы, ул аларныкы иде бүген. Гәрәй, куркып кына, Нинаны кочаклады, егетнең ни эшләргә белмәгән иреннәре Нинаның дымлы иреннәрен табып кушылдылар... Нина тын гына елый иде, аның күз яшьләре, агып төшеп, Гәрәйнең битен чылатты.

– Бәхетем минем син, бәхетсезлегем дә! Нигә безгә бу сынаулар? Ни белән тәмамланыр алар, Гәрәй?

Гәрәй кочагына кереп чумган шушы кадерле кеше өчен җанын да кызганмаганын аңлый иде бу мизгелдә, юеш күзләр, битләр бер-берсенә тиюдән, бер берсен якын тоюдан башларны сихри итеп исертте. Нина ике кулы белән тотып, Гәрәйнең башын битенә кысты, үзе тиз-тиз итеп сүзләрен кабатлады:

– Кит тизрәк, җаным, кит! Әти күреп калыр!.. Үтерә ул безне, әгәр... Гәрәй... сөеклем... мин сине көтәм! Ышанма берсенә дә! Курыкма, мин бармыйм бер кешегә дә. Мин бары синең белән... ни эшләргә мин беләм, кияүгә көчләп бирергә уйласалар! Бар инде. Кит! Берсекөнгә, юк өч көннән соң кил! Әти өйдә булмаячак! Көтәм, яме! – Һәм тагын да дымлы иреннәре белән Гәрәйнең кайнар иреннәренә үрелде.

Ишек шыгырдады, аннан Нинаның әнисенең сак тавышы ишетелде:

– Нина!

Гәрәй мәче тизлеге белән койма аша урам якка сикерде.

...Кызының сулкылдаган эссе тәнен кочаклап, озак елады Егорьевна. Бер сүз әйтми елады, бер тавышсыз, Нинаның болай да юеш мендәрен күл ясап. Шул күз яшьләре күлендә, шушы тискәре дөнья турындагы юанычсыз уйларда иртәнгә табан икесе дә йоклап киттеләр.

Ә Гәрәй, канатлары үсеп киткәндәй очып диярлек, аты янына йөгерде. Аның тирәсендә бәла булырын шатлыклы уйлары башына кертеп тә

чыгармадылар: ул Нинаны күрде, ул Нинаның да аны яратканын белде, Нина аңардан башка беркемне дә яратмаганын әйтте, Нина бары аны көткәне турында сөйләде.

* * *

Калдырган урынында ат юк иде.

Гәрәй, җиргә ятып, төнге тавышларны тыңлый башлады. Кинәт башка тавышлар арасында ул Йолдызның кызгандырырлык таныш тавышын ишетте һәм, торып, шул якка йөгерде. Ат кырында ике кеше тора иде, аларның сөйләшүен дә ишетеп өлгерде Гәрәй:

– Чүкеч!

– Ахмак, тот тоягын!

Беренчесе яңагына бер сугуда читкә егылды. Икенчесе, сакаллысы, чүкече белән кизәнеп, Гәрәйнең кулбашыннан эләктерә язды. Бер-берсенәябышып, озак кына җирдә тәгәрәделәр. Гәрәй аның көчлерәк икәнен сизде, әгәр теләсә, ул күптән аның сынмаган җирен калдырмас иде. Шунда анысы авызын ачты:

– Ярар, булдымы? Хәлең беттеме азрак? Тынычлан!

Ычкындырды кулларын сакаллы. Гәрәй, аңа ышанып та җитмичә, аның якасыннан бармакларын тартып алды.

– Гаепле түгел без, егет! – дип, беренче сүзләрен әйтә алды ул, тын алуын җайларга тырышып. – Степан сине көтәргә кушты. Атыңны харап итәргә. Өч көн көттек. Ярый, килеп җиттең. А то башын ашый идек.

– Ничек? – Гәрәйгә дә дулкынланудан һава җитми, ул башын чайкап торган атын әйләнеп чыкты.

– Тояк астына тутыккан кадак.

Гәрәй акрын гына чүгәләде, күзләрен әйләндереп, әйтәсе сүзен тыны белән өреп чыгарды:

– Һәм шулай иттегезме инде?

– Юк. Әйтәм бит, син вакытында килеп өлгердең.

Бераз вакыт үтеп китте. Җирдә яткан беренчесе селкенде, торып утырды, Гәрәйгә карап әйтеп куйды:

– Мин бит ахмак түгел, егетләр белән сугышып ятарга. Шуңа тиз генә егылдым. Ә Миронның сугышны туктатырын мин алдан ук белдем. Ә син, егет, молоток, син – ут!

Карт авырлык белән торды, иелеп, учакның көл эчендә яткан агачларын тартып чыгарып, тырышып-тырышып аларга өрә башлады.

– Ә бит гөнаһтан ерак та түгел идек. Йә атны юк итә идек, йә сиңа да ару гына эләгә иде. Нүжәли курыкмыйсың?

– Юк, бабай! Ә нидән куркырга?

Учакта яткан коры ботаклар кабынды, шул яктыда ак сакаллы картның йөзе яктырып янып китте, ә кызылсу ут атның ялларында уйный, очкыннар чәчә иде. Мирон шуны гына көткәндәй, сүзгә кушылды:

– Син, егет, кыю, тәвәккәл кешесең, монысы күренеп тора. Тик батыр кешеләр кайчакта сукыр булалар, син дә шундый. Степан белән дуслашуга өмет юк, аңла шуны. Сезнең дошманлык гомер азагына тиклем. – Мирон

кесәсеннән чигелгән тәмәке янчыгы чыгарды, бераз кулында тотып торды, аннан, авыр көрсенеп, янчыкны кире кесәсенә салды. Тәмәке төреп, тартып җибәрделәр.

– Кыюлык, батырлык әйбәт. Тик кирәге чыкканда гына, хәтәрдән саклана белү кирәк. Кыюлык дуамаллык булырга тиеш түгел. Сөйлиләр, ул сине карак дип атап, үтергәнче кыйнарга кушкан егетләргә. Әгәр шулай дип тотсалар – ычкыну авыр булыр. Уйла, егет! Йөрмә монда, сезнекеләр әйтә бит, батыр үлеме марҗадан дип.

– Сынок, йөрмә, йөрмә! – Монысын инде беренчесе өстәде. – Бу яшьтә бөтен кызлар да синеке. Бирми ул сиңа кызын!

Гәрәй кайный башлады, тик Мирон аңа әйтергә ирек бирмәде.

– Сезнекеләр дә беркайчан да ризалашмаячаклар. Сине авылдан куып чыгарулары да бар!

– Менә нәрсә, абзыйлар! – дип кычкырып ук җибәрде Гәрәй. – Өйрәтмәгез мине. Болай булгач, һәр көнне киләчәкмен.

Гәрәй нигәдер үзен җиңүче итеп хис итте. Шуннан ул атка сикереп менде, аның күтәргән кулын камчы дип белде, ахры, ат урыныннан юыртып китте. Карт авыр тын алып көрсенде, тагын ютәлли башлады, Мирон икенче якка таба карап утырды. Гәрәй бераз баргач, кире борылып, аттан төшеп, аны тезгененнән тотып, учак янында калганнар янына килде:

– Гафу итегез мине, Мирон дәдә, син дә, бабай. Кызып киттем нигәдер... – Һәм кулын сузды.

Мирон Гәрәйнең сузылган кулын кысты да йөрәк ачысы белән бер-ике генә җөмлә әйтте:

– Э-эх, егет, егет! Әлләкем булырга ярамый шул! Сиңа иртәрәктер әле!

Карт, ризалык белдереп, башын какты.

**27**

Ильяс үзендә әллә кайдан килгән тынычлык, үзе аңлата да алмаган рух биеклеге, дәрт барлыгын сизде – ул хәтта, болар кинәт югалыр дип, иркен итеп тын алырга да куркып торды. Бу гына да түгел, ул йоклап китеп, мизгелләрдән генә чигелгән хыялны күрми калырмын дип курыкты.

Бу хыял – арыган кешенең тынычлык турындагы хыялы, ул хыял булганда, күз ачып йомганчы вакытны онытырга була. Бер нәрсәдән кала барысын да онытырга була – яраткан кешең янында булуын, бөтен дөньяның менә шушы бер түгәрәккә кереп сыюын һәм тынычлык белән сугарылуын... Шул турыда уйламадымыни ул окопларда туңып ятканда, яраланган көннәрендә, саташып, яшәү белән үлем арасын үлчәгәндә? Күз алдына бер тотып ала алмаслык сын булып килеп баскан тынычлыктан колакларга авырту килеп керә, баш әйләнә, бер мизгелгә каннар куерып, агудан туктый. Шушы хыялны алып кайтты ул окоплардан, шушы хыял аны сугыш яланыннан исән алып чыкты, шушы хыял аңа иң авыр чакларда алга барырга юл күрсәтте.

Бүген тагын йокыдан куркуын аңлады Ильяс. Бүген йокы иң кирәкмәгән халәт, аны аккан көннәр тезмәсеннән алып чыгып китәр төсле иде, бүген ул тәүлекнең һәр мизгелендә уяу булырга тиеш. Чөнки бүген аның янында

ул, тормышка ашкан хыялы – Сәлимә! Шуңа да ул бер эсселе, бер суыклы. Шуңа да ул башка берни турында уйламый да, уйлый да алмый. Шуңа да ул күкләрдән төшкән бәхетнең вакытын мөмкин кадәр озынайтырга тели иде.

Үтеп баручы җәйнең тып-тын төне җирдәге бөтен нәрсәне дә үз кочагына алды. Болытлар күкнең ерак өлешен каплады, җил булмагач, аларның йөзгәнен йә тик кенә торганнарын аңлавы кыен иде. Көндезге эшләрдән соң авыл тынып калды, тик кайдадыр еракта чапкан ат тоякларының тавышы йә көчәеп, йә юкка чыгып ишетелә. Урыс граны ягыннан башка атларның пошкырганы, аларның муенына тагылган кыңгырауларның чылтыравы Казанлыга килеп җитә. Менә инде ярты төн дә үтеп китеп бара, озакламый яңа көн, яңа эшләр, яңа мәшәкатьләр көтә авыл халкын.

Урам буйлап йөреп, Ильяс белән Сәлимә чабылган үлән салынган арбага утырдылар. Арбадагы печән үзенә генә хас исерткеч исләр тарата, Ильяс шул исләрне балачактан хәтердә калганнары белән чагыштырырга тырыша. Ул кузгалырга, күкрәк тутырып тын алырга да курка, чөнки, утыра торгач, Сәлимә аның кулбашына башын салып йоклап та китте. Төннең күз өйрәнгән ярым яктылыгында аның ап-ак киемле гәүдәсе тирә-якны яктыртты, шул яктылыкта ул тагын да матуррак, искиткеч зифа буйлы булып күренде. Менә ул кинәт йокы аралаш елмайды, тагын төшендә нидер күреп җитдиләнде, Ильясның үз кулыннан ычкындырмаган кулын күкрәгенә кысты, тагын елмайды һәм тагын күңелсезләнде.

Бүгенге төн еллар киштәсендә калган егет чакларны искә төшерде. Шул ук кыскарып баручы көзгә караган төннәр, беренче кыюсыз сүзләр, кыюсыз, ләкин тиктормас куллар... Шушындый, тик тулы айлы кичләр иде ул чакта, Ильясның сугышка китеп барган иртәсе туарга тора иде, әллә нинди бер тигезсез тезмә итеп әйтелгән мәхәббәт сүзләре, бәлки бик үк матур булмасалар да, алар чын йөрәктән иде. Рекрутның әче балдан әйләнгән башында ул сүзләр гомерлек булып торып калдылар, бүген дә ул аларның һәрберсен бернинди ялгышсыз кабатлый ала.

Тагын әллә кайдан җиңел генә болытлар килеп чыкты. Бер мизгелгә күтәрелгән җил салкынлык алып килде. Арба янындагы биек юкәләр авыр ботакларын җиргә хәтле сузып ыңгырашып алдылар да тагын тынлык таләпләренә буйсындылар. Бу тынлык мәңгелек кебек тоела иде, тик шул мәңгелек кануннарына буйсынмыйча өй чикерткәләре үзләренең озын бер көйгә салынган җырын башлады. Кайдадыр саташкан эт ырылдап алды, кайдадыр адашкан колын, әнисен эзләп, тавыш бирде.

Ае да бар икән бит бу кичнең! Киткән болытлар таралып бушаткан урында урактан да нечкә яңа ай инде күкнең җир белән тоташкан кырыена барып җиткән. Төсе югалып барган ай очлы укка охшап торган болытлар белән капма-каршы басып, озакламый калкачак кояшны каршы алырга, аның янында Чулпан йолдыз да, бу теләккә кушылып, кояшның беренче нурларын күреп, күздән югалырга әзер. Кемдер айны көзге төннең матур рәсеменә урнаштырган, бу рәсем чынлап та шушы урактай айсыз тулы булмас иде. Әллә ул шул күкнең җир белән тоташкан кырыенда берәр нәрсәгә эләгеп калганмы, билгесез, тик әлегә шунда кереп югалырга бер дә ашыкмый, кояштан алган нурларны җир өстенә илтеп җиткерергә тырыша. Белә ул, озакламый ул көч җыячак, зур булып, төн хакименә әйләнәчәк, ә төннәр ул булганга яктырачак. Менә шунда күләгәләр озынаячаклар, менә

шунда башланачак шул төнге күләгәләрнең биюе, менә шунда айның көмеш яктылыгы дөньяга сихри үзенчәлекләр өстәп торачак. Болытлар яңа айны яшь баланы караган кебек карыйлар, өши күрмәсен дип, тагын аны ябып куйдылар.

Ильясның башында уйлар бер йомгак булып әйлән-бәйлән уйный, бу әйлән-бәйләндә балачак та, авыл тормышы да, фронт та, лазаретлар да, кайтып авырып ятулар да бар. Һәм монысы иң мөһиме: ул – Сәлимә... Язмышның аңламаслык борылышларында, булганнарын онытa язып, ни булачагын көтеп ятканда, аның турында уйлады ул, Сәлимәгә тартылды. Җир шарындагы миллионлаган кешеләр арасындагы бер кешегә, дөньядагы ышанычына, ярсу диңгездә үзенә чакырган маякка барырга тырышкан көймә кебек, ул да һәрчак юнәлешен аңа таба борды.

Сәлимә йокы аралаш тагын елмайды, уянып, Ильясны биленнән кочаклап алып, нидер пышылдады. Ильяс озак итеп, күзен дә алмый аңа карап утырды да, иелеп, нигәдер ярым калтырап, аның үпкәләгән баланы хәтерләткән иреннәреннән үбеп алды. Сәлимә уянды, тик күзләрен ачмады, Ильясның куллары аны кысып кочаклады, күз алдындагы ягымлы да, сөйкемле дә йөзнең, күзләрнең елмаюы әллә кая чакыра, әллә кайда һәм әллә нинди сихри бүләкләр вәгъдә итә иде.

Шушы бәхетле мизгелдә ай да якын булып тоелды, Ильяс башындагы уйларның әйлән-бәйлән уены Сәлимәгә дә күчкәндәй тоелды. Шунда бер уй аның бар дөньясын биләп алды: «Бу бит ул, Ильяс! Көтеп алынган язмышы!»

Сәлимә кабаттан күзен ачканда, ай инде юк иде, кояшның беренче нурларында коенып, ул икенче кичкә тиклем юкка чыкты. Ә Сәлимә янында бары тик Ильяс кына, Ильяс аның белән иде...

## 28

Җыенга чакырулары да кирәкмәде десятникларның. Базар белән волость бинасы алдындагы мәйданда иртәнгә аяк басарлык та урын калмаган иде. Октябрь башындагы иртәнге салкын кешеләрне урынында биетте, төньяктан искән җил битләрне өшетте, борын очларын агартты. Халык тик тормый, хәрәкәттә: ул җылыта, моны салкында туңганнар яхшы белә.

Тиздән волостьның һәм авылның хуҗалары күренде, алар, бик вәкарьле итеп, дәрәҗә саклап, алга уздылар. Мәйданда тавыш тынды, башлар өстеннән Ибраһим страшинаның сүзләре яңгырап үтте:

– Җәмәгать! Кичә генә Вакытлы Хөкүмәтнең фәрманын алдык. Без монда җыенга шул фәрманны сезгә җиткерү өчен җыелдык.

Халык арасында канәгатьсезлек, ризасызлык белән тулган тавышлар ишетелде.

– Нәрсә, сугыш беткәнме әллә?

Ибраһим авырлык белән генә тынычлык урнаштыра алды:

– Без иртәгәдән фәрманга ярашлы солдатка кешеләр җибәрергә тиеш, элеккечә әйткәндә, рекрутлар.

Тагын шау-шу.

– Нәрсә?

– Нинди рекрутлар тагын?

– Булмас андый фәрман!

– Авылда ирләр бетеп бара!

Ибраһим бу тавышны тагын чак-чак җиңә алды.

– Хәзер староста Хәмит әфәнде исемлекне сезгә җиткерәчәк, игътибарлы булыгыз. Исемнәре аталганнар «призывной лист» дигән кәгазь алачак.

Хәмит, югарырак урынга атлаганчы, ничек итеп Гәрәй турында әйтермен икән дип баш ватты. Бүгенге вазифасын башкарганда, бер җиңеллек – ул да булса, старостаның да улы сугышка алына. Мәйданда халык тагын шаулый башлады.

Зур түземлек белән укып чыга алды Хәмит исемлекне. Башында бер уй йөри, ул уй аның миен актара, тишә, бораулый: «Әллә дөрес эшләмәдем инде? Әллә хаталандым? Кешеләр, юк сәбәп табып, сугыштан качып калганда?» Тик эшлисе адым эшләнгән, артка юл юк.

Мәйданда елау, тавыш.

– Тагын безнең башка бу бәла! Ничек көн итәрбез? Гел безнекеләрне аласыз!

– Каян сезнекеләрне генә ди? Әнә старшинаныкы да, старостаныкы да китеп баралар түгелме?

Исемлекләрдә бу ике егетнең булуы чак кына хәлне җиңеләйтте.

Хәмит, халык арасыннан чыгып, өенә атлады, аның артыннан Ибраһимның әйткән сүзләре куып җитә бардылар:

– Рекрутларга иртәгә волостька җәвитсә итәргә! Тавыш-тынсыз, тәртипле итеп озатаек, җәмәгать! Җиңү белән кайтачаклар алар, Алла бирсен! Олауга атларны шушы йортлар бирә...

Башын иеп, өенә кайтып кергән Хәмитне аның кара ниятләрен ана йөрәге белән сизгән Рәхимә күз яшьләре белән каршы алды:

– Җибәрдеңме? Оятың юк икән! – диде һәм, елап, өйгә кереп китте.

Нидер эшләп яткан Гәрәй, балтасын ташлап, каушап, әтисенә карады. Каяндыр килеп чыккан вак калтырануны басарга тырышып, битенә чыккан юләрләрчә елмаюын яшермичә, әтисенең бирмәгән соравына җавап бирде:

– Нәрсә әйтим, эти... Хезмәт итәрбез.

Рәхимә, елап, аны кочаклап алды:

– Салихның үскәнен күрмәдем, инде монысын шул армияңә илтеп тыгасың! Ничек инде ул? Берәү хезмәттә бит инде, барысы да бездәнмени? Ә, этисе? Җибәрми-им!

**29**

Волость белән базар арасындагы мәйданда тагын халык җыелды. Тагын тальян елый, кайчакта җыр сүзләре ишетелеп кала, кемнәрдер бүген дә яшьләргә киңәш бирә.

– Барыгыз да мондамы? – Ибраһимның тавышы шыгырдаган кое чыгырын хәтерләтте. – Ярар, алайса исемлекне барлап чыгыйк.

Аның уйлары бүгенге хәл турында түгел иде, ул ике ярдәмчесе юкка чыкканына хафаланды. Әгәр алар янгын белән эшне азакка тиклем эшли алсалар, хәбәре күптән килеп җитәр иде. Хәбәр юк. Димәк, янгын да юк. Һәм кешеләр дә юк!

Исемлекне барладылар. Тиешле кешеләр барысы да монда, дезертирлар

юк, каршы килүчеләр юк, бар да тәртиптә. Озатучыларга Әхмәтгали хәзрәт җылы сүзен әйтте, догасын укыды.

Ә Хәмит ни эшләгәнен әлегә аңлап бетерә алмады. Шуңа да ул элеккечә кырыс һәм каты бәгырьле.

– Нәселне оятка калдырма! Туганың әфисәр! Моны да онытма. Безнең нәсел беркайчан да кеше артында качып ятмады!

Бераз башы авырткан Гәрәй аны тыңламый да иде. «Оят, кеше артына качма!» – болар берсе дә кирәкми Гәрәйгә. Сугышы да кирәкми.

– Хәтереңдә тот мин әйткәнне! – Йокысы туймаган башка бу сүзләр үтеп керә алмый иде.

– Бәлки, Салихны очратырсың? – Сүзгә Рәхимә кушылды.

– Кит әле, юләрләнмә! Ничек очратсын, ди, ул аны? Армияне Казанлы базары дип уйлыйсыңмы тагын?

Ибраһим икенче мәртәбә арбалардан урын алырга чакыра. Бу юлы инде китүчеләр урын ала башладылар.

Бик коры итеп саубуллашты Хәмит улы белән. Рәхимә аңа карап елады:

– Каты күңелле адәм син! Кеше кебек саубуллаша да белмисең бит! Нәрсә уйларлар синең турыда?

– Тик тор, тинтәк! Хатын-кыз эшеме ирләрне өйрәтергә? Бәлки, еларга да кушарсың? Сау бул, улым. Онытма безне. Хат яз. Менә әлегә шул.

Хәмит Гәрәйнең кулын кысты, Рәхимә, аны кочаклап, тавышсыз гына елавын дәвам итте.

Рекрутлар, башларын иеп, арбалар кырына җыелдылар, бары тик әлегә сакал-мыек күрмәгән битләр буйлап тозлы яшьләр ага.

Менә инде алар төялгән олау кузгалды.

Шул вакытта әллә нәрсә шартлап өзелде Хәмитнең күкрәгендә, түзеп булмаслык әче сагыш булып, йөрәгенә барып кадалды.

– Улым! Улым! – дип пышылдап, ул олауга якынрак килергә тырышты, тик андагы йөзләгән кеше аша үтү мөмкин түгел иде. Ычкынды шул чакта Хәмитне тотып торган ниндидер җепләр. Кешеләрне этеп-төртеп, ул алга йөгереп чыкты.

– Гәрәй!

Гәрәй аның ягына борылды. Олау да туктап калды.

– Гәрәй, улым, гафу ит мине, карт юләрне, ишетәсеңме?

– Ни өчен гафу итәргә, әти?

– Хәтереңдәме, мин сиңа суктырдым атна-ун көн элек? Гафу ит! Кайчан күрешербез – Алла гына белә!

Хәмит Гәрәйне күкрәгенә кысты.

– Менә инде, мин бит үзем гаепле идем! – Гәрәй күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышты.

Олау тагын кузгалды. Ике яктан да киңәшләр бирү дәвам итте.

– Улым, саклан!

– Хәбәр җибәрергә онытма!

– Сак бул, Алланы ташлама! Догаларыңны укы һәрчак!

Бераздан китүчеләр ягыннан саубуллашу булып җавап сүзләре килеп җитте:

– Без кайтырбыз озакламый! Көтегез безне!

Китүчеләр авылныкылардан ерагая төште. Шул вакытта алар арасында йә авылга табан, йә олауга иярергә тырышып, бер көчек бәргәләнә иде. Бар халыкның күзе шул көчеккә караган, гармун да уйнаудан туктады, яланда тынлык урнашты. Эт баласы, елап-елап, ике арада йөрүен дәвам итте. Шулчак олаудан бер яшь кенә егет юлга сикерде, очып диярлек килеп, көчекне тотып алды, күкрәгенә кысты, нидер әйтте, җибәрде. Һәм ул сикереп менеп олауга утыруга, атлар чабып та киттеләр. Ялан уртасында елап утырып калды көчек.

Олау артыннан бала-чага да йөгереп карады. Тик кая ул, иртәдән үк басып торган атлар, көзге сирәк тузанны күтәреп, алга омтылуларын белделәр.

Бик озак тордылар кешеләр, шул тузанга карап. Хәмит, авыр сулап, үзенә-үзе әйтеп куйды:

– Үз-үземне канатсыз калдырдым бит!

Гармун тавышы бик озак тынмый ишетелә килде. Кайчак ерактан авыл башында калган кешеләрнең колагына җыр сүзләренең кайбер өзекләре ишетелде, һәм алар инде йөздәге туктап өлгергән тозлы чишмәләрне кабаттан ачып ташладылар. Ул чишмәләрдә яшь кенә түгел, яшерен сукрану-зарлану да, төшенкелек тә, халыкка хас булган буйсынучанлык та бар иде.

Бик күпне күрде халык бу ун-унбиш ел эчендә. Кемнәрнедер япон, кемнәрнедер герман сугышына озаттылар, күпләрне көтеп ала алмадылар, күпләр, кайтып, туган йорт бусагасын атлап керә алмадылар. Кайгы таныш иде монда һәр өйгә, ул һәркемнең үзәгендә нык итепябышып утыра иде...

Хәертдин күперен чыгып, Сандугач тавы башына менеп җиткәч, урман арасыннан авылга табан туп-туры бер буй ачыла. Моны бар да белә; халык, таралмыйча, китүчеләрнең шул ачык буйны үткәнен көтте. Китүчеләр дә моны яхшы белә – беренче атлар күренү белән җыр сүзләре ындыр буенда калганнарга килеп иреште:

Казармаларның идәнен
Таптамам дигән идем,
Туып үскән авылымны
Ташламам дигән идем...

Бу юлы инде бөтенләй каткан күңеллеләр дә чыдамады – кешедән яшереп тормый, күз яшьләрен сөрттеләр...

* * *

Ике көнгә якын бардылар рекрутлар Бөре каласына. Аттан төшеп, пароходка утырдылар, пароходтан төшеп, Бөре урамнары буйлап төрмә саклаучы солдатлар казармасына барып, йокларга яттылар. Икенче көн Гәрәйне бер кеше эзләп тапты. Башта ул аның кайдан булуын сорашты, кем улы булуы белән кызыксынды. Староста Хәмит улы дип таныштырды Гәрәй үзен Тукмаков дип атаган бу кешегә. Шунда ук теге кеше аны башкалардан аерып алып китте, һәм шул ук көнне кич Гәрәй, тагын пароходка утырып, Уфа ягына йөзде.

## 30

Ярмине мал ызбасына керосин салынган шешәләре белән бергә төяп алып килделәр. Ярминең борыны салынган, ул эшнең ничек тәмамланасын бик яхшы күз алдына китерә. Пётр Васильевич аны җилтерәтеп арбадан тартып төшерде дә сөйләшергә җиңелрәк булыр дип, аның коты очкан аклы күзләренә зур йодрыкларын бер-ике мәртәбә тидереп алды. Ярми егылып китүдән мал ызбасының стенасына сөялеп калды, тик барыбер күктәге йолдызларның бермә-бер артканын күрде.

– Нәрсәгә дип керосин салынган шешәләр әзерләдең? Кемгә ут салырга исәбең?

Ташкинов аны әйләнеп урап чыкты, шул вакытта Ярми, куркып, тагын сугуны көтте. Аңлады ул, бу егетләрдән исән чыгу юк, бары башкаларны сатып, берәр төрле файда эшләп була.

– Миңа шундый боерык бирелде.

Пётр Алексеевич тагын сикереп чыкты:

– Кем?

Ташкинов, кулын күтәреп, аны туктатты, аңлатты, әлегә янгынның кайда буласын белү – монысы, чынлап та, башка сораулардан мөһимрәк иде.

– Йә?

– Сезнең Тәшкүр белән Борай янындагы пристаннәрне.

– Син – кайсысын да, Тамырбулат – кайсысын?

– Мин – Тәшкүрдәгене, ул – Борайдагыны.

– Әле кайда ул? Киттеме кушканны үтәргә?

– Юктыр, бүген ул төш вакытында ук йөри алмаслык исерек иде. Кәрәчине дә алынмаган, барлыгы алты шешә – менә, алар монда, – дип, өстәлгә күрсәтте, ымлап.

Димәк, бу бәладан котылып калдылар. Әлегә. Кем белә ни уйлаганын зур кешеләренең. Әгәр тагын ярдәмчеләре булса? Ул шушы ике аңгыра бәрәннәргә генә карап утырмыйдыр бит?

– Тагын бармы сезнең кебек аңа табынган тиле-милеләр? Ничек итеп ул сезне шулай куркыта алды?

– Куркытмас. Ул бит таныш-белеше күп булган кеше дә. Икебезне дә бик зур гөнаһлы эшләрдән алып калды ул. Шуңа без аңа рәхмәтлебез...

Иң җаваплы вакыт килеп җитте. Сатармы кушкан кешеләрен, әллә юкмы?

– Ярми, син үзеңнең язмышың кыл очында торганын аңлыйсыңдыр бит? Шуңа карышсаң, без сине исән калдырмыйбыз. Ә җәзаның нинди икәнен син беләсең. Сорау: кем сезнең хуҗагыз?

Ярми, ничек кенә юләр булмасын, бер нәрсәне аңлап алды – яшәүгә яшәүне алышу.

– Миннән – хуҗа исеме, сездән – миңа азатлык.

Пётр Алексеевич тагын кулларын уйнатып алды. Борыныннан бәреп чыккан кан Ярминең аягына тамды.

– Барыбер үләсе. Гомергә – гомер!

Ташкинов Пётр Алексеевичка карап, башын какты.

– Ярар. Син исемен әйтәсең, без тикшерәбез, дөрес булса, артыңа тибеп чыгарып җибәрәбез. Башка сүзем юк. Әйтмәсәң инде, иртәгәдән

соңгамы, берсекөнгәме сине шул Тәшкүр тирәсендә суда табарлар. Аңлашыламы?

Ташкинов та кушылды:

– Шуннан, синең гаебеңне тануың, хуҗагызны атавың да бик кирәкми безгә, чөнки без аны беләбез! Ул – Ибраһим старшина!

Ярми куркуыннан киеме эченә кереп киткәндәй булды.

– Юк! Ю-ук!

– Юк түгел инде, туган! Аның котыртканын без башта ук аңлап алдык. Ә сез, аңгыра бәрәннәр, ул кушканны эшләп, ике яшь баланы харап иттегез!

Ярми, каушап, котылыр юл эзләде.

– Без аңа каршы дәшә алабызмыни? Ул бит теге вакытта безне нинди җаваптан коткарып алып калды. Без аның алдында таудай тиешле!

Пётр Васильевич Ташкинов ераккарак карый иде. Аңа бу эшнең нәрсәдән башлануы мөһим. Гап-гади гына үч тойгысымы, карадан кара көнләшүме – нәрсә ята бу хәлләрнең нигезендә, алда нинди планнары бар Ибраһимның? Планнарын Ярми кебекләр белми инде – монысы ачык. Ә менә нидер сөйләгәндер бит ул боларга – шуны белергә тырышты ул төрле сораулар аша. Тик бернинди җавап та ала алмадылар алар бу юньсездән. Ә Ярминең бөтен тырышканы – судан коры чыгу. Җибәрсәләр, ул кая барырга белә. Ямаяз ерымын үтеп, Томафи яланына чыкканда, урман уртасында бик аз кеше белгән бер урын бар, аны шул белүчеләр Хатмул пучинкәсе дип йөртә. Пучинкә – Хатмул исемле юлбасарның кайчандыр качып яткан урыны, берничә яшерен чыгу юллары, берничә бүлмәсе булган бик уңайлы урын. Анда Ярмине беркем дә таба алмаячак. Тик болардан ничек котылырга? Ярми ике Петька кырында бик эчкерсез, ышандырырлык булып күренергә тырышты.

– Мин белгәнемне әйттем, сез дә үзегезнең сүзегезне үтәгез инде.

Тик алдарсың Ташкиновны!

– Ярар, карарбыз. Тамырбулат кайда, өендәме?

– Соңгы вакытта ул өендә йокламый, Көтмәстә, Нигъмәтҗан байның ерак тегермәнендә ята.

– Мартыштамы?

– Әйе.

Ике Петька бер-берсенә карадылар. Монысы саф алдашу инде, аны аңлыйлар алар. Ничек инде ике сәгать элек кенә монда булган кеше җәяү сигез-тугыз чакрым арадагы Мартыш тегермәненә йокларга йөрсен ди?

– Ярар, монысын да тикшерербез!

Пётр Алексеевич Ярмине базга этеп төшерде.

– Шым гына ятсаң, исән калырсың. Понялмы?

Баздан мыгырдаган тавыш кына ишетелде.

Мал ызбасыннан чыгып барганда, Пётр Васильевич туктап калды.

– Петя, сизәсеңдер, монда бит эшләр бик тирәнгә китеп бара. Үзебез генә ерып та чыгар идек, тик бу башбаштаклык булыр. Шуңа күрә хәзер үк Даниел Геворковичка җиткерергә кирәк хәлне. Без белмәгән нәрсәләр дә бардыр монда. Ул акыллы кеше, тиешле киңәшен бирер.

– Мин риза, һәрвакыттагыча син дөрес сөйлисең.

– Киттек, алайса, дуамалланып, дөньяны ватып-кырып ташлаганчы!

Өйдән чыгу белән икесе берьюлы мостикка карадылар. Анда кәнәфидә бөрешеп, бу авыр хәлләрдән бәләкәйләнеп калган, күләгәгә әйләнеп, көн саен тормыш мәшәкатьләреннән ерагая барган һәм кинәт картаеп киткән Даниел Геворкович башын иеп, үз уйларына бирелеп, тын гына утыра иде.

**31**

Барып җитә алмадылар Пётр Васильевич һәм Пётр Алексеевич Даниел Геворкович янына. Кинәт бөтен дөнья тын калды, аяз көндә яшен яшьнәгәндәй, аяклар атламас булды. Көн буена бертуктаусыз эшләп арыган миләр аңламаслык иде шул бу хәлләрне. Матусов биләмәләре кырында гына түгел, бар тирә-якны таң калдырырлык матур да, куркыныч та, шомлы да хәл иде бу – пианино тавышы, тагын Шопенның йөгерек музыкасы. Сихри музыка үз авырлыгы белән тормыш баскан кешеләрне йомычка кебек җиңел генә күтәреп ала да һавага алып менеп китә, анда очыртып йөртә дә башлары туктаусыз әйләнгән кешеләрне йомшак кына итеп җиргә төшереп куя, тагын үзе генә өскә авыша, тагын җиргә төшә, тагын кешеләрне югарыга алып менеп китә. Бу музыка шуңа да сихридер инде, чөнки аның эшләгән эшләрен, кешеләргә булган йогынтысын сихрилектән башка тормышка ашыру мөмкин дә түгел.

Тик кемнең йөгерек бармаклары уйный соң бу музыканы, бу фантазия-экспромтларны? Менә шунысы куркыта да, шомландыра да, аптырата да иде. Пианинода уйнаучылардан Анна юк, аның апасы Анита башкалага чыгып китте. Кем уйный? Куркытырлык, шомландырырлык хәл булды бу чынлап та. Хәтта көннәр буе мостикта утырган Матусов үзе дә, йортка чыгып, пианинолы үзәк йортка табан атлый, аның артыннан башкалар да акрын гына музыканың чыганагына таба баралар иде.

Балконның ачык тәрәзәләре аша көзге җил исә, тәрәзә пәрдәләре әллә җилдә, әллә музыка агышында дулап тибрәләләр. Нindидер җитез куллар шул сихри музыканы бар галәмгә тарата.

Өй алдында туктап калдылар. Матусов Петькалар белән бергә эчкә узды, икенче катка күтәрелеп, пианино торган залга аяк бастылар. Музыка коралы артында, бар дөньясын онытып, Анита утыра иде. Матусов куллары белән урындыкка күрсәтте, озатучыларның берсе аны йөгертеп китереп тә бирде, һәм ул картларча акрын гына биргән урынга утырды.

Тагын бераз уйнады Анита. Шуннан гына, кешеләр барлыгын сизеп, туктап калды һәм аларга борылды, яшьле күзләрен сөртеп тә тормыйча, әтисенең тезләренә килеп капланды.

Ике Петькага да кыен булып китте, алар артка таба атладылар һәм ишекне акрын гына ябып чыгып киттеләр. Матусовның хәлен аңлатырлык түгел иде: әнә бит, Петькалар чыгып китүгә дә игътибар итмәде.

Бераз тын гына утыргач, карлыккан тавыш белән сүзен әйтә алды:

– Кайттыңмы, кызым? Ә мин сине көткән идем...

Анита да җавап бирерлек хәлдә түгел иде. Алар берсүзсез кичкә хәтле утырдылар. Матусов ара-тирә кытыршы куллары белән Анитаның башыннан сыйпады, аның ярылган кулларына эләккән чәч бөртекләре, кулларга ияреп, кызның башында уралдылар.

Анита авыр сулап куйды, шуннан яше кипкән күзләрен әтисенә күтәрде.

– Питерда бүген-иртәгә инкыйлаб. Бу юлы властька бик усал кешеләр килә, большевиклар. Безнең кебекләргә көн бетә. Чит илгә китәргә кирәк!

– Юк инде. Мин кая барыйм? Аннан бу дөньяны ташлапмы?

– Нинди дөнья, ди, ул! Питер казан кайнагандай кайный, большевиклар безнең ишеләрне дошман сыйныф дип юкка чыгарачаклар, ә мал-мөлкәтне талап алып бүлешәчәкләр!

– Булмас! Бу бит дәүләт бетәчәк дигәнне аңлата! Мөлкәт, хосусый милек бит ул – нык дәүләтнең нигезе!

– Бәлки, шулайдыр. Тик бу юлы алай булмаячак!

Тынып калдылар. Матусов үз уйларына чумды. Анита, түземсезләнеп, аның кире кайтуын көтте.

– Акча кирәк. Алтын кирәк. Ул булганда, чит илләргә юл ачык!

– Ә? Акча? Алтын? Бар ул, тик ул бит банкта. Аны ничек итеп тиз генә ала алырбыз?

Анита әтисенә ышанмыйчарак карап торды. Матусовны, чыннан да, танырлык түгел иде. Кайда аның элеккеге эшкуарлык җитезлеге, вазгыятьнең агышын, юнәлешләрен тиз аңлап алучы кеше кая киткән? Әле бит яше дә алтмыштан чак кына өстә!

– Мин сине андый томана кеше дип уйлый да алмыйм, хакым да юк. Синең өйдә күпмедер акча тотмавың мөмкин түгел! Ишетәсеңме? Мондый тынычсыз чакта!

Матусовка да уңайсыз булып китте.

– Ну, табарбыз инде сиңа гына җитәрлеген. Так что, кайгырма! Нинди планнарың бар бүгенгә?

– Мин синең урында бар мөлкәтне сатар идем, аны акчага, алтын-көмешкә әйләндереп, чит ил турында уйлар идем. Әлегә соң түгел. Иртәгә соң. Беләсеңме нинәр булып ята башкалада? Салкын, утын юк. Аракы складлары ачык. Көн саен урам тулы халык, һәр төн саен кеше үтерү, талау. Урам тулы исерек солдат-матрослар, кичәге-бүгенге бандитлар. Зыялылар, акчалылар кача. Бер сүз белән әйткәндә, мәхшәр!

– Ул бит Питерда. Ә монда әллә килеп җитә, әллә юк.

– Мин аптырыйм, синме бу? Син бит һәрчак кулыңны дөньяның ялларында тотып килгән кеше!

Матусов башын күтәрде. Анита аның күзләрендә шушы сәгатьләрдә беренче тапкыр элекке очкыннарны күрде.

– Кайчан китәсең?

– Хәзер үк!

– Акча белән, төнгә каршы?

– Анысы уйланган.

– Ярар, әйдә, ашап алабыз. Шуннан үзең карарсың. Мин инде олы кеше, монда калам. Бу тикле мөлкәтне бер көндә юк итеп була, ә тиз генә сатып йә урнаштырып булмый. Карап карарбыз!

Анита сикереп диярлек торып басты.

– Тик мин озак була алмыйм. Төнге паровозга җитешергә кирәк! Чуен юлда да бер тәртип юк, кем көчле йә акчалы, шул беренче.

Анита җиңел генә атлап чыгып китте. Ул киткәч, тагын бераз утырды Матусов. Коточкыч хәбәрләр сөйли Анита, ышануы авыр, тик бер дә

ышанмаслык түгел. Гөрләп яткан дөнья һәлакәткә табан очып бара. Ил турында, кеше язмышы турында уйлаучы да юк, бары хакимлек итү турында уйлыйлар. Һәм бу юлда берсен-берсе таптап, изеп үтәргә әзерләр. Берничек тә тыгылып, үзгәртеп булмый торган, кирегә юлы булмаган таудай үзәрешләр өскә басып килә.

Матусовның да шундый һәлакәткә очрый язганы булды. Берчак таудан Көтмәс күперенә төшеп килгәндә, әллә нидән куркып, атлары дулады. Атларның юлны юл дип белми тилереп чабуын күргәне юк иде аның. Бар уйлаганы – тәгәрмәчләр таралып төшеп калмасын да, күпер төбендәге борылышны исән-имин үтәргә язсын. Үттеләр. Үлем белән күзгә-күз карашып торганнан соң, ычкындырды бугазны Газраил. Башкача Матусов бервакытта да, дилбегәне кулына урап тотмыйча, арбага утырмады, тимер авызлыкларны атларның авызына көчләп кидертмичә йөрми башлады юлында.

Ничек кенә булмасын, Матусов – бер кеше. Ә менә ил шулай бу һәлакәткә очып барса, әгәр барып җитсә, ни булыр? Нинди язмыш көтә бу халыкны? Нәрсә эшләргә? Анитага табар ул акчасын, мондый очракта, ул моны үзе дә сизә, аның чит илгә китеп өлгерүе өстенрәк. Тик менә үзенә нишләргә? Бу тикле мал-мөлкәтне беркая да куеп булмый бит? Ә-ә, әйдә кадалсын! Дәүләт тикле дәүләт җимерелгәндә...

Барысын да аңлый ул, тик нәрсәдер күңелне кыра, әлегә әйтә алмаган шул нәрсәне ул тотып ала алмый иде уй-фикерләре агышында. Авырлык белән урыныннан торып, ишек тоткасына тотынгач кына аңлады ул эзләгән «нәрсәне»: шушы очрашу барышында Анита бер мәртәбә дә аңа «әти» дип эндәшмәде, бер мәртәбә дә Аннаны искә төшермәде...

**32**

Ильяс та тик ятмады бу арада. Сәламәтлеге күзгә күренеп ныгыды, баш әйләнүләр сирәгәя төште, тавышы да уз урынына тулысынча кайтты, ниһаять. Бары атна-ун көн саен әллә кайдан килеп төшә торган баш авыртуы булып, узган контузияне оныттырмый кала килде. Аның кулы тигән йорт-куралар үзгәреп киттеләр. Әйтерсең шул куллар гына җитмәгән, шул куллар гына бу дөньяга теләгән үзгәрешләрне кертә ала.

Яков Константинович белән көн саен диярлек очрашып сөйләшүләр эзсез калмады. Ильясның башында эчтәлеге, башы-азагы булган, төзек бер тәгълимат формалашты. Ярты ел гына элек чыгуы мөмкин булмаган тыкрыкларга кертә торган сорауларга җавабы булмаган кешедән ул акрын гына һәрбер сорауга үз сүзен таба алырлык, ул сүздә торырлык шәхескә әйләнә барды. Халык та моны бик тиз сизде, көн дими, төн дими киңәшкә килүчеләр өзелмәде, ул әйткән сүзләрнең төпле булуына игътибар иттеләр, авыр, чишү юллары билгесез булган сораулар туганда, иң беренче булып аңа карадылар, аңа мөрәҗәгать иттеләр.

Еш булмаса да, Казан белән элемтәдә торырга тырышты Ильяс. Хат алышуның да җаен таптылар, чуен юлның эшен рәткә-тәртипкә салу моның мөмкинлекләрен бермә-бер арттырды. «Сугыш сафы» гәзитендә мәкаләләре күренә башлады, алар Камил Якуб тарафыннан әйтелгән җылы сүзләргә лаек булдылар. Тик очрашулар гына булмады әлегә. Монысы инде

аңлашыла. Сәяси казанда гөрләп кайнаган Казан тормышы нинди тизлектә әйләнәдер кояш тирәли, бусы бары Аллаһка гына мәгълүмдер.

Ильяс белән булган бу үзгәрешләрнең уртасында Сәлимә тора иде. Көн саен булган киләчәк турында сөйләшүләр вакытында ул Сәлимәнең шул тикле акыллы, зирәк кыз икәнлегенә инанды, кирәк чакта мәсьәләне уртага салып, бергәләп чишү юлларын эзләгәндә, аның фикере очлы булуына шатланып бетә алмады. Һәм шул көннәрнең берсендә, елга буендагы йөзьяшәр өянкеләр астында утырганда, ул, үзе дә сизмәстән, алдагы тормышның бергә булачак өлеше турында сүз кузгатты.

– Сәлимә, без синең белән бәләкәй чактан бергә, бәләкәй чактан мин сиңа якын итеп, яратып карадым. Сугыштан көтеп алдың, кайткач та, син гел минем янымда. – Ильяс үзенең әйткән сүзләреннән каушап китте. – Сиңа булган хисләремне дә беләсең. Ничек уйлыйсың, әгәр бергә булыйк дисәм?

Сәлимә бер сүз әйтми аның күкрәгенә капланды да елап җибәрде.

Бераз утыргач Ильяс, Сәлимәнең башыннан сыйпап, шаян сүзләрен әйтте:

– Мин аңламадым, бу елак кыз минем сүзләргә риза дип яшьләрен түгәме, әллә, кияүгә чыгам бит, ниһаять, дип, шатланып елыймы?

Сәлимә Ильяска сыенды, яшь аралаш җавап бирде:

– Болай шаярсаң, чыкмыйм дип тә әйтергә булдырырмын!

Икесе дә кычкырып көлеп җибәрделәр. Төнге тынлыкта, салкыннан курыкмыйча, өянкеләр арасында утырган ике яшь йөрәкнең көлүе әллә кайларга ишетелгәндер, бу көлү тормышның җиңүе, язмышларның бергә үрелеп баруы турындагы сүзләрдән көчлерәк иде.

* * *

Әйе, авылда хәбәр тиз йөри. Ильяс өйләнә икән, Сәлимә кияүгә чыга икән дигән сүз таралып та өлгерде. Җомга көн зур мәчеткә килеп, никах укыттылар да яши башладылар. Якыннар өчен чәй эчү үткәрделәр, шуның белән бар да разый булдылар. Вакыты бик болганчык, зур итеп туйлап яту килешмәс диде Ильяс, һәм бу фикер белән бар да ризалашты.

Менә шулай Ильяс та башлы-күзле булып китте. Никах чәендә Галләм карт һәрвакыттагыча үзенең шаян һәм җор сүзләрен сөйләп көлдереп алды.

– Ильяс туганым, син ысматри-матри, өйләнгәч, берничә нәрсәгә игътибар итәсең ул, шул турыда кисәтеп куярга димен. Беренчесе шул: өйләнгәч, куллар кыскара. Шуңа күрә бер дә курыкмыйча кыскарак җиңле кием алырга була. Шуннан, өйләнгәч, төннәр кыскара, димәк, эш вакыты бермә-бер озыная, димәк, ял итә белергә кирәк. Кияүне бит гел эшләтергә тырышалар, шуңа мин сиңа бу сүзләрне әйтәм, туганым!

Кемдер шунда, шаярып, Галләмнең сүзен бүлде.

– Әйтәм, син бик бетеренгәнсең. Шул, эшләтәләрдер?

– Минеме? Мин бит күптән яшь кияү түгел, үз кадеремне үзем беләм. Халыкта әйткәнчә, ысматри-матри, җәй җитеп, яшел үләнгә бассам, яшь бичә алыр идем дип тә хыялланам әле мин!

Өстәл артындагылар кычкырып көлеп җибәрде. Галләм үз сүзен сөйләде.

– Безнең як күпмилләтле бит, үзегез беләсез. Казанлыда гына ничә милләт яши: татар, башкорт, рус, украин, поляк, төрек, удмурт. Киленнәрнең

нинди булуын гел сынаганнар, шуңа да берьюлы өч милләт кызына өйләнергә кирәк дигәннәр безнең егетләргә.

Халыкның, бигрәк тә яшьләрнең, колаклары үсеп киткәндәй булды. Моны күргән Галләм шаярып алды:

– Карале бу өйләнмәгән малайларны! Сүзне эләктереп алырга гына торалар, ысматри-матри!

Инде яшьләр, битарафлык күрсәтергә тырышып, читкә борылдылар.

– Ярар инде, тыңлагыз! – Галләм сүзен дәвам итте. – Рус кызына өйләнсәң, гомереӊ күтәренке күңел белән, көлеп, елмаеп үтәчәк. Удмурт кызына өйләнсәң – аның уңганлыгына, эшчән булуына сөенеп туя алмассың. Безнең кызга өйләнсәң, аның битәрләвенә түзеп яшәргә туры киләчәк!

Бердәм көлеп җибәрүгә түшәмнәр күтәрелеп киткәндәй булды.

– Менә шулай, егетләр! Ысматри-матри, шәригатьтән рөхсәт бар, өйләнегез берьюлы өч милләттән өч киленгә! – Кунаклар көлеп туктагач, Галләм сүзен тәмамлап куйды: – Монысы шаяру гына инде, аңлыйсыздыр. Киленгә бер теләк – төшкән урының таш булсын. Кияүгә теләк: ике якны да тигез кабул итәргә. Олыларга теләгем – килен каенана туфрагыннан яралганын онытмаска, икегез дә бер кешене яратасыз, ызначит, бәхетле итегез аны! Шушы ук сүзләр киленнең әнисенә дә кагыла – кияү-балакай дип әйткәннән генә кияү балаң булмый әле ул. Аны балаң итеп кабул итәргә кирәк, балаң итеп карый белергә кирәк!

Бар да тын гына тыңладылар бу акыллы сүзләрне. Галләм тагын барысына берьюлы мөрәҗәгать итте:

– Ярар, күп сөйләп ташладым, ахры. Амин тотарга да вакыт!

Озак итеп дога кылдылар, бик канәгать булып таралыштылар бу мәҗлестән. Яшьләрнең бәхетле булачагына барысының да иманы камил, башкача беркем дә уйламый да иде.

Тик кем белсен бу дөньяның эреле-ваклы борылышларын, бәхеткә барып җиткәнче, юлларның урау-урау булганын...

**33**

Икенче көнне ике Пётр, хуҗаның мостикка менеп киткәнен көтеп алып, аның артыннан менделәр.

Көзнең салкын иртәсе, суларда яр буенда боз тундыра башлаган чак, озакламый кар күзе дә күренүен көттеләр авылда. Мостикта да салкын гына, Матусов алдында торган чәйнектән, борынны кытыклап, тәмле кофе исе тарала. Кечкенә тәлинкәдә телем-телем итеп киселгән лимон, зуррагында – француз күмәчләре. Шуларның берсен Матусов кетердәтеп тешләп алды да, кызарган күзләре белән бу икәүгә карап, ымлап кына утырырга кушты.

Мостикка күтәрелүчеләр Матусовның хәле яхшыга табан борылганына игътибар иттеләр: буй-сыны тураеп киткән, күзләрендә сүнеп барган очкыннар яңадан күренә, хәрәкәтләрендә элекке ныклык сизелә, сүзләренә дә тәвәккәллек кайткан төсле.

– Ну?! Нindидер яңалыклар бармы сездә? Шуңа икенче көн минем арттан йөрисезме?

Петр Васильевич, тамагын кырып, сүзен башлады.

– Даниел Геворкович, мин Гәвенгә менгереп куйган барканы тикшерттем.

Бигрәк тә такелажны. Йөкнең бәйләнгәне бәйләнгән, калганнары балта белән чабылган. Бик йомшак бәйләнгәннәре дә бар.

Матусов урыныннан сикереп торды.

– Димәк, син әйтергә телисең...

Петялар икесе дә баш кактылар.

– Әйе, Даниел Геворкович! Именно так!

Тынлыкта бер чебеннең тәрәзә пыяласына бәрелгәне генә ишетелде. Матусов күкрәк тутырып алган һаваның чыгуын бер сүзгә сыйдырды:

– Кем?

– Монысы турында аерым сүз. Үтәүчеләр – авылдан ике мужик, кичәге караклар, юлбасарлар.

Матусов бу турыда тыңлап та тормады, кулын селтәде. Ул монда кемнеңдер югарырак торганын аңлый, шуңа да аның исемен көтә. Тагын бар тынын бер сүз аша бушатты:

– Кем?

– Старшина!

Хуҗа, лып итеп, урынына утырды.

– Мин аны шулайрак түгелме дип уйлаган идем дә...

Бу юлы чебен дә курыкты бугай, кешеләргә кушылып, тын калды.

– Үтәүчеләрне тотып ябып куйдык икесен ике урынга. Рекрутларны озаткан көнне алар якындагы ике пристаньны да яндырырга тиеш булган. Керосин тутырылган шешәләре белән тотып алдык.

– Алдашмыйлармы?

– Юк. Аерым-аерым сорау алдык. Барысы да тап килә, алдашмыйлар. Ә нинди файда алдашудан? Гаепләрен таныйлар, исән калдыруны сорыйлар. Ибраһимны саттылар, эче-бавыры белән.

– Чыгып качмаслыкмы?

– Алар көтүчеләр йортында, базда. Анда баз таштан салынган бит, беләсез.

Матусов яңадан аягына басты, мостик бүлмәсен урап-урап йөри башлады. Ике Петька да белә, мондый вакытта аңа эндәшү ярамый, ул ниндидер карарга килү юлларын карый. Бераздан барыбер ул карарын җиткерәчәк. Шуңа да алар тыныч кына үз урыннарында утырдылар.

– Боларын расходка елга кануннары буенча. Тик ераккарак алып китегез, монда дөнья ямьсезләп ятмасыннар. Ә... ә Ибраһим белән ни эшләргә мин үзем белермен. Әлегә тими торыгыз!

Әйтүе генә җиңел – расходка дип. Нинди генә явыз юлбасар булмасыннар, кеше бит әле алар. Тик монысы турында уйлаучы да юк, шулай булырга тиешле дип кабул ителгән кагыйдәдер инде бу. Халыкта сөйлиләр бит, ут төртүчеләрне элек-электән утка, буаларга зыян итүчеләрне суга ташлаганнар дип.

Шулай уйласалар да, ике Петька да бу турыда әйтмәделәр, әлбәттә, Матусовка. Ничә еллар эшләү дәверендә алар икесе дә аның тәртибен, холык-фигылен бик яхшы аңлый иде.

Озак кына тын утырдылар. Матусов, өстәлдә булган кофе һәм башка нәрсәләрне читкәрәк этеп, ярдәмчеләренә эндәште.

– Күреп торам, сез дә бик дулкынланасыз, бу карт ни уйлый икән дип.

Икесе дә кузгалып куйдылар.

– Тыңлап бетерегез. Алда нәрсә булыры билгеле – тагын бер инкыйлаб. Аннан берничә ел рәттән сугыш. Ата улны, инә кызны белми торганы. Байларны тураклау, аларны талау, үтерү. – Матусов авыр итеп көрсенеп куйды. – Так что, бик ипсез вакытлар туарга тора. Монда килеп җитмәс дип әйтеп булмый бу хәлләрне, бөтен Рәсәйнең асты өскә киләчәк. Тел төбен аңлгансыздыр инде. – Матусов тагын көрсенде. – Мин теге көнне сезгә мал-мөлкәтнең башын-азагын билгеләргә кушкан идем. Шуны эшләдегезме?

Икесе дә бик тиз җавап бирделәр:

– Әзер, Даниел Геворкович!

– Әйбәт. Димәк, эшкә тотынабыз. Төшкә тиклем үзегезнең эшләрегезне бетерегез, төштән соң утырабыз.

Сөйләшү тәмамлаганын аңлап, ике Петька да кузгалдылар. Ишеккә барып җиткәнче, Матусов аларны туктатты.

– Менә нәрсә, егетләр! Мин теге чакта ук әйткән идем, сезне буш итмәм дип. Шул сүземдә калам. Ничә еллар бергәләп кордык шушы дөньяны, бергә тәмамлап та куярбыз инде. Жәл! Тик авызыгызны үлчәп ачыгыз. Беркем белергә тиеш түгел!

Петькалар аңлашылды дип баш кактылар һәм чыгарга ашыктылар.

Матусов урынына утырды, инде суынган чәйнекне тотып карап, кыңгыравын шалтыратты. Көмеш кыңгырау шалтыравына җавап итеп, эшче кызлардан берсе йөгереп керде дә чәйнекне эләктереп йөгереп чыгып китте. Күп тә үтмәде, тагын йөгереп диярлек кереп, пары чыгып торган савытны Матусов алдына утыртты, күмәчләр өстәде, алар янына сап-сары май куйды.

Мостик бүлмәсенә тагын яңа гына әзерләнгән кофеның хуш исе таралды.

## 34

Үзенең ике юлбасарын бер атна эзләтеп, эзен дә таба алмагач, Ибраһим эшнең кайсы якка юнәлгәнен аңлады. Бу ике адәм артыннан аның үзенә дә чират җитәчәгенә ул бер дә шикләнми, тик ни эшләргә кирәклеген әлегә белми иде. Ә шулай да, ул-бу була калса, аның җаваплары әзер, ул аларны онытмас өчен кат-кат кабатлап йөрде. Беренчедән, бу әтрәк-әләмнәр аның ише түгел, ул алар белән бернинди бәйләнештә дә түгел. Ул кайда да, бу кешеләр кайда? Икенчедән, Матусов – ихтирамга лаек кеше, бу сәнәгатьне аңардан башка беркем дә шулай төгәл һәм тәртипле итеп алып бара алмый. Ә авыл кешеләренә нинди файда – әнә күпме кеше эшли анда җәен-кышын? Өченчедән, Ибраһимның аның белән уртак эше, бер үче юк. Нигә дип әле ул аның белән якалашырга тиеш?

Ибраһим шулай да, үзенең куркуларын, шик-шөбһәләрен язып, өязгә җибәрде: ул-бу була калса, старшинага булган һөҗүмне оештыручыларның туры адресы бар иде анда.

Язу – язу инде, ул гына саклап алып кала алмас. Саклanганны саклармын дигән Аллаһы Тәгалә. Алдын-артын карап йөри башлады, өйдәгеләрне инкыйлаб дип куркытты. Бүлмә саен мылтык һәм хәнҗәр таратып куйды, ишекне, капкаларны бикләүне зарур итте, авылда булган берничә шымчысына көн саен күргән-белгәннәре турында хәбәр биреп торырга

кушты. Иң курыкканы – төн, төнен ни булырын кем генә белә. Йорт-курада торган бозау хәтле ике этне кичкелеккә бәйдән ычкындыра башладылар.

Иң мөһиме – Матусовның, аның кешеләренең нинди адым ясарын белү һәм шуңа әзер булу. Матусов берни булмагандай яшәвен дәвам итә, Ибраһим турында уйламый да, күрешкәндә элеккечә исәнләшә, күз карашында да бернинди дә усал уйлар сизелми. Монысының алданчык тышкы кыяфәт кенә икәнен аңлый старшина, тик аның аңлавы гына эшне берничек тә җиңеләйтә алмый, бары курку өстәп, аны катлауландыра гына.

Ә бер нәрсәне, өязгә язылган хатның Матусов кешеләре кулына төшкәнен барыбер сизми калды ул.

* * *

Октябрьнең азагында станциядән кичкә калып кына кайтты ул. Ничә мәртәбә үзенә әйткәне булды – төнгә каршы чыкмаска дип, җитмәсә, берүзе. Тагын уйлаганча эшләмәде, тыңламады әллә кайдан, тирәннән килгән искәртүне. Кәлтә урманнарына кергәндә, икенде-ахшам арасы җиткән иде инде. Берничә тапкыр кире борылырга дип тә уйлап карады, тик үзсүзлелек алдарак туган шул. Якында Танып күпере, бер-ике чакрым урман, аннан ялан, авылга да чак кына кала. Нигә дип әле кирегә борылырга?

Шундый уйлар белән тулган башын төрле якка борды Ибраһим, урманда әллә ниләр булып күренгән һәрбер төпкә, һәрбер агачка игътибар белән карап, кулындагы револьверны ычкындырмыйча, атын каулады.

Урманны чыгарга күп тә калмаган иде. Сизми дә калды Ибраһим, агач дип караган карачкылардан икәү аерылды: берсе атның башын тотып кинәт туктатты, икенчесе тигезлеген югалтып, арбадагы печәнгә таянган Ибраһимның револьверлы кулын арба тактасына кысты. Һәм шунда әллә кайдан, һавадан яңгырагандай тавыш ишетелде:

– Ну, саумы, юлбасар! Никак, калтырыйсың? Дөрес, правильно делаешь! Пришел твой последний час!

Кем тавышы икәне билгеле иде, тик Ибраһим вакытны сузарга тырышты:

– Кем бу? Сез нишлисез? Мин бит власть вәкиле, бу эшләрегезнең кая барганын аңлыйсызмы?

– Ладно, танымаган булып кыланма, каналья!

– Даниел Геворкович, син шаярасыңмыни әле шулай? Котны алдың бит! – Ибраһим көләргә маташты. – Шаяруларың бик кызык!

– Юк, нинди шаяру ди? Сөйләшәсе генә бар.

– Иртәгә, волостьта сөйләшик, бүген бик соң да инде? Аннан урыны да...

– Соң түгел. Урыны да менә дигән! Итак. Сине кара көнчелек харап иттеме? Ә? Сиңа минем тегермән кирәк булдымы? Сиңа минем лесопильня кирәк идеме? Сиңа минем йорт ошадымы? Син минем акчаларга кызыгып йөри идеңме? Боларның барысын да сиңа сатып та бирер идем әйбәт кенә хакка. Килешер идек, анысына гына калса. Мин бит үз ягыма кайтып китәргә карар кылган идем күптән түгел.

– Даниел Геворкович, сез нәрсә! Кирәкми миңа болар! Мин бит, беләсең, дәүләт эшендә. Вакытым да юк, теләгем дә! Буш сүз җиткергәннәр сезгә!

– Буш сүз! Ә хәзер иң мөһиме: нигә дип егермесе дә тулмаган баланы үтердең, явыз? Мин бит монысын сиңа никогда не прощу!

Ибраһимның тавышы бөтенләй калтырый башлады.

– Әст-стәгъфирулла, Д-даниел Геворкович! Ни сөйлисең син? Минем бер гаебем юк! Шуннан, минем вазифадагы кеше аны эшли аламы?

– Ала икән шул! Тик мин бит Аллаһ түгел синең гөнаһларыңны, язык эшләреңне барларга-ярлыкарга. Аның каршында, Матусов бармагы белән һавага күрсәтте: җавап бирерсең совсем скоро. Ә минем өстән язган жалуың? Менә ул! Күрсәтегез әле аның хатларын!

Матусов егетләренең берсе кулындагы кәгазьләрне өскә күтәреп күрсәтте. Коты очкан Ибраһимның тавышы калтырый, ул, ычкынырга юл эзләп, тирә-ягына карый, сүз кушып, боларны сөйләндерергә тырыша.

– Нишләтергә уйлыйсыз мине? Мин гаепсез!

– Эшләтәбез. Әгәр сиңа кызык булса, әйтәм. Танып күперенә кергәч, синең атың нидәндер куркып дулап китә. Ә син егылып төшеп каласың, башың белән елгадагы субайга бәрелеп, муеныңны сындырасың. Ә субайга табан турыларга сиңа ярдәм итәрбез!

Ибраһим, тотып торучыларның куллары нык булуга карамастан, Матусовның аягына егылырга маташты, авызыннан аңлашырлык сүз чыкмый иде.

– Беләсеңме, башта мин, сине тотып, властька тапшырырга дигән идем – власть юк, власть бетте, тәртип бетте. Аннан атып кына китәргә уйлаган идем, кире уйладым. Син һәлак иткән балалар кебек һава җитмәүдән үләчәксең. Бер-ике көннән табарлар, кайгырма! Так что прощай!

Ибраһим котыла алмаячагын аңлады, аны тотып торган кеше кулларына эреп-агып төште.

– Даниел... Даниел Геворкович! Гафу ит! Ярлыкау сорыйм!

– Бог простит!

Матусов борылды да китеп барды.

* * *

Яман хәбәр дә тиз йөри авылда. Старшина Ибраһим Кәлтә урманында дулаган атыннан күпердә төшеп калып муенын сындырган дигән хәбәр кешеләрне аптыратты. Атының дулавы, күпердән төшеп калуы, субайга туры килүе – болар барысы да бәлки очраклы түгелдер дигән фараз да йөрде, бу сәбәпләрнең бергә туры килү мөмкинлеген дә истән чыгармадылар. Тик берничек тә аңларлык түгел иде: уңышлы кеше, эше дә барган кебек, өстәгеләр дә аннан канәгать, күпере дә көн саен диярлек үтеп йөргән күпер...

Тик монысы баштарак булды. Соңрак Ибраһим тарихы чуен юлы тирәсендәге җирне сату белән бәйләнеп китте, кемдер Матусов кешеләрен үтерү белән дә кушып җибәрде. Ул гына да түгел, халык телендә ятканнардан иң күп сөйләнгәне булып, ике атна элек кенә югалган Ярми белән Тамырбулатның үч алуы булды. Ни генә уйлап чыгармадылар, ничек кенә итеп сөйләмәделәр, нинди генә фаразлар кылынмады бу нәүбәттән. Шулар арасында Матусовны көлдергәне – Ибраһимның, бандитлар башлыгы булып, урманга качуы, чуен юлда таланган бер вагон алтынны бүлешә алмый, иптәшләре тарафыннан суга ташлануы булды.

Кешенең авызын ябып куеп булмый, моны барысы да аңлый. Бераз сөйләделәр дә оныттылар. Ничек кенә булмасын, бу адәмнең язык

эшләреннән иң зур каза күргән Матусов, авызына су капкандай, бер сүз эндәшми, ләм-мим, ә элекке старшина Гаязетдин бары берничә сүз әйтте: «Ходай үзе ярлыкасын. Урыны оҗмахта булсын, әгәр лаек булса!»

Халык әйтсә, хак әйтә шул: кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең...

**35**

Башланды. Башланды теге курка-курка көткән мәхшәр.

Октябрь азагында чуен юл аша Петроградта булган инкыйлаб турындагы хәбәрләр килеп төште. Тик әлегә ул хәбәрләр каршылыклы, кайсыбер өлешенә ышанырлык та түгел иде. Бернәрсә ачык – кичәге тәртип юкка чыга, бүгенгесе әлегә юк. Әгәр инде теге ата улны белмәгән сугышы да була калса, ил юкка чыга язачак. Чынлап та, монысы – алда көтелгәннәрнең иң начары.

Мең дә тугыз йөз унсигезенче ел башында фронттан солдатлар күпләп кайта башлады. Солдатлар белән бергә таудай мәгълүмат та кайтты: Питерда инкыйлаб, власть эшчеләр кулында, сугыш бетә, солых турында, җир турында декрет, хөррият, иске власть юкка чыга. Кемнәрнеңдер көткән көннәре килеп җитте. Бу инкыйлабның иң ошаган ягы байларның мөлкәтен бүлешү дигән сүзләр булды. Солдатлар алып кайткан яңалыклар яшен тизлегендә авылларга тарала башлады. Әллә ни хәрәкәт күренмәсә дә, байларда булган мөлкәтне ярлыларга таратып бирү тәкъдимен ошатучылар аз түгел икәне беленде. Мәңгелеккә китеп барган старшинаның урынбасары Зарифка бу тәртипсезлеккә каршы чыгарлык бернинди дә көч юклыгы да ачылды.

Яңа елдан соң гыйнвар аеның җепшек бер көнендә волостьта һәрбер авылдан бер вәкил Казанлыдан балигъ булган кеше исәбеннән җыен җыеп алдылар. Җыенда катнашучылар арасында Ильяс та бар, тик аңа иртәдән үк баш авыртуы күз ачарга да ирек бирмәде. Җыен башланганда, ул өй алдына чыгып утырды – андагы хәлләр болай да яхшы ишетелә иде.

Җыенның рәисе итеп Шаһиәхмәт хәзрәт билгеләнде, өстәл артында утырган наганлы мулла Сафа күбрәк сорау бирде һәм сөйләде. Кайткан солдатлар ягыннан инкыйлабта Кышкы сарайны алуда катнашкан өч фронтовик – бертуган Низаметдин һәм Хисаметдин, беренче көненнән үк сугышны үткән Фазлыйәхмәт – белгәненчә вазгыятьне бик тәфсилләп аңлаттылар.

Күпләрне җир мәсьәләсе кайгыртты. Монысына җавап итеп, Фазлыйәхмәт кесәсеннән ике бит кәгазь тартып чыгарды.

– Менә, пжалыста, укыгыз. Бу – Җир турында Декрет.

– Үзең генә укы, әйдә!

Фазлыйәхмәт, махоркадан саргайган бармагы белән төртеп укып, Декретның төп мәгънәсен тыңлаучыларга җиткерде.

– Барысын да укып тормыйм, сайлап, кыскартып кына.

– Ярый, ярый, кирәген генә укы!

– Беренче. «Помещичья собственность на землю отменяется немедленно без всякого выкупа». Икенче. Земли «переходят в распоряжение волостных земельных комитетов и уездных Советов крестьянских депутатов, впредь до Учредительного собрания».

Мәйдан өстеннән «Ух!» дигән тавыш очты һәм әллә кая югарыга менеп югалды. Күзләрдә очкыннар очканы күренә башлады.

– Тагын! Тагын нәрсә?

– Тагынмы? Пжалыста! «Право частной собственности на землю отменяется... Земля обращается в всенародное достояние и переходит в пользование всех трудящихся на ней... Право пользования землей получают все граждане, желающие обрабатывать её своим трудом, ... пока они в силах её обрабатывать. Наёмный труд не допускается».

– Димәк, ялчылар булмаячак?

– Ш-ш! Тик тор! Тыңлап бетерик башта!

– «Землепользование должно быть уравнительным, земля распределяется между трудящимися, смотря по местным условиям, по трудовой или потребительной норме... Распределением её заведуют местные и центральные самоуправления. Земли рядовых крестьян не конфискуются. Вопрос о земле может быть разрешён только... Учредительным собранием».

– Кара, ике-өч кат кабатладың. Ә нәрсә соң ул Учредительное собрание?

Монысына җавапны Низаметдин бирде.

– Безнең полкка соңгы айларда агитаторлар бик күп килде. Алар шулай аңлатты. Учредительное собрание ул – шул ук җыен, ул иң мөһим карарлар кабул итә. Нинди дәүләт булачак, сугыш турында, җир турында.

Тик җыен бераздан алда уйланылганнан читкә китте. Моңа Сафа мулланың тәрбиясезлеге баш булды. Ул солдатларга алар җавап бирә алмаслык сораулар бирә башлады, Петроградтагы инкыйлаб хәтле инкыйлаб килеп чыгуда аларны гаепләде, соңга таба инде аларга авыз ачарга да ирек бирмәде. Ә солдатлар авызга су кабып куркып тора торганнардан түгел, булган мәгълүматның барысын да уртага салып, белгәнен сөйләделәр.

– Сез нигә кысылып йөрдегез инде ул эшләрдә?

Кичәге солдатлар көлеп җибәрделәр.

– Бәй, ничек инде «кысылып», ди? Без солдат, солдатка приказ бар, солдат шуны үти инде.

– Бу эшләрнең властька каршы икәнен белә торып, анда катнашкач, сез гаепле!

Солдатлар бер-берсенә карап көлештеләр.

– Ничек аңлатасың инде боларга армия тәртибен?

– Беләбез тәртипне. Сездән башка да! Җәмәгать, нишлибез? Болар меңәр ел буена килгән дәүләтне кырырга өндиләр түгелме? Безгә кирәкме бу?

Хисаметдин бу сүзләргә каршы эндәште.

– Без белгәнен сөйләдек, сез тыңладыгыз. Ишетсәгез – кабулым бар, ишетмәсәгез – сабырым бар. Берничә көннән яңа властьның фәрманнары килеп тә җитәр әле, көтегез!

– Әле син безгә яный да башладыңмы? – Сафа иярченнәренә ымлады. – Бирегез кирәкләрен бу Алласызларның алай булгач! Кһем-кһем!

Сафа мулла үзе чыгып ук китте мәйданнан. Солдатлар тиз генә, стена буена басып, арка ягыннан һөҗүм мөмкинлеген юк иттеләр, аяк астында яткан агач кисәкләрен эләктерделәр. Иярченнәр дә якын килмәделәр, тик шул арада аларның берсе, әрдәнә итеп өелгән утын яркаларын алып, аларга ыргыта башлады, аңа башкалары да кушылды.

Тавышның бер көчәюенә, бер тынуына карап, хәлне бик тиз аңлап алды Ильяс, башына уралган чүпрәкне алып ташлап, волостька табан йөгерде. Ул килеп җиткәндә егылган солдатларга утын ату дәвам итә иде әле.

– Туктагыз! Ни эшлисез? Кеше үтерәсез бит?

Кайдандыр читтән Сафаның тавышы ишетелде:

– Монысын да! Күптән вакыт бу бәлшәүикнең дә арт сабагын укытырга.

Тик барып чыкмады бу эш. Ильяска ярдәмгә күсәк күтәргән Шакир һәм башкалар килеп чыкты, Сафаның куштаннары тиз арада качып беттеләр. Ильяс солдатларга иелде. Аларның кызыл-кара канга баткан башларын тотып карап, бераз сүзсез торгач, зур итеп ачылган күзләрен йомдырды. Фазлыйәхмәт әлегә исән булып чыкты, тик күл булып аккан кан эчендә ятуына караганда, аның гомере дә санаулы булуы һичшиксез.

Ильясның егетләре бу кансыз кешеләр артыннан йөгереп тә карадылар. Тик Сафаның куштаннары, волость артында торган атларга сикереп менеп, Казанлыдан Чүпрәлегә таба качып өлгерделәр.

Сугыш тиклем сугыш кансызлыгын, шәфкатьсезлеген үтеп исән кайткан ирләр шулай бер дә юкка башларын салдылар туган җирдә...

Унсигезенче елның кар күзе төшеп торган бу көнендә Казанлы, кире кайтмаслык итеп, икегә бүленде. Һәм бу ике якның бервакытта да килешә алмавын күзаллау бер дә авыр түгел иде.

**36**

Калган вакыйгалар бер-бер артлы таудай ишелеп төшә башладылар.

Иң беренче булып, җир турында карарлар кабул ителде. Крестьян җир банкының сигезенче район бүлеге мөдире А.Котовның җирне бирү турындагы карары барлыкка килде. «Настоящим доношу Уфимской губернской коллегии по земледелию, что 13 (26) февраля с.г. на основании декрета СНК от 26 октября 1917 г. и постановления Бирского уездного Совета крестьянских депутатов от 30 января 1918 г., мною произведена передача всех имений вверенного мне района и прочего, находящегося в моём распоряжении волостных земельных комитетов». Кызык, кем соң җир хуҗасы? Шунда эшләгәннәрме, җирне эшкәрткәннәрме, әллә банкмы? Җир хуҗалары бөтенләй читтә торып калды бу карардан.

Икенче итеп, өязгә советлар съездына вәкилләр сайладылар. Рәсәйнең чиксез зур булуына ышыкланып, унҗиденче елның беренче декабрендә булган Беренче җыенга, унсигезенче елның февралендә булган Икенче җыенга бу яклардан бер вәкил дә сайланмый калды. Ә сайланган вәкилләр арасында күпчелекне эсерлар, меньшевиклар, кулаклар тәшкил итә. Бу хәл чынлап та бер фиркане дә канәгатьләндермәде, шуңа да Өченче җыен алдыннан – анысы март аеның егерме бишенә тәгаенләнгән иде – бик кызу эшләр алып барылды. Сафа мулланың нык тырышуына карамастан, ул, вәкил булып, җыенга үтә алмый, төшеп калды. Ике кешене – Ильяс һәм тагын да берәүне, элекке старшина Галишан Казыйхановны сайлады халык.

Шул арада тагын бер яңалык бөтен авылны, бөтен тирә-якны гөрләтте. Старшина урынында йөргән Зарифның бер эшен дә күрмәгән халык, аның урынына эшләрдәй кешене куюны таләп итте. Бу эшне күтәреп чыгучы булып, гомум эш бармаганга җаны көйгән Гаязетдин булды, шуңа да ул

башлап чыгыш ясаучы, тәҗрибәле кеше буларак, җыенның рәисе итеп сайланды.

Старшина сайлау турында ишеткәч тә, халык бу вазифага аның үзен кыстый башлады, тик Гаязетдин нык торды, сәбәп итеп фронт яралары үзенекен итүен, йокы, тынычлык юклыгын әйтте. Шуннан: «Әнә хәтта туп ядрәсе дә бер чокырга рәттән ике мәртәбә төшми», – диде ул шаяру катыш. Чынында исә аның максаты бу эшкә инде үзен күрсәтеп өлгергән Ильясны кертеп җибәрү иде. Барысын да алдан уйлап, әзерләнеп килделәр алар бу җыенга.

Җыен башланып өлгермәс борын волостьның зур залында басып торырга да урын юк иде.

– Җәмәгать, Рәсәйнең җиккән аты бик зур тизлек белән әллә кая таба чаба башлады. Алда ни булырын Ходай үзе генә белә. Бу чорда, бу чакларда нык, төпле кеше, халыкка терәк булырлык кеше кирәк старшина урынында. Ни Аллага, ни муллага булып йөргән кеше безне канәгатьләндерә алмый. – Гаязетдин Зарифка ымлады. – Нинди тәкъдимнәр бар?

Шуны гына көткәндәй, берничә урыннан Сафа мулланың кешеләре чәчрәп килеп тә чыктылар:

– Сафа мулланы куярга кирәк старшина итеп. Хәзрәт дин эшен дә, волость эшен дә яхшы белә. Бар ягы белән дә килгән!

Гаязетдин тыныч кына үз уен алга сөрде:

– Шулайдыр, без монысына ышандык инде. Күп вакыт та узмады бит аның үтә «законлы» эшләренә.

Монда инде Сафа үзе кычкырып диярлек җибәрде:

– Мин беркемгә дә тырнак белән дә кагылмадым. Гаеплеләрне эзләгез, ә миңа тимәгез! Якын да киләсе булмагыз!

– Дин кешесенең теле бик ипле булырга тиештер, хәзрәт? Хөрмәтле җыен белән сөйләшкәндә, бу бигрәк тә зарур. – Гаязетдиннең тынычлыгы куркыта иде Сафаны. – Старшина кеше дөнья күргән, утын-суын кичкән, армиядә булган кеше булырга тиеш. Дөньяви тәҗрибәсе булмаса, аңардан ни файда? Шуңа да мин, авылның ихтирамга лаек булган кешеләре белән сөйләшеп, икенче кешене тәкъдим итәм.

Гаязетдин, җыенга җыелганнарны кызыксындырып, махсус рәвештә туктап калды. Халык та тынды, кемдер кычкырды:

– Кемне? Исемен ата!

– Хәзер әйтербез. Старшина кылган эшләренә җыен алдында җавап бирә, андый кешене сайлаган җыен үзе дә өстенә җаваплылык ала. Шуңа күрә дә сайланасы кеше очраклы кеше булырга тиеш түгел!

– Сузма инде! Кем? Исемен әйт!

Күренеп тора, җыендагыларның алдан әзерләнгән бер өлеше башкаларны авыз да ачтырмый, төрле урыннан кычкыра башлады:

– Сафа! Сафа мулла! Сафа! Сугышта булган, әфисәр булып кайтты!

Халыкны тынычландырырга теләп, Гаязетдин кулын күтәрде. Бераздан гына тынычлык урнашты. Өстәл артында бөтенләй битараф булып утырган Зарифка бернинди игътибар юк, ул үзе дә бу эштән төшеп каласына инде ышанган иде, шуңа да тын гына утыра бирде.

– Мулланың эше муллалыкта, җәмәгать. Без икенче кешене тәкъдим

итәбез. Ул да булса – Ильяс Ягафаров. Барыгыз да беләсезме аны? Белсәгез, аның турында сөйләп тору артыктыр.

Бу исемне тыныч кына каршы алган халык, сорауның икенче яртысыннан көлеп, шаулашып алды. Чынлап та, ярты ел эчендә аңа булган хөрмәт бермә-бер арткан иде. Ильяс кешеләр каршысына алгарак чыкты. Җыенга ул солдат киемендә килде: гимнастёркасы, коеп куйгандай, көчле иңбашларда утыра, каеш белән билен кысып буып куйган, аяктагы итекләре чистартылып, исе килмәсен өчен кичә үк дегет белән буялган. Ильяс, фуражкасын бер кулыннан икенчесенә күчерә-күчерә, дулкынлануын яшерергә тырышты. Кыендыр ул бөтен халык карап торганда үзеңә: бер күзләрдә – ышану һәм өмет, икенчеләрендә «Курыкма!» дип дәрт бирү, өченчеләрендә икеләнү чагыла...

– Беләбез, яхшы беләбез! Ильясны сайлыйбыз! Ул безне рәнҗетергә ирек бирмәс!

– Ильяс яшь, сугышны үткән, чынлап та дөнья күргән, ата-бабасы, чыгышы белән тулысынча безнең якныкы. Тагын нинди кеше кирәк? Эзләп тә тормаек, кардәшләр!

– Шундый Ильяс кебек теремек кеше кирәк безгә. Зариф кебек утырган урынында оеп, йоклап торганнан нинди файда ди инде ул?

Сафаныкылар да калышмады, халык арасында буталып, кычкырудан туктамадылар:

– Сафа! Сафа мулла старшина! Сафа!

– Сафа укымышлы, зыялы кеше!

– Ә Ильяс укымаганмы? Ул бит – «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган кеше! Бу сиңа шүтке түгел!

Әйе, Сафа тик кенә ятмаган бу көннәрдә, күп кенә кешене алдан әзерләп өлгергән. Ике арадагы килеп чыккан тарткалашу сугышка барып җитә язды. Шунда моңа хәтле тын гына утырган Галләм карт алга чыкты.

– Кордашлар, башта сезгә эндәшәм. Ысматри-матри, Ильяс – ир уртасы, башы бар, укыган, фронтта сугышның беренче көненнән булган, кайтты да эшкә чумды. Халыкның мәнфәгатьләрен аңлый, белә, халыкка кирәгенчә сорауларны куя да, чишә дә. Тагын кем кирәк соң безгә? Бары тик Ильяс! Яшьләр, сезгә мөрәҗәгать итәм – Ильяс бит сезгә өлге! Ысматри-матри, бармы тагын андый кеше сезнең арада?! Олылар белән сезнең тирә яшьләрне бәйли торган старшина булачак ул! Сайлаек аны, матур тормыш аның ягында, менә шул! Ысматри-матри, ялгыша калсак, ул ялгышны төзәтү кыен булачак бу болганчык заманда! Менә шул! Бары тик Ильяс!

Сафа кешеләре иң авырткан җиргә сукмакчы булдылар:

– Ә аның тазалыгы хөрти! Фронттан кайтканнан бирле чирләп ятты!

Зал тынып калды, барысы да бер Ильяска, бер җыенны алып баручы Гаязетдингә карадылар. Тамагын кырып, шул ук тынычлык белән Гаязетдин кычкыручыга табан борылды:

– Йә, кем әле син! Халык арасына качып сөйләүче Ходай бәндәсе! Син авылда теләгәнеңне эшләп ятканда, Ильяс, сине саклап, окопта ятты. Син авылда кеше талап ашап-эчеп ятканда, ул лазаретларда яшәү белән үлем арасында булды. Ул үзенең бурычын тутырып үтәде, әле дә халык өчен бар көчен салырга әзер. Аллага шөкер, тазалыгы да кайта. Менә, карагыз, аның

кебек барыбыз да шундый баһадирдайбызмы бу җыенда? Күз тимәсен, менә дигән егет! Шулай булгач, син, мондый сүзләр сөйләүче – тәрбиясез кеше. Мин сине Ходай бәндәсе ди атаган идем, кире алам сүземне. Син Ходай бәндәсе түгел, син – адәм актыгы! Җәмәгать, бармы минем белән ризалашмаучылар?

Тын калган халык кычкыручыдан читкә тайпылды, ул мескен берүзе торып калганын аңлагач, тиз генә залдан чыгып ычкынды.

Бу сүзләр барып җитәр урынын тиз таптылар. «Сафа! Сафа мулла старшина! Сафа!» дип кычкыручыларның саны күпкә азайды.

Гаязетдин монысына инде игътибар да итмәде:

– Риза булсагыз, ике вәкилне дә тавышка куябыз. Исегезгә төшерәм, җыенда старшинаны авыллардан ун өйдән бер кеше исәбеннән күрсәтелгән вәкилләр сайлый. Сайланырга теләүчеләр, халык күрсәткән вәкилләр белән танышкач, турыдан-туры сайлау мәшәкатьләренә күчәбез. Күрәсез, өстәлдә тартма тора, анда ике тишек. Сайлаучылар, ризамы-каршымы икәнен күрсәтеп, шул тишеккә шарлар сала.

– Бигрәк катлаулы эш, җиңелрәк ысулы юкмыни? – дип, башны катырырга теләде берәү. Аны тиз туктаттылар.

Гаязетдин дәвам итте:

– Сайлауны без уйлап чыгармаган, аның үз тәртибе, җае бар. Өяздән өстәрәк җирдән килгән язулар кушканча, тиешенчә эшлибез, җәмәгать!

– Алай икән! – Сафаныкылар тагын шаулап алды.

Гаязетдин, алар ягына кулын селтәп, сүзен тәмам итте:

– Шуннан, җиңүче билгеләнгәч, аның тормыш юлын бик тәфсилләп язып, Өяз дворяннары җитәкчесенең исеменә хат әзерләрбез.

Җиңделәр Ильяс ягындагылар бу сайлауда. Сафа мулла тагын төшеп калды. Ачыктан-ачык дошманлык булмаса да, эшнең тирәнгә кереп баруы турында Сафа ягыннан булган кара йөзләр сөйләде. Сафаның куштаннары тагын, волость артында торган атларына сикереп менеп, Казанлыдан Чүпрәлегә табан очтылар.

Бу юлы нинди планнар коралардыр...

**37**

Унсигезенче елның язы озак, ашыкмыйча гына килде. Әллә нинди хәл – Казанлыда тавыш-тын басылды, кинәт дөнья тынып калды. Әйтерсең яшәешнең кискен үзгәреш көтүе кешеләргә авыр йөк булып баса, шул басымга табигать тә үзенең бакыр биш тиенен өсти иде.

Иң куркытканы, иң аптыратканы – власть юкка чыгу. Чуен юлдан килгән хәбәрләр чехословак корпусының фетнәсе турында көн саен төрле яңалык алып килә. Казанда да, Уфада да Учредительләр җыелышының шулай бер сәбәпсез таратылуына каршы чыгучылар саны күз алдында арта барды. Өяз белән волость арасында мөнәсәбәтләр өзелде, бернинди күрсәтмәләр, фәрманнар килми башлады.

Ильяс, старшина буларак, үз белгәне буенча эшләргә тырышты. Ә белгәнне башта аксакаллар белән, Яков Костантинович белән киңәшләште. Иң беренче карар (власть бары шунда гына власть була, әгәр кулында нидер булса) – шул җир турындагы Декретны тормышка ашыру булды.

Бу эштә иң кыены – җирне яңадан бүлү. Эшнең бу өлеше бервакытта да тыныч кына тәмамланмый, һәрвакытта да канәгать калганы да, канәгать түгеле дә күп була. Кемдер үзенең ызанын тирә-якны тазартып зурайтып өлгергән, кемдер ел саен черемә керткән, чүп үләнен юк иткән, ә кемнеңдер җирләрендә билчән һәм кычыткан үсеп утыра. Соңгы мәртәбә бу җирне кабаттан бүлешү ике гасыр очрашканда була, әле бүген дә кайсыбер авылдашлар ул елны иң усал сүзләр белән искә төшерәләр. Шушы хәлләр кабатланмасын өчен, Ильяс бер көнне, хәлле кешеләрне, аксакаллар һәм дин әһелләрен чакырып, бик озак сөйләште. Ә моңа хәтле ул Декретның үзен, Учредительләр Җыелышына әзерләнгән бик күп документларны, бигрәк тә «Крестьянский наказ о земле» дигән өлешен зур дикъкать белән өйрәнде.

Иң беренче булып, Ильяс үзе яклы, үзгәрешләргә тарафдар кешеләрне җыярга тырышты. Шулай итми дә булмый, бу җыелышка наганлы мулла Сафа үзе, җитмәсә, үзенең куштаннары белән килеп керәчәк.

Чынлап та, шулай булды. Сафа үзенең башкисәрләре белән бер сәбәпсез урам буйлап чаба, волостька килеп керә, сүз тарата, кешеләрне куркыта. Ильяс былтыргы елны Петроградта «Ике властьлылык» килеп чыкканын һәм бу хәлләрнең нәрсәгә китергәнен яхшы хәтерли. Монда да шул ук хәл – кайдандыр корал тапкан Сафа, үзе кебек чаяларны җыеп, зур гына төркем корып җибәргән, аларны атарга, коралны карарга өйрәтә, айга ике-өч чуен юл станцияләренә барып, кеше таларга да булдыралар. Бусына каршы чыгарлык бары бер чара – төркем төзү, корал табу, кешеләрне азмы-күпме сугыш эшенә өйрәтү, саклый торган чикләрне билгеләү. Менә шушы сорауларны күтәрде Ильяс бу җыелышта. Тик аның башында ук Сафа кешеләре белән беренче бәрелеш булып алды. Сафа бу бәрелештә үзенең бик усал, астыртын һәм хәйләкәр булуын күрсәтте. Ничек тә булмасын, яңа төркем төзетмәскә – менә монда күренде аның хәйләкәрлеге:

– Кһем-кһем! Җәмәгать, мин ничә ай инде кеше җыеп, аларны үзем ашатып-эчереп, өйрәтеп ятам. Әллә бик җиңел дип уйлыйсызмы? Мин бит әле дини вазифа да башкарам. Тагын нинди төркем, ди, инде ул? Аларны карарга, тәртиптә тотарга кирәк! Әле күпме вакыт үтеп китәчәк алардан кеше ясаганчы. Ә минем әзер команда бар. Кһем-кһем!

Кемдер ризалашырга итте, кемдер каршы килде – соңгылары күбрәк булып чыкты.

– Сафа хәзрәт, бу болганчык заманны алдан күреп, бик кирәкле эш башкарган, туганнар!

– Әйе, тик хәзер стансада кеше талап йөриләр!

– Кем әйтте моны? Кем кемне талый торгандыр, тик минем егетләр андыйлардан түгел!

Көлеп җибәрделәр. Беләләр, беләләр, кем кешеләре оят һәм вөҗданын югалтканны.

– Егетләр бер дигән, кирәксә, халык өчен утка-суга керергә әзер. Кирәкми дисәгез, мин сезне көчләп, җәннәткә куып кертә алмыйм!

Шунда Ильяс, барысын да аптыратып, Сафаның бәкәленә суктырырлык тәкъдим кертте:

– Ярар, сезнең тәкъдимне карап карарбыз. Тик бу төркем волость кул астына күчә, һәм аның командиры итеп без икенче кешене куябыз.

Сафа хәзрәткә, чынлап та, бик җиңел түгел берничә эшне берьюлы алып барырга.

Ильяс яклылар бик тиз аңлап алды аның бу җиңүгә алып барган юлын.

Сафа да моны беренчеләрдән булып сизде һәм кычкырып җибәрде:

– Ю-у-ук! Ничек итеп мин үземнең карап үстергән бала кебек эшемне сезгә бирим ди? Кара әле, әзергә-бәзер! Кһем-кһем! Мин моңа риза түгел һәм беркайчан да риза булмаячакмын!

Сафаның риза булмаячагы билгеле инде. Шуңа да Ильяс бу сүзләрне әйтте дә.

– Ярар, алайса, хәзрәт. Юк, димәк, юк! Без монда үз юлыбыз белән барырбыз, болай булгач.

Сафаның, кызарынып, бөтен чикләрне чыгып китүе җыелыштa утырган дин әһелләрен каршы сүз әйтергә мәҗбүр итте. Иң беренче булып, Фәйзерахман мулла туктатып карады:

– Сафа хәзрәт, бу сүзләрең, бәгъзе эшләрең изге динебез кысаларына сыя торган түгел. Сезләр әдәп вә тәүфыйк барлыгын онытa башладыгыз, ахры. Халык ни әйтер сезгә карап? Дин турында, дин кешеләре турында?

Аның сүзләрен Әхмәр хәзрәт куәтләде:

– Эшләреңдә зәррә хәтле дә ихтирам юк дингә дә, кешегә дә. Халык та сезләрнең юлын юлбасарлык, ягъмачылык дип атый бит! Нигә дип наган тагып йөрисең, син бит – мулла!

– Булса тагы. Кһем-кһем! Әнә Мөхәммәт пәйгамбәребез үзе дә сугышларга йөргән, вакыты җиткәч. Миңа да менә вакыты килеп җитте.

– Өч әзмәвердәй солдатның гомере синең кулда! Гөнаһтан курык, хәзрәт!

Сафа күтәрелеп бәрелде:

– Яла! Яла бу! Минем кул да тимәде аларга. Ә инде кем аларны тукмаган – сезнең күз алдында булды бит. Ник туктатмадыгыз? Ник кысылмый, читтән генә карап тордыгыз? Хәзер гаепләне эзлисезме? Эзләгез, тик ул мин түгел! Кһем-кһем!

– Ярар инде, синең бәхеткә власть юк! Элеккечә ыстанувай булса, үрәтник булса, күптән рәшәткә артында утырыр идең дә бит.

Бу хәлләргә озак кына карап утырган Әхмәтгали хаҗи сүз алды. Җыелыш шунда ук тып-тын булды, аның сүзен беркем дә бүлдерергә кыймады:

– Җәмәгать, тавышланмагыз, гаепләмик бер-беребезне. Ипле генә, тәртипле генә кайтыйк кабаттан көн тәртибенә.

Ильяс та халыкны тәртипкә чакырды.

– Әйе, җәмәгать, без бер-беребезгә сүз атышырга җыелмадык бит, башка мәсьәләләребез бугаздан.

Бу сүзләрне шунда ук Сафа эләктереп алды:

– Әлегә! Әлегә сүз атышабыз. Бераздан чын-чынлап атышырга туры килмәгәе! Менә шунда ярдәм сорап килерсез миңа, тик өмет тә итмәгез! Кһем-кһем!

Бу сүзләрне әйткәч тә, Сафа пыр тузып чыгып китте. Ачык тәрәзә аша тояк тавышлары гына ишетелде. Галләм карт кузгалып куйды.

– Ысматри-матри, ә! Элек бездә бик билгеле сунарчы бар иде, мәрхүм Зиннәтулла бабай. Менә шул әйтә торган иде, ни дип: Аю кешене бер тәмләп караса, гел аңа ау корыр дип. Бу да бит шулай, туганнар, ә? Аңарда

дин дә, чурт та калмаган хәзер. Уяу, аяу булаек, туганнар. Саклanganны саклармын дигән Ходай!

Җыелыш берничә карар кабул итте. Алар арасында сугышчылар төркемен булдыру иң мөһиме булды, командир итеп, бик теләп, Шакирны тәкъдим иттеләр. Ә фронтовиклар аны Кызыл гвардия төркеме дип атарга куштылар.

**38**

Тагын җыйды үзенең ярдәмчеләрен Матусов. Ул-бу була калса дип, югалтуларны төрле яктан исәпләп карадылар. Ни генә эшләмәсеннәр, югалтуларның очы-кырые күренми иде. Авыр булса да, бер нәрсәне инкарь итәрлек түгел: монда булган милек монда калачак, киткән баркалар өчен акча килүе икеле. Матусов күп нәрсәне эшләп өлгерде өлгерүен, тик мөлкәтне сатып өлгерә алмады. Гаязетдин нидер сизгән, аңлаган, алны-артны карарга, чабуны җыеп йөрергә киңәш биргән иде дә соң. Тик нәрсә әйтерсең хәзер – терсәк бик якын, ә тешләп булмый!

Мостикка тагын кофе китерергә кушты, бәллүр графиннан затлы аракы койды, шуннан ике Петькага сүз катты:

– Мин сезне тагын киңәшкә чакырдым. Әйдә, үтегез, утырыгыз минем белән. Мин берничә сорау бирәм, җавап – сездән. Шуннан бер карарга килербез. Беләсез, аңлыйсыз, бүгеннән миңа монда калу бөтенләй мөмкин түгел. Беренчедән, мин – бу як өчен чит-ят кеше. Икенчедән, мин чит милләт кешесе, монысы да бик хәвефле нәрсә. Моңа тикле бер кеше бер сүз әйтмәде, мин русларга да, татар-башкортларга да рәхмәтле монысына. Тик хәзер икенче дөнья!

Матусов кулындагы чәркәне искә төшерде.

– Әйдәгез, күтәрик!

Аның элек тә ярдәмчеләр белән бер-икене үткәреп җибәрә торган гадәте бар иде. Шуңа да ярдәмчеләр тын гына, тугрылыклы күзләре белән хуҗага карап, тыңлап утырдылар. Матусов нечкә генә көмеш чәнечке белән лимон эләктереп капты да дәвам итте:

– Өченчедән, Аллага шөкер, иң бай кешедер мин әле бу якларда. Күршең бай булса, тавыгың тук була, диләр татарлар. Тик мондый болганчык заманда тавыклар гына түгел, кешеләрнең дә тук буласы килә. Шуңа да төшкәнгә, тамганына гына риза булмыйча, бугазга үреләбашлыйлар. Сорау: сез минем белән китәргә ризамы? Юк дисәгез, бер дә үпкәләмим, сез мондагы кеше, язмышыгыз үзегезнең кулда.

Ике Петька да тынып калдылар. Икесенең дә күз алдыннан әлегә күрмәгән таулар, ят телдә сөйләшүче ят халык үтте бугай. Ә җәелеп баручы, чикләрне танымаган сугыш? Монда гәрчә сөйләшергә, аңлашырга була. Ә тегендә? Ә гаилә? Матусовка рәхәт, алтыныңны күтәр дә чык та кит.

Килеп чыккан бу сорауга җавап юк иде. Пётр Алексеевич беренче булып, җавабына булган шөбһәләрен кушып, риза түгеллеген белдереп, башын чайкады. Пётр Васильевич та, шул ук сүзләрне кабатлап, кире җавабын бирде.

Матусов башка җавап көтми дә иде алардан. Тик күңеленең бер почмагында кечкенә генә бер өмет чаткысы яткач, бу соравын бирми булдыра алмады. Тагын ашыкмый гына затлы аракысын салды.

– Аңлашылды. Чыннан да, үпкәм юк! Икенче сорау алдыннан күтәрик әле!

Ул, карап та тормыйча, кулы белән капшап, кыңгырауны табып шалтыратты. Йөгереп кергән кызга өчесенә дә ашарга китерергә кушты.

– Икенчесе. Һәм монысы – авыр сорау. Нишләтәбез мал-мөлкәтне?

Көмеш кашыкларга тотынырга кыенсынып утырган ярдәмчеләр бөтенләй туктап калдылар.

– Даниел Геворкович, чынлап та, бар нәрсә дә шулай куркырлыкмыни?

– Егетләр, буласы булган инде. Артка юл юк. Мин баштарак яндырып китәргәме дип тә уйлап куйган идем. Тик нигә? Сезнең калачакны белдем, яши торыгыз. Кем белә, бәлки дөньялар үзгәрер. Хотя бер өмет тә юк.

Шул арада Матусов яраткан хашламаны өстәлгә чыгардылар. Ул тагын аракы салды. Күтәреп җибәргәч, сорау бирер алдыннан көмеш чәнечке белән лимон эләктереп, авызына китерде дә, чәнечкегә карап, бер мизгелгә туктап калды – аның башыннан утлы бер уй йөгерде.

– Сез ризамы мин кайтканчы бу дөньяны ватмый-кырмый саклап торырга? Эшләтеп инде, файдасы үзегезгә дә өлешләтә чыгар.

Бусына инде әллә ни уйлап торасы юк – белгән-күргән эш, беренче тапкыр түгел, бик тиз ризалаштылар.

– Даниел Геворкович, сез... сез кая китәргә җыендыгыз?

– Рәсәй зур, Петя. Башта туган якларга. Сагындырды, ничә ел бит кайтканым юк. Аннан күз күрер.

– Еларлык безнең хәлләр. – Пётр Васильевич юешләнә башлаган борынын тартты.

– Елама. Дөнья бу.

– Ә кайчан?

– Ике-өч көн булам әле. Кирәкмәгән язуларны юкка чыгарам.

Пётр Алексеевич Ташкинов тел очында торган соравын бирде:

– Ә безгә бирәр нәрсә язаргамы – расписка-фәлән?

Матусов көлеп җибәрде.

– Эх, Петька, Петька, дорогой мой! Мин сезгә бит үземнән дә ныграк ышанам! Нинди расписка ди ул?

Монысы дөрес, ике Петька да бу ышанычның тирәнлеген аңлыйлар иде. Ташкинов җавабын тирәнәйтергә ашыкты.

– Борчылмагыз, Даниел Геворкович! Исән-сау булыйк, барысын да төзек килеш гөрләтеп эшләтербез. Ә сез кайткач – яңадан-яңа эшләр эшләрбез.

Алар икесе дә торып, акрын гына чыгып киттеләр. Матусов ярты гына чәркә аракы салды да, аны эчмичә, читкә этеп куйды, кыңгыравын шалтыратты. Кызлар өстәлне бушатып, сөртеп чыгып киткәч, бер кочак язуларын алып, яңадан өстәл артына утырды.

* * *

Буа өстендә Матусовның утырып ял итә торган өч урыны бар. Алар барысы да Көтмәс елгасының үзәнендә, шуңа да буаның иң тирән җирендә. Ул урыннарда аңардан башка беркем дә утырмый, якын да килми. Һәр кич саен, яңгыр яумаса, бик җилле-гарасатлы булмаса, өч урынга да йөзеп килә. Һәм һәр кич саен шул өч урындагы агачлар төбендә бик озак, башын иеп,

көймәдә утыра. Бу хәлгә бар да күнеккән, аңа беркем дә комачауламый, ул урыннарга якын килергә дә кушмыйлар. Беренче кичне өянкеләр төбендә күрделәр Матусовны эшчеләр. Эңгер-меңгер вакыты җиткәч, ул сак кына, тирә-якка каранып, ныклап сумалага буялган зур булмаган ике мичкәне суга батырды. Икенче кичтә таллар уратып алган яр буенда, кечкенә култыкта тагын бик озак утырды ул. Кеше күрмәгәндә тагын ике мичкәне су төбенә озатты. Өченче урын аның иң яраткан урыны иде. Көймәдән ярга чыгып, яшел үләндә бик озак тәгәрәп ятты Матусов. Читтән караганда, кешенең үләндә тәгәрәп ятуы гына иде бу, тик шул арада тагын ике мичкә су астына төшәргә өлгерде. Бу эшләрне башкарып чыккач, Матусов канәгатьлек кичерде: алтын-көмештән булган барлык савыт-саба, иң кадерле булган башка вак-төяк әйбәт итеп төрелеп, буаның чоңгылларына төшеп ятты. Су китә калса да, аны кем дә булса таба алуы шикле, чөнки Матусовтан башка Көтмәснең борылмаларын бер кеше дә белми – заманында, елганы буар алдыннан ул бик төгәл картасын эшләткән иде. Хәзер ул кешеләр инде юк, карта барлыгын беркем дә белми. Бу урыннарда аны еллар буена көн саен күргән кешеләр алтын-көмеш яшереп йөри дип һич тә уйламас. Ә инде мичкәләргә килгәндә, алар имәннән, сумалаланган, кимендә ун ел череми түзә алырлык. Матусов үзенә кире кайтырга өч елдан артык вакыт куймый: бер-ике ел эчендә бу дөнья үз җаена кайтыр дип өметләнә. Бу утардан шул утлы елларда казык та калмаячагын да аңлый ул. Ни эшлисең, анысы язмыш, тәкъдир…

Өенә кайткач, Даниел Геворкович Матусов, Рәсәйнең иң уңышлы сәнәгатьчеләре исемлегенә кергән кеше, юлга аласы әйберләр тутырып куелган саквояжына карады да, гади пыяла савытка затлы эчемлек салып, гади тимер чәнечке белән соңгы лимон кисәген эләктерде.

Шул вакытта атылып чыгып, бите буйлап агып төшкән кайнар яшьләрен беркем дә күрмәде...

**39**

Ташбака тизлегендә сөйрәлгән эшелон килеп туктау белән штабс-капитан Салих Җиһаншин вагоннан җиргә сикереп төште. Артыннан иярген ярдәмчеләренә тиз-тиз генә күрсәтмәләр бирде дә, бер ярдәмчесен үзе белән алып, урындагы хәрбиләрнең штабын эзләп, вокзалга кереп югалды.

Ак армиянең йә алга, йә артка барган 8 нче Кама дивизиясенең штабы Ижау каласының Яр буе урамында урнашкан завод казнасын саклар өчен төзелгән бинасында булып чыкты. Ижауга килеп кергәч тә, полковник Зеньковский иң башта үз җаен карады. Солдатлар кулы белән тиз арада вак-төяк ремонт ясалды, бина алды тәртипкә китерелде, архитектор Иван Коковихинның моннан ерак та булмаган өеннән пианино, чиновник Юровскийның шунда ук урнашкан өеннән җиһаз алып килделәр. Урнашу шартына полковникның таләпләре күп. Беренчедән, бу урын чуен юлдан әллә ни ерак булырга тиеш түгел. Икенчедән, кайчандыр сугышка хәтле булган уңайлыклардан бер дә баш тартасы килми. Өченчедән, аның уенча, аны урап алган мохит Зеньковскийның каны башкаларныкы кебек кызыл түгел, зәңгәрсу булуына ишарә итәргә, һәр нәрсәдә аристократлык күзгә бәрелеп торырга тиеш иде. Башта ул яшәү һәм хезмәт урынын мондагы

эшкуарларның берәр матуррак йортында урнаштырырга да уйлаган иде, тик күп еллар буе җыелган хәрби тәҗрибә өскә чыкты – иң беренче булып полковникка бу бина үзенең метр ярымлы стеналары, алдында оператив бушлык булуы белән ошады. Тыштан әллә ни мәһабәт булып күренмәгән бинаның эче кояшлы көндәй балкый, чисталык-пөхтәлек белән башкалардан берничә карышка аерылып тора, һәм моның белән полковник үзенең теләгенә иреште. Монда кергән һәр кеше бу матурлыкны, бу тәртипне күреп коелып төшә, курка-курка йомышын сөйли, полковникка ничек тә ярарга тырыша.

Көтәргә туры килде Салихка – ул килеп кергәндә, төшке аш вакыты иде. Нинди ризык ашагандыр Зеньковский, аның төшкелеге бик озакка сузылды. Ничек кенә булмасын, төрле хәлләргә өйрәнгән Салихка Ходай түземлеген җәлләмәде. Шул арада, пошкырып, берничә эшелон үтеп китте, күк йөзендә берүзе йөзгән кояшны болытлар каплап алды.

Ниһаять, Салихны полковникка чакырдылар. Ул, хәрбиләргә тиешенчә, үзенең кем булуын, Зеньковский кул астында хезмәт итәргә тәгаенләнгәнен һәм әзер булуын әйтте. Чал чәчле, кыска сакал-мыеклы, бик пөхтә киенгән Зеньковский кул очы белән генә исәнләште һәм Салихны икенче өстәлдә яткан карта янына чакырды.

– Әйе! Сезгә мин бүгеннән үк, кичектермичә, көнчыгышка таба барырга боерам. Тимер юл буен мин берничә җаваплылык зонасына бүлдем. – Ике җөмләгә ике «мин». Моны шунда ук игътибарга алды Салих. – Әйе! Һәрбер зонага кирәк булган хәтле кеше бүлдем. Сезнең бурыч: Чернушкадан Красноуфимскига хәтле зонаны ныклы кулда тоту. Диверсия, хәрби вагоннарны талау, фетнә – болар барысы да катгый бастырылырга тиеш. Әйе! Зонаны большевиклардан, аларга ияручеләрдән тазартыгыз, сөргендә ятканнарны тикшерегез. Бу урында сез власть та, хәрби министр да. Турыдан-туры минем карамакта буласыз. Әйе! Хәбәрләшеп торыйк!

Зеньковский, картага иелеп, кызыл карандаш белән сызылган озынча түгәрәкне зәңгәр төсле карандаш белән тагын бер мәртәбә урап үтте.

– Аңлагансыздыр, бусы инде сезнең зона. Аның зурлыгына аптырамыйбыз – нигездә ул тимер юл янәшәсендә уннан чак кына артык станция. Кайсы станциядә күпме кеше калдыру сезнең ихтыярда. Тагын бер нәрсә. – Полковник, нигәдер өстәлне әйләнеп чыгып, кабаттан үз урынына басты. Бүлмәдә аның шыгырдавыклы итекләренең һәр адымы яңгырап алды. – Әйе! Сезнең шул яктан икәнлегегезне беләм. Кисәтәм, йомшарып китмәгез!

Салих сүзгә кушылды:

– Ышанычыгызга рәхмәт. Ә соңгысы өчен борчылмагыз, тәҗрибә җитәрлек дип уйлыйм.

– Тәҗрибәгезнең барлыгы билгеле. Бу якларны яхшы белү – икенче плюс. Өченчесе – сезнең күрсәткән батырлык мисаллары. Әйе!

Нәрсәне күз уңында тота икән бу? Мәскәүдәге, бигрәк тә Петроградтагы демонстрацияләрне тарату батырлыгынмы? Казандагы «Бердәмлек» профсоюзы оештырган эш ташлаучылар белән күңелсез аралашунымы? Эчтән генә боларны уйлап, ул тыйнак кына рәхмәтен белдерде.

– Ничә кешегез бар ротада?

– Ротада, кызганычка каршы, кеше аз. Бары ике йөз дә сиксән ике.

– Әйе, күп түгел икән! Совсем негусто... – Полковник та уйга калды бу хәбәрдән. – Әйе! Бүгеннән сезнең рота 8 нче Кама дивизиясенең 30 нчы укчы батальоны дип аталачак. Тагын бер нәрсә бар. Ничек кенә булмасын, Казанбург тимер юлына бар яктан да бик зур игътибар. Яхшы беләсез, бу – Мәскәү белән Себерне тоташтыручы иң якын ара. Бу юл бернинди тоткарлыксыз эшләргә тиеш! Бу юл безнең җиңү юлы булырга тиеш! Сугышта кайчак аз көч белән дә зур эшләр башкарып була. Әйе!

Соңгы сүзләргә, чынын әйткәндә, сөйләшүчеләр үзләре дә ышанмый иде. Тик берсе дә үзенең башкача булган фикерен әйтмәде. Зеньковский, бүлмәдәге икенче өстәл янына килеп, гәзит тартып чыгарды.

– Менә Омскида адмирал Колчак Хөкүмәте тарафыннан чыгарыла торган «Правительственный вестник»ның яңа номеры. Карыйбыз, укыйбыз. Әйе, менә. «Уфимско-Бирский район». «На Аскинском направленіи 20 января съ утра красные повели наступление на Алмазскіе хутора, д. Жуки и Тюинско-Озерский заводъ. Весь день шел бой за обладаніе Тюинско-Озерскаго завода, который нѣсколько разъ переходил изъ рукъ в руки, наши части под натискомъ превосходныхъ сил противника вынуждены были отойти къ Тюинскому, но перейдя въ контръ-атаку выбили красных из Тюинского и Тюинско-Озерского завода и заняли ихъ. Въ районѣ д. Вашіязы, Тупралы-Казачьи поиски разведчиковъ».

– Әйе, миндә дә бар шушындый мәгълүмат.

– Әйе! Казачьи дигәне сез белгән Казанлы була инде.

Алдан әзерләнгән, күрәсең, Зеньковский. Барын да белә, барысы белән дә аптыратырга тырыша.

– Әйе! Кайда урнашырга телисез – анысы сезнең карамакта, мин кысылмыйм. Тик тәртип кенә булсын!

– Әгәр мин волость үзәге Казанлыда урнашсам, ул сез күрсәткән ике станциянең нәкъ географик уртасы була да инде.

– Каршы түгел, үзегез карагыз! Ләкин тәртип – барысыннан да өстен!

Зеньковский бәләкәй генә көмеш кыңгырауны шалтыратты. Бер төргәк кәгазьләр тотып, ординарец килеп керде, Зеньковский шуларның берничәсен алып, Салихка тоттырды.

– Монысы безнең аналитиклар әзерләгән рапортлар. Казанбург тимер юлы буендагы шәһәрләрдәге, авыллардагы безгә каршы хәрәкәт турында. Менә бусында Казанлы волосте турында. – Зеньковский кирәкле битен тапты. – Казанлы волосте. Старшина Ильяс Ягафаров, белемле кеше, большевик, Казан, Уфа белән тыгыз бәйләнештә. Зур отряды бар, хәрби әзерлек бара. Командиры Шакир Закиров, сугышта катнашкан. Авылда марксист Плехановның якын кешесе Яков Никонов сөргендә. Башка географик нокталарны әйтеп тормыйм. Болар сезгә, игътибар белән карарсыз тагы. Әйе, шуннан. Киткәнче безнең контрразведкага кереп чыгыгыз. Полковник Бородин сезнең турыда белә, ул төгәлрәк мәгълүмат бирер, килеп чыккан хәлләр белән таныштырыр.

Полковник тагын өстәлне урап чыкты да Салихны бөтенләй аптыратты:

– Ә хәзер кофе тәкъдим итәм!

Зеньковский әлеге дә баягы көмеш кыңгырауны шалтыратты. Ординарец ике кофе тотып килеп керде.

– Әйе! Монысын көтмәгән идегез бугай? Мин махсус укыган, сугышта

катнашкан чын офицерларны тирән ихтирам итәм. Зур бәрелешләрдә катнашып, батырлык күрсәтүегез белән дә таныш. Уңышлар сезгә!

Чынлап та, аптырап калды Салих. Тыштан караганда, бик коры булып күренгән кеше шулай ихтирамлы сөйләшкәч, ни әйтерсең?

– Рәхмәт, Всеволод Всеволодович, бу сүзләрегез өчен чын рәхмәт! Ышанычны аклармын!

– Әйе! Башкача булмый да! Рәсәй, Рәсәй юкка чыгып ята! Бездән башка кем генә коткарыр аны? Сезнең кебекләрдә бар ышаныч!

Кечкенә савытка салынган кофены эчеп бетерде дә Салих, полковникка карап, итекләрен итекләренә тидереп алды:

– Юлга чыгарга рөхсәт итегез?

Зеньковский, ризалык биреп, кулын селтәде:

– Әйе!

* * *

Контрразведка башлыгы белән сөйләшү бик эчтәлекле булды. Тимер юл тирәсе үзләреннән үзләре барлыкка килгән кызыл, ак отрядлар белән тулы, җитмәсә, кая карама, гади юлбасарлар эш итә. Барысы да эшелоннарга һөҗүм итә, базарга барган, мал белән аралашкан авыл кешеләрен талый, корал җыя.

Салих килгәндә, сугышчылар ашатылган, ял иткән, вагоннарда команда көтеп тора иде. Тиз генә командирлар җыелды, ротаның һәр берәмлегенә бурычлар йөкләтелде, кайда урнашу, кайда нинди эшләр башкарасы – барысын да күз уңында тотты Салих, барысы буенча да җентекле әмер бирде. Булган сугышчыларның иллесен үз кул астында калдырды, ә калганнарын зур станцияләр һәм авыллар исәбеннән ун «летучий» отрядка бүлде, һәрберсенә командирлар тәгаенләде, хәбәрләшеп тору вакытын билгеләде.

Күп дигәндә, ярты көн эчендә тиешле эшләрне тәмам итеп, алар көнчыгышка таба юл алдылар.

## 40

Казаннан авылга кайтып төшкәч тә, атын волостька борырга кушты Нигъмәтҗан. Бүген аны бик җиңел булмаган бурычны үтәү көтә иде. Ильяс белән мөнәсәбәтләре аларның элеккечә, Фазыловлар – сәяси эшләргә тыгылмаулары белән үзләренә ихтирам казанган бай кешеләр. Ничек кенә булмасын, ике як та бу эшләрнең вакытлыча гына икәнен төгәл аңлый, кайчан да булса яңа власть һәм билгеле байлар арасында булган бу тигезлек пыяладай ватылачагы бәхәссез иде.

– Әссәләмегаләйкүм, Ильяс әфәнде!

– Вәгаләйкемәссәләм, Нигъмәтҗан! Кайчаннан башлап, мин әфәнде булып киттем әле?

– Син бит власть! Зур кеше! Ә зур кеше түрә, мәэмүр! Ә түрә чын әфәнде инде ул!

Икесе дә көлеп җибәрделәр.

– Син шәкерт заманыннан онытыла башлаган сүзләрне искә төшердең бит! Элек шулай шаяра торган идек тә.

– Хәтерлим, нигә онытырга ди әле ул чакларны. «Күп яттык без мәдрәсәдә, Аңламадык бер нәрсә дә».

Ильяс шунда ук эләктереп алды:

– «Селкенмәдек таш төсле без, Җилбер-җилбер җил бәрсә дә».

Әллә Тукай сүзләре тәэсир иттеме, әллә бергә укыган мәдрәсә еллары искә төштеме, икесе дә тын калдылар. Беренче булып Нигъмәтҗан сүзен башлады:

– Бернинди йомышым юк сиңа, әҗерне үтәргә дип килдем.

– Бик тиз тоттың әле эшне!

– Тотмыйча. Вакыты бит шундый. Өяздә кеше атлап түгел, йөгереп йөри. Ә Казанны, Уфаны сөйлисе дә юк. Анда чын-чынлап мәхшәр! Барган саен аптырап кайтам.

– Казан, Уфа... Мин Бөредән ерак китә алганым юк. Зур теләк белән йөреп кайтыр идем дә бит.

– Булыр әле, Алла бирсә. Ә Казанда сине бик яхшы хәтерлиләр. Менә хат та җибәрделәр сиңа.

Нигъмәтҗан, түш кесәсеннән алып, хатны Ильяска тоттырды.

– Ярар, укы. Бераз йөреп киләм дә керермен әле соңрак, сөйләшәсе бар. Һәм чыгып та китте.

Хатның кемнән икәне язылмаган, бары Ильяска икәнлеге генә. Колакта гөрләп торган Казан тавышлары ишетелгәндәй булды. Тик ул тавышлар нигәдер шомлы иде, Ильяс хатны кулына алгач та, ул шомлылык тагын да көчәйгәндәй булды. Калтыраган бармакларын кысып тотып, ул хатны ачып җибәрде.

«Хөрмәтле вә гыйззәтле Ильяс туган!

Казан казанында кайнап, бергә үткәргән көннәрне искә алып, дуслар белән яңа тормыш турында хыялланганнарны, ислах (бу сүзне хәзер «реформа» дигәнгә алыштырдылар монда!) дип җан атканнарны онытмыйча, бу хатны Мәхмүт Алиев яза. Тик, туганым, бу юлы минем сүзләрдә хыялларыбызның баллы тәме түгел, ә матәм әчелеге сизелә. Менә нәрсә игълям итәмен, дустым.

Ишеткәнсеңдер инде, без бик зур кораллы бәрелешләр мәйданына әйләндек. Комучлар, һөҗүм итеп, бер көн эчендә без күз терәп торган гарнизонны да, башка ышанычлы да булган гаскәрне пыран-заран китереп ташладылар. Иң кызганычы – безнең милли батальоннар баш күтәрде. Егерме бишенче июльдә Камил Якуб шулар белән бәйләнешкә керергә, сөйләшергә дип, очрашуга китте. Сөйләшү бик кызу барган, Камил Якубның ялкынлы, кешене ышандырырлык сүзләре солдатларның аңын каплаган пәрдәләрне ачканын сизеп, контрреволюционерлар аның аркасы ягыннан туп-туры йөрәгенә аталар. Цицероннан бер дә ким булмаган хатыйп иде бит ул! Менә шулай без Камилсез торып калдык, дустым...

Тагын да бер бик аянычлы хәбәр. Комучлар җиңгәч, Мулланур да алар кулына эләкте. Ул бик тирән мәсхәрәләнүләр кичерә, җәза инде бусы, җәза, торганы бер зилләт. Унтугызынчы августта атып үтерделәр аны дошманнар... Хаксыз хөкем чыгаручылар вә аны башкаручылар аптырап ишеткәннәр аның соңгы сүзләрен. Ошбу булганнар алар: «Коммунизмны үтерә алмассыз!»

Менә шулай ике асыл егетсез калды безнең халык. Аларның исеме, ялкынлы сүзләре, эшләре мәңгегә безнең йөрәкләрдә яшәр дип ышанам...

Гафу ит, туган! Бүген күңелләрдә дә, йөрәктә дә зорлык, авырлык... Бинаән галәйһи башкача яза алмыйм. Яраларның яңа чагы, ни әйтерсең.

Соңрак, бераз хәл алгач, уй-фикерләрне җыя алгач, бәйләнешкә керербез, Иншаллаһ! Бакый ихтирам: Мәхмүт»

Ильясның күз алдыннан берсеннән-берсе бай табигатьле, кешелекле, зыялы ир-егетләр үтеп китте. Күңел берничек тә бу хәлләргә ышанмый иде.

Күпме утыргандыр Ильяс башын иеп, очрашуларны искә алып. Аны бу хәлдән кабаттан килеп кергән Нигъмәтҗан чыгарды.

– Хәбәрнең хәерле булмасын сизгән идем – шулай булып та чыкты, ахры?

– Шулай! Шушы тотрыксыз дөньяда мине – мине генә түгел, меңнәрне! – җитәкләп барган ике дусымнан колак кактык. Берсе – Мулланур Вахитов, икенчесе – Камил Якуб... Урыннары оҗмахның иң түрендә булсын инде!

– Ишеттем Казанда алар турында. Әйтерсең Вахитов соңгы сүзләрен барысына да әйткән, бар да шуны кабатлыйлар: «Коммунизмны үтерә алмассыз!» Чынлап та, бик ихтирамлы кешеләр булганнар алар. Жәл, бик тә жәл.

Озак кына тып-тын утырдылар алар. Кайдадыр болай да нечкә генә калган йөрәк кылларын өзеп, скрипка елый. Аның артыннан зиһен бу җырның сүзләрен кабатлый да кабатлый:

Чияле генә таулары,
Өзелә камыт баулары.
Камыт бавын ялгый-ялгый,
Сызыла йөрәк майлары.
Ә-ә-й!

Күңелсез уйларны бүлеп, Ильяс сүз башлады:

– Ярар, яшәргә кирәк. Аларны кайтарып булмый инде.

Нигъмәтҗан да хуплады бу сүзләрне:

– Әйе, үлгән артыннан үлеп булмый. Яшәргә кирәк! – Ул бераз тын алды да дәвам итте. – Без монда бөтен эшебезне дә туктатабыз. Бар дөньябызны калдырып чыгып китәргә әзерләнәбез.

– Кая китәсез дип сорамыйм, нигә дип тә. Бу болганчык заманда бәлки бу бердәнбер дөрес карардыр. Жәл, ни әйтерсең.

– Әти елый. Аның бар гомере монда үткән, шушында бар дөньясын корган кеше бит ул. Туган җирдән торган җир яхшы дип тиккә генә әйтмиләрдер шул.

– Хак сүзләр. Бу якның тарихына кереп калган кеше сезнең әти.

– Казанга табан берәр авылга барып сыеныргa теләк. Бәлки, Актаныш тирәсендә, әтине туган ягында урнаштырырбыз. Без үзебез авылда яши алмабыздыр инде. Шуңа Казанны уйлыйбыз. Мал-мөлкәт турында сөйләп тормыйм. Булганын сатып өлгердек, әти бик вакытлы Гаязетдин ага белән киңәшләшкән бу турыда. Калганы кала инде, мал дип баштан колак кагасы юк.

– Совет властеның иң беренче карарларында ук шәхси милек юкка чыгасы күрсәтелгән. Шулай булгач, бу хәлләр безнең алда булачакларыннан.

– Аның өчен башта җиңеп чыгарга кирәк, элекке тормышны кайтарырга. Бөтен яктан да урап алдылар советларны. Җиңмәсләр дип уйлыйсыңмы?

– Булмас. Большевиклар халыкның иң авырткан җирләрен ачып салдылар, аны дәвалый да башладылар.

– Әгәр Учредительләр Җыелышын үткәргән булсалар, большевиклар бу тиклем начар хәлдә дә калмаслар иде бит. Хәер, ул җыелыш булса, эсерлар җиңеп чыгар иде. – Нигъмәтҗан тынып торды да сүзен дәвам итте. – Эсерларга да ышаныч бетте, күз буяучылар булып чыктылар. Бернинди эш юк, бары сүз.

– Ә большевиклар әйткәннәрен үти киләләр.

– Белмим, күпкәме, азгамы. Беләсеңме, бүгенгә алдагы көннәрне егерме-егерме биш елга күргән фирка да, шәхес тә юк бездә. Димәк, юлның, дөресрәге – юлсызлыкның бер ягыннан икенче ягына ташлану булачак. Теге өч сукыр турындагы мәсәлдәге кебек, «уңга-сулга, алга-артка» дип, упкынга атлыйбыз.

– Ничек кенә булмасын, туктый да, артка да баралмаслык дәвердәбез. Акыл белән, алны-артны карап җиңеп чыга алырбызмы, мин белмим. Халыкта булган төплелеккә ышаныч бар-барын, күпмегә җитәр ул, кем белә.

– Ә мин беркемгә дә, бернәрсәгә дә ышанмыйм. Менә, кара. Безнең якта теләгән кеше әллә нинди уңышларга ирешә ала, алды. Теләсәң, эшлә, теләмәсәң, үзең бел. Шул ук вакытта нindидер гауга, нindидер аңлашылмаучылык та килеп чыкмады. Әйбәт кенә яши идек. Хәзер ни була инде? Якалашабызмы? Бер-беребезне талый башлыйбызмы? Сугыш-үтереш китәме? Кая алып барып җиткерәбез илне? Ленин шуны телиме?

– Большевиклар да, шәхсән, Ленин да гаепле түгел монда.

– Ә кем?

– Мин дә синең кебек. Белмим. Ничәнче ай инде старшина, әле бернинди акыллы карар күргән юк. Менә якын арада монда да сугыш башланачак – Салих кайта дигән хәбәр бар. Аның нинди кеше икәнен беләсең. Димәк, ике лагерь, ике як, ике яктан да кыргыйлык.

Бу сүзләрнең дөреслеген алар икесе дә яхшы аңлый иде. Нигъмәтҗан сүзгә кушылды.

– Бая әйткән «алдагы көннәрне егерме-егерме биш елга күргән фирка да, шәхес тә юк бездә» дигән сүзләргә кире кайтам. Тарихта булган бар инкыйлаб та бер-берсен үтереп бетерү белән тәмамлана. Бөек француз революциясен исеңә төшер. «Революция үзенең балаларын ашый» – бу бит шул заманнан калган сүзләр. Сез үзегез дә шул хәлләрдә калмассызмы икән? Менә минем сүзләрне хәтерләп кал!

– Кем белә, кем белә! Синең чыгып китәр мөмкинлекләрең бар, ә безгә нишләргә? Франция дигәч, шул көннәрнең герое Дантонны да искә ал: «Туган илне итекнең олтырагы астында алып китеп булмый!»

Бүлмәдәге тынлыкны әллә кайдан монда кереп урнашкан өй чикерткәсе генә боза, тыштагы көчәйгән җил кайдадыр ябылмаган капканы ябарга тырышып суккалый.

– Ярар, Ильяс туган! Болай булуы кыен хәл, билгеле. Тик ни эшлисең? Язмыштыр, аңардан узмыш юк. Исән-сау бул. Очрашырга язсын!

– Иншалла! Бирсен Ходай!

Бу якларның тарихында тирән эз калдырган, яңа дәвер тагын йөз ел файдаланырлык мөлкәт калдырган Фазыловлар гаиләсенең эшлекле кешесе

Нигъмәтҗан, башын горур тотып, волость бинасыннан чыгып китте. Алар арасында волость ишеге генә түгел, алдагы дөньяга алып барган ишекнең мәңгелеккә ябылуын бүген беркем дә күз алдына китерми иде әлегә.

**41**

Михайловкага Степан кайтып керде. Шат күңелле, кунак киемендәге Степан менә инде ничәнче сәгать өстәл артында утыра, чакырылганнарга үзенең сәфәре турында сөйли. Чакырылганнар күп тә түгел: туганы Григорий, чиркәүдән Евлампий, чегәннәрнеке кебек бөдрә җирән чәчләренә буй-буй булып ак төшкән тегерменче Семён, Семённың улы. Ашыкмый гына көмешкә тәмләделәр, авызларын чапылдатып, зур-зур кисәкле майлы ит ашадылар. Шул арада Степан, чиста тастымал белән тирләгән битен сөртә-сөртә, сәфәрнең йомгаклары белән мактанды, кырда утырган ирләрне куркаклыкта гаепләп тә алды.

– Бара-бара күзләр тонып бетте, ник чыкканыма үкенә башладым. Эшелон-эшелон булып солдатлар үтеп китә, ә авылларда бер солдат та юк! Бары Щучье Озерога килеп җитәрәк туктаттылар мине: син кем, кая барасың, кайдан киләсең, ниләр эшләп йөрисең... Киемнәренә караганда – безнекеләр кебек, тик кем белә? Башта куркып калдым, соңрак мин дә сорау бирәм тегеләргә: ә сез кем? Әйтә шунда берсе, озынрагы, көлеп: без, ди, Рәсәйне кызыл бандитлардан тазартабыз. Ә син монда ни эзләп йөрисең? Тәк, мин әйтәм, менә сезне эзләп килдем дә инде! Шуннан ни, командирларына алып килделәр.

Степан голт-голт итеп чүлмәктәге квасны эчте.

– Яшь кенә усал егет, күзләре кып-кызыл. Ике сүзнең берсе тәүфыйксыз. Китте миңа бәйләнеп, түз генә. Кот табанга төште, инде, мин әйтәм, сәгать соңгы минутларны саный, шартлатып аталар да китәләр. Бар белгәнем – Аллага ялвару!

Ул, тиз генә почмактагы образларга күз салып, кулларын киң итеп җәеп чукынды, икенче кулы белән яшьләнгән күзләрен сөртте дә дәвам итте:

– Пыр туза бу егет, авыз ачарга да ирек бирми. «Без монда алны-ялны белми көрәшәбез, ә сез ашап-эчеп, йоклап ятасыз! Бернинди файда юк сездән! Безгә генә кирәкме большевиклар белән бу сугыш? Волостегыз большевиклар кулында. Нәрсә карап тордыгыз? Нигә каршы чыкмадыгыз?»

Түзмәде Григорий, үзенең чынлап та дөрес булган фикерен әйтте:

– Ә нигә без сугышырга тиеш әле? Моның өчен махсус оештырылган армия бар түгелмени?

– Шулай да соң. Бер сәгатьтән артык баш миен таптады.

Степан да түзмәде, бик тиз хәрәкәт белән чирекле шешәне аударып, стаканга көмешкә койды, бер кабымда аны йотып, тастымалны иснәде. Шуннан тозлы кыяр табып, аны кетердәтеп чәйнәп алды. Өстәл артындагылар аның тәмле итеп кыяр чәйнәгәнен көттеләр. Семённың улы аны ашыктырды:

– Шуннан? Шуннан?

– Шуннан ни? Кара мужиклар сез ди! – Степан бераз тынычланды. – Якын көннәрдә сезгә зур отряд килә, ди. Алар килеп җиткәнче, үзегез отряд оештырыгыз, властьны кулыгызга алыгыз. И – марш өеңә, ди.

Мин ни, аның кабатлаганын көтеп тору юк, атка сикердем дә станциядән чыгып тайдым.

Өстәл артындагылар тынып калды. Авыл кешесенә хас булган акыл беренче булып килгән канәгатьлектән өстенлек алды. Отряд – әйбәт, тик ул кайда урнаша? Шуннан аларны ашату-эчерү дә бар бит әле. Ә атлар? Монысы ничек булыр? Ә солдатлары тыныч булса, бер эш, әгәр тыныч булмасалар?

– Нишлибез инде? – Семён барысын да аптыраткан сорауны бирде.

– Нишлисең инде? Бездән берни дә тормый. – Степан бу турыда озак уйлаганын күрсәтте. – Отряд килә, урнаша. Безгә икенче мәсьәләне чишәргә кирәк – үзебезнең команданы җыюны.

Кунаклар дәшми-тынмый утыруын белделәр. Отряд җыю да җиңел эш түгел, җитмәсә, җаваплы да. Әгәр баягысы «авыл кешесенә хас булган акыл» булса, монысы инде «авыл кешесенә хас булган хәйләкәрлек»: берәүнең дә бу эшкә беренче булып тыгыласы килми. Моны Степан да, кунаклар да яхшы аңлый иде. Ә Степан аларның бу хәйләкәрлегенә өстән генә көлеп карады да өстәл артындагыларга сорауларын яудыра торды.

– Казанлыдагы отрядта кемнәр? Безнең халыктан бармы?

Бусы инде аның отрядтагы халыкның татармы, русмы икәнен ачыкларга уйлавыннан, тик нигә моны белергә кирәклеген әлегә беркем дә аңламый иде.

– Анда төрле халык: руслар да, татарлар да, башкортлар да бар. Удмуртлар килеп кушылды күптән түгел.

– Ә без руслардан гына торган отряд төзербез алай булгач. Михайловка белән генә чикләнмик, бөтен рус авылларын да кушыйк. Отряд кына түгел, икенче төрле атыйк: Беренче Аскын полкы.

– Нигә Беренче?

– Димәк, Икенчесе дә, Өченчесе дә булыр!

Кунакларга ошап китте бу карар, алар хуплап: «Ярар, ярар!» – диештеләр.

– Отрядның командиры итеп, мин Аркадий Дедухинны тәгаенләр идем. Аны Казанлыга кайткан диләр, шул дөресме?

Дөрес икән бу хәбәр, Казанлыда ял итеп ята сугыштан качыпмы, яраланыпмы кайткан Аркадий Дедухин. Степан Григорийга борылды:

– Җибәр берәрсен Казанлыга, чакырсын Аркадийны. Сөйләшик. Ә әлегә отрядның исемлеген төзи башлыйк.

Күптән саф һавага чыгарга хыялланып утырган Григорий ике әйткәнне көтмәде, Степанның башы белән ымлавын күрү белән тышка атылды. Ә Степан тагын көмешкә өстәп чыкты, стаканын күтәреп, бер генә сүз әйтте:

– Ну, Алла ярдәме белән!

Бүлмәдә тагын кыяр кетердәде. Степан уңайсызланыбрак Евлампийга карады, шуннан кулын селтәп, уйлаганын әйтте:

– Алладан көт, тик үзең йоклама. – Алла исемен ишеткән дин әһеленең башы өскә күтәрелде дә, тагын күкрәгенә төшеп китеп, тын гына йокыга талды. – Әйдәгез, исемлек буенча уйлашыйк әле.

Әллә кемне эзләгәндәй томанланган күзләре белән тирә-ягына каранып, усал тавыш белән күрше бүлмәгә табан кычкырды:

– Нинка! Кәгазь белән канат алып кил тиз генә!

Тын гына басып, Нина бүлмәгә керде дә, башын иеп, тагын тын гына юк булды. Степан ашыга-ашыга эчәргә салды, иптәшләрен көтеп тә тормыйча, стакандагы көмешкәне авызына ташлап, тагын кычкырды:

– Нинка, кая юк булдың? Тиз бул дим!

Нина этисе кушканнарны кертеп өстәлгә куйды, анда яткан ашамлык калдыкларын тәлинкәгә җыеп, язарга урын әзерләде дә чыгып китте.

– Исемлек. Беренче Аскын полкы. Киттек, Аллага тапшырып! Каршы булмасагыз, исемлекне Савелий Чуров башлап җибәрә.

Дин әһеленең башы тагын өскә күтәрелде дә, бу юлы аның күзләре беренче кат күргәндәй, өйдәгеләрнең йөзен барлый башлады.

Сөйләшмәскә тырыша Нина этисе белән. Соңгы вакытта Степан бөтенләй үзгәрде, бер кешене тыңламый, бер кешене ишетми башлады. Гәрәй армиягә китkәч, тагын да ныграк үчләшә, Савелий Чуровка кияүгә бирәм дип куркыта башлады. Иң кыены – Гәрәйдән бернинди хәбәр дә юк... Бары тик авыл егетләре шатланып-сөенеп: «Синең татар малаеның башын борганнар», – дип кычкырып калдылар. Ә шуннан соң эзәрлекләүләр, куркыту-янаулар китте. Степан булачак кияүне үзе генә белгән сыйфатлар аша сайлый башлады, аның уенда бары байлык та шөһрәт... Тик «Балык булмаганда, кысла да – балык», тормыш тәҗрибәсе кабат-кабат Савелийга алып кайта торды. Шуңа да ул аны үзенә якынайта төште, кирәксә-кирәкмәсә дә мактады, башкаларны читкә тибәрде. Исемлекне дә аннан башлап җибәрүе дә юкка түгел, ул аны зур эшләргә бәйләргә тырышудан. Савелий дә хәйлә артыннан кесәсенә керми – кыз ярәшү турында ләм-мим. Бусы инде Степанны аптырата да, кайгырта да иде. Башка уй-фикерләре бардыр, ахры, егетнең...

Булган ачуын Степан кызы белән хатыныннан ала башлады. Аларның алдында бер генә юл – кочаклашып елап алу, анысын да бер тавышсыз, бер сүзсез, сулкылдау тавышын беркемгә дә ишеттерми генә. Тагын нәрсә эшләргә була, ни кылырга мөмкин инде аларга? Юк, берни дә юк...

Сәгатьтән артык бәхәсләшә торгач, исемлек әзер булды. Ул, чынлап та, зур иде – йөздән артык кеше иртәгә кичкә чиркәү алдына җыелырга тиеш дигән карар да чыгардылар.

Чак-чак атлап кунаклар кайтырга чыктылар. Капка төбенә озатырга чыкканда, Степан йөзгә-йөз Казанлыдан килеп җиткән Аркадий Дедухин белән исәнләште.

Ул шунда ук Григорийның улына борылып, аңа ниндидер эш кушты.

**42**

Дөнья бөтенләй бозылды, моны Ильяс инде күптән аңлады. Салих кайтып керсә, яңа властька борылган бер кеше дә исән калмаячагы ачык иде. Йөздән артык кеше – ә аларның күбесе фронтовиклар – авылны саклап чыгарга әзер, тик корал юк. Шул йөздән артык кешегә искереп беткән унлап винтовка, калганы... Калганы корал түгел инде ул.

Салих баштанаяк коралланган солдатлар белән кайтачак. Аларга каршы фронт тоту турында сүз дә юк. Өченче көн бушап калган волость бинасында арлы-бире йөри торгач, Ильяс бер карарга килеп, киңәшкә Гаязетдин белән Галләм картны чакырып алды.

Озак көттермәделәр, бик тиз килеп җиттеләр киңәшчеләр. Исәнлек-иминлек сорашу белән Ильяс, сүз башлап, ачыктан-ачык хәлләрнең бик әйбәт булмаганын бәян итте.

– Значитца, фронттан кайткан һәрбер ир кеше йә мобилизациягә эләгәчәк, йә кулга алыначак. Каршы торырлык отряд бар, тик корал юк. Тагын өяздән ашлык запасларын тиз арада Уфага җибәрү кирәклеге турында күрсәтмә килде. Халыкның ачуын чыгармый гына үти торган юлы бар бу күрсәтмәнең. Дөнья ташлап, каядыр чыгып киткән Фазыловларның келәтләрендә инде хуҗасыз булган бик күп ашлык ята. Әгәр шуның белән капласалар, бу таләпне? Тик аны станция ягына – Чернушкага җибәрү аклар кулына илтеп тапшыру белән бер. Казанцевога пристаньга олау белән җибәрү дә шикле, анда бүген кемнең хуҗа икәнен белүче юк. Ашлык күп, олау да зур булачак, аны сакларга да кирәк. Бу тиклем ашлыкны яшереп кую да мөмкин түгелдер. Киңәш кирәк. Нишлибез?

Олылар, баш чайкап, озак кына бер сүз эндәшми утырдылар. Бераздан Гаязетдин үзеннән олырак булган Галләметдингә карады. Тегесе «сөйлә» дип башын каккач, Гаязетдин сүз башлады.

– Хәл авыр, тик аннан да начарракларны күргән булды. Мин отрядны Томафи яланына алып чыгып урнаштырырга киңәш бирәм. Күзәтүләргә караганда, көз җылы булачак, урманда яшәрлек. Үктәбр уртасына килеп кердек, ә тышта җәй азагы кебек җылы.

Томафи яланы! Бер яктан тирән Танып, аның өсте кырдагы кебек, беркем күренми үтә алмый, ике яктан кеше үтә алмаслык Тукмай сазлыклары, кайчандыр дамба итеп күтәрелгән арбалы ат үтәрлек тар гына юл. Юлның башында, дозор ятарлык бәләкәй генә булса да, өстеннән бар дөнья уч төбендәгедәй күренеп торган сырт. Моннан да яхшы урын юк, стратегик яктан да, тактика ягыннан да бик ышанычлы урын ул Томафи яланы.

Галләм сүзгә кушылды.

– Ысматри-матри, киңәш берсүзсез шәп, бу урын йөз кешене генә түгел, күбрәген дә сыйдыра ала. Керү юлы берәү генә, ул да күз алдында. Ашамлык, утын, чиста су кул астында. Томафи картның иске булса да, өе дә сакланып килә, анда да яшәрлек. – Галләм туктап калды. – Тик ике начар ягын күз уңында тотарга кирәк. Сазлык аша борынгы юл бар. Ул Үгез чишмәдән башлана, Томафига килеп тоташа.

– Кем белә инде ул борынгы юлны хәзер?

– Бездә дүрт кеше. Икесе синең алда утыра. Өченчесе сугыштан агач аяк белән кайткан Галәветдин. Тагын Ярми, ул юк инде. Михайловкадан кем беләдер.

Гаязетдин Галләмгә борылды:

– Тагын бер кешене оныттың.

– Ә-ә, матри-ка. Бишенче кеше – Ризван! Аның белмәгән нәрсәсе юк!

– Ә икенче начар ягы?

– Ысматри-матри, икенче начар ягы – Томафи Матусов буасыннан астарак урнашкан. Әгәр дошман буа суын ерып җибәрсә, Томафины бер аршинга су баса. Монысыннан инде Салих туктап тормаячак, билләһи! Син ысматри-матри, ә!

Өчесе дә туктап калдылар. Шунда Гаязетдин кинәт башын күтәрде:

– Без Хатмул пучинкәсен оныттык бит? Томафиның сазлыксыз башында?

Ильяс дәртләнеп китте.

– Теге Ямаяз ерымы ягыннанмы? Хатмул юлбасарның качып яткан урыны, чыгу юллары, яшәү бүлмәләре.

Галләметдин үз алдына сөйләнгәндәй итеп фикерен әйтте:

– Ә-ә, ысматри-матри! Әгәр ул юлларны алдан карап куйганда? Тик атларны ничек алып чыгарга? Хатмулның юллары ат чыгарлык түгел бит.

Гаязетдин Галләмнең сүзен үзе уйлаганча дәвам итте:

– Кайчандыр аның юллары Каюм мәгарәсенә кергән диләр иде. Яшьрәк чакта мин ул юлларны карап йөргән бар. Тик мәгарәдә бик куркыныч, сөйләшкән тавыштан ук ишелеп төшәргә торган кызыл балчык. Ат белән анда керсәң, исән чыгуың икеле.

Галләм тагын сүзгә кушылды:

– Монысы дөрес. Мин хәтта адаша яздым әле бер. Шуннан башлап анда кергәнем дә юк, ә керә торган җиренә агачлар өеп куйдык, ысматри-матри. Хәзер ни хәлдәдер, белмим. Барып карарга кирәк, тикшерергә. Шуннан, ысматри-матри, безгә бит мәгарә буеннан-буена кирәкми, тау астыннан үтеп китәр өчен генә. Чыга торган җирләре аның берничә. Ни хәлдәләр икән, анысын менә белмим.

Ильяс аларны тынычландырды.

– Барысын да уйлап җиткерә алмабыздыр бүгенгә. Моннан да кулайрак башка юл юктыр бит?

Озак уйладылар өчесе дә. Башта «юк» дип, Галләметдин, аннан Гаязетдин әйтте, аннан Ильяс үзе дә баш какты.

– Болай итәбез, значитца. – Ильясның тавышында командир авазлары яңгырады. – Иртәгәдән ун-унбиш кешене Томафиның өен карарга, землянкалар казырга, Хатмулның юлларын тикшерергә, кирәк булса, төзекләндерергә, киңәйтергә җибәрәбез.

Аны Галләм карт бүлдерде.

– Вакыт, вакыт кыска, Ильяс, ысматри-матри! Унбиш кеше аз. Утыздан да ким түгел. Өлгермибез. Мин иртәгәдән алар белән чыгам, берьюлы теге иске юлны да карармын. Бәлки, исән дә түгелдер инде ул. Шуннан бер-ике кеше белән мәгарәне дә үтәрбез. Шуннан, ысматри-матри, баулар кирәк булыр бик озын, иртәгә безнең белән баручыларга алырга кушарга кирәк.

– Ярар. Шулай итәрбез. Тик... Тагын бер сорау калды бит. Ашлык! Аны нишләтәбез?

– Күпмерәк инде ул?

– Аз түгел. Капчыклап исәпләгәндә, йөз илледән артык булыр. Димәк, ун арбадан күбрәк бер олау була инде.

– Бая үзең әйткәнчә, аны Чернушкага җибәрсәк, аклар кулына илтеп тапшырабыз. Казанцевога ун арба ашлык куу да якын араны үтү түгел бит инде ул.

Бераз тик кенә утыргач, Гаязетдин үзенең алтын киңәшен әйтте:

– Бер генә юл. Гәвендә Матусовның яздан бирле ике баркасы тора. Шуларның берсен алсак, ашлыкны сыйдырырга була. Тик Танып Казанцевога табан акмый бит. Димәк, Борай авылында аны атларга төяргә

туры кilә, аннан кырык чакрым тирәсе. Шуннан, бер-ике кораллы кеше дә кирәк озатып барырга, бүгенге хәлләрне үзегез дә беләсез.

Ильяс та көттермәде:

– Баркасын алырбыз, каршылык күрмим. Матусовныкылар озатып барырга ризалашмас. Значитца, Гаязетдин ага, синнән башка беркем дә алып төшә алмый ул барканы елга буйлап. Ризалаш, ә?

– Ну, ярар инде, төшәрбез, алайса! Тик ике нәрсә борчый мине. Берсе иң куркытканы – салкын булып, елга туңып китсә, нишләрбез? Тагын, ни булса, шул булыр дип юлга чыгып булмый бит.

– Ә нишлибез? Башка бер чара да юк бит!

– Бар. Син Борай волостена ярдәм сорап хат яз. Бу беренче, иң уңайлы юл, әгәр волостьта безнекеләр утырса. Ә мин хәзер Борайга Шәрәфигә хат язам. Монысы инде катлаулы юл, беренчесе барып чыкмаса дип.

– Кем инде ул Шәрәфи? – Галләм сүзгә кушылды.

– Бик хәлле кеше. Безнең карт әтиләр башкорт-мишәр гаскәрендә бергә хезмәт кылганнар. Аның бер ярма яргыч, өч су тегермәне, Агыйдел буенда бер иген пристане бар иде, алып бетермәсәләр власть файдасына.

Ильяс та нидер исенә төшерде.

– Ялгышмасам, ул бит ел башында большевикларга каршы Борай ихтилалын оештыручы. Меңнән артык кеше катнаша. Алар губерна продуправасы тарафыннан үзәккә озатырга әзерләгән ярты миллион потка якын игенне кулга төшерәләр. Значитца, март аенда ихтилал бастырыла, Борай кантоны туздырыла. Икмәкне яшереп өлгермиләр, ул продразвёрстка фондына кире кайтарыла.

– Ул, хәзер кайдадыр, белмим. Тик безнең очракта, әгәр волость аклар кулында булса, аңардан башка ярдәм итә алучыны күрмим. Язган ике хат белән Борайга берәр кешене җибәрергә кирәк булыр. Су буйлап сигез-тугыз көн төшәсе, ул анда, Казанцевога тиклем барырлык олау җыеп, безне көтеп торырга тиеш.

– Ә кемне? Монда бар да кирәк, һәрбер кеше алтын урынына.

Тик кенә эндәшми утырган Галләм җанланып китте:

– Бар андый кеше бездә, бар. Аңардан башка беркем дә үти алмый мондый бик тә үзенчәлекле йомышны.

Һәм Ильяс белән икесе берьюлы бер үк исемне атадылар.

Сүзләр бетте. Тиешле кешеләргә эш кушасы гына калды, кемне кая җибәрәсен билгеләп, иртәгесен кайгыртырга кирәк.

Волостьтан чыгып, өчесе өч якка таралдылар: икесе үзләренең өйләренә табан, Ильяс югары очка – Ризванның өенә.

**43**

– Көттем, көттем сине, Аркадий Михайлович! Без бит синең туган Николай Михайлович белән бергә үстек, укыдык бергә, яткан урыны йомшак булсын... Аның кебек кануннарны яхшы белгән, кеше белән эшли белгән урядник булмас инде хәзер! – Степан кулын селтәде. – Өнә андый кешеләрнең булмавының нәтиҗәсен күрәбез түгелме? Законсызлык, тәртип югалу, Рәсәйне таркату!

Аркадий уңайсызланып китте, ахры, күзләрен челт-челт йомып алды.

– Рәхмәт, Степан Акинфиевич, рәхмәт истә тотканыгызга.

– Ипполит ничек? Исән-саумы?

– Начар, кызганычка каршы, начар. Ята ул. Ничә ел урман ерып йөрү аның бар тазалыгын алды, ахры.

– Дааа! Ул да үзен аямый эшләде инде. – Степан ябылып өлгергән капканы ачты. – Әйдә, өйгә үт!

Алар кергәндә, өстәл җыештырылган, кунаклар калдырган аяк эзләре сөртеп алынган иде инде.

– Аркадий Михайлович, чәйгә утырганчы сөйләшеп алыйк әле.

Кара-каршы утыргач, Степан әңгәмәне башлады. Башта ул тагын бер мәртәбә үзенең кайда йөреп кайтканын сөйләде. Бу юлы ул курыкканын, теге яшь егетнең янауларын да сөйләп тормады. Бары тик отряд җыярга кирәклекне ерактагы командирлар кушуы икәнен аңлатты.

– Отряд бар дип әйтергә була, йөздән артык кеше язылды да инде. Бар да безнең православныйлар. Иң мөһиме, Аркадий Михайлович, командир кирәк полкка. Шул эшне сиңа тапшырырга карар кылдык. Син сугышта булган поручик, фронтовик, барысын да беләсең. Ни уйлыйсың?

Дедухин шундыйрак тәкъдим булырын көткән иде. Шуңа озак уйлап тормады, ризалашты, тик үзенең шартларын әйтә салды:

– Минем эшкә тыгылмаска. Мин кушканны берсүзсез үтәргә. Миңа каршы сөйләмәскә. Башбаштаклык рөхсәт итмим. Һәрбер бозык эшкә җәза! Корал җыярга, аны сатып алырга. Язылганнарны ашатырга акча табарга. Монысын инде халык өстенә ташлыйбыз. Һәркем отрядка үз аты белән килә. Халыкны җыю бөтенләе белән сездән, аларны өйрәтү миннән, боерыклар миннән!

– Халык риза. Мин әле генә безнең хәллеләр белән сөйләштем, килештем. Акча җыябыз, үзеңә дә жалованье булачак. – Монысын сөйләшеп өлгермәгәннәр иде дә ул, Степан алдашты, башкача мөмкин дә түгел иде бу очракта.

Аркадий соңгы соравын бирде.

– Кайда, кайчан?

– Иртәгә кичкә, чиркәү мәйданында җыелабыз. – Степан, кулларын җәеп, Аркадийны өстәл артына чакырды. – Әйдә, Алла җибәргән ризыктан авыз итик.

– Аштан өстен булып булмый, Степан Акинфиевич!

Чәен дә эчтеләр, мәен дә каптылар. Бераз гына салып алгач, Степан сүзнең үзе өчен иң әһәмиятле булган өлешенә күчте.

– Аркадий Михайлович, сугыш сугыш инде, кайчандыр туктар. Минем гаилә турында уйлавымны дөрес аңларсың димен. Кызым бар, аңа күзе төшеп йөргән авыл егете бер. Ал әле шуны үзеңә урынбасар итеп.

Степан бик озак сатулашырга туры килер дип уйлаган иде, тик алай булып чыкмады. Аркадий шунда ук ризалашты, бары иртәгегә тиклем егетне күрсәтергә генә кушты.

– Бернинди авырлыгы юк моның! – Степан, тәрәзәгә барып, пыялага чиртте. Григорийның улы чакырып китергән, әлегә урамда йөргән Савелий йөгереп кереп тә җитте.

– Менә ул, Савелий Чуров!

Ишек төбендә озын буйлы, ыспай гына киенгән, аксыл чәчләре маңгаена төшеп, кашларын каплап торган матур озынча йөзле егет басып тора иде. Дедухинга килгән беренче уй «синә кичке уендә кызларны саташтырып, елатып йөрергә генә инде» булды, тик ул аны әйтмәде дә, сиздермәде дә.

– Ярар. Степан Акинфиевич, яшь бит инде бу, армиядә булмаган, солдат эшен якыннан түгел, ерактан да белми. Ну, ничего. Өйрәтербез! – Дедухин, Чуровка борылып, бая гына әйткән сүзләренең яртысын кабатлады. – Баштанаяк мине тыңлау. Мин кушканны берсүзсез үтәү. Миңа каршы сөйләмәү. Башбаштаклык юк. Һәрбер бозык эшеңә җәза! Бел, җәлләп тормаячакмын, атып китәргә дә булдырырмын! Бары тимер тәртип кенә безне коткара алыр бу афәтле елларда.

Степан ризалашып башын какты. Савелий әллә куркудан, әллә уңайсызланып, бөтенләй коелып төште, ишек төбендә таптанып басып торуын белде. Хуҗа белән аның кунагы бераздан аны бөтенләй оныттылар бугай.

– Йә, Степан Акинфиевич, исемлекне йөгертеп кенә карап чыгыйк әле! – Аркадий егеткә борылды. – Әйдә, безгә табан, нәрсә ишек яңагын терәп торасың?

Шунда гына Савелий акрын гына алга атлады да өстәлнең бер почмагына утырды. Дедухин исемлек белән канәгать калды, кешеләрне белүе белән Степанны аптыратты хәтта.

– Иртәгә гомум сөйләшүдән соң әзерлекне башлыйбыз. Йөз кешене өч взводка бүләбез, кече командирлар билгелибез. Мин фронттан үзем белән өч винтовка, бераз патроннар эләктергән идем. Иң башта ату буенча күнекмәләр үткәрербез. Шуннан рекогносцировка – монысы ачыклау, эзләү була. Басуда күнегүләр – окоп, блиндаж. Чуров, сиңа приказ: иртәгә, халык җыела башлагач та, бу исемлеккә өстәмә керт: кем кайда хезмәт иткән, званиесе бармы, нинди бүләкләре – орден, медальме. Гаиләсе, кемнәре бар. Бөтен мәгълүматны яттан белергә тиешсең! Аңладыңмы?

– А-аңладым!

Дедухинга аның болай куркуы ошый да иде. Әйдә, шулай булсын, курыксын, калтырап торсын.

– Казанлы отрядының исемлеген кулга төшерергә кирәк, монысын мин үзем табарга тырышырмын. Ул безгә бик кирәк булачак. Аларда да күбесенчә фронтовиклар, бүрек белән генә бәреп ега торган түгелләр. Командирлары белемле кеше, власть та алар ягында. Бер сүз белән әйткәндә, уен-муен түгел!

Чуровның башын «Мин монда нигә килеп кысылдым икән?» дигән уй бораулады да бораулады...

Степан, сузган стаканны бушаткач, Аркадий, кара икмәк өстенә дуңгыз мае салып, тәмләп чәйнәде дә иптәшләренә борылды:

– Бүгенгә җитәр. Иртәгә төшкә килеп җитәм. Чуров, мәктәпнең ишеккә якын булган бер бүлмәсен, хәзер үк барып, парталардан бушат, анда безнең штаб булыр.

Озаттылар кунакны. Бу тиклем эш булыры башларына да кермәгән кешеләр капка төбендә аптырап туктап калдылар. Беренче булып Степан аңына килде.

– Ярар, өйрәнеп китәрбез әле, – диде ул йомшак кына. – Син, Савелий,

бар, мәктәптә берәр бүлмәне әзерлә. Командирны тыңламау бик начар нәрсә, хезмәт итмәсәм дә, моны гына беләм.

Мәктәп Савелийның беренче җиңелүе дә булып чыкты. Ул, ишекне каерып ачып, беренче бүлмәдән парталарны өстери башлаган гына иде, мәктәпкә укытучы Андрей Афанасьевич Коновалов килеп керде.

– А ну, тукта! Кем шаяра монда? Кая өстерисең парталарны? – Яктыдан караңгырак бүлмәгә кереп, тышта калган күзләре белән карый торгач, ул Савелийны танып алды. – Чуров? Савелка? Нишлисең монда? Кая ташыйсың парталарны, ә?

Савелий, беренче класс баласыдай, коты очып укытучы алдында туктап калды, аның нидер әйтергә теләгән теле аңкавына ябышты. Калтыраган куллары белән баш киемен тартып төшерде, ә анысы кулда гына калмады, тапталган идәнгә үк очты.

– Нәрсә мыгырдыйсың? Мин сине шулай мыгырдарга өйрәттеммени җавап урынына?

Ниһаять, Савелийның теле ачылды.

– Ан-андрей Аф-аф-анасьевич, миңа Степан А-акинфиевич кушты, а-аңа А-аркадий Михайлович Дедухин кушты.

– У-ух, син! Ул кушты, бу кушты! Эт – эткә, эт – койрыкка. Миңа калса, император үзе кушсын! Мин бит, нинди авырлык белән буяу табып, әле генә буяп чыктым идәнне. Ә син! Кара, нинди эзләр калдыргансың! Парталарны өстерәп, идән буявын тырнак эзләре кебек актарып ташлагансың, итегеңнән коелган пычракны күр! Нигә дип ишекнең keләсен каердың? Ачкычның болдыр тактасы астында ятканын бөтен авыл, барлык укучылар белә бит! Менә инде, көч бар, акыл кирәкми!

– Гафу итегез, Ан-андрей Аф-аф-анасьевич!

– Немедленно! Ишетәсеңме, немедленно класс идәнен юып чыгарасың! Әнә, ишек төбендә калган буяу тора, сызылган эзләрне буйыйсың. Шуннан, идән бераз кипкәч, парталарны үз урынына! Шуннан ишекнең келәсен көйләп кагып куясың! Ә шуннан инде минем рөхсәттән башка якын киләсе булма мәктәпкә! Ишетсен колагың! Ә эшеңне бер сәгатьтән килеп тикшерәм!

Укытучы, эре адымнар белән атлап, мәктәптән чыгып китте. Ә Чуров, авыр сулап, ул кушкан эшләрне эшләргә ашыкты.

**44**

Аяз көндә яшен уйнатып, күк күкрәтеп бер көн үтәсе араны икенче атна үтеп килә Салих. Аның артында асылган кешеләр, таланган авыллар, төтен һәм көл, елаган карт-коры, хатын-кыз, бала-чага кала, бары алар Салихның кара эшләренең телсез шаһитлары иде... Ул авылларга якынлашканда, ирләр, гаиләләрен алып, урманга чыгып качалар, авыллар бушап кала, бары картлар гына өй сакчылары булып, урамга да чыкмый, базда яталар. Мондый кыргыйлыкны, мондый кансызлык-шәфкатьсезлекне күргәне булды микән бу якларның үтеп киткән ихтилаллардан соң? Тәфкилевнең экспедицияләре, болар белән чагыштырганда, бер читтә торсын.

Иң начары – тимер юл буенда була торган усал кешеләр Салих отряды исеменнән эш итә башладылар. Шул ук талаулар, шул ук мыскыл итүләр,

кеше гомере сукыр бер тиенгә төште. Авылдан авылга булып үткән коточкыч хәлләр турында сүзләр йөри, һәрбер тукталыш саен Салихка килеп ул хәлләр турында түкми-чәчми сөйли башладылар. Күпне күргән Салихка иң нык тәэсир иткәне бәләкәй генә Лидовка авылы кешеләренең килүе булды. Иң олылардан булгандыр инде, сүзне бер бик карт әби башлады:

– Ярдәм, яклау, саклау сорап, өмет белән сиңа килдек, улым!

Иягендәге кып-кызыл тиресе суелган карт, яшьле күзләрен челт-челт йомып, авылда булган фаҗигане бәян итте:

– Авыл бае Афанасий Кинев башта, халыкны җыеп, бу эшләрне синең исемнән аткаруы турында әйтте, акча таләп итте. Кайдан булсын инде ул акча? Авызларын ачсалар, үпкәләре күренеп тора бит халыкның! Шуннан китте! Киневка каршы чыгып сөйләшкән Шуравин Николайны, штыкка кадап, урам буенча йөрттеләр, минем – ояты гына ни тора! – сакалны йолкып алдылар. Күршедәге авырлы хатын Вера Замятинаның эченә штык кададылар... Бәләкәй генә авылда уналты кешене җәзаладылар, шуларның алтысы – картлар.

Рус кешесенә охшамаган аксыл чәчле карт та сүзен кыстырды:

– Никольский хуторында бер чокырга анда яшәгән немецларны үтереп ташладылар, өсләренә граната да ыргыттылар. Качканнарын табып, коега салдылар. Ә Змеёвка хуторында яшәгән эстонлыларны атып киттеләр.

Сүз яңадан беренче картка кайтты:

– Бөтен чуен юл буендагы төбәктә шундый ук хәл. Петропавловскида туганнан туган Андрей һәм Пантелей Морозовлар атылды, аларның этисе Захар да шул уңайдан, Меркурьев Федор Васильевич, Кавардаков һәм тагын берничә кеше, атылгач, Күбәяз урманындагы чокырга ташланган. Барысы унөч кешене табып җирләдек. Фронтовикларны үтерә башладылар. Казанлыда кызыллар ягыннан яраланып кайткан Хәсби Сәйфетдиновны тукмап үтергәннәр.

Карт, үзенең ялгышрак әйткәнен аңлап, хатасын төзәтергә маташты:

– Ул ни, акмы, кызылмы, кеше бит әле, Ходай бәндәсе. Жәл! Бу бандитлар барысын да син кушты дип сөйлиләр адым саен.

Кемгәдер нидер вәгъдә итә Салих, кемнәрнедер игътибар белән тыңлый, бандитларны табарга сүз бирә. Лидовка авылы тарихы аны чыгырыннан чыгарды, шунда ук ярдәмчесен чакырып, картлар белән шул авылга чыгарга боерды. Ике көннән, бандитлар тотылып, чиркәү алдындагы мәйданда бөтен халык алдында сугыш вакыты кануннарына ярашлы рәвештә атылдылар.

Ничек кенә булмасын, бу адымы аны халык арасында геройга әйләндерде. Озын буйлы, какча гәүдәле, тар гына мыеклы – чынлап та, матур кеше ул Салих. Итекләре ялтырап, киеме килешеп тора. Битендәге әллә кайчан төзәлгән җөй дә аның файдасына – батыр һәм тәвәккәл булуы турында сөйли. Авыл кешеләре аңа зур ихтирам һәм соклану белән карыйлар. Ышануы кыен – чыннан да, кайдан бу тыштан ялтырап торган матур кешедә шулкадәр усаллык, шәфкатьсезлек? Кызылларга ышаныч күрсәтә дигән бер сүз житә кешене кулга алырга, җәзаларга, атарга. Авылларга кинәт килеп керүләре белән, алдан ук мәгълүмат җыеп, кемнең кем икәнен белүе

белән, бик тиз үткәрелгән үч алулары белән ул бу якның Робин Гудына да, юлбасарына да әйләнеп бара, аның исеме кешене куркыта, ихтирам итәргә мәҗбүр итә.

Менә бу юлы да Ямаш-Павловога шаулап-гөрләп килеп керделәр. Авыл тынып калды, хәтта эт өргән тавышлар да ишетелми.

Авылга керү белән Салих атын күптәнге танышы, дусты Герасим йортына табан борды. Солдатлар турында Салих уйлап та тормады, чөнки алар үз эшләрен беләләр. Килгән уңайдан ук берничә кешене ябып та куйдылар, үзләренә ошаган йортны сайлап, төркем булып ялга туктадылар. Хуҗалардан ризалык сорап тору юк, ризалык урынына шунда ук үзләренә игътибар таләп иттеләр, ә хуҗалар аларның шартын, авырсынып булса да, кабул итәргә мәҗбүрләр.

Салих алдан хәбәр бирмәсә дә, аны Гераська көтеп торган иде. Өстәл байлыктан сыгыла, ашау-эчү мул, беркем дә комачауламый, аш-суны алыштырып торучы апалар үз эшен яхшы белә. Ярымачык тәрәзә аша мунча ташында пешереп алынган мәтрүшкә һәм тагын әллә нинди үләннәр кушылган каен миллегенең тәмле исе килә. Өйгә кереп, мондый муллыкны күрү белән Салих соравын бирде:

– Герась, син минем бүген кайтасымны кайдан белдең?

– Бер атна шулай көтәм сине! Миңа керми китмәячәгең билгеле, ашау-эчү әзерләү, мунча ягуның ни авырлыгы бар? Аның каравы, син миндә бүген кунакта! Слава тебе, Господи! Күпме телисең, шул тиклем ял итәсең, ни кирәк, әйт кенә. Күгәрчен сөтен дә табам!

– Рәхмәт, Герась! Бер тәүлек инде, күпкә булдыра алмыйм. Алла бирсә, сугышлар беткәч, махсус килермен.

Өстәл артына утырдылар. Герасимның мул табынында барын да онытырга теләп, ничек кенә йөзсә дә, Салихны бүген эчү алмый иде.

Уйлары белән ул әле булып үткән вакыйгаларны җентекләп кичерә, аларның очына чыгарга тырыша. Щучье ягында партизаннар шартлаткан тимер юлның бер бүлемтеген көйләгәнне көтеп кузгалып китә алмый тәүлек тирәсе торырга туры килде. Салих штабны тиз генә бер хәлле сәүдәгәр өенә күчерде. Шунда күрде ул Маринаны, күрше авылда укытучы булып эшләгән кызны. Шул мәлдә алар арасында ниндидер баллы, татлы яшен чаткылары үтеп китте. Дулкынланып торган йөгерек сынлы, алтын чәчле бу кызны сугыш афәтләре урап үтмәгән, мобилизациягә эләккән ире сугыш яланнарында югалган. Нинди генә хәлләрдән исән-имин чыккан Салих югалып калды, бар дөньясын онытты, өч көнгә ял игълан итте, үзе дә сизмәстән, әлегә тиклем таныш булмаган шәхси мохиткә башы-аягы белән чумды. Төштәге кебек әллә нинди кыска көннәр, тиле дә, сихри дә төннәр, башкаларның канәгать булмаган күзләре – болар бар да шушы өч көн эчендә яшен тизлегендә үтеп киттеләр. Шул арада Марина Салих тормышының бер кирәкле өлешенә әйләнеп китте. Солдатларның кансызлыгы, авыл кешеләренең аһ-зарлары, байларның кире эшләре, Салихның үзенең ялгыш карарлары һәм адымнары – барысын да ул сөйләп бара Салихка. Болар, бер яктан, аның күңелен китә, икенче яктан, аның белән сөйлә-шер, киңәшләшер кеше булуы шул кителгән күңелне күтәрә төште. Өченче ягы да бар шул. Салих үзен кенәз кызы белән көймәдә баручы Стенька Разин итеп тоя башлады. Кайчандыр бу мөнәсәбәтләрне

туктатырга кирәк булачак, тик Маринаны уйнап килүче дулкынга аның бер дә ташлыйсы килми.

Соңгы киче хәтердә уелып калды. Инде китәргә барысы да әзер булганда, Марина аның кырына килде дә, атның башыннан сыйпап, әллә ничек итеп назлы һәм таләпчән тавыш белән әйтә салды:

– Салих, мин дә синең белән!

Салих, аптырап, аягын өзәңгедән тартып алды:

– Н-нәрсә?

– Мин дә синең белән!

– Син... син беләсең бит безнең кая барганны?

– Беләм! Алсаң да, мин сезнең белән, алмасаң да. Башканы ишетергә дә теләмим.

Салих ни әйтергә белми бераз басып торды. Солдатлар үзара нидер сөйләшә, бер-берсенә мәгънәле караш ташлыйлар, ихатада тынлык урнашты. Шуларга күз йөртеп чыккач кына, Салих үзендә ниндидер тынычлык сизде.

– Син безнең белән азакка тиклем барырга уйлыйсыңмы инде?

– Сезнең белән түгел, синең белән! – Аның тыныч та, көчле дә булган тавышы Салихны тагын аптыратты.

– Әйе-е... Тик... кара әле. Сиңа бит авыр булачак. Көне буе ат өстендә.. Беренче тапкыр...

– Ә син кайгырма. Берәр ничек җаен табармын. Бары тик синең белән.

Үз гомерендә беренче тапкыр уңайсызлык кичерде Салих солдатлар алдында. Шуңа да ул тизрәк бу хәлләрдән чыгу өчен ярдәмчеләренә борылды:

– Ярар, бирегез аңа ат!

Кич ул атта йөрергә өйрәнде – монысы, чынлап та, аның кулыннан килә торган эш булды. Ярымйокыда, сөйләшүдә тагын бер төн узды, иртәнгә Салих оеп йокыга талды.

Солдатлар йөгерешкәнгә ул сикереп торды – Марина юкка чыккан дигән хәбәр белән керделәр сакчылар. Атын тезгененнән тотып, ул авыл кырыендагы сакчылар янына килә, бераз сөйләшеп утыра, Салих аны куып җитә дип, Танып ягына атын җитәкләгән килеш атлый. Сакчылар берни сизми, Салих үзе дә килә дигән сүз аларны йомшарта. Бераздан гына шик корты керә аларга, Маринаны эзли башлыйлар. Тик кызның эзләре суынган була инде бу вакытта. Сакчыларга нык эләкте Салихтан, нык. Шунда ук, тиз генә барысын да җыеп, ул юлга чыкты.

Менә шулар башыннан чыкмый иде Салихның. Кем ул Марина? Нигә ул өч көн эчендә аның күңелен яулап ала алды? Ә нигә чыгып качты? Герасим сөйләгәннәрнең бер өлеше генә барып җитә иде аның аңына. Күптәнге дус кешегә җавап бирергә кирәклеге өскә чыкты, ул аны игътибарлырак итеп тыңлый башлады. Ә Герасим сөйли дә сөйли...

– Хәзер сату-алу белән бик авыр. Кешеләр дә фәкыйрь, товар да юк. Нәрсә сатасың инде? Шикәр дә чәй. Кәрәчин ярдәм итә. Лавканы ябаргамы әллә? Авылныкылар акча түләми, яздырып кына алалар. Юк, вакытлар тәмам үзгәрде. Ә ничек була торган иде, ә?

Салих аның акыллы итеп сөйләвенә игътибар итте.

– Син менә офицер, укыган кеше. Күпмегә барыр бу хәлләр? Салих, син

мине гафу ит турыдан-туры ярып салганым өчен. – Герасим ару гына исерә бара иде. – Ну, ышанмыйм мин чехларына да, Колчагына да!

Салихның күзләрендә сагаю утлары күреп, ул бу сүзләргә өстәргә ашыкты.

– Мин сиңа дуска, туганыма сөйләгәндәй итеп! Бәлки, син мине гаеплисең дәдер бу сүзләр өчен. Тик мин генә болай уйламыйм, син мине аңла да гафу ит! Әнә, Чернушка тиклем Чернушкада ниләр булып ята. Нindидер партияләр килеп чыккан, халык йә монда, йә тегендә митингка йөри. – Герасим калын, юан бармаклары белән ит кисәген эләктерде. – Туктап торырга кирәктер, Салих, туктап торырга. Алда ни буласын кем белә?!

Салих аны күпне күргән кешеләргә хас түбәнсетү аша тыңлады.

– Туктап торырга, бозылмастаен җиргә күмәргә. Николаевскидан Никанорычны хәтерлисеңдер. Менә ул былтыр ук бар мөлкәтеннән бик уңышлы котылды да каядыр чыгып тайды. Сөйлиләр, чит илгә. Парижның үзенә диләр. Анда бит аның туганы, Рус сезоннарын үткәрүче Сергей Павлович Дягилев яши. Ә Дягилевның нигезе безнең Николаевскидан, аның туганы Иван Павлович монда яшәгән!

Дягилев дигәч, Салих кузгалып куйды. Шул Сезоннарында аңа да тамашачы булып катнашырга туры килгән иде заманында.

– Менә шул Никанорыч минем өше кара мужик түгел, ул икенче калыптан. Сугышка хәтле әнә нинди чиркәү төзетте бит ул! – Герасим, төрле якка борылып, чиркәүне эзләп чукынып алды. – Җиңел дисеңме әллә шундый мәһабәт Алла йортын төзү! Менә ул нинди акыллы баш, бар дөньясын ташлап чыкты да китте.

Кыска гына аяклары белән Герасим арлы-бирле йөри башлады. Идәннең бер тактасы шыгырдап елап алды, ә Герасим үткән саен нәкъ шул тактага баса иде. Аның чигәләреннән елга булып тир ага, ул аны озын тастымал белән сөртеп тора, ә тастымалның икенче башы идәннән сөйрәлә, Герасимның аяклары арасында бутала. Салих, сөйләшми торуын килештермичә, сүз башлады.

– Беләсеңме, Герась, бу хәлләр бик озакка китте. Шуңа ашыгабыз да инде. Төрле яктан бастырып киләләр большевикларны. Төрле яктан – төньяктан, көньяктан, көнчыгыштан, көнбатыштан. Чехлары да бар, адмирал Колчак та бар, тагын әллә кемнәр безнең байраклар астында. Ә большевиклар коралсыз, ач-ялангач, ыштансыз. Менә син, ач-ялангач, тишек ыштан киеп, сугышыр идеңме яңа власть өчен?

Борын астына нидер әйтеп, Герасим канәгать итеп көлеп җибәрде:

– Матур сөйлисең, оста сөйлисең, ә!

– Минемчә, болай булса, озакка бармас, озак тота алмаслар мондый фронтны. Ә син курыкма, власть юклыктан файдалан, байлыкны җыя тор!

Герасимның киң авызы беразга ачык торды, бары тик берничә мизгелдән ул аны яба алды һәм җөмләләр тезмәсенә ирек бирде:

– Ничек, ә? Власть юклыктан файдалан! – Салихка булган соклanудан һәм күңеле күкләрнең җиденче катына менеп китүдән үзен-үзе тыя алмыйча, Герасим әңгәмәдәшен кочаклап алды, майлы иреннәре белән аның чигәсенә төртелде.

– Синнән башка минем бер дустым да, бер туганым да юк! Бары бер син! – Ярымелап, Герасим Салихны, нык итеп әләктереп, үзенә тарта, Салих акрын гына бу куллардан ычкынырга тырыша. Җитмәсә, Герасимның кайнар яшьләре аның алтынланган погоннарына тама иде.

– Ял ит, Салих! Хет бер атна, хет бер ай! Бөтен ышанычым синдә, башка беркемгә дә ышаныч юк!

Ниһаять, Салих бу кочактан ычкына алды. Чынлап та, бу кеше үзен маймыл кебек тота иде: сикерә, чиктән тыш соклану белдерә, эчә, елый, көлә. Салихның аңа йомышы бар, тик аңлар микән ул аны?

– Герась, сиңа сүзем бар, тыңла әле игътибар белән. – Герасим ялт итеп айныды да куйды, монысы Салихны аптыратты да хәтта. – Минем аша бик күп нәрсә үтә, ә мин элеккечә ыштансыз, булган байлыгым бары менә шушы форма. Юньләп жалование дә түләмиләр бит. Сугыш барыбер бер бетәр, аннан соң ничек яшәрбез? – Менә шуның турыда уйларга кирәктер. Сүз шул: мин сиңа тапкан мал-туарны җибәрештереп торсам, акчага әйләндерә алырсыңмы? Кәгазь акчага түгел инде, аңлыйсың.

Герасим яшен тизлегендә бу эшнең нинди отышлы булуын башыннан үткәрде дә җавабын озак көттермичә әйтеп тә салды:

– Була ул! Син әйткәнчә эшләрбез.

Ни турында сүз барганын икесе дә аңлый иде. Кул кысыштылар, кемгә нинди өлеш төшәчәген аңлаштылар, иртәгедән үк эшне башларга сүз куештылар. Герасимның тагын кочаклашырга ниятләп якынаюын күреп, Салих торып басты. Хуҗа кунагының торганын күреп туктап калды да бөтен эчке кайнавын сүзләр аша җиткерде:

– Ял ит, Салих! Син – минем көтеп алган иң зур кунагым!

Һәм кинәт пышылдауга күчте:

– Бәлки, сиңа берәр яшь бичәкәй кирәктер? Хәзер мин аны табам! Бар ул яшь килennәр, бар!

Герасим ишекләрне тибеп ача-ача, ул барган юлда торган урындыкларны тибеп җибәреп, шунда ук юкка чыкты.

Шул гына җитмәгән иде тагын... Күз алдына Марина килеп басты. Эх, Марина, Марина! Нишләдең син? Нигә болай иттең инде, ә?

Салих Герасим артыннан ниндидер җирәнүгә охшаш тойгылар белән карап калды, алдында торган болганчык, яшькелт көмешкәне эчте дә, стаканны өстәлгә ташлады. Шунда гына ул стакан төбендә мыекларын, тәпиләрен кыймылдатып йөзәргә маташкан әллә таракан, әллә чебенме ятканын күрде…

**45**

Юл, берүзе иркенләп үсеп утырган имәнне урап чыгып, Таныпның биек ярына килеп терәлде. Астарак, куаклар артында, җитез елга үзенең суларын бернигә карамый алга куа, тонык суда көзгедәге кебек бөтен дөнья чагыла. Бер карасаң, ул бөтенләй акмый төсле, суда чагылган агачлар да, болытлар да тып-тыныч кына, каккан кебек бер урында торалар. Тик бу алдый торган тынлык: кайчакта елга су астыннан өскә табан әйләнмәләр ыргыта, әллә кайдан табып, өскә ак күбек ташлый, суүсемнәрнең яшел җепләрен уйната, каршы яктагы таллардан саргая

башлаган яфракларны өзеп алып, агым уңаена әйләндерә-әйләндерә алып китә.

Ильяс бүген әзерлекне карар өчен махсус килде Томафи яланына. Әйе, яланга авыл ягыннан күренми генә керү мөмкин түгел. Бер куркыныч бар – анысы инде елга буйлап. Елга буйлап һөҗүм башланса, аны туктатып була торган түгел. Монысына да Гаязетдин акыллы киңәш бирде: баркага төялгән ашлыкны алып чыгып китү белән, Танып өстенә ике яктан да ярда үскән биек карамаларны кисеп төшерергә, шулай итеп андагы хәрәкәтне туктатырга. Ул агачлардан елганы азат итү – тавышлы эш, акларның уйлары шунда ук билгеле була.

Кичә иртән агып төшеп китте ашлык төялгән барка Танып буйлап. Анда кораллы өч кеше, алда ниләр көткәнен берәү дә белми. «Аллага тапшырдык!» – диде Гаязетдин, юлга чыкканда. Бар ышаныч Аллада, Гаязетдинның осталыгында, дошманнарның бу сәфәр турында белмәвендә, тимер юл буенда, су буенда кеше талап йөргән бандитларның сизгерлеген югалтуында, һава торышының яңгырлы булуында, салкын булып елга туңып китмәвендә, барканың исән-имин ерак юлны үтә алуында, Борайда ашлыкны олауга төяп, Казанцевога илтеп тапшырып булуында. Иң кайгыртканы – Казанцевода нинди хакимият вәкилләре, кемнәр хакимлек итә? Ризван Шәрәфи бай белән килешә алырмы? Күп шул бу уңышның шартлары, бик күп...

Текә ярдан борылып, Ильяс тар гына юлдан Томафига табан кузгалып китте. Ярты сәгать дигәндә, ул Томафиның чабылмаган болынына килеп чыкты. Әллә кайда эчтә, йөрәкләрне-бәгырьләрне телгәләп, сары сагыш узып китте. Казанлылар өчен якын булган берничә болын шулай итә кешеләрне: бу Чәчрәтке болыннары, Томафи болыны, Чана Чыгыш болыннары.

Алда матурлык. Алда хозурлык. Сары, кызыл япмалар ташланган кара яшел урман елга борылган киң тугайның суына хәтле төшә дә, аны атлап чыгып, яңадан көчле, кырыс булып, караңгы һәм серле булып, күккә күтәрелеп китә.

Болын читендәге Томафи картның өе кырында учак яна, анда берничә кеше ял итә иде. Ильяс килүгә аларга тагын бер-ике кеше өстәлде, аның сораганын да көтмичә, башкалардан олырак Хәертдин хәлләрне аңлата да башлады.

– Землянкалар, куышлар, алачыклар әзер.

Ильяс тирә-ягына карады, тик бернәрсә дә күрмәде.

– Яшердек без аларны, хәзер күрсәтербез ничек итеп яшергәнне.

– Хатмулның юлларын таптыгызмы?

– Таптык, тик алар инде убылып төшеп баралар. Кайбер урыннарын файдаландык, вакытлыча яшәп торырлык. Хатмул белгән уңайлы җирне сайларга, ышанычлы итеп төзегән пучинкәсен.

– Ә Каюм мәгарәсе ни хәлдә?

– Монысы авыррак, Ильяс! Кереп карадык. Танып ташыган вакытта мәгарәнең кызыл балчыгын юып чыгарып барлыкка китергән куыш җир ул. Чак кына тавыш булдымы, җимерелергә тора.

– Берничек тә үтәрлек түгел инде, алай булгач? Значитца, Томафи

болынынаннан керергә дә, чыгарга да бер генә юл. Монда отрядны кертсәк, капчыкка кереп бикләү белән бер. Капкын! Эзләргә кирәк берәр җаен.

Су буендагылар бер-берсенә карашып көлештеләр.

– Әзерләп бетерми торып, сиңа күрсәтмәскә иде дә бит, әйдә инде, күрсәтәбез. Тик башта монда кара! – Хәертдин, кулына чыра алып, җиргә сыза башлады. – Менә монысы Танып. Ул менә ничек киң итеп борыла. Елганың теге ягында – удмуртларның Гыйбадәт тавы, аның астында – Каюм мәгарәсе. Аңа керә торган урынны агач баскан, болай гына күренми, якын барырга кирәк.

Ильяс көлеп җибәрде:

– Фронтта безнең командир да атака башланыр алдыннан шулай җирдә сызып күрсәтә иде!

– Безнеке дә шулай итте! Дәлше. Мәгарәнең күп өлеше ишелгән, ишелүне туктатып булмый, ул гел бара. Тик без анда эчкә үк кереп йөрмибез.

– Значитца, башка юл бар?

Хәертдин ташлаган чырасын тагын кулына алды.

– Мәгарәгә кергәч тә, уңга борылабыз, анда ташлы урын, җимерелү куркынычы юк диярлек. Без аны барыбер ныгыттык.

Сүзгә икенче абзый кушылды.

– Тик без уңга бармыйбыз! Анда сул якта яланга алып чыга торган борылыш бар, шуның буйлап чыксаң, удмурт авылына иң кыска юл.

Ильясның соравы озак көттермәде:

– Күпме барырга инде җир астыннан?

Монысына инде тагын Хәертдин җавап бирде:

– Барлыгы өч йөз адым тирәсе. Җимерелергә сәбәп булган тавыш чыкмасын өчен атлар арасында унбиш-егерме адым ара калырга тиеш дип уйлыйм. Булмаса, атларның борынын бәйлибез.

– Кемнәр белә инде андый юл барын?

– Елганың безнең ягында беркем дә белми. Еш йөргән урын түгел. Шуннан, Гыйбадәт тавы бит, кеше курка анда барырга. Бәлки, удмуртлар беләләрдер.

Монысы әйбәт инде, күп кеше белсә, барыбер бер очы чыга, үзара утырганда, кемдер сөйли, хәбәр тарала.

– Теге якка ничек чыгабыз? Күпер салыргамы, әллә су өстеннән юл түшибезме?

– Астарак кичү дә бар. Су тирән түгел, кайда билдән, кайда муеннан, төбе ташлы. Арбаларны шуннан чыгарып урманда яшерәбез. Монда юл түшибез атлыларга.

– Значитца, тагын бер мәртәбә сорыйм инде: мәгарәне хәвеф-хәтәрсез үтү мөмкинме?

– Мөмкин. Әйдә, бер килгәч, карап та чыгыйк. Шуннан аш ашарбыз.

Атынып торган агач буйлап Таныпны чыгып, Гыйбадәт тавына атладылар. Бу тау турында халыкта төрле сүз йөри. Имеш, яп-якты көнне караңгы булып китәргә мөмкин, имеш, монда кош та сайрамый, имеш, тау ялгыз йөргән кешеләрне адаштыра. Әллә шулай, әллә имеш-мимеш. Тик барысы да тау кырында тып-тын калдылар.

Мәгарәнең авызыннан ук салкын бәреп тора, аяк астындагы юеш кызыл

балчык урыны белән тая, тик анда вак таш күп булу сәбәпле, каты гына юл хасил булган. Стеналар да шул ук ташлы кызыл балчыктан, бер ат сыярлык үтеп йөрү юлы берничә адым саен баганалар куеп ныгытылган. Монысы инде хәвеф-хәтәрне күпкә киметә.

Өч йөз адым сизелми дә калды. Юл, чынлап та, канәгатьләнерлек, димәк, үтеп булачак. Учак янына чыктылар. Ильяс авылдагы хәлләрне сөйләп алды, аклар-кызыллар фронтының нинди сызыкта булуын аңлатты.

– Безнең өчен иң куркынычы – Салихның авылга кайтуы. Кайтса, значитца, аңардан миһербанлык көтеп булмаячак. Бездә булган хәбәрләр буенча бүген-иртәгә кайтып җитәчәк ул. Димәк, бүген кич безнең отряд монда булачак.

Аш тәмамланыр алдыннан Галләметдин кайтып керде.

– Ысматри-матри! Болар кунак булып яталар! Ә Салих инде Ямашта! Өч-дүрт сәгатьтән монда булачаклар!

Аш өзелде. Ильяс шунда ук отряд артыннан авылга кеше җибәрде, Шакирга тиз генә җыелырга боерык бирде. Өч-дүрт кешегә Танып өстенә агач аударырга кушты. Бераздан йөзьеллык карамаларның елгага гөрселдәп ауганы ишетелә дә башлады.

Ашап алган Галләм карт аны читкәрәк чакырды.

– Таптым юлны. Әле дә бар икән ул. Түшәлгән агачлары череп беткән бетүен, тик җәяүлеләр үтәрлек.

Монысы начар, бик начар яңалык булды. Димәк, ул якка да сак куярга кирәк булачак, чигенү юлларын карап билгеләргә туры киләчәк.

– Үгез чишмәгә хәтле барып урадым. Чишмә бик киң җәелгән, ат белән керү мөмкин түгел. Ә менә атсыз, түмгәктән түмгәккә үтәргә була. Солдатларга нәрсә, аларга боерык бир генә.

– Галләм ага, барысын да күз уңында тота алдыкмы? Әйдә, барлап карыйк. Значитца, ашлыкны җибәрдек.

Галләметдин бармакларын бөгә башлады.

– Бу бер. Гаязетдин Тәшкүрне үтеп барадыр инде.

– Таныпка агач аударып, су буйлап йөрүне чикләп киләбез, значитца.

– Бу ике, һәм бу – бик дөрес карар.

– Монда яшәргә урын әзер, значитца. Кирәк булса, күпер кебек нәрсә түшәп ала алабыз.

– Өч, дүрт сиңа менә!

– Каюм мәгарәсен тикшердек, бүрәнәләр бастырып ныгыттык.

– Биш, алты! Йөрер юлны тиз генә үтәр өчен тигезләп тә чыктык.

– Әйе. Иң мөһиме – ары китәргә юлны таптык.

– Удмуртлар Гыйбадәт тавына елына бер-ике генә киләләр, значитца, тау тирәсен бик чиста тоталар. Шуңа безнекеләрне кисәтеп куярга кирәк, бу урын белән бик шаярмасыннар.

– Нәрсәне оныттык?

– Онытмадык. Искә төшкәнен эшли торырбыз.

– Бер нәрсә күңелне кыра. Буа ерылса, бу тирәне чынлап су басамы?

Галләм уйга калды.

– Бу турыда мин Гаязетдин белән сөйләштем, ул елгаларның холкын яхшы белә. Матусов кешеләре суга батканда, буаны бер карышка

төшергәннәр иде. Ә Таныпта ул суны сажиннан биегрәккә күтәргән. Дәлше. Син, ысматри-матри, ярның биеклеге өч сажин булсын, ди. Бу тирәне су белән каплау өчен буадагы суны дүрт-биш карышка төшерү кирәк. Дәлше. Улаклардан дүрт-биш карышка суны төшереп булмый. Шартлатырга кирәк. Монысы инде, белмим, суны күпмегә күтәрер?

– Значитца, тагын бер бәла безнең башка!

– Кайгырма, Ильяс! Һәрбер хәйләкәрлеккә үзенең җавабы бар. Шартлатсыннар да, ди. Без моны ишетәбез бит инде. Дулкын Танып бормалары буйлап монда хәтле ким дигәндә ярты сәгатьтә генә килеп җитә. Шул арада без теге якка чыгып, мәгарә аша үтеп өлгерәбез, минемчә. Шуңа бик күп нәрсәне теге якка алдан ук чыгарып куеп, анда сакларга кирәк.

Беразга тын калдылар. Шунда Ильяс ничәнче көн инде башын әйләндергән сорауны бирде:

– Ә нигә без баштан ук теге якта гына туктамадык әле?

Бу сорауның үзенә караганын Галләм яхшы аңлый иде.

– Нигә дип, ни... Ысматри-матри менә! Кем белгән акларның күп булырын? Без монда озакка килмибез дип уйлаган идек. Шуңа да Казанлыга кайтырга туры юлны өзәсе килмәгәндер. Дәлше. Ә алар безгә һөҗүм итәрләрме – монысы билгесез бит! Салих дивана түгел, монда һөҗүм итү һәрхәлдә уңышсыз булачагын белә. Дәлше. Теге якта бу хәтле халыкны урнаштырырга урын да юк бит? Анда урман-чытырман, ысматри-матри! Томафи картның аучылар өе дә бит бу якта, ә бу өйдә егермеләп кеше урнаша ала. Ә чишмә?

– Ярар, җитәр, Галләм ага. Ышандырдың, значитца. Алла бирсә, югалмабыз! – Ильяс сүзне икенчегә борды. – Син кайтып торасыңмы, әллә монда каласыңмы?

– Калам. Балыкка ау куелган, шуларны тикшерәм. Үрдәк карап йөреп киләм, бу тиклем мирны ашатырга да кирәк бит.

– Мин кайтып урыйм, алайса. Җылы кием алырга.

Әйе, көзгә борылып ятучы кояш, югары булса да, әллә ни җылытмый иде инде. Бары тик турыдан-туры төшкән нурлары гына инде суынып барган җәйге эссене саклый, аның кабат кайтачагын искә төшереп өметләндерә.

Ильяс атына атланды да Казанлыга табан юл тотты.

*(Ахыры киләсе санда).*



Лилия
Сәгыйдуллина

# БЕЗ – АДАШКАН АВТОБУСТА...

## Җир белән сөйләшү

Җир шарын учыма алам да
Тибрәтәм: тынычлан, тынычлан!..
Кешелек авыру. Күрәсең,
Ул хәтәр зәхмәткә юлыккан.

Тетрәнеп ала Җир... Ут яна...
Туфандай коела кан яше...
Җир булып Җир түзми! Ә без соң?..
Нишләде кешелек, нишләде?!

Җир йөзен кабилләр яулаган.
(Һабилнең нәселе калмаган.)
Әллә соң шуңамы җаннарны
Үч, нәфрәт ялкыны ялмаган?

Вәхшилек чорымы яңара?
Таш дәвер туйлыймы дөньяны?
Кешелек кай якка юл сала?
Буталды дөресе, ялганы...

...Туктаусыз ком юам, ком юам:
Табылыр хакыйкать алтыны!
Ком тавы – Һималай... Ә учта
Бер мыскал чын табыш ялтырый...

Каһәрле заманда яшибез –
Кемнәрнең кемнәргә каргышы?
Рәхимсез кешелек Җиргә дә,
Күккә дә кирәкми, ахрысы...

---

Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА (1956) – *шагыйрә, галимә, Уфа фән һәм технологияләр университеты доценты; «Абага чәчәге», «Мизгелләр йолдызлыгы» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

Бирешмә, Җир генәм-бер генәм!
Кылычлар кайтыр ул кынына...
...Кешелек сынауны үтәрме?
Без – сират күпере кылында.

***

Юк!..
Мин килмешәк түгел бу Җирдә.
Вакытлыча гына килсәм дә,
Кайтып китәсемне белсәм дә,
Туган җиргә никтер җан тарткан,
Туган җирдә Ходай яраткан.
Эчәр сулар, сулар һава да,
Яраларым белән дәва да
Туган җирне миңа үз иткән,
Туган җирдә миңа җан керткән.

Юк!..
Мин килмешәк түгел бу Җирдә.
Кирәклекне бик үк тоймасам да,
Мондый яшәешкә сыймасам да,
Антей белән мин дә – кан-кардәш,
Асман гына Җиргә – төп көндәш.
Чәчәкләнеп үлгән орлык та,
Җаннар тансыклаган тормыш та
Тамырларга мине беркеткән –
Туган җиргә мин дә җирләшкән.

## Канатлар

Канатларны еш яшереп йөртәм,
Аңламаслар диеп белсәләр,
Гади генә бер җир баласының
Канат кагынганын күрсәләр...

Канат очын кискән чак та була:
«Соң җитмиме сиңа җир?!» – диеп...
Тоташ «җирский» дә булалмадым.
Һәм күкләр дә һаман бик биек!

Аралыкта яшим: җир-terәксез
Җирсүләнә талган канатлар;
Әгәр алар кояш уятмаса,
Төн-карыныннан ничек таң атар?..

Очам әле, очыш күнекмәсен
Онытмасын диеп канатлар:
Җир өлешен җиргә кайтарыр да
Туган төягенә җан ашар.

## Азатлыкка барышлый

«Азатлыкка еракмы?» – дим.
«Утыр, – диләр. – Ерак, ерак.
Туры барсаң – кул сузымы!
Без барабыз урап-урап».

Ник сайланган бу урау юл?
Аңлыйм дим дә – булмый аңлап.
Юл кыскартам уйлар уйлап,
Чакрымнарга ният чорнап...

«Азатлыкка җитсәмме!..» – дип,
Йөз, мең төрле фараз кылам.
Һәм күз салам тәрәзәгә –
Дөм караңгы әле урам.

Автобусны йөртүчегә
Һич ышанып булмый кебек:
Азатлыкта тукталышны
Ул бит юри күрми кебек.

Менә тагын туктамады.
Һәм башланды яңа урам.
Без – адашкан автобуста.
Моннан чыгу кирәк, туган.

## Яулык

Яулык бәйләргә яратам.
Бәйлим элек-электән.
Урап та бәйлим, чөеп тә...
Мин яулыкка күнеккән.

Күз-кышларга – шәльяулыклар.
Җәйгә – ап-ак батисттан.
Француз яулык... Чын ефәкне
Алам тирән сандыктан.

Хәтер сандыгыннан барлыйм
Яулык бәйләү өлгесен.
Анамчамы?.. Заманчамы?..
Үземчәме?.. Кем белсен...

Эшләпә кигән чак булды...
Баш биргән чак башлыкка...
Иске башлык нык туйдыргач,
Кабат кайттык яулыкка.

Яу туктатканга – яулык ул!
Кем яулыкка ук атар?
Бик күп дәһшәтләрне, бәлки,
Ак яулыклар туктатыр?..

...Яулык бәйләргә яратам.
Бу гадәтем электән.
Төрлечә бәйлим – килешә:
Җан яулыкка күнеккән...

## Җәй: халәтләр

Җәй өлгергән:
менә-менә өзелеп төшәр
вакыт агачыннан.
Пешкән алма сыман...

Мин учымны куям:
һәр мизгелне җыям,
акса да ул бертуктаусыз
бармак арасыннан...

Җәйнең җиләк чагы.
Ә мин сагышланам.
Хушлашуны белеп –
ничәнчегә! – утсыз янам...

(Нинди гадәт соң бу –
җан өзгәләү алдан?!
Бәлки, көз дә,
хәтта кыш та –
тик фәлсәфи ялган?..)

Җәй өлгергән – әзерләнгән
бу мәйданны калдырырга –
җим булырга – хушлашырга...
..................................

Алмагачлар
алма коя, алма җуя:
балаларын җиргә җыя...
Ишелепләр алма ява.
Алма туа...

## Җыену

Кайтканыма күпме генә?.. –
Китәр көнем ишек кага.
Әйдәләмә! Өлгермәдем!
Күр: дагасыз атларым да...

Җигәсе бар уй-ниятне:
Чыгамын бит ерак юлга!..
Барлыйсы бар: ниләр кала,
Ниләр алам... ике кулга?

Озын юлга җыясы бар
Оя-оя кучмә кошны;
Кунак итеп озатасы
Тугры сердәш – карлыгачны...

Күңелдәге зур сандыкка
Сыйдырасы матурлыкны,
Җанга дәва булыр диеп,
Юксынганда чын чынлыкны.

Кояш нурын урыйсы бар
Түп-түгәрәк зур йомгакка;
Талчыкканда тәгәрәтеп
Юлланырмын нурлы чакка...

Җыясы бар – җыенасы,
Өметләр төйнәп төенгә:
Яз-җәй – кайта... Һәр ел кайта,
Киенеп яңа киемгә...

Киткәч, җирсү баш күтәрер.
(Тамыр җәяр кар астында!)
Вакыт, тукта! Аңласана
Әйтелмичә калганын да...

«Эш-мәшәкать!..» – дигән булып,
Каласылар (Эһ...) бик киләә!
...Ай елмая... Кояш көлә...
Ә Каз* юлга йолдыз сибә...
Алар, шиксез, нидер белә.
Нидер белә... Нидер күрә...

*Киек каз юлы – йолдызлык.

## Күз: прелюдия

Көз хакында ифрат күп язылган.
Үз хәлемчә, мин дә өстәдем...
Рубиконны кичәсемне уйлап,
Истәлеккә сүз-моң эзләдем.

Күңелемә җуелмас эз салдым,
Көзгә кайтуымны фаразлап.
Шул эз буйлап янә юлга чыгам,
Үзгә-таныш моңны кабатлап.

Бу моң әле бары гамма гына...
Һәрбер нота яши үзаллы.
Тиздән ноктюрнга әйләнәчәк –
Көзге эңгер җанны яулады...

Моңсу моңга табигать тә әсир:
Җәй белән көз елап очраша.
Шатлык яше? Сагыш? Бәлки, өмет
Өмет белән шулай хушлаша?..

Миндә дә бит шундый моңдаш яши.
Вакыт-вакыт тыңлыйм тын калып.
...Көзне туктатыгыз! Мин төшәм дә
Монда калам. Калам моң булып...

## Язгы күңел

*Мин бозларга ябышып китәр идем*
*Ташкын булып аккан суларда...*
Л.С.

...Юк, китмәдем. Монда калдым әле,
Бу яз килмәс кебек тоелса да.
Өмет очкыннарын давыл йота –
Күңел исә нәкъ тә бала-чага!..

Сабый күңел белән сабый үлән
Игезәкләр сыман бу язымда.
Киләчәкне уйлап, ут йоту да
Онытылып тора бераз гына.

«Китәм!..» – дисәм, әнә кошлар кайткан!
Яңа җырлар иңә! Ишет кенә!
Күңел күтәрелеп канатлана:
Ашар кебек хәтта гарешкә дә.

Язның һәр мизгеле – җан җәррахы[**]:
Җайлап кына чүпли ярчыкларны.
Җуелмастай җәрәхәтне җуя
Һәм дәвалый җаны талчыкканны.

Юк, китмәдем. Мин китәсе юллар
Көтәр димен, көтәр чак-чак кына...
Җанда лепелдәшкән күбәләкләр
Җир җиләкле җәйне бик сагына.

**P. S.**
Ә ташкынның быел коточкычы:
Шашкан ташкын ашый үз ярын да...
Тик гарасат күпме шашынмасын,
Йотылачак соңгы дәрьясында.

[**] Җәррах (гарәп теленнән кергән алынма сүз) – хирург.



Рәҗәп
Бәдретдинов

# ЮЛАУЧЫЛАР*

ХИКӘЯ

Кышкы карлы басу юлыннан җай гына юыртып баручы Ак бия кинәт кенә тартылып алды да, үзен-үзе юл читенә тотып аткандай, янга сикерде. Шулчак камыт бавы чишелеп китте, ат, тагын да дулап, дугасын бер якка авыштырып та куйды. Күз ачып йомганчы сыңар ягы тәртәдән шуып ычкынган дуга бераз өстерәлеп барды да, аннан аяк астына төшеп, кар бураны эчендә күмелеп юк та булды. Шул мизгелдә ыңгырчак бавы тартылып өзелде, зирек тәртә, кинәт бер ягына кисәк кенә авышып китеп, арбадагы ике юлаучыны уптымилаһи көпшәкләнеп торган кар өеме өстенә алып та атты. Шомырт агачын кайнар дегет сумаласында тотып ясалган калын төпле чана, дилбегәгә эләгеп, бераз яны белән карны сыдырып, эз салып барды да кар юрганы өстенә әйләнеп капланды. Чанадагы төенчекләр, иске толып, төймәләре төшкән бишмәт, кайры тун, кечерәк кенә агач тартмага салынган сохари-каты күмәч ише ризыклар, сабы хәйран гына шомарган, башын сүстән үргән камчы, ястык-түшәкләр – барысы да кайсы кая таралып очып төште. Салам-печән чүпләре, кар өемнәренә куна-куна, язгы көндә беренче тапкыр очарга чыккан күбәләкләр кебек, гүя кояш нурларына күзләре томаланып, кая бәрелергә урын тапмыйча, кинәнеп очтылар да очтылар. Чанадагы яфраклы урман печәненең вак кисәкләргә теткәләнгән чүпләре, иркенгә чыккандай, тирә-якка чайкалып, ак җирлектәге ымсындыргыч яктылыкта айкалып-айкалып уйнакларга керештеләр. Кар өемнәренә ышыкланып туктап калганнарын да кышның әрсез салкын җиле, артларыннан куып, кымырҗытып очырта-очырта, үзе артыннан мәҗбүриләп ияртеп алып китте.

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2023 елда уздырылган татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Хикәя» номинациясендә икенче урынны алган әсәр.

Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ (1971) – *язучы, филология фәннәре кандидаты. «Каһәрле еллар корбаны», «Төнге яктылык» исемле китаплар авторы. Балтач районында яши.*

Малкай кисәк тартылып алганда каплаган чанасын бераз өстерәп барды да кинәт шып итеп туктап калды. Шуннан ул, килешмәгән, җаны тартмаган эш эшләгәндәй, ачы итеп пошкырып җибәрде.

– Пфыхы-хы-хы-хыр-хы-х-ы-р-р, пфыхы-хы-хы-хыр-хы-х-ы-р-р...

Ат авызыннан бөркелгән ак пар паровоз төтене кебек ишелеп-ишелеп чыкты һәм тиз генә таралырга теләмичә, эзен юарга теләгән сусардай, әле анда, әле монда сузылып-сузылып, акрын гына кар күмәчләре арасыннан барды-барды да биеккә үрләгәннәренең йөзләренә барып сыланды. Тәненең кайнарлыгын басар өчен бахбай алгы аяклары белән кар түшәге астыннан нидер эзләгәндәй, тырнарга, казырга, актарырга тотынды. Аягы каты җиргә тигәнче казыды ул баскан җирендәге карны. Бертуктамый казыды да казыды. Аягы туңга тиеп, җирнең ныклыгын тойгач кына, туктады. Ышанды, кар катламы астында җирнең бар икәнен тойды булса кирәк. Шуннан соң да әле ат дагасының ток-ток килеп җирне актарганда чыккан шомлы тавышы колак төбендә яңгырап ишетелеп торды. Өстенә япкан «кар сырмасын» салып атып таптанасы, карга ятып, җанын-тәнен басарлык итеп бер ауныйсы килүдәнме, берара бөтен гәүдәсе белән калтыранып тартышып куйды. Аннан, башын берничә мәртәбә күтәрә-төшерә, янәдән пошкырып алды да, үзенекеләрен эзләгәндәй, артына борылып, кар өстендә әрле-бирле чүмәкләшеп яткан хуҗаларына карап тора башлады.

– Иманыңны келим, шаштың мәллә? – дип, Муллахан агай атына сукрана-сукрана, аягына торып басып, Ак биясенә йодрыгын төйнәп җикеренергә тотынды. – Күзеңә фиргавен карачкысы күрендеме әллә, саташкан, сыртыңны каезлыйсы нәрсә?.. Чана астында калдырып катырып үтерергә дә күп сорамассың син болай булсаң, – дип, башта хәйран гына кызып, аннан әллә ни ярсымыйча гына, үзалдына сөйләнгәндәй итте ул. Бераздан тынычлыгы кайта башлаган карт: «Хәерсез юлга чыктык бугай ла без. Күңелем нидер сизенә, хәерсез юл булды бугай бу», – дип, янәшәдә чүлмәк кебек чүмәшеп, кар өеме өстендә тәгәрәп яткан карчыгына кулын сузып, берникадәр вакыт аңа торырга булышты.

– Нәрсә җәелдең? Бозлы карны ыштан төбеңә шулкадәр тутырмасаң? – дип, гомер иткән карчыгының кыска плүш пәлтәсен, артларын кардан каккалап, бер гөнаһсыз Нәгыймәттәйгә сукранып алды. Атына каты бәрелмәсә дә, Нәгыймәттәйгә каты ук эләгә иде мондый вакытларда. Шулай буласын белә карчыгы, аты дулаганда, гел хатынын әрләгән иренең холкын үтәли күрә. Шуңа да бер авыз сүз дәшмичә, ат чанасыннан төшеп калган әйберләрен җыярга кереште. Муллахан агай исә атын тугарып, яңадан җикте: бушап беткән ыңгырчак бавын ныгытты, камыт бавын яңага алыштырып тарттырып бәйләде, дуганы тәртәгә киертте. Шулай иткәч, тәртәләр дә үрә катып торып басты. Агай, карчыгына ымлап:

– Сиңа әйтәм, ярый әле тәртәләр нык, тәртәләрне сындырмады дим. Ярты юлда кала идек, карлы басу ышыгында, бер чыра да тапмыйча, әҗәлне көтеп утырыр идек менә. Тәртә шәп булу кирәк шул тормыш иткәндә дә, тәртәң нык булу кирәк. Сыңар тәртә белән бернишләп булмый. Тәртәне аны, ыслушай, зиректән ясамасаң, урталай сынарга да күп сорамый. Тик тормыш зирек тәртәләрне дә шартлатып сындыра шул кайчак, кисәк сындыра... Ә тәртә сыну машинаның кәрәчине бетү белән бер ул сиңа. «Беттем» дигән сүз ул, кыр уртасында әче суыкта катып.

Карчыгы гына кара коелып, иске сырлы толып эченәрәк яшеренеп, сыңар кулы белән инде шактый таушалган мамык шәлен бераз баш өстенәрәк тартып, сүзсез генә баруын дәвам итте. Бераздан карт тагын карчыгына сүз катты:

– Йә, ник дәшмисең, ул-бу булмагандыр бит?

– Сыңар бияләемне таба алмадым менә. Кар астыннан күпме актарсам да, чыкмады, – дип, Нәгыймәттәй кесәсенә тыккан сыңар кулын суыктан яшереп һәм еш-еш сулап, сузыбрак сөйләргә кереште. – Үземнең кулымнан Коръән китабын барыбер ычкындырмадым анысы. Менә очып барып төшсәк тә, кулым белән аңа ябышып саклап калдым, Аллаһы Тәгалә дә безне саклар әле, боерган булса, – дип тынычлангандай итте.

Нәгыймәттәй кая гына барса да, әтисеннән калган чиккән ашъяулыкка төреп, ефәк бау белән бәйләп, киндер капчыкка салган Коръән китабын үзеннән бервакытта да калдырмый иде. Тик менә карчыгының тын алулары авырлашуын сизсә дә, карты ул турыда сорарга батырчылык итмәде. Бары:

– Йә инде, бетеренмә шулкадәр, карчык, җилләнеп кенә мендек бит, сиңа әйтим. Бияләй югалу – пүчтәк ул. Башың исән булсын. Кышкы юлны тигезләп мендек менә бераз. Беләсеңме, җирнең тарту көче бар бит аның. Җир ул магнит кебек, без үлгәч тә үзенә суырып ала. Берәүне дә үзеннән ерак җибәрми. Әнә шуңа җирдән ерак китмәдек тә инде. Ак бия дә, әнә, ныклыгы булмаган көпшәк кардан баруны үз итмичә, җирне казып табып, аяк астындагы катыга орынып, кая басканына тәмам ышангач кына, борчылуыннан-шөбһәләнүеннән туктады, – диде агай, карчыгына даһиларча карашын ташлап. – Атка сүз әйтмим мин, зерәгә алай эшләми ул малкай. Хәерсез юлга чыктык дип әйттемме мин сиңа? Әйттем. Әнә Ак бия дә тикмәгә генә тәртәгә типмәде. Ай-һай, хайваннарга биргән сиземләүне адәм балаларына дә бирсәң икән?! Ник дәшмисең, имгәнгән җирең юктыр бит? – дип, карчыгына бөтен гәүдәсе белән каерылып карады агай.

– Ниткән хәерсез булсын, ди, әллә ниләр уйлап чыгарасың кайчак. Каян башларыңа килә җыен тузга язмаган хорафатлар? – дип, җай гына сузды Нәгыймәттәй, һәрвакыттагыча үзенең ныклыгын күрсәтеп. Сулышы аз гына көйләнә башласа да, башы үтереп шаулавын иренә белгертмичә. – Кайчакта күргән төшләреңне дә өндә раслатып баш катырасың.

– Иҗекләмә, – дип, коры гына үзенең ризасызлыгын белдерде карт. Ул гел шулай, карчыгы берәр нәрсә әйтә башласа яки аның белән җене килешмәсә, «Иҗекләмә!» дип, авызын йома да куя. Сүзен сүз итүеме ул аның, әллә мыскыл итүеме – ничек кенә булса да, Нәгыймәттәй һич кенә дә үпкәләми картына. Димәк, шулай кирәк. Шуңа да авылдашлары Муллахан агайны, якын итеп, «Иҗекләмә!» дип йөртәләр дә инде. Моны үзе дә белгән Муллахан агай да үпкәләми, шулай әйткәннәренә исе китми. Кайтарып, ник алай әйтәсез дип сораганы да, бу сүзне әйтүдән аларны туктатканы-тыйганы да булмады. Начар сүз түгел бит! Теләгәч әйтә бирсеннәр. Бу тормышта аннан күпкә начарраклары да җитәрлек әле...

Юлаучылар берара сүзсез бардылар. Ак бия дә, «миңа барыбер барасы инде, ни эшләтсәгез дә, күнәм» дигәндәй, адымнарын кызулатты, бераздан салмак кына юырта да башлады. Аннан тагын акрынайды, тагын кызуланды. Ашкынулы карашын акка төренгән басу-кырларга бага-бага атлады да

атлады бахбай. Карлы юлның барлык урыннары да бертөсле булмыйча, ара-тирә шактый ук кар салган җирләре дә очрый иде юлаучыларга. Андый кар тозагыннан кисәк алдырып китеп, тиз генә үтеп чыгарга күнекте малкай. Кайбер вакытларда чана кырыйларына кадәр үрмәләгән кар дулкыннарына каршы торырлык бүтән чик тә, чама да, алым да юк иде бугай.

Нәгыймәттәй йокымсырап киттеме, тирән уйларга биреледеме – берара сүзсез бардылар. Тик кайвакыт ул да, кышкы тынлыкны бозып, тамак төбе белән йөткергәләп ала башлады. Монысын инде Муллахан агай һич кенә дә кабул итмәде. Авырып кына китмәсә ярар иде дип борчылды. Үзләренең дә матур киләчәк өчен тырышып йөрүләре бит. Әле дә әнә шул изге юлда. Пайтәхетнең бер кешесе аркылы белешеп, әтисен кулга алганнан соң, эзе-юлы бетеп, әнисе үлеп, тома ялгыз калган нарасый баланы үзләренә уллыкка алырга барулары аларның. Шуның өчен ара ераклыгы да, кышкы озын юл да аларга киртә була алмады. Аллаһы Тәгалә кушса, малайлы да булып куярлар әле. Көенеп-сөенеп, тулы тормыш корып яшәүләргә җитәме соң инде!..

– Карале, сиңайтәм, ул баланың әти-әниләре кемнәр икән, белешмәдеңме? – дип сорарга булды Нәгыймәттәй, инде меңенче кат иренә шушы сорауны биреп.

– Соң, кичә генә ул турыда өйдә сөйләштек бит, – дип, теләр-теләмәс кенә җавап бирде агай. Исенә төшкән саен, ул шуны сорый. Авырып кына китә күрмәсен тагын. Белгән кадәресен Нәгыймәттәйгә дә гел әйтеп бара. – Атасы бик укымышлы, гыйлем кеше иде диде бераз туганрак тиешле авылдашы Габсаттар абзый. Ә әнисе абыстай, мөгаллимә булган. Атасын кулга алганда, кочак-кочак китапларын, кәгазь-каләмнәрен, язу-сызуларын да җыештырып алып чыгып киттеләр, ди. Абыстай: «Тимәгез, аның бер гаебе дә юк, – дип, кулларына барып асылынган икән, тибеп кенә очырганнар үзен зобанилар. – Җибәрегез, ул контр түгел, аның сәүит властена каршы кеше котыртып йөрерлек түгел, минем белән утырып сөйләшерлек тә вакыты юк. Ул – язучы. Ул – мөгаллим. Ул – дин кешесе. Ул андый түгел. Аны алып китмәгез. Анда нишләр ул?» – дип илереп-илереп елаган диләр. Авылдашларының ник берсе, арага кереп, туктагыз әле, җәмәгать, алай түгел, болай ул димәгән. Тоташтан ашамый-эчми йөри торгач, ябыгып, урын өстенә ауган да бер-ике көннән җан-тәслим кылган абыстай. Әнә шуларның улы – мәхдүм япа-ялгыз калган. Авыл кешесе, ихлас булса да, бик астыртын була бит ул. Кайчак капка ярыгыннан карап кына, вакыйгалар агышына бәя бирергә ярата. Анда да – көчленеке замана. Тышкы яктан гына суфи булып кыланалар. Авыл тормышының эченәрәк кергән саен аның үзенең язылмаган законнары өстенлек итүен бик тиз күрәсең. Бот буе баланы авылдашлары үзләренә сыендырмаганнар бит менә. Аны башта, өйдән-өйгә йөртеп, чират белән караганнар икән, аннан ятим ни, түгел ни, берсенең-бер исе китмәгән, берсе дә үз канаты астына сыендырмаган бугай. Атасы да, анасы да муллалар, абруйлы кешеләр нәселеннән бит әле. Җитмәсә, малайның күңелендәге җәрәхәте дә көннән-көн тирәнәйгәннән-тирәнәя барган, ди. Көн дә: «Әти артыннан барам», – дип, өйләреннән чыгып китеп югала икән бу бала. Кайсы көнне көчкә табып алалар икән дә, бикле өйгә ябып куеп, көннәр буе чыгармыйча асрыйлар икән мескенне. Кыскасы,

бөтен авыллары белән дә карап бетерә алмаганнар бу малайны. Тора-бара исләре дә китми башлаган. Авылдашларының үзләренә дә бер кайгы янына икенчеләре өстәлеп, бичарага игътибар бөтенләй калмаган. Дөрестән дә, үз балаларын да ачлы-туклы асраган авыл халкының читләргә исе китәме соң инде? Ачның уе – икмәктә, тукның уе – хикмәттә дип белми әйтмәгәннәр шул борынгылар. Исең дә китмәслек түгел. Заёмы, налогы дисеңме. Көн туган саен югалган тынычлыгын әймим дә инде. Көн дә ут йотып яшәү генә җитмәгән, авылны ду китереп, дошман эзләү башланган. Кем дус та кем дошман? Иртә белән дус, кичкә дошманга әйләнгәннәр күпме булган. Кемнәр кемнәрне генә әләкләп сөргеннәргә сөрдермәгән. Кемнәр кемнәрнең кулы белән генә утлы күмер тотмаган. Шуннан, алып китегез сез ул малайны дип, безгә хәбәр иттеләр, – дип, Муллахан агай тагын бер гади дә, гадәти дә булмаган ачы гыйбрәтле язмышка дучар булган авыл укымышлыларының аянычлы тормышын бәян итте.

Менә шуннан Муллахан агай белән Нәгыймәттәй бергәләп утырып фикерләштеләр дә, кышкы юл мәшәкатьле булыр дип тормыйча, юлга кузгалдылар. «Алабыз булгач алабыз. Калганын юлда сөйләшеп бетерербез әле», – диделәр. Инде шактый олыгая барсалар да, күңелләре якты, ихлас шул аларның. Нәселләре дә мәгърифәтчеләргә барып тоташа. Авыл укымышлылары Түнтәриләр, Ишми ишан оныкларының дәвамчылары бит алар. Шуңа исемен дә ерак бабайларының ядкаре итеп Муллахан дип кушканнар. Тик менә куштаннар төзегән власть кына нәсел-нәсәпне тар-мар итеп ташлады шул. Берара Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовның исемен телгә алырга да ярамады. Әле дә тыюлар җитәрлек. Шул карагруһчылар төзегән нигез төпле була аламы инде, йә?

– Атасы дим, карале, исеме ничек дидең әле улыбызның? – диде Нәгыймәттәй, отыры кызыксынуын баса алмыйча. – Матур исемле булмаса, яңаны үзебез кушарбыз дим.

– Юк сүз сөйләмәче, – дип бүлдерде аны карты. – Кешегә исем бер генә тапкыр кушыла. Маэмай дип белдеңме әллә син аны? Исеме дә юклы-барлы түгелдер әле. Укымышлылардан туган бала бит ул. Хәтере дә яхшы, бик хәрәкәтчән дә дигән иде Габсаттар агай.

– Алайса, бик хәрәкәтчән диген.

– Иҗекләмә, баланың хәсрәте зур булган бит, – диде Муллахан агай, карчыгының башы юка булуына уфтанып. – Әле бармаган, күрмәгән. Тумаган колынның билен сындырмакчы буласың бик тиз генә...

* * *

Якын иткән аты Ак биягә дә кайчак «иҗекләмә» дип ычкындыргалый иде карты. Әллә белеп, әллә белми, авыз уңаена гына әйтә идеме ул аны? Тик бер вакыйгадан соң Ак биягә телен гел кымырҗытып торган бу сүзне бөтенләй әйтмәс булды ул. Әйтәсе килгәндә дә, шап итеп туктап калып, авызын яба белде. Картая-картая олпатлыгы чәчәк аттымы, чигәсендәге чәчләре чалара башлагач, төпле акылы кире кайттымы, ничек кенә булса да, бу сүзне Ак биягә әйтүдән туктады агай беркөнне.

Җәйнең матур көннәре иде. Туйганчы тамакка ашауны белми торган вакытлар. Муллахан агайның Шәмәрдән элеваторына Ак биясе белән

икмәккә барган чагы. Авылдашларына да, үзләренә дә булыр дип, шулай илле чакрымны узып булса да, җае туры килгәндә, Шәмәрдән элеваторына айга бер сугылып кайткалый иде ул. Дөрес, икмәк күп эләкми дә эләгүен. Юнәлткән биш-алты кирпеч ипи өчен дә түбәсе күккә тиеп, күңеле булып, ихласлыгы артып кайтыр иде Муллахан агайның. Кайсы көннәрне буш кул белән кайтыр иде дә атын шундый ерак юлга алып чыгып киткәне өчен үзен үзе атналар буе битәрләр иде. Менә шул «тамак кирәге» артыннан йөргәндә, Ак бия һәм аның колынчыгы белән булган аянычлы хәлне ул мәңге исеннән чыгармас, башка бервакытта да атына теге сүзне әйтеп иҗекләмәс булды...

* * *

Муллахан агай бу юлы тамак хакын хаклап бару юлында Ак биянең колынын да үзләре белән ияртергә булды. Вакытында анасын имәр, тамагы туяр дип уйлады ул, ике айлык колынчыгы турында кайгыртып. Абзарда көне буе анасының кайтканын нәүмизләнеп көтеп ач ятканчы, җайлап йөреп кайтыр, тамагы ач булмас, иң мөһиме – бергә булырлар.

Урман эченнән генә салынган юл чакрымнарны киметкәнгә, агай да шуннан гына юыртырга булды. Хәер, отыры очраган тирән-тирән сазлыклы урыннарны уйламаганда, урман юлы ярыйсы гына кебек иде. Барып җитеп, көчкә буш урын табып, читтәге капкаларның берсенә атын бәйләп, үз бәндәләрен шулай кайгырткан ил-дәүләткә рәхмәтләрен укый-укый, ипи чиратына барып басты.

Борынны кытыклап, ашыйсын китереп торган ипи исенә беркем дә каршы тора алмыйдыр ул. Агай да нәкъ шулай уйлады. Тирән итеп күкрәген киереп, бөтен күзәнәкләренә кадәр үткәреп, ипи исе килеп торган һаваны берьюлы үпкәсенә тыгызлап тутырды. Андый ымсындыргыч, үзенә чакырып, тартып торучы бүтән бер генә дә ис юктыр ла ул дөнья йөзендә. Исләр бар ул, ләкин алар гайрәтне чигереп, үзләреннән читләштерә торган була шул. Башка төрле ис белән бутап та, чагыштырып та, алыштырып та булмый ул икмәк исен. Менә бирегә дә шул ипинең бернигә дә алыштырып булмый торган могҗизаларга тиң өстенлеге, изгелеге тартып китергән дә инде халыкны. Тамак хакын хаклау өчен җыелганнар бит бирегә. Ризык хакы бәндә хакыннан соң өченче урында тора диләр бит. Беренчесе аның – Аллаһ хакы. Шулай... Аннан узды юк. Тик мондагы хәлләрне күреп, исең-акылың китәрлек. Шәмәрдәннең «Зинаһар тишеге» дип аталган лавкасы каршында сузылган чиратның озынлыгын әйтеп-аңлатып бетерерлек кенә түгел иде. Икмәген алганнар да, чиратның ахырына яңадан басып, ипи җыялар булыр. Шуңа халык ыгы-зыгы килеп кайнаша, әрле-бирле килә, авыз әйткәнен колагы ишетми, кырмыска оясыдай кайный, гөж килә. Татары да, русы да, чувашы да, мукшысы да, керәшене дә, башкасы да шул бер тишеккә – «Зинаһар тишеге»нә якынлашкан саен, «зинаһар, зинаһар, Аннаттә, Аннаттә» дигән тавышлар тагын да якынрак булып җанга елышыр, әллә ни вакыт һавада эленеп торыр иде. Төрле милләттән, төрле уй-фикерле, төрле хезмәттә булсалар да, тамак кайгысы барысында да берүк, бертөрле иде. Ил-дәүләтнең үз халкын шулай «кайгыртуына» да җен ачуы чыгар иде Муллахан агайның. Мондый хәлгә төшүләренә дә, һәрчак башкаларны төртеп күрсәткән илдә яшәүдән яшәмәвең артык дип,

үз-үзенә келәймәләп фикерен беркеткән иде инде агай. Тик ни хәл итәсең? Акыллы башларны чүпләп кенә торалар шул. Аларга куштаннар, әләкчеләр, нәзберекләр, тагын әллә кемнәр кирәк, тик гадел, тырыш, укымышлы, горур халык кына кирәкми. Димәк, бу илдә әнә шундыйлар нигезенә төзелгәнгә, беркайчан да гаделлек эзләп баш катырасы, бәргәләнәсе юк. Барыбер таба алмыйсың. Әнә эзләп-эзләп караганнарның да гомерләре сары йортларда, махсус отрядларда, сазлыклы утрауларда очланды. Укыганнар да, тырыш-намуслылар да юк аның нигезендә. Тырышлык коймаңның бу ягында гына кирәк икән, ә теге ягында шома телең кирәк. Гаделлекнең урыны да мәктәп-мәдрәсәләрдә генә калды шул инде. Шулай булгач, гаделлекне кемнән генә көтәсең бу илдә? Менә безнең халык та бит элек-электән үк гайрәтле булган. Батырша дигән әзмәверләре генә ни торган. Андыйлардан куркып, тиз арада аларны юк итә башлаганнар да инде. Башлыракларны, укымышлыларны җыеп, төрмәләргә ябып, сөргеннәргә сөреп, юкка чыгарып бетерә торганнар. Җыймаслар иде, алар бит башкаларга дөресен аңлата, дөресен сөйли, дөресен эшли. Менә шунысы гына җаннарны телгәли. Кайчак артык бер кәлимә-сүз өчен дә алып китеп баралар. Киткәннәре бөтенләйгә шунда кала. Каберләрен белсәләр дә, ярар иде. Аларны да отыры оныта баралар шул. Әнә Габдрахманнан булган Афзал Таһировны да алып китеп атып үтергәннәр, ди. Үзе зур кеше булса да, янәшәсендәге сатлыклар аркасында гомере киселгән татар зыялысының. Башкортка җибәреп, дәүләт эшләрендә эшләтсәләр дә, аларның үз язучылар оешмасын төзеп бирсә дә, уку-укыту буенча хуҗа булса да, ак йортларына җитәкчелек итсә дә, барыбер ярамаган. Магаданы, Колымасы – берсе дә калмаган татарсыз. Биредәге ипи лавкасы янында ач халыкның иманын гына түгел, илен да сатарга әзерлиләр әнә. Ник шуны белмиләр микәнни? Ач халык сиңа биргәннең табанын яларга әзер ул. Әллә махсус эшлиләр, әллә эшләтәләр, белмәссең...

Лавка сатучысы керәшен татары булганга, «Зинаһар тишегенә» килеп төртелгәч, кайберәүләр муеннарына таккан «каз тәпиләрен» алып үбә башлый, моның белән Аллаһкамы, Анна тәтәгәме тагын да якынлыкларын күрсәтә. Шуңадырмы, Аннаттәй дә андыйларга күңеле киң колач алып, юмартланып китепме, үз кешеләр – карендәшләрем дипме, аларга мулрак өлеш чыгарып куя. Берара Муллахан агай да бу алымга кызыккан иде, тик кечкенә вакытта әнисенең «Иманыңны сатма берүк, иманыңны бер алыштырсаң, мәңге тәмугта янарсың» дигәнен исенә төшереп, бу уеннан кире кайтты. Биредә танышларын очратмаса да, шактый вакыт бу языклы уе башына килгәнгә, үз-үзеннән оялып, уңайсызланып та йөрде әле. Очраклы вакыт чыккан саен динеңне үзгәртә башласаң? Аллаһ сакласын, шәһадәт-кәлимәсен башкага алыштырамы соң? Шуннан ул Аннаттәй каршына һәрчак бисмилласын әйтеп, башына кәләпүшен киеп, белгәннәрен укып бара торган булды. Тик кайвакытта, зинһарлап үтенсә дә, файдасыз икәнен белеп, йөрәкләре теткәләнде. Тамак тәмугка кертә диюләре хак икән дип, гел иманын ныгытты: уразасын тотты, намазларын калдырмады.

Бу юлы да Муллахан агай, «Зинаһар тишеге»нә якынлашкач, үзе дә сизмәстән: «Зинһар, миңа гына җиткерегез, бер кирпеч ипи булса да бирегез инде, ерактан килдем, бик ерактан. Минем кайтуны бөтен авыл

көтә, мөселманнар көтә, зинһарлап сорыйм», – дип, Аннаттәйгә ялынса да, керәшен карчыгының сыңар кылы да селкенмәде. Муллаханның чираты җитүгә, кәләпүшле авыл агаена күз кырыен гына ташлап, «Зинаһар тишеген»ә өстән такта төшереп, каплап та куйды. Гаиләң көтәме, авыру карчыгың көтәме, авылың белән көтәләрме, барлык мөселманнар көтәме, ил көтәме – барысын да бер мизгелдә шушы карчык хәл итте дә куйды. «Райком закрыт», янәсе...

Әле монысы баласы, алда булган анасы. Кәефсез генә кайтыр юлга чыкты Муллахан абзый. Килгән юлдан арурак булыр дип, бахбайны артык куаламыйча гына, урман эчендәге сукмактан теркелдәтте ул. Ак бия дә каршы килеп маташмады, белгән юлыннан атлады да атлады. Шуңа да дилбегәне арбаның бер кырыена буш кына бәйләп куеп, табигатьне күзәтеп барырга булды агай. Көзгегә карасаң, үзеңне күрәсең дигәндәй, замана чиренең шәүләсен табигатьтә дә шактый аермачык күрергә була икән бит! Башта күзе агачтан-агачка сикереп уйнаклап чапкан гамьсез тиеннәргә төште. Аңа исе китеп, бирелеп карап торды ул. Тиеннәрнең әрле-бирле йөргән мәгънәсез хәрәкәтен күзәтеп, үз фикере булмаган, башкалардан эләктергән фикерен шунда ук икенче фикере белән туктаусыз алыштырып торучы, тотрыксыз характерлы кешеләр белән чагыштырды. Бу күренешне икенчесе алыштырды. Анысы да озакка бармады, чираттагысы пәйда булды. Шулай итеп, һәрбер күренештән дә мәгънә эзләп табып, фикерен калынайтып барды авыл агае. Алдарак кына, җеп сузып турылаган шикелле тезелеп, юлны аркылы кисеп чыгып баручы кабан дуңгызларын күреп шаккатты. Башта ана кабанның, аннан балаларының, ахырдан ата кабанның бер-бер артлы тезелешеп баруларын күреп гаҗәпләнде. Менә сез аңлатыгыз: аларның балаларын аналары артына кечкенәдән зурга таба кем шулай итеп тезеп бастырган? Ата кабан ник арттан бара? Шабыр-шабыр атлап, кабаннар да күздән югалды. Бераз баргач, Муллахан агай атын туктатып, ял иттереп алды. Колынчык та, тәртә арасыннан гына башын тыгып, анасын имеп кинәнде. Кайтыр юлның яртысыннан артыгын узгач, Ак биянең назлы кызы бөдрә койрык башын катырып, өскә сузылып тартылды да анасына – Ак биягә борылып карады, шуннан кинәт сөрлегеп китеп, гөрселдәп җиргә ауды. Колынчыгы егылган җиргә Ак бия Муллахан агайдан да алдарак барып басты. Ике генә сикерде бугай бичара. Аналарның бу халәтен бер генә язучының да, шагыйрьнең дә язып, бәян итеп биргәне юк әле. Бу – ана кешенең баласын саклау инстинкты гына түгел, бу шушы мизгелдә секундлы яшәп алу, нидер башкару, эчке халәтнең тышка атылып чыгуы, анадан тугандагыча үзең булып калуның бер гайре табигый торышы иде. Ак бия кисәк сикергәндә, арба аумаса да, җайсыз килеп кереп, черегән төп өстенә менде дә яртылаш авышып калды. Муллахан агай, арбасыннан шуып төшеп, колынчыкның башын куенына алып, җылы сулышын өрсә дә, күзләрен пыялаландырып, колынчык җан бирде. Муллахан агай тәүге мәртәбә шунда үкседе. Савылып-савылып елады ул. Ни булды колынчыкка? Нәрсә ярамады? Беркем берни белмәде. Колынчык өчен үзен гаепле сизеп, кая бәрелергә урын тапмыйча, шактый буталып йөрде агай урманда. Шуннан, колынчыкның җансыз гәүдәсен күтәреп, арбага салып, атын куа-куа, авылына ашыкты. Өзлексез кешнәгән ат тавышын басарга

теләп, абзый Ак бияне куалады да куалады. Атны алдыйм, димә икән син. Ярсыган ат бертуктамый чапты да чапты. Өйгә кайткач та, тынычлыгы булмады Ак биянең. Ашавының да, эчүенең дә рәте китте. Ә беркөнне ат, йөгәнен салып атып, үзе кадәр биеклектәге утардан сикереп чыгып, урман ягына чапты. Пошкыра-пошкыра, урман эченә кереп киткәнен күреп калганнар үзе. Муллахан агай, артыннан чапса да, җитә дә, тота да алмады ярсыган атны. Кич җиткәч кенә, башын аска иеп, моңсуланып кайтып керде тагын үзе. Иртәгесен тагын юк булды бахбай. Муллахан агай урманга, колыны җан биргән җиргә китте. Шунда ул Ак биянең колынын җуйган урында җиргә ятып аунаганын, алгы аякларын югары күтәреп, ачы тавыш белән ачыргаланып кычкырганын һәм аның зур кара күзләрендәге яшь тамчыларының агып төшүен, яңаклары юешләнеп бетүен, аннан исәр кеше кебек күзен-башын акайтып, кире чабып кайтып китүен үз күзләре белән күреп, йөрәгендәге ачы ярасын ярсытты. Шуннан бераз күңеле катып та калды. Баласын җуйган Ак бия көн дә урманга чыгып чабып, колынчыгын эзләде. Адәм балалары кайчак, үз-үзләре белән горурланып, үз бөеклекләренә масаеп, тәкәбберләнеп, җир өсләрендә туфрак буласы урынга, патша булырга ярата. Андыйларга ат күзләрендәге яшьләрне генә күрсәт икән. Әнә шушы күренеш: атларның бәгырьләргә үтеп керерлек итеп бәргәләнүләре, кайгыларын каезлана-каезлана кичерүләре бүтән бер җан иясендә дә юктыр. Атлар сагышы адәми затларның борчулары, өзгәләнүләре янында да чүп кенә булып кала икән шул. Ак бия озак вакытлардан соң гына бераз тынычлана алды. Әле дә кисәк томырылып алып китә торган гадәте калды. Бу баласын югалткан аналарда була торган табигый халәт иде.

* * *

Юлаучылар карлы басудан бардылар да бардылар. Очы-кырые күренмәгән аклык диңгезенең кай ягына борылып карасаң да, карашларың белән тоташ карга барып төртеләсең. Уңда да – кар, сулда да – кар.

Башы-ахыры булмаган бу юлга соң чыктылар шул алар. Карлы юлны туктаусыз ерып барып, кичкә дә калдылар, ахрысы. Барасы юл күрше авыл гына да түгел шул. Басу юлыннан да сиксән чакрымнарга җыеладыр әле. Аны кем үлчәгән дә кем чакрымнарын исәпләгән?! Яшь чакта атка атланып чапканда, Пайтәхеткә шундук барып җитеп, әйләнеп кайтып та җитәр иде Муллахан. Хәзер картайды шул. Юллары да адәм рәтле түгел. Кыш көннәрендә караңгы тиз төшә. Уйлаганча тиз генә барып җитәм димә. Әле ярый иптәшкә карчыгы, парлы тәртәләр күк, үзеннән бер адым да калмый ияреп йөри, «иҗекләр» идең аннары юл буе. Вәт гомерләр диген?! Югыйсә әйтте бит карчыгы: «Кичектереп торыйк мәллә, янмый бит», – диде. Үзе бит, үзе. Аңа да: «Иҗекләмә», – дип кырт кына кисте. Шулай булгач, карның күзләрне камаштырырлык аклыгына хозурланып, атыңны камчыла да камчыла инде. Актан башка берни күренми торган нинди очсыз-кырыйсыз басу юлы булды соң бу? Ни башы юк, ни ахыры күренми. Мондый тоташ аклыкны кышын гына күреп була шул. Әнә җәен тузан-туфрак, чебен-черки, кигәвеннәр бимазалаган вакытларны уйла да шым бул. Никадәр чисталык, пакьлек диген син кышын. Кайчак күзләрне томалый торган аклык та кара караңгылыкка алышына да куя. Ни хәл

итәсең? Яктылыкны да караңгылык алыштыра. Әнә шулай караңгылык белән яктылык чиратлашып, берсен-берсе алыштырып торган җиһанда да кеше дигән зат караңгылык вакытында да яктылык эзләп тырмашкан була. Аннан гына тормый бит ул лабаса. Күкләрдә язылганны үзгәртергә тотынып карый да хәле бетеп артына егыла. Һәрнәрсәнең үз вакыты, үз җае барлыгын гына кабул итеп бетерә алмый изалананалар.

* * *

Үзләре бит, үзләре. Юлга вакытында кузгалмадылар. Бала имезәселәре бар идеме? Ачуым килмәгәе. Күпме гомер итеп, балалары булмауга моңарчы алай күрсенгәннәре дә юк иде бит әле. Бүген, әнә, иртән торуга ук баласыз яшәүнең кызыгы да, гаме дә юк дип, балавыз да сыгып алды карчыгы. Нәрсәне исенә төшергәндер? Барылды бит әле моңарчы да, туктап тормады. Тормыш дигәнең мулдан кыланмаса да, җай гына бара иде бит әле баласыз да. Әллә нәрсә шунда сузылды бит бүген карчыгы, тиз генә оеша алмады. Әзерлән дә чыгып кит идең. Кышын өйлә үттеме, кар өстенә әлҗе-мөлҗе булып караңгылык тиз төшә башлый ул. Аннан чаларган чәчен чем-карага буяткан Сара Саниясенең башы шикелле, иң әүвәл, яктылыкны томалап, караңгылык алдан күзгә ташлана. Бераздан дөм караңгылык иңүен көт тә тор. Караңгы төшкәнче ничек тә барып җитәсе иде дә бит.

– А-а-бау, нәрсә бу? Кара әле, каршыга нәрсә килә ул? – диде ашыгып Нәгыймәттәй, кисәк толып эченнән шуып чыгып, аягына чүгәләп, каршыга таба озак кына карап барганнан соң. Аннан, кулын алга сузып, баш бармагы белән йон бияләенең эчендә генә каршыдагы кара төрткегә төртеп күрсәтеп. – Йә эт инде бу, йә бүре, – дип, үзалдына гына нәтиҗә дә ясап куйды. – Чү! Чынлап та, ни булыр бу? Басу юлыннан боларга таба нидер килә түгелме? Этме-бүреме? Каһәрең төшкере. Бүре бит, бүре. Аермачык күреп тә булмый, карның аклыгы күзләрне камаштыра. Нәкъ боларга таба килә. – Әйттем бит, хәерсез юл булды бу, хәерсез юл, – дип, карга кебек һаман бер сүзне тәкрарлады карты. – Хәерле булса, күптән барып җиткән булыр идек инде. Ни башы, ни ахыры булмады бу юлның. Кайчанга кадәр барабыздыр? Могҗизаларга тиң көн булды, билләһи газыйм.

– Бүре булса, зур булыр иде ул. Эттер ул, әтисе, эткә рәвешле.

– Этләр алар япан кырда болай ялгызы гына йөрмәс. Бүре түгелме икән?

– Бүре дә, эт тә түгел бу. Козгын бугай ла ул. Әнә селкенер-селкенмәс кенә кыймылдый бит. Көлтә койрык төлке-мазармы?

– Мөгаен, шулайдыр. Тукта, ялгыз мосафир түгелме икән? Кешегә дә охшаган. Атлап килә димме? Юлаучы бит...

– Берәр качкынмы, юлбасармы? Дөньялары да тыныч түгел бит әле аның. Кем булса да, безне генә харап итмәсәләр ярар иде. Юлдан килүче синең авылдашың булса да, колач җәеп йөгерә торган заман түгел. Берсенә ышанып та, якынаеп та, берсе белән ачылып сөйләшеп тә булмый шул хәзер. Сөйләшерлек кешесе дә калмады бит аның. Ир-атларның да кайсын кая алып китеп бетереп баралар. Кичә дә Арча мулласын алып киткәннәр. Абыстае белән безнең якларга килеп, ун еллап мулла булып торса да, авыл халкы никтер өнәмәде шул аларны. Ни гаебе булгандыр? Юкса авыл халкына үгет-нәсыйхәтен биреп, туган балаларга исем кушып,

яшьләрне кавыштырып, мәрхүмнәрне ахирәткә озатып торды. Инде шул да ярамагач. Берәүнең әләге аркасында диделәр. Төнлә килеп, каты итеп кыйнап, Малмыж төрмәсенә алып китеп япканнар бахырны. Артыннан хатыны Фатыйма абыстай берүзе күкрәк баласын алып төшкән Малмыж төрмәсенә. Бала белән булгач кертмәгәннәр. Шуннан баласын шул тирәдә яшәүче йортка кертеп калдырып, судка көчкә җитешкән. Суд булган. Атарга хөкем иткәннәр. Фатыйма абыстай һушын җуеп егылган. Бераздан хәл алып торып баскан да, күрше йортта калдырган баласын алып, авылдашларга әйтим әле, бәлки коткарып калырлар дип кайтырга чыккан. Кайтып җитсә, бөтенләй икенче йортка кереп, бөтенләй икенче баланы алып чыгып киткән, бичара. Башларны миңгерәүләтерлек вакыйгалар башланды шул. Бәндә язмышлары белән шулай уйнаучыларны берәр вакыт тотармы икән бу кеше рәнҗешләре? Ил болганды шул... Болгатучылар да, шул суга кармак салып утыручылар да – үзебезнекеләр, әнә шул йөрәккә тия.

– Шаулама, карчык, китүчеләр дә, илтеп бирүчеләр дә үзебезнекеләр булгач, хөкем итүчеләр дә безнекеләрдер инде. Әллә юкмы? Ышаныч калмады хәзер беркемгә дә. Ышанычлылар йә атылып үлде, йә үзләрен үзләре бетерде, йә Төркия дигән җирләргә чыгып шылуны хуп күрде.

– Шул Арча мулласын әйтәм әле, аны яклап, судка авылдан беркем бармаган бит. Әнә күрше авыллар булдырганнар, ичмасам. Төнлә алып киткән муллаларын яклап, авыллары белән Малмыж төрмәсенә караңгыда барганнар. Судта муллаларына сүз әйттерү түгел, аякларын җиргә дә тидермичә, күтәреп алып кайтып та киткәннәр. Менә шулай да була икән ул!

– Йә, Аллаһка тапшырдык. Без күрәсен кем күрсен?! Нәрсә язган – шул булыр, – дип, Муллахан агай, бөкләгән аякларын алга таба сузып җибәреп, алай-болай була калса дип, сикереп төшәргә җайлашып утырып, кулына камчысын алды. Тик Нәгыйматтәй генә ат чанасының бер ягына, мәңге төшеп калмас сыман, бияләйле кулы белән чытырдатып ябышты. Менә бер-берсенә якынлашканнан-якынлашты сәер нәрсә белән атлы юлаучылар. Очраштылар да шаккаттылар. Бала!.. Ир бала. Нишләп йөри ул япа-ялгыз кыр уртасында? Кайсы авылныкы? Кем баласы? Ник чыккан? Авыл үзе түгел, морҗа башларыннан чыккан төтене дә шәйләнми бит әле монда. Кая бара бу бала берүзе?

Бала янына килеп җитү белән, Ак бия шып туктап калды. Бүтән аягын атламас булып туктады бия. Аяк астына карап барган бала да, кинәт каршысындагы атны күреп, барган җиреннән сөрлегеп китеп, кар эченә кереп егылды. Бала белән атның, сүзсез генә аңлашып, бер-берсенә юл бирүләре булдымы, әллә бүтән сәбәпме – һәр икесе дә, туктаган җирләреннән ары китүне белмичә, аркан белән тартып торгандай, хәрәкәтсез калдылар.

– Балам, – дип, чанадан сикереп төшеп, кочагына алды Нәгыйматтәй бу сабыйны. Өч-дүрт яшьләрдәге бу бала да, юлаучыларны үз итепме, күптән наз-җылылык эләкмәгәнгәме, кулын сузып, Нәгыйматтәйнең кочагына атылды.

– Кая барасың, балам? – диде Нәгыйматтәй, аналарча үтенеп.

– Әт-т-т-т-и арт-т-т-ыннан, – диде малай, тотлыга-тотлыга, ана назын күптән оныткан, бәлки әле, бөтенләй белмәгән дә кебек, сабыйларча беркатлыланыпмы, хатын-кызның җылы карашын тоепмы, Нәгыйматтәйне кочаклаган кулын озак кына җибәрмичә.

– Әтиең кая китте соң? – дип сорыйсы итте Муллахан абзый малайдан.

– Ә-ә-ә-нә те-те-те-гендә, – дип, алга төртеп күрсәтте малай.

Нәгыймәттәй дә, Муллахан агай да малай төртеп күрсәткән якка бик озаклап карап тордылар һәм, берни дә күрмичә, карашларын кабат малайга төбәделәр. Сүзсез генә аны игътибар белән кабат күздән кичереп чыктылар. Шулчак Нәгыймәттәй балага ипләп кенә:

– Әниең бармы синең, улым? Ул кайда соң? Әниең кайда?

– Әни ю-ю-юк, ү-ү-ү-лде әни, – диде малай, тотлыга-тотлыга.

– Үлде? Ничек үлде? – диде Нәгыймәттәй, аптырап һәм кызыксынуы катыш җәлләү төсмере дә өстәлеп.

– Иҗекләмә, карчык. Ник баладан сорау аласың алай? Әнә туңган бит үзе, чанада урын әзерлә малайга тизрәк. Тамагың да ачкандыр. Әйдә, безнең чанага утыр әле, – дип, ир баланы җәһәт кенә күтәреп, чанага түшәк өстенә утыртты да кулына каты күмәч сындырып бирде. – Толып капла өстенә, кигәне дә юка бишмәт кенә, ыштаны да хатын-кызлар гамажы кебек нәмәрсә бит, аяк астына ук төшеп, җыерылып, кар белән укмашып катып беткән, аягында да зурлар итеге, – дип, Муллахан агай баланы кызгана ук башлады.

– Кире борылабыз әйдә, бор атыңны, өйгә кайтып китик, – дип, Нәгыймәттәй ирен бөтенләй аптыраашта калдырды. – Баланы үзебез белән алыйк та юлның кыйбласын борыйк, – диде иренә, бераздан ялына ук башлады карчык. – Апкайтыйк үзебезгә дим.

– Ничек? Урлап алып китикмени? Шәригатькә сыймаганны. Авылда берәр туганымы-ниеме бардыр әле. Караучысыз булса, бер хәл. Эзләп табыйк башта. Аннан күз күрер, – диде Муллахан агай, атка камчы белән орып.

– Юк, юк. Син баланың нинди булып беткәнен күрдеңме? Аның беркеме дә юк икәне күренеп тора бит. Әй, кадерсез бичара җан. Атны бор кирегә, кайтабыз, – диде Нәгыймәттәй еламсыраган тавыш белән. – Күңелем сизгән иде аны. Аллаһы Тәгалә күктән сораганны җирдән бирде бит, әлхәмдүлиллаһ. Үзебез тапкан баланы үз кулларыбыз белән илтеп бирикмени инде? Юк. Безгә дә кадерле ул. Без очрамасак, туңып үләр яки берәр ерткыч азыгы булыр иде, Аллаһ сакласын. Бу дөньяда бернәрсә дә тик торганнан гына булмый. Аллаһы Тәгалә бүләге.

– Мин атны кирегә борырга җыенмыйм, карчык. Аны болай урлап алып китеп булмас. Авылын табыйк, сорашыйк, бәлки, үзен әле эзли дә чыкканнардыр, – дип аңлатырга тотынды. – Ярамаган эш эшләп, гомер буе үкенеп яшәр хәлем юк.

– Соң, алайса, эзләп табыйк башта авылын, сорашыйк. Бәлки, ташлап калдырганнардыр. Абау, әстәгъфируллаһ. Белмим инде, белмим, нәрсә дияргә дә. Ярый соң. Барып карыйк әле алга таба. Без барасы Пайтәхетнеке түгелме икән бу балакай? Аннан күз күрер, – дип, нәрсәдер планлаштырды карчыгы, кисәк кенә авызы сөйләгән уңайга фикерләп.

Суыктан кергәч, бераз җылынып киттеме, тамагына ризык эләккәч, бераз хәл кердеме, әллә артык арыгангамы, толып эченә кереп чумган малай шунда ук йоклап та китте. Аның шулай сөйләшүен, бераз гына тотлыгып алуын, ир белән хатын ишетсәләр дә, бердәй белсәләр дә, ничектер уртага салып сөйләшәсе итмәделәр. Бәлки әле, артык туңгангадыр дип, әйтеп

торуны да, бу турыда гәп куертуны да кирәксенмәделәр. Анысы мөһим түгел бит. Малайны үзе Аллаһы Тәгалә юлыбызга чыгарып куйды дип, икесе дә эчтән генә юанып, кабат аклык эченә кереп югалдылар.

* * *

Күп тә үтмәде, тыныч кына ява башлаган карны буран өермәсенә алмаштырды да куйды. Карлы буран, көчәйгәннән-көчәя барып, кырны ап-ак пәри туена күмеп ташлады. Берара тирә-юнь күзачкысызга әйләнде. Җиле үзәкләргә үтәрлек булып дулый башлады. Ишелеп-ишелеп яуган кар бөртекләре, һава тегермәненә эләгеп, туракланып беткән хәлдә, әйләнә-тирәгә туктаусыз атылып очты да очты. Битләргә, күзгә, авыз-борынга учлап-учлап кар тутырды. Бөтен җиргә: арка-күкрәкләргә, гәүдәгә, бот, аяк очларына кадәр суык җил башын тыгып улады, аннан, сыеныр урын эзләп, чанадагы юлаучыларның өс-баш киемнәрен, печән-салам сабакларын үрле-кырлы сикертте. Дулады да дулады буран.

– Хараплар булдык, бетүебез шушы икән, – дип, Нәгыйматтәй салкын җилдән башын качырып, толып эченә яшерде.

– Берни дә юк иде бит әле, кайдан чыкты бу күзачкысыз буран? – дип, авыр көрсенде Муллахан агай, кайры тун якаларын тагын да өскәрәк күтәреп һәм баланың өстенә толыпны тартыбрак япты.

Тик юлаучы малай гына, артык арыгангамы, тамагы ачып хәлсезләнгәнгәме, бернигә исе китмичә, чана уртасындагы сырлы толыпка күмелеп, күзен йомып, бөгәрләнеп хәрәкәтсез килеш ятты да ятты. Йоклый идеме, күзен йомып уйланып кына ята идеме. Юлаучылар үзләре дә, Ак бия дә, арып-талып, адашкан малай каршыга килгән якка, Пайтәхет тарафларына таба юл алдылар.

* * *

Дөнья бетеп килгәндәй, коточкыч буран кузгалды. Мондый мәхшәрдә Ак бия алҗыдымы, әллә инде, ялгышып, юлдан читкә кереп киттеме – ат чанасы-ние белән кар диңгезенә керде дә чумды. Муллахан агайның чанадан аягын төшерүе булды, ул да кар көртенә төшеп китте. Бер аягын кардан алса, икенчесе кар көртенә кереп батты. Көчкә бераз тернәкләнеп, көчле җилдән башын яшерергә теләп, аска таба азрак бөкрәя төшеп, чана кырыена тотына-тотына, ни булуын карарга омтылып, бот төбеннән карга бата-бата, ат каршына таба атлады. Эшләр харап, чананы кардан тартып чыгарырлык түгел. Ат та, биленнән кереп, карга чумган. Ни алга бара алмый, ни артка чигәрлек түгел. Нишләргә? Иң элек атны тугарырга дигән фикер килде агайның башына. Аны тугарып маташканда, җил тагын да көчәеп, буран котырганнан-котырып, барыр юл бөтенләй томаланып, юлаучыларны тәмам борчуга салып, кич якынлашты. Буран бераз гына басылгандай булды. Абзый ак бияне чана үрәчәсенә бәйләп, тәртәне өскә күтәртеп куеп, сбруйларны чанага урнаштырды. Басу төпкелендә бәхет эзләп чыгып киткән юлчылар барысы бергә толып эченәрәк, бер-берсенә тагын да якынрак килеп, үзара елыштылар. Кичке суык юлаучыларның толып эчләренә үтеп кереп, гәүдәләренә урала-урала, аларның чыдамлылыгын, сабырлыгын сынарга кереште. Тешләренә кадәр суык йөгерде бичараларның. Муллахан

агайны салкын җил калтырата ук башлады. Шулвакыт, адәм баласының соңгы өметен, соңгы мөмкинлеген сынап, читтәрәк тонык ут күренгәндәй булды. Шуны күреп, Муллахан агай: «Йа Хода, бар бит Син. Коткар безне бу газаптан», – дип ялынырга, ялварырга тотынды. Нәгыймәттәй дә эчтән генә белгәннәрен укып, сыңар бияләйле кулын өскә күтәреп: «Шушы бала хакына булса да, буран тозагыннан чыгарлык көч, акыл, җегәр бир, безләргә хак юлларны күрсәт», – дип дога кылды.

Ут шәүләсе бераз боларга якынайган булды да тагын икенче якка таба китеп барды. Кычкырып та карадылар үзе. Ләкин мондый җилдә чит кеше ишетерлек түгел, янәшәдә утырганның да тавышын көчкә аңларлык иде шул. Муллахан агай түзмәде, бата-чума булса да, ымсындыргыч шушы ут артыннан китте. Кулларын бутый-бутый кычкырып та карады, туктаучы гына булмады. Менә ут тагын бу якка килә башлады. Эңгер-меңгердә тылсымлы якты йомгак якынайган саен, аның кеше икәнлеген, кулындагы таягының башында ут булуын бераз чамаларлык иде. Ут тоткан кеше боларны да күрде булса кирәк, алга барган җиреннән кисәк борылып, турылап, юлаучыларга якыная башлады. Менә аралар тагын да якынайды, һәм... Болар каршына озын нәзек буйлы, зур кара сакаллы, үзләренең якларындагы Сәрдегән Шакир рәвешле яшь кенә бер ир килеп басты. Муллахан агай да кулындагы таягына ут чорнаган солдатка охшашлы бу кешене шактый сынап күзәтте. Аннан аның утын үз кулына алып, йөзенә якынрак китереп карады. Ут дигәнебез дә таяк башына консерва банкасын кадаклап, шуның эченә керосинга манчыган чүпрәк тутырган сыек кына янган сүрән яктылык иде. Яктыртып карагач та, Муллахан агай болай үзе угры-фәләнгә, юлбасарга охшамаган, тик бик таушалган ирдән:

– Мөселманмы? – дип сорады.

– Әлхәмдүлиллаһ, мөселманмын, – дигән җавап ишеткәч, Муллахан агайның күңеле тынычлангандай, бураннар басылып, юллар ачылгандай булды.

– Динең нинди?

– Динем Ислам.

– Раббың кем?

– Сине дә, мине дә бу дөньяга китерүче – Раббым Аллаһ.

– Пәйгамбәрең кем?

– Мөхәммәд галәйһиссәлам.

Муллахан агай, шушы кыскача гына әңгәмәдән дә тирән мәгънәле сүз сөрешен аңлап алып, күңеленнән генә юлаучыга уңай бәя бирде. Гомерендә дә күрмәгән, белмәгән, эш итмәгән кешенең иңенә кулын куйды, аннан ике куллап күреште, бераздан якын кардәшен күргәндәй кочаклап ук алды. Аны чанага утыртты. Бу вакытта инде буран басылып, җил тынып килә иде. Чанага утырган бу яшь ир үз мөселманнары арасында яклау тапканга тәмам ышанып, сүзен дә тиз башлады:

– Кардәшләрем, саумысыз!.. Кем икән бу дисездер инде? Сөйлим сезгә минем белән нәрсәләр булганын. Кулга алгач, бик каты тикшерделәр, утырттылар, аннан мине, гаепсез дип танып, төрмәдән чыгардылар. Авылыма кайтсам, анда торыр урыным калмаган, өебез янган, белмим яндырганнар, хатыным үлгән, балам югалган. Үземне тегендә бертуктаусыз

сорау алып, кыйнап, кешелектән чыгарырга теләп азапладылар. Бер генә гаебем булмаса да, судлар ясап, камераларда утыртып, булмаган гаепләр тагып, шактый изделәр. Аннан урамга чыгарып аттылар. Бүген генә әле туган якка кайтып җиттем. Менә исәннәр бер кайта ул дип кайтып керсәм... иртәрәк куанганмын икән. Авылдашларымның да күбесе миннән йөз чөергән. Сабак биргән кайбер шәкертләрем биргән сәламемне дә алмады. Шуннан, малаемны сорап, һәр өйгә сугылдым. Берсе дә уңай җавап бирмәгәч, эзли чыктым менә. Мине җил-давыл да, туктаусыз яуган кар-буран да, ачлык-ялангачлык та туктата алмас, – дип әйтә башлау белән, чанадагы малай толыпны бер якка алып ташлап торып утырды да кинәт әлеге иргә карап тора башлады, аннан кисәк кенә аның кочагына ташланды.

– Әти, әтием, әти!

– Улым, синме бу күз нурым?! У-л-ы-м. Табармын дип уйладым мин сине. Барыбер табармын дип. Ләкин исән килеш күрермен дип уйламаган идем. Менә шушы тирәдә генәдер, кар көрте астында ятадыр дип, синең җансыз гәүдәңне таяк тыгып эзләп йөрдем. Җәсәде вәйран булып ятмасын, табып, җиргә иңдерермен дип уйладым. Көне буе басу-кырларны, урман-күлләрне әйләндем. Менә Аллаһка мең шөкер. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән сине таптым. Син исән. Син сау-сәламәт. Синең белән кавышасын көттем мин. Бик көттем, улым. Аллаһтан көн дә сорадым.

Ата белән улның кавышу шатлыгын бернәрсә белән дә чагыштырырлык түгел иде бу минутларда. Куанычыннан ир малайны һавага күтәреп чөйде, күкрәгенә кысып кочты, тез башларына утыртты, тагын чөйде, тагын кысып кочаклады... Башыннан төшеп киткән бүреген дә иелеп алмыйча сөйде-яратты, назлады газизен. Нәгыймәттәй дә ата белән улның шатлануын күреп, авызын шәльяулыгы белән каплап, күңеле тулып үксеп еларга тотынды. Муллахан агайның да күзләре яшьләнеп, аксыл төс керә башлаган сакал-мыеклары арасыннан эре яшь тамчылары тәгәрәде.

– Бу дөньяда да бар икән әле сезнең кебек игелекле кешеләр. Аллаһның рәхмәте булсын сезгә. Баланы коткарганыгыз, аны саклап калганыгыз өчен.

– Хәерлегә булсын. Без берни эшләмәдек. Ул безнең каршыга үзе чыкты. Без... берни түгел. Ул үзе... Малай үзе безне эзләп тапты, – диде Муллахан агай.

– Исемен дә белә алмадык бу изге баланың, исеме ничек соң? – дип, Нәгыймәттәй сорап куясы итте.

– Мөхәммәт атлы ул минем улым. Ә минеке – Гомәр, – диде, Нәгыймәттәйгә якын ук килеп. – Сез бик бәхетле Анадыр. Балаларыгыз да бик бәхетледер. Менә минем дә шундый әнием, әтием, тормыш юлын бергә башлап җибәргән хатыным бар иде. Харап иттеләр шул аларны. Хәзер беркемем дә калмады минем. Ни өем, ни җирем. Авылга кайтсам, өйдән кара күмерле агачлар гына өелеп калган, хатыным кисәк килгән бу кайгыны күтәрә алмаган, баланы чәч-баш китереп, котын алып бетергәннәр. Кайтмас идем мин кире авылыма, кайтмас идем. Мөмкин булса, риза булсагыз, мине дә үзегез белән алыгызчы, улымны да. Сезнең кая барыш иде? Ни йомыш белән бу якларга килеп чыктыгыз? Кемнәр сез?

– Без ни, улым, без эш белән, эш тә түгел инде, – дип, Муллахан агай, теле көрмәкләнеп, авызыннан бер рәтле дә сүз чыгара алмагач, Нәгыймәттәй кушылды:

– Улым, улларым. Сезне эзләп бара идек без. Сезне эзләп. Менә табыштык та. Аз гына алданрак борылып кайтып киткән булсак, бер уллы гына була идек, менә хәзер ике уллы булып кайтабыз, рәхмәт яугырлары. Әйдәгез, әйдә безгә кайтабыз. Барыбыз бергә кайтабыз.

– Ничек? Сезне кем җибәрде соң? Безне алырга килдегезмени?

– Сезне алырга бардык, балалар. Аллаһы Тәгалә җибәрде. Менә хәзер борылсак та була, – диде Нәгыймәттәй.

– Аллаһы Тәгаләнең кушмаганы булмас, әйдә, кузгалыйк, балалар, – дип, Муллахан агай белән Гомәр бераз кырыйдарак калган чананы юлга тартып та чыгардылар. Юнәлешне кайту ягына үзгәртеп, чананы шул якка борып куйдылар. Нәгыймәттәй белән Мөхәммәтне чанадан төшереп тә тормадылар ирләр. Ак биягә кипкән сохарилар каптырганда, капчык төбеннән Нәгыймәттәйнең сыңар бияләен дә табып алдылар, аннан тиз генә Ак бияне җигеп, үзләре дә чанадагы каты күмәчләр белән бераз тамак ялгап алгач, кайтыр юлга кузгалдылар.

Юлга кар шактый салган булса да, йөрмәслек түгел иде әле. Ак бия дә ничектер икенчерәк булып, җанына бер рәхәтлек табып, юлаучыларны үзләренең килгән юлларыннан җай гына юыртып алып китте. «Моннан атлап баруы ук рәхәт, үзем белгән юл, сыналган юл» дигәндәй, Ак бия шат, күңеле көр иде. Чанада кайтучылар ниндидер бер күтәренке рух белән гәп куерта башладылар, тик бер Мөхәммәт кенә, чана башына барып басып, ат тоягы астыннан чәчрәгән карларны ялан куллап тотарга тырышып карый иде.

Күзләрне камаштырырлык булып җәелгән аклык дөньясының иң югары ноктасыннан бар җиһанга яктылык тарала. Һәрберсенә аерым бизәк төшерелгән тәңкәләрдән генә торган мамык кар ипләп кенә җиргә куна. Тирбәлә-тирбәлә, җиргә төшимме-юкмы дип, берара һавада асылынып торганнары белән җилләр парлап вальс әйләнә. Кайсы кар тәңкәсенең биюе җиңелчә, гади хәрәкәтләрдән генә тора, андыйлары җиргә тоткарланмыйча гына төшеп, әле генә юлны сызып үткән чана эзен шундук каплап та бара, ә кайберләре татар биюендәге кебек катлаулы борылышлар, әйләнмәләр ясый. Андыйлары аяк-куллар белән генә түгел, бөтен барлыгы, булмышы белән хәрәкәтләнә. Алар югарыда эленеп торып, катлаулы элементлардан торган хәрәкәтләрне башкарып кына калмый, шунда ук башкаларны да үз артларыннан тамаша кылырга, күмәк чарага чакыра, алар белән зыр килеп әйләнә-әйләнә, кышның асылын, матурлыгын, аклыгын, җил-давылларын – барысын да берьюлы ачып салырга, күрсәтеп бирергә ашкына.

Чанадагы юлаучылар, югарыдан коелган һәр кар бөртегенә сокланып, ясалышларына гаҗәпләнеп, аларны каршы ала, учларына алып, якыннан кызыксына, бераздан алар, җылы кулларда вакытлыча эз калдырып, эреп юкка чыга, шулай булса да, бу тылсымны, илаһиятнең могҗизаларга тиң асыл халәтен, элеккеге матур башлангычында башкаларга бәян итә.

Колач җитмәслек биеклектән коелган һәм аз гына да керләнмәгән ап-ак кар өстенә дугалы чанасы артыннан бизәкләр сырлап, Ак бия юырта. Бу юлы тарафлары кай яккадыр?.. Төшергән бизәкләре ярымаймы икән, әллә башкамы?



Алинә
Хәбибуллина

# КАЗАН ТЕЛИ СИНЕ КҮРЕРГӘ...

***

Онытылыйк, әйдә. Кире какмыйк.
Белсен җиһан! Әйе! Без гашыйк!
Ялгыш кына билетлар алыйк та
Казан урамында очрашыйк.

Һәм ташланыйк дымлы кочагына
Тынгы белмәс җанлы каланың.
Күкләр күрмәс! Сизәр бары асфальт
Эзләргә наз түгелеп калганын.

Кызыл янганда да, хистән шашып,
Йөгерербез урам аркылы.
Җелегендә кайнар бу шәһәрнең
Без уяткан хыял ялкыны.

Бер чынаяк чәйдән исерербез.
Моңарчы соң ничек түзелгән?
Еллар элек, ахры, бу шәһәр тик
Без очрашсын өчен төзелгән.

Ялкын капкан йөрәкләрне күреп,
Җиһан чынлап ихлас сөенә.
Ялгыш кына билетлар алыйкчы!
Казан мохтаҗ безнең сөюгә...

***

Кулларда безнең җәй, кояшы – күңелдә,
Мәхәббәт, нур булып, дөньяга түгелә.

Түгелә кырларга, ярларга, тауларга,
Бу галәм курыкмый йөрәкне яуларга.

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА (2001) – *шагыйрә, прозаик. «Иделем акчарлагы» (2020) әдәби бәйгесенең Гран-при иясе, Шәриф Камал исемендәге әдәби премия лауреаты (2021), «Татнефть» ААҖнең Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия стипендиаты (2021). Казанда яши.*

Очкынлы карашлар омтыла болытка,
Ялкынның сөюдән булуын онытма.

Онытма бәхетнең тик жирдә тууын,
Ә җәйнең учакка ут өстәп торуын.

Иреннәр елмая, тәм белеп, ямь белеп.
Шикләнмә беркайчан: мәхәббәт – мәңгелек.

***

Шат тамчылар йөгерешкән иде
Син бер үткән кайнар пакь юлдан.
Ләкин хәзер юксынуга түзми,
Гөрләвекләр кибеп юк булган.

Эзләреңне саклап кала алган
Сукмаклар да моңсу тоела.
Көз килгәнгә түгел, сәбәп башка...
Агачлардан яфрак коела.

Сине өзелеп сагынудан һәркем
Калыр иде, ахры, күмергә.
Юк, мин түгел, ялгыш уйлый күрмә,
Казан тели сине күрергә.

Шәһәр күптән тоташ күмердә...

***

Шагыйрь үлә, авыр сулыш алып.
Елмаеп йә яшькә күмелеп.
Соң юлына озатканда, кайнар
Мактау кала, эзгә түгелеп.

Шагыйрь үлә канлы сугышларда
Йә сыенып тынчу почмакка.
Исән чагын аның беркем белми,
Ә аласы иде кочакка...

Һәрбер сүздә үлеп терелә ул,
Тик өлгерми соңгы юлына.
Аңа тиеш хөрмәт никтер кала
Йә кызына, яки улына.

Мәңгелеккә исән калыр өчен,
Үлә шагыйрь. Җаннар күшегә.
Һәр ел саен, һәр көн, сәгать саен,
Шагыйрь үлә һәрбер кешедә.

***

Салкын кышның күге елый сулык-сулык
Яраларын ялый җирнең күлләвекләр.
Дөнья үзе, әллә язлар көткән күңел
Күчәреннән купкан кинәт бер тәүлеккә.

Күчәреннән купкан галәм. Ул хәтерле
Синең эзгә басып килгән кайнар язны.
Аһ, ул язны!.. Карашыңнан карлар эреп,
Минем дөньям су астында кала язды.

Шул язларны сагынуы әллә җирнең –
Кышларымда саташулы яңгыр ява.

Тик юатмый, кайнар яңак буйлап кинәт
Тәгәрәгән өметләр дә тоташ яра.

Яраларга дәва булмас, янмас кояш
Дип баш иеп атлаганда урамнардан,
Ак-караны күрми-белми йөгергәндә,
Нәкъ каршыга килеп чыктың бураннардан.

Очраштык та, камап алды карлы яңгыр:
Гасырга бер килгән кышның кайнар мәле.
Кабат язлар өмет итеп алдандыммы?
Керфегеңә кунган карлар эремәде...

***

Алгы тәрәзәдән өй эченә
Сирин чәчәкләре үрелгән.
Язлар белән син килерсең төсле,
Ялкын салып минем күңелгә.

Чәчләремә сирин тажы када,
Учыңа ал җанның ярасын.
Тик син генә якты язларыма
Мине гашыйк итә аласың.

Кочагымда сирин чәчәкләре,
Караш тулы җылы наз гына.
Җанны учка кысып көтәм һаман –
Язга кадәр калды аз гына.

Йөгереп кенә үтеп булмый икән
Кышлар белән язлар арасын.
Язлар килгәч, ялкынланып калган
Эзләремнән эзләп табарсың.

Сириннәргә күмелеп, синең белән
Бер иңлисе килә каланы.
Әгәр язлар синсез килер булса,
Кышларымда гына каламын...

***

Тезләремнең терәге бул,
Йөрәгемнең йөгәне бул
Һәм бул җанга җавап,
Тынсыз гына ялварам да,
Күкнең яшьләренә кушылып,
Түгеләмен кабат.

Бер ышыксыз, кулчатырсыз,
Калган чакта яклаучысыз,
Күңел төшсә кабат,
Пышылдыйдыр кебек Ходай:
Камил түгел бу дөньяны
Син барыбер Ярат...

Пышылдыйдыр кебек күкләр:
Утлы яулар килсә,
Мин булырмын канат...
Ә син ярат…
Син барыбер ярат…

***

*«...Шулай булгач, минем йөрәк*
*Туеңда дуласын ла.*
*Кыңгырау итеп тагамын*
*Атларның дугасына».*
Рәшит Әхмәтҗанов

Кыңгыраулы тулпар узды
Ике йөрәк арасын.
Белдең микән тояклардан
Җиргә ялкын кабасын?..

Нидән болай ялкынлана,
Сызлый дисәм куеным,
Таптап узган йөрәгемне
Тулпарлары туеңның.

Яшь аралаш елмаямын,
Ак тузанга күмелеп.
Үзем өчен борчылмыйм ла –
Сине юатам кебек.

Сизәм синең дә йөрәгең
Бүген тыныч булмавын.
Минем йөрәгемдә – буран,
Синең йөрәктә – давыл.

Дәшмим ләкин, бозмыйм яңа
Тормышыңның иртәсен.
Беләм чөнки, бер ым каксам,
Шундук минем белән бергә
Җир читенә китәсең...

***

Сискәндерми инде салкын күзләр,
Сызландырмый шыксыз җилләре.
Мин бу юлы кайнар җәемне дә
Күз яшьләрсез генә җибәрдем.

Мин җибәрдем... Кинәт тыпырчынып
Талпынмады никтер йөрәгем.
Үзем суындыммы, белмим, әллә
Йөгәнләргә хисне өйрәндем...

Ятим җәем мөлдерәмә тулы
Күзләр белән калды үткәндә.
Үпкәләде, ахры, эчтән әрнеп,
Саубуллашмый гына киткәнгә.

Эндәшмәдем, сүзләр артык иде,
Гафу сорарга да тарсындым.
Мин бу юлы тормыш канунына
Карышмыйча гына буйсындым.

Буйсындым да җансыз салкын көзнең
Яңгырында эреп югалдым.
Кабатладым эчтән, юангандай:
«Җәйдән җәйгә кадәр бер адым».

Хушлашканда җаннар телгәләнә,
Хушлашканда юллар өзелә.
Саубуллашмый гына китәм шуңа,
Кайтырмын дип җәйнең үзенә...

Җитлегүме? – Инде сискәнмим дә,
Үзгәргәндә тормыш көйләре.
Мин, ахрысы, чынлап сабыр гына
Йөгәнләргә хисне өйрәндем…



Гөлфия
Исхакова

# АЛАМАЧЫ БАБАЙ ДӘРЕСЛӘРЕ

хикәя

Безнең тормышны күреп үсмәгән яшьләр өчен бәлки бүгенге заманда минем хикщям кызык булып тоелмас, шулай да мин, үземнең бала чагымның тагын бер истәлеген искә төшереп, укучыларга тәкъдим итәргә булдым.

Безнең авылда элек иске-москы җыючыны аламачы дип атаганнар. Аламачы турында олылар сүз кузгатканда мин аны котым очып тыңлый идем. Ул миңа шулкадәр куркыныч, төрле төстәге йонлач зур бер җәнлек булып күз алдыма килә.

Бүгенгедәй хәтеремдә: ул, җигелгән ат арбасына утырып, авыл урамнарын узганда, әниләр аның тавышын тиз танылар. Ерактан: «Алама җыям, кемдә тире, кемдә кәгазь бар? Иске-москы чыгарыгыз», – дип кычкырып килә. Юл уртасында туктый да кешеләрнең үз янына җыелганнарын көтеп тора. Кайчак халык күп җыела, кайчак әз була. Мин дә әни белән аламачыны күрергә чыгам. Карасам, ул ала мачы дигәннәре туп сыман таза, зур корсаклы, пуф-пуф дип сулыш алучы бер бабай икән. Шулай да берүзем аның янына якын барырга куркам, чөнки абыйлар бәләкәй чакта «Еласаң, аламачыга биреп җибәрәбез», – дип, гел куркытып тордылар. Аламачы утырган ат арбасы янында, әни артыннан гына бабайны күзәтәм, усалга да охшамаган үзе, гел шаярып сөйләшә. «Бу бабай гел елакларны гына алып киткәч, бу юлы кемне алырга килгән икән?» – дип уйлыйм. Шул вакыт мине куркудан телсез калдырып: «Бу почык борын кем кызы?» – дип сорамасынмы... Мин: «Беттем!» – дип, күзләремне чытырдатып йомам да әнинең күлмәк итәгенә ябышам. Әни,

минем чәчләремнән сыйпап: «Бу минем төпчегем, Габделхәй абзый», – ди. Шунда гына минем курку бераз басыла төшә. Бабайның әле үз исеме барлыгын да аңлап алам.

– Менә бит, ничек гомер үтә, атасы үлгәндә, бу сабый үз бишеген үзе тирбәтеп утыра иде. Хәзер, әнә, әнисенә ярдәмче булган, – дип, мине мактап та куйды. Мактаганда, бала бит ул бер башка үсеп китә. Мин дә шулай, җыелган күрше апалар алдында бер башка үстем сыман ул көнне.

Икенче тапкыр әни мине аламачы бабайларның өйләренә үк алып менде. Алар югары очта торалар икән, елганы чыгып, тыкрыктан таугарак менәсе генә кала. Мин әнидән алда йөгерәм, зур, матур йорт эзлим. Бабай зур булгач, өйләре дә башкалар өеннән зуррак төсле.

Тик никтер әни гап-гади йорт каршында туктап калды. Шул чакта әни шаярадыр кебек тоелды миңа. Әнинең кулларыннан тотып, мин аны алга барырга чакырам. «Килеп җиттек, кызым, ач капкаларын», – ди әни.

Бозау тиресен тапшыргач, аламачы бабайның карчыгы безне өйләренә чакырды. Өй алдыннан узып, зур бүлмәгә кердек. Андагы аклыктан күзләр чагылып китте. Бүлмәдә бар нәрсә дә ак төстә һәм чигелгән иде. Почмакларда сөлгеләр эленгән, урын-җирдә чигелгән япмалар, мендәр тышлары. Хәтта өстәл япмасында да чигелгән пар күгәрченнәр гөрләшә. Менә шулай мин бу өйнең матурлыгына сокланып торганда, Габделхәй бабайның тавышыннан айнып киткәндәй булдым.

– Әнисе, минем счутны алып кил әле, – диде ул тыныч кына.

Менә шул чакта мин беренче тапкыр зур агач счут күрдем аларда. Бабай ялт-йолт итеп зур счутның агач төймәләрен чалт-чолт китерде дә әнигә тире өчен тиешле бәяне әйтте. Миңа ул чагында бу эш бик җиңел булып тоелды. Аннан соң, бик тәмләп, бал белән чәй эчкәнне дә хәтерлим. Тапкан мактаныр әйбер, дисезме? Таптым, чөнки бала чакта бал ашау безгә бик тәтеми иде. Авылда умартачы Шакир абзыйның барлыгын ишетсәм дә, аның умарталары урманда булып, моңа кадәр бер тапкыр да умарта күргән юк иде. Кайтып киткәндә, аламачы бабай безне үзе озата чыкты. Миңа:

– Кызым, иске гәҗитәләрегез җыелса, миңа менгер, мин сиңа аның өчен матур-матур шарлар бирермен, – диде.

Мин шатланып: «Ялал, бабай, илтәгә үк менделелмен», – дидем.

Бабай көлеп җибәрде:

– Гөлфия, үзең зур кыз булып үскәнсең, ә үзеңә кара каргалар һаман «Р» хәрефен алып килмәгәннәр икән... Ешрак алар артыннан «кар-кар» дип кабатларга тырыш, ату мәктәпкә баргач көләрләр үзеңнән, – дип, безне озатып калды.

Мин моннан соң да ул агач счутны аламачы бабай кулында еш күрдем. Әнидән сорап, иске газета-журналларны Габделхәй бабайга алып менәм. Ул мине таный, тик һәрвакыт: «Оныттым, кем кызы әле син?» – дип сорый. «Мин Мәгъмүлә кызы», – дим. Бабай кулын колагына

куеп: «Мәймүнә кызы дисеңме?» – дип, берничә тапкыр миннән әнинең исемен кабатлата. «Әәәәә, танадым хәзер, Гөлфия бит әле син. Сезнең урамга әле һаман кара каргалар килмәдемени?» – дип елмая. Аннары гына: «Мәгъмүрәнең ярдәмчесе», – дип мактый, «Укырга кердеңме әле?» – дип сорый. Мәктәптә укый башлагач, безнең урамга да аламачы бабай сораган кара каргалар килеп җиттеләр. Тырыша торгач, «Р» хәрефен өйрәндек әни белән, бабай да әнинең исемен сорамас булды. Йомыш белән менгән саен бабай мине һәрчак: «Әллә тагын да үсеп киткәнсең инде?!» – дип елмаеп каршылый.

– Саный беләсеңме? Куша-ала беләсеңме? Әйдә әле, санап күрсәт, – дип, каршыма чүгәли. Аннары икәүләп мин алып менгән кәгазьләргә күпме шар тиясен чутлыйбыз. Аламачы бабай мине мактый-мактый, үзем теләгән төстәге ике-өч шарны тоттырып, озатып кала. Кайткач, мин әнигә: «Миңа да Габделхәй бабайныкы кебек агач счут кирәк, ул булса, мин тизрәк тә чутлый алачакмын, яхшырак укырмын да», – дим. Соңрак булса да, әни миңа аламачы бабайныкы сыман тиз чутлый торган зур счут алып бирде. Габделхәй бабай, картаеп килсә дә, миңа дәрес бирүдән туктамады. Көз көне маллар чалгач, тиреләрне үзем менгерәм, бабай кулына сантиметр ала да саннарны әйтеп тора, мин язам, аннары чутлыйм. Бу хәлләр мин авылда сигезенче классны тәмамлаганчы дәвам итте. Аламачы бабай булса да, мин аны ул вакытның алдынгы кешесе булган дип саныйм. Ул күңеленнән укытучы, тәрбияче булган. Аларның балалары да укымышлы кешеләр иде. Аламачы бабай күптән юк, шулай да кешенең изгелеге җирдә ятмый, күпме гомер үтсә дә, кеше күңелендә якты истәлек булып саклана икән. Минем күңелдә дә яхшы истәлекләр һәм рәхмәт хисләре яши аламачы Габделхәй бабайга карата.



*Айсылу Кәлимуллина (1955) Сарман районы Анак авылы кызы. Әүвәл Бөгелмә кооператив училищесында, соңрак Казан кооператив техникумында белем алып, хезмәт юлын район сәүдә системасында сатучы булып башлап җибәрә, соңрак сәүдә предприятиесе һәм җәмәгать туклануы оешмасының җитәкчесе була, башка җаваплы тармакларда да хезмәт куя. Бүгенге көндә ул – Сарманда гомер итүче эшкуар.*

*Аның шигырьләре район газетасы битләрендә еш басыла, җирле радио эфирларында яңгырый. 2020 елны шәхси нәшриятларның берсендә аның «Җырлы йорт җылысы» дип аталган шигырь җыентыгы дөнья күрә.*

Айсылу
Кәлимуллина

# КУЛГА АЛАМ КАУРЫЙ КАЛӘМНЕ...

## Кем ала?

Тирән тынлык биләп ала җанны,
Ялгыз калам бары уй белән.
Уйлаганым сүзгә әйләнер дә
Ак кәгазьгә күчәр, мин беләм.

Укырлармы минем язганымны,
Озак яшәрләрме югалмый?
Җиргә коелсыннар орлык булып,
Бөреләрсез чәчәк була алмый.

Шау чәчәкле болын итеп күрәм,
Йөрәгемнән чыккан сүзләрне.
Чәчәкләрнең тәмле исләренә
Сукмак салыр бик күп эзләрне.

Шифа булса иде шигырьләрем,
Уйландырса иде җаннарны.
Моңлы кошлар, сүзне көйгә салып,
Җырлы итсә иде таңнарны.

Тирән тынлык. Күңел түрләреннән
Сихри көчкә ия сүз ага.
Сүтәм, җыям шигъри такыялар,
Бүләк итәм сезгә. Кем ала?

## Күңел халәте

Очкан чаклар булды, күңел очты
Яшьлегемнең назлы кичендә.
Тормыш корып, балаларым иңгә
Канат куйган көннәр исемдә.

Яраткан эш мине очындырды.
«Югарыга» диде йөрәгем.
Җиңелүне түгел, җиңүләрнең
Биеклеген генә теләдем.

Уйларымны җигеп чабар өчен
Әзер торды тулпар атларым.
Авылымны, болын, чишмәләрне
Көйгә салып, җәяү атладым.

Илһамланып, күккә талпындым мин,
Күрдем югарыдан барын да.
Яшәү ямен, туган-дусларымны,
Табигатьнең яңгыр, карын да.

Очтым. Төштем. Тагын күтәрелдем,
Язмыш чөйде, янә төшерде.
Җиргә якын булу отышлырак,
Мәгънә асылына төшендем...

Очкан чагы була күңелемнең,
Хыялларым гизә галәмне.
Уй корабы җиргә бастыруга,
Кулга алам каурый каләмне.

## Җырлы юл

Йөрәкләрне айкап, моң агыла.
Бәгырьләрне телә сүзләре.
Татар-башкорт илен тетрәндереп,
Төбәп карый солдат күзләре.

Көчле дулкын булып күтәрелеп,
Җыр бәрелә кыя-тауларга.
Бу аһәңнән күкләр тынсыз калып,
Тынычлыкны тели дауларга.

Бүгенге көн гимны дөнья гизә:
«Киек каз юллары югары...»

Хәсрәтләнеп, күңел теләк тели:
Өзелмәсен бары җырлары.

Өзгәләнгән җанда кайтаваздай,
Тына алмый шавы колакта.
Ихтыярсыз калган ир-егетләр
Җырны алып китте еракка.

Тик озакка түгел, акыл җиңәр,
Киек казлар кайтыр күленә.
Егетләр дә тизрәк, җырлый-җырлый,
Кайтсын иде туган иленә.

## Карлар яна

Син читләргә ишек шакыганда,
Мин, бикләнеп, сине көткәнмен.
Ак хыялым салган сукмаклардан,
Җитәкләшеп, бергә үткәнмен.

Син йөргәнсең шаян җилләр куып,
Мин йолдызлар тездем юлыңа.
Аңышмыйча, кайнар йөрәгемне
Салдым синең салкын кулыңа.

Күңелеңдә буран өермәсе,
Хисләреңне кырау каплаган.
Елмайсаң да, күзләреңнән күрәм:
Ышанычлы кочак тапмаган.

Язгы ташкын сулар, ташып аргач,
Тынычланып кайта ярына.
Син дә мине җылытырга теләп,
Учак яктың кышның карына.

## Авыл кешеләре

Сокландыра авыл кешеләре,
Кара җиргә тама тирләре.
Алар җилкәсендә авыр хезмәт,
Тоташалар төнгә көннәре.

Уяналар әтәч тавышына,
Сайрар кошлар моңы кушыла.
Ат-сыеры, чеби, каз-үрдәге –
Оркестрлы сәхнә шушы ла!

Таң атуга абый-апаларны
Тавык чүпләп бетмәс эш көтә.
Ата-бабалардан канга сеңгән,
Кеше иткән җиргә беркетә.

Иген игә авыл агайлары,
Комбайннар иңли басуны.
Иртә яздан кара көзгә кадәр,
Шунда җайлый күңел ачуны.

Фермаларда, маллар арасында
Резин итек кигән апалар,
Сыер савып, бозау үстерәләр,
Ай калыккач эштән кайталар.

Көзгеләргә алар карамыйлар,
Җир тузанын биттән сөртмиләр.
Гадәти бер яшәү рәвешедәй,
Беркемнән дә мактау көтмиләр.

Куркыта алмый җиле, яңгыры да,
Балчык, сазы, көчле давыл да.
Җир, су белән бергә сулый алар –
Яшәү өчен дәрман авылда.

Алар җыры иген басуында,
Алар моңы кошлар җырында.
Табигатьтән аерылмас җаннар,
Мактау язам сезнең турыда.

Көчле булып кала алган кешем,
Җир кадерен, гамен аңлаучы.
Авыл җирләрендә билен бөккән,
Сез ул – илне, көнне данлаучы!

## Каз өмәсе

Каз өмәсе гөрли авылларда,
Каз өмәсе гөрли өйләрдә.
Ак мамыктай күңелләргә тула
Талгын гына аккан көйләр дә.

Казлар очмый бүген каңгылдашып,
Ак мамыгын сава ак куллар.
Бәйрәм төсен алган өмәләрдә
Урамнарны урый җыр-моңнар.

Йорт казлары, ак туннарын салып,
Куандырыр өйнең хуҗасын.
Казны туйлар, Яңа еллар көтә –
Бәйрәм табыныннан узасы.

Көянтәгә пар казларын элеп,
Кызлар атлый чишмә юлыннан.
Йолаларга тугры калган халкым,
Тапкыр эшләр килә кулыннан.

Ак мамыгы мендәрләргә күчәр,
Затлы бүләк туйда мендәрләр.
Күңелендә хатирәләр саклар,
Каз өмәсен күргән-белгәннәр.

Табын бизәр майлы тәбикмәкләр,
Каз итеннән бәлеш пешәдер.
Әби-бабай гореф-гадәтләре,
Безнең буынга да күчәдер.

Каурыйларын сукмакларга сибеп,
Изге теләк юрар йөрәкләр.
Бүген бездә каз өмәсе гөрли,
Кабул булсын барлык теләкләр.

## *«Татар әдәбияты – Россия киңлекләрендә»*

*Журналыбызда яңа сәхифә башлап җибәрәбез. Исеменнән үк күренгәнчә, ул Россиянең төрле төбәкләрендә бүген татар телендә иҗат итә торган каләм әһелләрен барлау максатын куя. Сер түгел, XXI гасырда Татарстаннан читтәге күп кенә урыннарда татарча газета-журналлар чыга башлады, электрон сайтлар алып барыла, җыентыклар нәшер ителә. Бу әдәбиятның да үсешенә китерәчәк хәрәкәт. Мәгълүм бит, татар әдәби авазы үзенең олы тарихында гаять киң мәйданнарда яңгыраган, милләтебезнең Казаннан бик еракта яшәгән талантлы ул-кызлары татар әдәбияты дигән диңгезне саф сулы чишмә-инешләре белән сугарып торганнар. XX гасырның классик язучылары – Дәрдемәнд, Ш.Камал, М.Җәлил, Г.Кутуй һ.б. бик күпләрнең татар әдәбиятына ерак төбәкләрдән килеп кушылуы мәгълүм. Әмма XX гасырның икенче яртысында бу хәрәкәт сүнеп, бары тик Татарстан-Башкортстан арасында гына сакланып калган иде. Инде яңарышның матур нәтиҗәләре дә күренә: республикада уза торган бәйгеләрдә елдан-ел чит төбәкләрдән катнашучылар югары урыннар ала. Бу сәхифәбез татар укучысын төрле төбәкләрдә каләм сынаучылар иҗаты белән таныштыру урыны да, алар өчен әнкә әдәбиятыбызга фатиха биргән мәйданчык та булыр дип ышанабыз.*

# САМАРА ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Икътисадта, фән-мәгариф һәм мәдәнияттә Россиянең иң эре үзәкләреннән берсе саналган Самара өлкәсе – милләттәшләребез күпләп гомер итә торган урын, татар җире дә. Кайбер галимнәр тарафыннан туган җире хәзерге Самара өлкәсендәге Камышлы төбәгенә нисбәт ителгән С.Сараины, Туктамыш һәм Аксак Тимер арасында көрәшне, Тайдула ханбикәләрне хәтерләгән, 600 елга якын тарихы булган бу җирдә бик күп татар исемнәре мәңгеләштерелгән. Дистәләгән төрле фән докторлары, дөньякүләм танылган милләттәшләребез бу төбәктә туып үскәннәр: татар балалары өчен «Әлифба» китабы авторы, Татарстанның атказанган укытучысы Сәләй Вәгыйзов, Советлар Союзы геройлары – очучы Ольга (Ләйлә) Санфирова һәм Бөек Ватан сугышы елларында Дунай буйларында батырлыклар күрсәткән Рәүф Кутуев, виртуоз гармунчы, Татарстан Республикасының халык артисты, Россиянең атказанган артисты Рөстәм Вәлиев, бокс буенча дөнья чемпионы Олег Сәитов, танылган татар көрәшчесе Хәбил Бикташев, Татарстанның халык артистлары Зәкия Туишева һәм Рәшит Шамкаев, каһарманлык күрсәтеп, дөньяга танылган үзйөрешле «Т-36» баржасы экипажы әгъзасы – диңгезче Әсхәт Җиһаншин, данлыклы биатлонист Эдуард Латыйпов, мәшһүр нәкышчы, монументаль сәнгать рәссамы Нурхәтим Бикколов, Россия кино һәм театр артисты Ренат Кадыйров, тел галиме Латыйф Җәләй... Татар халкының горурланырлык шәхесләре тупланган бу исемлекне тагын озак дәвам итәргә була. Башка җирләрдә туып, тормышы һәм эшчәнлеге Самара өлкәсе белән бәйле булган, хезмәтләре белән милләтебезне танытКан шәхесләрне, дин һәм җәмәгать эшлеклеләрен дә саный китсәк, бу якларның талантларга уңдырышлы җир икәненә инанырбыз.

Самара өлкәсенең татар әдәбияты картасында да якты йолдызлар юк түгел. Богырыслан өязе (хәзер Самара өлкәсенең Киләүле районы) Иске Ярмәк авылында

туган, Тукай шигъри мәктәбе үрнәгендә, классик татар поэзиясе һәм халык җырларына хас ритмик үлчәмдә язылган шигырьләре, халык арасында «Ак каен» җыры (М.Вәлиев музыкасы) белән танылган шагыйрь Зыя Ярмәки (1887–1965) һәм шигырь, пьеса, очерк, хикәя, повесть, роман жанрларында иҗат иткән Садри Халикъ (1890–1955), чыгышы белән Самара өлкәсенең Камышлы авылыннан булган, публицистик яңгырашлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган фәлсәфи-лирик поэмалар, шигъри романнар язган шагыйрь Әнвәр Давыдов (1919–1968), Камышлы районы Йолдыз авылында туган Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь, драматург Рөстәм Мингалим (1937–2014) кебек әдипләр күптәннән татар әдәбияты һәм мәдәниятендә лаеклы урын алдылар.

Хәзерге көндә дә Камышлы районындагы Иске Ярмәк авылының шифалы суларын эчеп, сихәтле һавасын сулап үскән талант ияләре аз түгел. Алар арасында инде шактый гына багажлысы да һәм яңарак кына каләм тибрәтә башлаучылар да бар. Әсәрләрендә гыйбрәтле язмышларны чагылдырган «Тормыш яме», «Йөрәк хисләрем», «Күзләр балкышы» китаплары авторы Гөлсинур Гафурова, «РСФСРның Хезмәт отличнигы» күкрәк билгесе, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены иясе, Хезмәт ветераны, «Якты хыял бүләге», «Гомерләр балкышы», «Язлар моңы» китаплары авторы – Гөлсем Хөббатова төбәкләрен, үз нәселен, халкын данлаучылар. Аларның шигырьләрендә туган авылның яшәеше, табигате, кешеләренең ихлас кичерешләре бербөтен булып күз алдына килә.

Шигырьләре көйгә салынган шагыйрә, прозаик, журналист, 200дән артык шигырь, 50дән артык хикәя-нәсер, берничә дистә очерк авторы Фәния Кәримованы исә бу якларда белмәгән татар кешесе юктыр. Ул – Россия Федерациясе журналистлар берлеге әгъзасы, 25 ел буе «Бердәмлек» өлкә газетасында актив эшчәнлек алып баручы, «Камышлы яңалыклары» район газетасы журналисты, «Күңел моңы», «Томаннарның таралуын көтәм», «Ярсу йөрәк», «Туган илкәем, сөйгән җиркәем», «Алмалы, миләшле күзләрем», «Вакыт борылышларында» исемле проза һәм шигъри әсәрләр җыентыклары авторы. Күзәтүчән әдибәнең ихлас шигырь, хикәяләре беркемне битараф калдырмый. Татар милли сәнгатен саклау һәм үстерү, төрле милләтләр арасында дуслыкны ныгыту өлкәсендә эшчәнлеге өчен ул күп тапкырлар өлкә рәхмәт хатларына, 2016 елда «Камышлы районының ел хатын-кызы» премиясенә лаек була. Әсәрләренең күбесе авыл табигатен, аның хезмәт сөючән халкын, булдыклы хатын-кызларның язмышын чагылдыра. Кеше гомеренең мәгънәсе, тиз узучанлыгы турында уйланучан әдибә гомумкешелек кыйммәтләре, яхшылык-яманлык турында гади итеп җиткерә белә.

Тагын бер иҗатчының – Илшат Сәгыйть улы Галимовның исеме 2023 елда Татарстан Республикасы Язучылар берлеге һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсына йомгак ясаган вакытта Татарстанда да яңгырады. Аның «Урман юлында» хикәясе иң яхшы әсәр исемлегенең беренче унлыгына кергән иде, өметле каләм, әле үзен күрсәтәчәк иҗатчы дип бәяләнде. Кем икән ул Илшат Галимов дигән сорау да куелды. Шуңа сүзебезне аның үзе белән таныштырудан башларбыз.

Илшат Галимов 1972 елның 1 маенда Куйбышев өлкәсе Клявлино районы Иске Ярмәк авылында гади колхозчы гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Яшьтән колхозда төрле эшләрдә катнаша. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, 1987 елда Шонталы СПТУының Камышлы филиалына укырга керә. 1990 елда Совет Армиясе сафларына алына, аннан хезмәт итеп кайткач, өйләнеп, гаилә корып җибәрә. Күп еллар тракторчы, комбайнчы булып эшли. «2006 елда, каты авырудан соң инвалидлык бирелгәч, яраткан эшемне ташлап, җиңелрәк эшкә урнашырга туры килде, – ди Илшат. – Хәлем яхшыра башлагач, гаиләдә уртага салып сөйләшкәч, инәй, кызыбыз Ләйсән, улыбыз Альмир тарафыннан безнең ниятебез хуплау алгач, балалар йортыннан

бертуган малайлар алып кайттык. Аларның олысы Андрейга 4 яшь, кечесе Алексейга 1 яшь 3 ай иде», – дип искә ала ул.

Еллар уза, кызлары үсеп укырга китә. Тагын гаилә белән киңәшләшеп, тәрбиягә бер кыз бала алырга телиләр. 2012 елда ниятләрен тормышка ашырырга дип барган балалар йортыннан янә бертуган ике малай – 7 һәм 6 яшьлек Рома белән Мөхәммәтне алып кайталар. Шулай итеп, аларның 5 уллары, 1 кызлары була. Балалар, үсеп, төрле якка тарала. Хәзерге вакытта олы уллары Альмир Самара шәһәрендә эшли, Андрей, Рома, Мөхәммәт әлеге шәһәрдә көллияттә укый, яннарындагы кече уллары Алексейга да инде 16 яшь тулган. Башта русча сөйләшсәләр дә, таза әхлакка корылган гаиләдә тәүфыйклы балалар, әти-әниләре телен өйрәнеп, әбиләре белән татарча сөйләшеп үсәләр, кайберләре хәтта мәчеткә укырга йөриләр. Әлеге мәгълүматлардан менә шундый игелекле зат булып күз алдына басты ул Илшат Галимов.

«Тормыш яхшырган саен, күңел җыр-моңга тартылды, яшьтән җырлап-биеп үскәнгәдер инде, 2016 елда мине үзебезнең мәдәният сараенда 50 елдан артык тарихы булган «Ак каен» татар фольклор ансамбленә чакырдылар», – дип яза ул. Шул ук елны каләмен сыный: пьеса иҗат итеп, әдәбиятка килүне драматургиядән башлый. 2019 елда аның 4 пьесадан торган «Өлешемә тигән көмешем» җыентыгы дөнья күрә. И.Галимов исә, сәхнә тормышында кайный: З.Хәкимнең «Бармы ришвәттән дәва?» пьесасы буенча эшләнгән спектакльдә катнаша, үзе язган «Өмет» пьесасын сәхнәләштерә, әлеге спектакль белән коллектив 2019 елда Казанда уздырылган Шамил Закиров исемендәге Бөтенроссия «Идел-йорт» театрлар бәйгесендә катнашып, 2 нче дәрәҗә лауреат исеменә лаек була. 2020 елда ТАССРның 100 еллыгы һәм Бөек Җиңүнең 75 еллыгы кысаларында үткәрелгән Ш.З. Закиров исемендәге «Идел-йорт – 2022» төбәкара театр коллективларының XX юбилей бәйгесендә Гөлшат Зәйнашеваның «Чиккән яулык» пьесасы буенча эшләнгән «Рамай» спектаклендә Тимерхан ролен башкарып, И.Галимов «Иң яхшы эпизодик роль» номинациясендә бүләкләнә.

2021 елдан ул авыл мәдәният йортында сәнгать һәм үзешчән театраль төркем җитәкчесе булып эшли. Өлкәдә чыга торган «Бердәмлек» газетасына даими язып тора. Драматургиядән дә ераклашмый: 2023 елда «Идел-йорт» театрлар бәйгесендә И.Галимовның «Гафу итми, әни, йөрәгем!» исемле пьесасы буенча эшләнгән спектакльне уйнап, коллектив дипломант исемен ала. Нур өстенә нур булып, «Татар моңы мәңге яңгырар» II Бөтенроссия фестиваль-конкурсында солист буларак катнашкан Илшат «Вокал» номинациясендә I дәрәҗә дипломант исеменә лаек дип табыла.

И.Галимовның пьесаларын үзешчән театр коллективлары сорап ала, димәк, халык аларны яратып карый. Әйтик, «Таң атканда» пьесасы (аның хикәя варианты да бар) бик гади сюжетка корылган, әмма кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрнең матурлыгы хакында якты, оптимистик сурәтләр бирелә, халыкның рухи бай булуын дәлилләүче геройлар тасвирлана.

«Язмышлардан узмыш юк» драмасы балаларга артык игътибарның тискәре нәтиҗәсе турында сөйли: җитәкче гаиләсендә үскән Әнвәр, әтисе ярдәмендә армиягә бармый калуга ирешсә дә, сөйгән кызының әтисе белән хыянәтен кичерә алмыйча, үзенә кул сала. Янәшәдә генә тагын бер язмыш: Әфган сугышына киткән егет аннан исән-сау әйләнеп кайта, әмма баласы өчен борчылган әнисе иртә вафат була. Әсәр язмышларның ни сәбәпле фаҗигале юлга борылуы турында уйландыра, игътибарны заманның актуаль мәсьәләләренә юнәлтә.

«Өмет» драмасында Бөек Ватан сугышы елларында балалар йорты төзү вакыйгасы үзәккә алынган. Әсәрне автор яу кырларында башларын салган, Җиңү көнен якынайту өчен тылда аяусыз хезмәт куйган авылдашлары истәлегенә багышлаган. Сюжет чынбарлыкта булган хәлләргә нигезләнгән: Куйбышев өлкәсе Иске Ярмәк авылында балалар йорты ачып (ул 1943 елдан 1964 елга кадәр эшли), бирегә Орёл өлкәсе

Касыйм шәһәрендә булган ятимнәр йортыннан балаларны күчерәләр. Шушы вакыйга драматургка иң авыр вакытта чын йөзләре-холыклары ачылып киткән күп геройларны тулы характерлар буларак тасвирларга мөмкинлек бирә. Броне була торып та, фронтка китәргә ашкынучы Нәгыйм, ир-егетләргә илһам, өмет биреп торучы, ярата белүче, чиста күңелле, тормышны җигелеп тарткан Назыймә кебекләргә каршы куелган Гыйльманов шикелле геройлар да бар. Кызганыч, иҗтимагый-тарихи проблемаларга китерерлек куәткә ия бу мотив үстерелми, атап кына кителә:

«НКВДшник:

– Ә Гыйльмановның эшкә чыкканы бармы, ярдәм итәме?

Шәяхмәт:

– Ул бит бик каты яраланган, эшкә чыгарлык түгел диделәр бит. Әллә алдаганмы, кабахәт? Ул бит сугышка хәтле дә бөтен кушкан эшләрдән шома гына качып кала иде.

НКВДшник:

– Безгә хәбәр килде, иптәшләр, ул үзенә-үзе атып яра алган икән, без аны кулга алырга тиеш (...).

Шәяхмәт:

– (...) Әй Алла, яшьли кеше төсле булмады, тәмам юлдан чыккан икән. Ярар, эзләгәнен тапкан».

Драмада сугыш, ачлык-ялангачлык алып килгән кыенлыкларны җиңеп чыгуда халыкның бердәмлеге хәлиткеч роль уйнаганлык турындагы идея нигезгә салынган. Бу яктан үзәккә ятимнәр йорты ачылу вакыйгасын кую гаять отышлы: ул иң авыр елларда, колхозда эшләргә кеше җитмәгәндә дә, халыкның, бердәм булып, ятим балалар өчен көчен кызганмый хезмәт куюын искәртә, шуның белән иң куркыныч заманнарда да балаларга киләчәгебез, өметебез дип карау булганлыкны, чөнки бу карашның – кешелек язмышы белән бәйле икәнлеген беренче планга чыгара.

«Гафу итми, әни, йөрәгем» драмасында ятимнәр темасы бүгенге көн яссылыгында: кайчандыр баласыннан баш тарткан ана, инде улы үсеп җиткәч, фатир юнәтү өчен баласын эзләп килә. Әлеге гайре табигый хәл авторга егетнең һәм аны карап үстергән ананың кичерешләрен гаять тирән чагылдырырга мөмкинлек бирә. Әсәрнең конфликты кеше тормышын бозарга тайчынмаган Асия белән бәйле һәм гомер буе серне яшергән хатын белән ир арасында туган. Пьесадагы «Аң булыгыз! Бер-берегезгә ышаныч бетсә, ул тормыш түгел. Ир белән хатын арасында яшерен сер булырга тиеш түгел. Арагызда бер сер була икән, димәк, ышаныч бетә, тормыш бетә» дигән соңгы реплика яшьләргә өлкән буыннан үгет-нәсихәт, киңәш булып яңгыраса да, ул тормышчан, заманча ишетелә.

«Йөрәк ярасы» драмасында да тормыш коллизиясе тасвирланган. Рәмзиянең әтисе үләр алдыннан кызына серен ача: авырлы килеш аварийдән чак исән калган кызының малае үлмәгән булуын, балалар йортына тапшырып ялгышканлыгын әйтә. Әсәрнең ахыры хәерле тәмамлана – Рәмзия улын таба, 25 ел элек иптәш кызы нахак яла табып, аны аерган ире белән бергә кала.

Әлбәттә, күзәтеп узган әсәрләрдә заманның кино яки телевидение аша таныш сюжетларын күрмәү мөмкин түгел. Әмма И.Галимов әсәрләрендәге ихласлык, яшәү көченең серләрен мәхәббәттә, туганлык җепләрендә, табигатьтә, хезмәттә, кешелеклелек, иман кебек кыйммәтләрдә табу тамашачыда кызыксыну, теләктәшлек уята. Шуңа да алар үзешчән сәхнәләрдә уйналып киләләр.

И.Галимов исә каләмен башка өлкәдә – прозада сынап карый. Аның «Таң атканда» хикәясе дә укучылар тарафыннан җылы кабул ителә.

Әсәр хәрби фронттан, хезмәтен тәмамлап, туган якларына кайтып баручы Сарыйм Кәримовның юлда күргәннәрен, Япон сугышына китеп баручы улы белән күрешү вакыйгасын үзәккә ала. Искә төшерелгән күренешләр заманның кайбер четерекле мәсьәләләренә дә кагылырга мөмкинлек бирә. Әйтик, хәрби күнегүләр вакытында

ялгыш граната шартлый, матрослар зур зыян күрмәсә дә һәм тикшерү комиссиясе матросларның гаепләре юк дип тапса да, особист Сергей Ильич кебек адәмнәр «халык дошманы дип, һавадан алып эш ачарга» тора. Ләкин дөньяда капитан Дудин кебек мәрхәмәтле кешеләр дә бар. Сарыймга әнә шундый үзе кебек ярдәмчел кешеләр очрап, аларга мөнәсәбәттә геройның характеры ачыла. Җор телле, нечкә күңелле бу образ җанлы булып күз алдына килеп баса. Әсәрнең тормышчанлыгы, бәлки, прототиплары булу белән бәйледер: язучы әсәрендә икетуган абыйсының язмышын гәүдәләндергән.

Башка әсәрләрендәге кебек үк, әлеге хикәядә дә автор, поэтик алым буларак, җыр куллана. Ул әсәрнең лирик-эмоциональ аһәңен билгели, ата белән Япония ягына сугышка китеп баручы улны очраштыра. Бу яктан, әсәрдә Ә.Еники аһәңнәре яңгырап китә.

Проза туган якның матурлыгын сурәтләргә, яшеллеккә күмелгән Юкәле тау, өч яктан авылны уратып, салмак кына аккан Сок елгасы, Әүлияләр тавы, болыннар, Акчарлак, Аккош, Хәсән күлләрендәге әрәмәлекләр, Ярмәк вагын биюләр, табигатьнең матур манзараларына бай күренешләрне сурәтләргә кулай булып чыга. Әлеге әсәр кешенең туган җире белән бәйләнеше нык булганда көчле икәнлеге турындагы фикерләргә китерә, дөньяның матурлыгын танырга өйрәтә.

Тагын бер хикәя – «Урман юлында» – шулай ук үткәннең фаҗигале, үкенечле күренешләрен тергезә. Анда Рәхимҗанның сугышта, яраланып, әсирлеккә эләгүе, сугыш беткәч, лагерьларны узып кайтканда, капка төбендә үк янә милиция алып китүе, бары тик үзе кайчандыр үлемнән коткарган кешенең, аны танып азат ителүе сөйләнә. Ул Рәхимҗанның сеңлесе исеменнән бәян ителә, баласын сугыштан, аннары тоткынлыктан көтеп алган ата белән ананың улларын каршылау һәм шул мизгелдә үк аннан аерылу фаҗигасен үзәкөзгеч бер драматизм белән тасвирлый. Авыр юллар узып, туган өенә кайтып кергән солдатны ишегалдыннан ук якыннары белән күрештермичә дә алып китүләре яшь чыгарырлык үкенечле бер дулкында тасвирлана. Яшь кыз өчен үзе шатлыгын уртаклашкан абзыйның шунда ук әләк өчен телефонга тотынуын аңлау да гаять тетрәткеч хәлгә әйләнә. Шул рәвешле, хикәя сугыш чорының куркытылган кешеләр буыны, алардагы усаллыкның, хөсетлекнең шушы атмосферадан ук килүен күрсәтә. Шушы контекстта, беренче хикәядәге шикелле үк, аның исеме символик яңгыраш ала: илнең, кешеләрнең олы юлда түгел, урман юлында булуын калкуландыра.

Хикәяләрдә дә авторның драматургиядән килүе үзен сиздерә: аларда диалоглар күп булып, төрле интонацияле җыйнак репликаларда төрле характер, темперамент, психология үзенчәлекләре гәүдәләнә, герой күңеленең мөһим тибрәнешләре персонажның сөйләме аша сизелә.

Әлбәттә, И.Галимовның әсәрләрен әле җитлеккән, камил текстлар дип бәяләп булмас. Җыйнак кына традицион сюжетларга корылган текстларда кайчак схематиклык күзгә ташлана, тормыштагы катлаулы социаль-иҗтимагый күренешләр үзәккә алынмый. Әмма бу иҗат тормышчанлыгы, ышандыру көче, халыкчан гыйбарәләргә бай теле, хикәяләүнең сыгылмалылыгы, төгәллеге белән игътибарны җәлеп итә.

Иске Ярмәк авылына 1737 елда рәсми нигез салынган дип исәпләнсә дә, аның оешуына 500 еллап тирәсе бар дигән фараз яши. Татарстаннан ерактагы Самара төбәгендә яшәп ятучы халык, зур тарихы булган Иске Ярмәк авылы милләтпәрвәр, татар мәдәниятенә хезмәт итә торган шундый егетләре булганда, татар рухын югалтмас, билгеле. Алга таба да бу төбәктән үз халкының бай тарихы һәм гыйбрәтле язмышы, гореф-гадәтләре һәм аның данлыклы шәхесләре белән горурланучы язучылар чыгар дип ышанабыз. Ә Илшат Галимовтан татар укучысы заман проблемаларын киңрәк яктырткан әсәрләр көтә.

**Венера МАКАРОВА,**
*филология фәннәре докторы.*

# НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ КАЙЛАРГА КИТӘ...

## Габденнасыйр Хөсәеновның балалары

Габденнасыйр Хөсәенов һәм аның хәләл җефете Фатыйма биш ул һәм бер кыз тәрбияләп үстергәннәр.

Чынлыкта Фатыйманың ничә бала табуы һәм ничәсенең үлгәнлеге безгә билгеле түгел. Беренче бала дип исәпләнгән Габделхәй 1820 елда – Габденнасыйр һәм Фатыйма никахының сигезенче елында гына туа. Ике елдан соң (1822) Бибиҗәмилә исемле кызлары дөньяга килә (*ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 96 эш*).

1823 елда Габденнасыйр Хөсәенов гаиләсендә малай туа, аңа Габделкаюм дип исем кушалар. Әмма 1824 елда малай үлә. Һәм 1825 елның 2 (14) февралендә туган балага да Габделкаюм дигән исем бирәләр (1834 елгы ревизия кенәгәсендә Каюмның яше ялгыш 14 дип күрсәтелгән (*ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 96 эш*)). Габденнасыйр баласының туган көнен һәм аның Габделкаюм исемле булуын үзе күчереп язган «Әмин тәзәк» исемле кульязма хезмәт битендә теркәп калдырган (*Гайнетдин М. Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат // Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 1 том. Казан, 2003. Б.3-4*).

Аннан соңгы елларда Габденнасыйрның гаиләсе ике ел саен ишәеп барган. Габделгани дөньяга 1829 елда аваз сала (1834 елны аңа 5 яшь була), дүртенче уллары Габделвәли 1831 елда туа (1834 елны аңа 3 яшь була). Төпчек уллары Габделкави 1833 елны дөньяга килә (халык исәбен алган 1834 елның 12 апрель көнне ул 6 айлык бәби була) *(ТДА, 3 фонд, 2 тасв., 96 эш)*.

Гаилә башлыгы яраткан кызы Бибиҗәмиләне өйдә үзе укытып үстерә – абыстайлыкка хәзерли – һәм Кармыш авылының имам-хатыйбы Вәли муллага кияүгә бирә *(Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г.Гомәров (проект җит. һәм җавап. мөх.), З.З.Рәмиев, А.М.Ахунов; төзүчеләр: Л.Ш.Гарипова, Г.М.Ханнанова. Казан, 2020. Б.54)*.

Ата кеше улларының киләчәген дә алдан кайгырта.

Габденнасыйрның коммерция җәһәтеннән сәләтле олы улы Габделхәйгә (1909 елда вафат) *(Ногман М. Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кульязмаларының тасвирламасы. III чыгарылыш. Каюм Насыйри кульязмалары / Җаваплы редакторы А.Г.Кәримуллин. – Казан: ТАССР Культура министрлыгының Татполиграф типографиясе, 1958. Б.37)* өметләре һәм планнары зурдан була. Гаилә башлыгы, улын русчага өйрәтеп һәм арыш белән арпа сатудан кергән 150 сумны биреп, Габделхәйне сәүдәгәрлек эшенә җибәрә. Габденнасыйр 1847 елда улына тагын 700 сум бүлә *(Оренбург иҗраә шәргы ислам өчен насыйп кыйлынмыш мәхкәмәи исламиясенә Зөя өязе Рече Шырдан карьясенең Габденнасыйр Хөсәен угылының вәрәсәләреннән түбәнчелек илән гариза // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф.Исламов. – Казан, 2017. Б.721-722)*. Күрәсең, шуннан соң Габделхәй Мәскәүдә сабын һәм 1861 елдан соң шәм җитештерү буенча предприятие ача.

Билгеле булганча, XVIII гасырның соңгы чирегендә татар сәүдәгәрләре Оренбург һәм казакъ далаларыннан сабын кайнату өчен арзанлы чимал кайтартуны җайга салалар, шуның нәтиҗәсендә губерна каласы булган Казан илдә иң эре мануфактура химиясе сәнәгате үзәгенә әверелә, бөтен илгә даны таралган «Казан сабыны»н зур күләмнәрдә җитештерә башлый. Әмма XIX гасыр урталарына Казанда җитештерүнең әлеге тармагы, илнең үзәк губерналары белән көндәшлектә җиңелеп, элгәреге әһәмиятен югалта. Ә Габделхәй Мәскәүдә сабын җитештерүдә уңышларга ирешә.

Габделхәй, гашыйк булып, 1858 елда Себер сәүдәгәре Гибай кызына өйләнә, никахы исәп-хисапка корылмаган була *(Абыйсы Габделхәй язган хатлар // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.605)*.

Габделхәй сабын белән генә түгел, башка шуның ише товарлар белән дә сату итә. Сәүдәгәр, башкалалардан тыш, ел саен үзенең предприятиесендә җитештерелгән һәм башка продукцияне Киев, Вильна, Түбән Новгород, Тула, Саратов, Бөгелмә, Әстерхан һәм башка шәһәр ярминкәләренә дә алып барып сата. Максатчан һәм тырыш холыклы Габделхәй ярты гомерен Россиянең Европа өлешендә урнашкан шәһәрләрендә йөреп уздыра, туган нигезгә еш кайтып йөри алмый (*Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.44*). Димәк, ул ил буйлап алыш-биреш итәргә мөмкинлек бирүче 2 нче гильдия сәүдәгәре шәһадәтнамәсенә ия булган.

Эшлекле даирәләрдә Габделхәйне «Казанның сабын кайнату остасы» буларак беләләр *(Абыйсы Габделхәйгә язган хатлар // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.564*). Булдыклы эшмәкәр, әтисе белән киңәш-табыш итмичә, Мәскәү шәһәренең вакытлы сәүдәгәрләре исемлегеннән чыгып, даими сәүдәгәр булып языла, алай гына да түгел, «Хөсәенов» фамилиясен «Казанский»га алыштыра.

Габделхәй эшләп тапкан мал «гаилә капиталы» булып санала: әти-әнисенең табышның бер өлешенә исәп тотуы, аңа еш кына акча җибәрүен сорап, хат язуы шуның белән аңлатыла. Шунысы игътибарга лаек: икътисади хәлләре нинди булуга карамастан, Габденнасыйрның бөтен балалары да әти-әнисенә мөмкин кадәр матди ярдәм күрсәтә торган булганнар. Гомумән алганда, Габделхәй төрле яклап – киңәш белән дә, матди яктан да – туганнарына ярдәм итеп торган, әти-әнисе турында кайгырткан, гәрчә әтисенә язган хатларында еш кына акча җитмәве турында зарлануы да билгеле. Әйтеп кителгәнчә, Габделхәй 1874 елда үз акчасына туган авылында агач мәчет салдыра, анда төпчек энесе Габделкави мулла була.

Габделхәйнең үз-үзен тотышы 1871 елда әтисе үлеменнән соң кискен үзгәрә, ул эчкечелек белән нык мавыга башлый. Бу хәлләргә аптыраганнан, Габделхәй белән сөйләшергә дип, аның янына Габденнасыйрның бертуганы Мөхәммәтгалимне җибәрәләр. Шуннан соң Габделхәй Мәскәүдәге предприятиесен сатып, 1873 елда Казанга күчеп кайта. Габделхәй, әтисенең васыяте буенча, гаилә капиталын тотучы булып кала, һәм шәһәрдә арендага биреп акча эшләү өчен өч йорт сатып ала *(Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.44)*.

Китап укучылар даирәсендә Г. Казанский өй шартларында шәһәр фатирлары өчен электр кыңгыравы һәм көзге ясарга өйрәткән фәнни-популяр китап авторы буларак таныла. Шулай ук берничә тапкыр төрле авторларның әсәрләрен бастырып чыгарырга матди ярдәм күрсәтүе дә билгеле (*Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.44*).

Габденнасыйрның икенче улы – Габделкаюм – бала чагында чәчәк һәм кызамык белән авырый. Малайның сул күзе тумыштан сукыр, уң күзенә бераз ак төшкән була, кызамыктан күз кабагына зыян килә, һәм ул күзен каплап тора: шул сәбәпле күзен кысып йөргән кебек тоела *(Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.483)*. Шул рәвешле, малайга «Сукыр Каюм» кушаматы тагылып кала.

Каюм кечкенәдән тырыш һәм зирәк малай була, 7-8 яшеннән әтисеннән укырга һәм ислам дине гыйлеменә өйрәнә башлый, 9 яшендә иркен рәвештә укый-яза белә. Казанга укырга киткәнче, яшүсмер әтисенең кулъязма китапларын күчереп язу белән дә шөгыльләнә *(Җәләй Л. Каюм Насыйри (1825-1902) // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945. Б. XIV)*. Мәдрәсәгә киткәнче, әтисе аны каллиграфия серләренә төшендерә, Каюм матур итеп язарга өйрәнә (Р. Фәхретдин үзенә билгеле булган матур язуияләре арасында К.Насыйрины Мөхәммәтҗан Аитов, Мөхәммәтгали Мәхмүдов һәм Латыйфулладан гына калыша иде дип искә ала) *(Фәхретдин Р. Габделкаюм Насыйри // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.312)*.

Әтисе Каюмда эшкуарлыкка һәвәслек күрми, шуңа да аңа мәдрәсәне тәмамлау мөмкинлеге бирә. Казанда, эре сәүдә-сәнәгать үзәгендә яшәп, Каюм әти-әнисенә генә түгел, бертуган энеләренә дә, апасы белән җизнәсенә дә ярдәм итеп тора, киемсалым, баш киемнәре, аяк киемнәре тектерү, хуҗалык кирәк-яраклары сатып алу кебек йомышларын төгәл үти. Аның туганнары белән аралашуы, нигездә, шуның ише мәшәкатьләрне хәл итү аша бара.

Габденнасыйр планы буенча, аның уллары эшмәкәрлектә бер-берсенә аркадаш булырга тиеш була. Каюм да гаилә бизнесына җәлеп ителә. Аерым алганда, 1850 нче елларның икенче яртысында – 1870 нче еллар башында ул даими рәвештә, ел саен диярлек, берничә дистә мең сабын тутыру өчен агач савытлар эшләттереп, аларны Мәскәүгә җибәреп тора. Габделхәй, Каюмның җаваплы һәм ышанычлы икәнен белеп, күпчелек очракта Казанда җитештерү өчен кирәкле материалларга заказ бирүне аңа йөкли, энесе белән еш кына киңәшләшә дә *(Ногман М. Күрс. хезмәт. Б.42-43)*.

Габденнасыйр, Каюм һәм төпчек улы Габделкавидан (аңа, татар гаиләләрендәге гадәт буенча, төп нигездә калып, әти-әнисенең имин картлыгын кайгырту бурычы йөкләнә) тыш, калган улларын Мәскәүгә, Габделхәйнең сабын кайнату мануфактурасының «җитештерү практикасы»на, эшкуарлык серләренә төшенергә җибәрә. Бу исә Габделвәли һәм Габделганинең (1847 һәм 1851 елда аның Каюм абыйсы янында Сәгыйть мәдрәсәсендә укуы билгеле) (*Әти-әнисенә язган хатлар //Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б.540*) мәдрәсәдә берничә генә ел укыганлыгын аңлата. Бигрәк тә соңгысының туганнарына язган хатларында грамматик хаталар күп очрый.

Габденнасыйрның өченче улы Габделгани, олы абыйсының Мәскәүдәге сабын кайнату предприятиесендә өйрәнчек булып йөргәннән соң, мөстәкыйльлек алырга теләп, Себергә, Байкал күле аръягына күчмә тормышта яшәүче монголлар һәм орочилар янына китә, күпмедер вакыт далада почта ташый. Сәүдәгәр Перминкинга аена 15 сум жалованьега хезмәткә ялланып, сәүдә белән шөгыльләнә. Аннан соң тайгага китә, алтынга бай руда катламы эзләп таба һәм алтын приискасын җитәкли. 1867 елда Каюмга язган хатында үзенең Нарак приискасында староста булып эшләвен, аның карамагында 300 ат булуын, башлыча сөргенгә җибәрелгән кешеләрдән торган 70 эшчегә җитәкчелек итүен әйтә. Староста буларак, Габделганинең вәкаләтләре зур була: аның рөхсәтеннән башка ярдәмчеләре дә, денщиклар да яшәгән урыннарыннан чыгып китә алмый. Шулай да Себернең кырыс табигать шартлары Габделганинең сәламәтлеген какшата (*Ногман М. Күрс. хезмәт. Б.45-46)*. Ул рус кызына өйләнә, бу никахтан бер балалары туа. Габделгани чит җит җирләрдә вафат булып кала.

Габденнасыйрның дүртенче улы Габделвәли дә Габделхәй янында сабын кайнату серләренә өйрәнә, әмма тиешле дәрәҗәдә тырышлык күрсәтми. Шуннан олы абыйлары, күпмедер акча биреп, егеткә «үз эшен» башлап җибәрергә мөмкинлек тудыра. Ләкин эчү белән мавыккан Габделвәлинең эше килеп чыкмый. Абыйсы энесен, үзе белән компаньон итеп, ярминкәләргә алып йөри. Каюмга язган хатларында Габделвәли олы абыйсының акчаны аз түләвенә зарлана, гәрчә аның белән бердәй хезмәт куйса

да. Күрәсең, олы абыйлары Габделвәлигә булган ышанычын югалткан *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле Б.44-45. Г.Рәхим, ялгышып, Габделвәлине Габденнасыйрның өченче улы, ә Габделганине дүртенче улы дип яза).*

Габденнасыйрның төпчек улы – Габделкави (1901 елның башында вафат булган), әтисе планлаштырганча, 1864 елның 12 мартында Кече Шырдан авылы мәчетенә имам-хатыйп итеп билгеләнә. Ул төп нигездә әти-әнисен тәрбияли. 1872 елда аның мәктәбендә 40 ка якын ир бала укый. Хезмәте өчен Габделкави мәхәлләнең һәрбер кешесеннән 10 фунт (4,5 кг) икмәк ала *(ТДА, 2 фонд, 2 тасв., 273 эш)*. Моннан тыш, мулла гаиләсенең кереме яңа туган балага исем кушу, яшь парларга никах уку, үлгәннәргә җеназа чыгару кебек йолаларны башкарган өчен бирелгән садака хисабына да беркадәр арткан. Шулай ук Корбан гаетеннән соң мәхәллә халкы садака хисабына корбан итеп чалынган терлекләрнең тиресен китерә торган була. Бу керемнәрнең бер өлешен мулла мәктәп чыгымнарына тоткан.

Муллалык вазифасына керешеп, ике ел узгач, Габделкави, рухани вазифасын башкару үзенә генә кыенга килә дип исәпләп, авылдашларыннан ярдәмче итеп мөәзин билгеләүләрен сорый. Мулланың үтенечен канәгатьләндереп, 1874 елның 3 гыйнварында авыл старостасы Сиражетдин Хәйбуллин рәислек иткән җыенда 1842 елда туган Хөснетдин Вәлиуллинны мөәзин итеп сайлап куялар. Ул хәрби хезмәттән азат ителгән һәм мәдрәсә белемле кеше була. 1874 елның 18 февралендә Казан губерна идарәсе аны Уфада имтихан бирергә җибәрә. Х.Вәлиуллин, шул ук елның июнендә Мәхкәмәи шәргыянең сынавын уңышлы узып, имам үзе булмаганда, аның вазифасын башкара алу хокукына ия мөәзин дәрәҗәсен ала *(ТДА, 2 фонд, 2 тасв., 525 эш).*

Нәсел шәҗәрәсеннән күренгәнчә, Габделкави гаиләсендә Хәбирә, Мәэнүнә исемле ике кыз һәм Габделкасыйм белән Габделхак исемле ике ул үсә *(Фәхретдин Р. Габделкаюм Насыйри. Б.311).*

Шул рәвешле, Габденнасыйр Хөсәенов гаиләсе берничә яктан игътибарга лаеклы.

Гаилә башлыгының, мулла вазифасыннан баш тартып, эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башлавы үз заманы өчен гадәттән тыш хәл буларак кабул ителгән.

Габденнасыйр, олы улы Габделхәйгә сәүдә итүне оештырып биргәч, бөтен игътибарын балалар тәрбияләүгә юнәлтә һәм мәдрәсәдә укыганда мавыккан шөгыленә күңел бирә – кульзмалар күчерә, дини трактатлар яза, шулай ук улларын укырга һәм язарга, ислам нигезләренә һәм каллиграфия сәнгатенә өйрәтә, аларны кульязмалар күчереп язарга күнектерә; изгелеккә, иманлы булырга өнди. Шуңа да авылдашлары аны хөрмәт белән «Габденнасыйр мулла» дип йөртә. Габденнасыйр туган ягының тарихы һәм мәдәнияте, халык авыз иҗаты белән кызыксына, күрәсең, аның бу кызыксынуы улларына да күчкән.

Каюм Насыйри үскән гаиләдә һәрвакытта да рус хакимиятләрендә хезмәттә булган ата-бабалары ирешкән казанышлар үрнәк итеп куелган. Габденнасыйр гаиләсендә бабаларының җәмгыятьтә югары дәрәҗәләргә ирешүе һәм тирә-якта абруй казануы рус телен белүләренә һәм хакимиятләр белән хезмәттәшлек итүгә бәйле дигән ышану яши. Шуңа да рус телендә укый-яза белү бу нәселдә традиция булып киткән, ул үзенә күрә бер өстенлек, абруй-дәрәҗә булган, дәүләт телендә сөйләшмәгән халык арасында тормыш итү өчен керем чыганагы буларак та гарантия биргән. Үтенеч-гаризалар язу белән шөгыльләнеп һәм хакимият каршында авыл җәмгыятенең ышанычлы вәкиле булып, Габденнасыйр ата-бабаларының һөнәрен дәвам иттергән. Нәтиҗәдә Габденнасыйр гаиләсенең барлык әгъзалары да рус мәдәниятенә һәм рус кешеләренә карата ачык мөнәсәбәттә үсә.

Кайгыртучан ата максатчан рәвештә туган нигездә калырга тиешле Габделкавидан һәм күзләре сәламәт булмаган Каюмнан кала өч улын эшкуар булырга әзерли, шул рәвешле алар имин-мул тормышта яшәрләр, авыр крестьян хезмәтеннән котылырлар дип ышана.

Каюм менә шундый гаиләдә үсә.

## Каюм Насыйри – Сәгыйть мәдрәсәсе шәкерте

1841 елда белем алуын дәвам итү өчен мәдрәсә сайлаганда, Каюм ике ут арасында кала: данлыклы Кышкар мәдрәсәсенә барыргамы, әллә Казанның берәр дини белем бирә торган уку йортына керергәме? 17 яшьлек егет мөстәкыйль рәвештә икенче вариантны сайлый. Уку йортын сайлаганда, аңа туганлык хисләре дә йогынты ясый. Әтисенең энесе Мөхәммәтгалим Ак мәчет мәхәлләсендә мөәзин булып хезмәт итә, ә мәчет каршындагы мәдрәсәдә әтисенең остазы булган авылдашы Сәгыйть мулланың (1831 елда вафат булган) варислары укыта.

Сәгыйть мулланың улы Габделсаттар, татар мөдәррисләрендә укыганнан соң, XVIII гасыр ахырында белем алуын Бохарада дәвам иттерә. 1813 елда тарихи ватанына кайтып, Ак мәчеттә икенче мулла һәм бер үк вакытта Казан һәм Казан төбәгенең ахуны булып тора. Мәдрәсәдә укытмый; ел саен Түбән Новгородка, халыкара Мәкәрҗә ярминкәсенә барып, анда ярминкә имамы вазифаларын башкара. 1824 елда мөфти М.Хөсәенов вафатыннан соң, ахун Габделсаттар әлеге югары вазифага дәгъва итеп карый. Ләкин, Казан губернаторының теләктәшлек итүенә карамастан, мөфти билгеләгәндә, Оренбург генерал-губернаторының сүзе өстен чыга. Габделсаттар 1830 елда Мәкәрҗә ярминкәсендә чума авыруы йоктырып, вафат була (*Шигабутдин Марджани. Полезные вести о состоянии Казан и Булгара (Муставад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар); часть вторая, перевод на русский язык; предисловие и перевод с арабского, старотатарского Р.А. Адыгамова. Казань, 2002. С.79*).

Сәгыйть мулланың икенче улы – Габделгаффар – шулай ук Бохарада укый. Ш.Мәрҗани мәгълүматларына караганда, аның Казанга кайтып укыта башлавы Сәгыйть мәдрәсәсенең абруен бик нык югары күтәрә, данын тиз арада еракларга тарата. Ул да 1830 елда – абыйсын җирләп, бер ай чамасы узгач – вафат була *(Шунда ук. Б. 79-80)*.

Каюм мәдрәсәдә башта шәкерт Шәмсетдин бине Шәмсуардан белем ала, аннан соң Сәгыйть мулланың өченче улы Әхмәт хәзрәттә (1867 елда вафат) укый. Әхмәт хәзрәт, Бохарада укуын тәмамлагач, 1830 елда Ак мәчеткә имам-хатыйп һәм шундагы мәдрәсәдә мөдәррис булып тәгаенләнә. Ш.Мәрҗани аның турында болай дип яза: «Бу кеше бик тыйнак, яхшы тәрбияле, кеше хәленә керә белә торган иде, башкалар белән һәрвакытта да яхшы мөнәсәбәттә булды. Мөдәррис буларак, гыйлемлелеге ягыннан дан тотмаса да, ул, агаларын да узып, озын гомер кичерде, Казан голәмәләре һәм халкы арасында ихтирам яулады. 1276 елда (1859) ике бистәнең дә халкы бер булып, аны Корбан бәйрәмендә гает намазы укырга имам итеп сайлады. Без Казанга килгән елны (1849 ел – *И.З.*) аның мәдрәсәсендә ун мөгаллим һәм бер шәкерт бар иде...» *(Шунда ук. Б. 80-81)*. Ш.Мәрҗани телгә алган шәкерт Каюм Насыйри булып чыга инде.

1851 елның 19 декабрендә Каюмга әнисе һәм энесе Габделкави язган хатта шундый юллар бар: «...бу көннәрдә Кышкарга китмәгәнсең икән, әлхәмделиллаһ. Безнең морадыбыз синең Казанда торуың иде. Бәбкәм, ник ул кадәр уфтанасың? Кышкарга барырга без дә бик җыраксынадыр идек. Ходай теләвеннән тыш булмас. Ходай Тәгалә Казанда гына торып тәгалллекъләнергә *(бәйләнештә, элемтәдә торырга)* насыйп итсен дип, догалар кыйлып торабыз. [...] Кышкарга барып, нә ашыйм, нә эчим дип торганчы, Нигъмәтҗанның хатынын күрә торгансыңдыр. [...]» *(Әнисе һәм энесе Габделкави язган хатлар // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. – Казан, 2017. – Б.587-588)*. Димәк, Каюм, Сәгыйть мәдрәсәсендә укытудан канәгать булмыйча, әти-әнисенә Кышкар мәдрәсәсенә күчәргә теләвен әйтеп хат язган булган. Шәкертнең әти-әнисе баштан ук Кышкар мәдрәсәсен ераксынган һәм улларының ашау-эчүен кайгыртуга, күрәсең, авылдашлары Нигъмәтҗанның хәләл җефетен җәлеп иткән булганнар.

Каюм Кышкарга китәргә өлгергәнче, авылдан тагын бер хат килеп төшә. Хатта аның

тәрбиясенә Сәгыйть мәдрәсәсендә укырга 18 яшьлек энесе Габделкавиның барачагы турында әйтелә. 1852 елның гыйнварында Каюм Кышкар мәдрәсәсенә барып кайта һәм Казанда кала *(Әти-әнисенә язган хатлар // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. – Казан, 2017. – Б.541)*. Без, Габделкавиның кыш уртасында, Сәгыйть мәдрәсәсенә, Каюм карамагына укырга җибәрелүен, әти-әнисенең улларын Казанда укытып бетертү өчен махсус кылынган эше дип бәялибез.

Шулай итеп, әлеге дини уку йортында тырыш шәкерт 14 ел дәвамында схоластик белем ала, гарәп һәм фарсы телләреннән белемен камилләштерә, кадими мәдрәсәдә укылырга тиешле дини китапларны өйрәнә. Шулай да аның текстлары белән таныш Ризаэтдин Фәхретдин *(Фәхретдин Р. Габделкаюм Насыйри. Б.317)* һәм Гали Рәхим Каюм Насыйриның гарәп телендә хаталы язганын билгеләп үтәләр. Гарәп телен сыйфатлы итеп өйрәнүдә хилафлыклар татар схоластик мәдрәсәләренең йомшак урыны була.

Каюм мәдрәсәне пишкадәм, ягъни мәдрәсәнең барлык курсларын да уңышлы үткән шәкерт булып тәмамлый *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 45)*.

Сәгыйть мәдрәсәсендә укыган вакытта Каюм белән Габделкави әтиләре Габденнасыйр теләге белән Тихвин чиркәвенең ишегалдында урнашкан Михайлов училищесында да белем алалар *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Казан, 2020. Б. 86)*. Алар биредә ярыйсы гына укырга-язарга өйрәнәләр. Рус теле дәресләренә хәзрәт рөхсәте белән йөриләр.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: мәдрәсәдә укыган чорда Каюм татар халык авыз иҗаты белән кызыксына һәм аның үрнәкләрен дә җыя башлый. Каюм 1898 елда тюрколог Н.Ф. Катановка тапшырган «Рус-француз сугышы бәете» кулъязмасының ахырына «1855 елның 12 февралендә тәмамланды» дип теркәп куйган була *(Халык иҗаты әсәрләре // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. Казан, 1874. Б.337)*. Ихтимал, ул вакытта Каюм халык авыз иҗаты белән әтисенең төбәк тарихына һәм мәдәниятенә булган кызыксынуына ияреп мавыгып киткәндер. Мәдрәсәдә вакытта бәетне күчереп язуы Насыйрины яңа яктан – халык мәдәнияте белән кызыксына торган шәхес буларак ача.

Шулай ук Каюмның Михайлов училищесында рус мәгарифе һәм мәдәнияте турында алган белемнәре һәм яңа мәгълүматны татар җәмгыятенең дини-мәдәни хәле белән чагыштырып карау мөмкинлеге аның киләчәк тормыш юлын билгеләүдә хәлиткеч рольне уйнаганлыгы шик тудырмый.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

## Әдәби мизгелләр

*Июль башында «Казан утлары» редакциясе Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә оештырган «Яңа исем» иҗат лабораториясендә катнашучылар һәм аларның остазлары, язучылар, журналистлар халык шагыйре Равил Фәйзуллинның туган ягы – Балык Бистәсенә сәфәр кылды. Сәфәр барышында алар Юлсубино авылында шагыйрьнең салон-музеен карады, Яңасала авылында тарихчы, туган якны өйрәнүче галим Нурулла Гарифның шәхси музеенда, чишмәләрдә, борынгы Чаллы шәһәрлеге урынында булды. Фотоларда – әдәби сәфәрдән мизгелләр.*



*Яшь иҗатчылар Равил Фәйзуллинның салон-музеенда очрашуда.*
*Сулдан уңга: Рәфидә Галимҗанова, Айзилә Габдрахманова, Ихтыяр Кыямов, Равил Фәйзуллин (утырган), Азалия Сабирова, Мәрьям Ибраһимова, Гөлинә Фәрхуллина.*



*Остаз Ләбиб Лерон һәм Равил Фәйзуллин яшь иҗатчыларга әдәбият серләрен ача.*




*Татарстанның халык язучысы Вахит Имамов салон-музейга үзенең «Ерактагы якын туганнар» китабын бүләк итә. Сулдан уңга: Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон, Вахит Имамов.*



*Тарихчы Нурулла Гариф кунакларны Чаллы шәһәрлегенең тарихы белән таныштыра.*



*Юлсубино авылындагы «Күгәрчен чишмәсе»ндә җанга да, тәнгә дә сихәт алган мизгел.*



*Юлсубино кунаклары. Басканнар (сулдан уңга): Алинә Хәбибуллина, Гүзәлия Сафиуллина, Рөстәм Галиуллин, Нәзирә Гыйззәтуллина, Нурулла Гариф, Рәфидә Галимҗанова, Айзилә Габдрахманова, Азалия Сабирова, Мәрьям Ибраһимова, Светлана Мөхәммәдиева кызы Мәдинә белән, Ихтыяр Кыямов, Камилә Билалова, Гөлинә Фәрхуллина, Игорь Кузнецов; утырганнар: Хәмит Хәлиуллин, Ләбиб Лерон, Равил Фәйзуллин, Ландыш Әбүдәрова, Гөлүсә Закирова.*

*Ленар Гобәйдуллин һәм Вахит Имамов фотолары.*

# *Хатлар яздым утырып*

## Фәсәхәт апа хатлары

*31 декабрь, 1972 ел*

Хөрмәтле Рәдифкә!

Сезне Яңа 1973 ел белән котлыйм!

Сезгә бу данлы яңа ел көч-куәт, гайрәт, зиһенегезгә зирәклек, иҗатыгызда яңа уңышлар, гаиләви шатлыклар өстәп китерсен!

Барча туган-тумача, дус-ишләрегезгә шул ук изге теләкләрем булыр!

Сезгә зуррак итеп тагы язган идем. Өйдә булмадыгыз бугай, җавабыгыз юк... Шулай да ышанам-ышануын...

Пермь-Мәскәүдән җирле радио аша хәбәрләр тыңлаштырам. Үткән айда булса кирәк, сезнең Пермь-Кудымкар тирәсенә кунакка килгәнлегегезне ишеттем. Язучылар белән очрашкансыздыр, дөрес аңлаган булсам. Аннан бәлки Уфа-Дүртөйле тарафларына юнәлгән булуыгыз да ихтимал – туган ягыгыз бит.

Ни булса да, эшегездә уңышлар, иминлекләр генә булсын.

Кайчакта хат башкалар кулына төшеп, юкка чыга яисә аяк астына төшеп таптала да бит. Анысы сезнең арада булмас дип өметләнәм.

Ярый, хушыгыз. Сәлам сезгә дә, гаилә әгъзаларыгызга да.

Хатны начар яздым инде, карчыкларча гына. Гафу итегез. Бик бетерештем инде. Тик хат язарга кечкенәдән һәвәслегем көчле булганга әле дә сүрелмим. Шуңа сөенәм дә.

*Сәлам белән, Фәсәхәт апагыз.*

***

*19 декабрь, 1973 ел*

Рәдиф энекәш!

Котлы булсын Яңа ел!

Мин сездән икенче мәртәбә 1972 елның 1 ноябрендә язган хатыма җавап алмадым. Сез бәлки сәфәрдә булып калгансыздыр,ә хат югалгандыр.

Былтыр Әсәнгә бара алдыгызмы? Фәнүс яисә андагы укытучы ханым Ольга Янгированы очратмадыгызмы?

Ш.Бабич хакында нинди хәбәрләр бар? Былтыр да, быел да нинди үзгәрешләр бар? Курыкмагыз, мин гап-гади бер карчык кына. Үзем 24 яшьлек Шәехзадәдән 18 яшькә кечемен, ә үзем 60 яшьтәмен. Моның исәбен укыган кешеләр чыгара ала. 1962 елда Темәстә укучы балалар мине Бабичның энисе дип йөрттеләр. Мин аларга әйтеп үткән идем үземнең Шәехзадәдән күпкә кечерәк булуымны. Ә алар миңа карыйлар да Хуҗа Насретдин сыман дөресен оныталар.

Мөмкин булса, хатымны җавапсыз калдырмагыз әле.

Миндә сезнең «Шагыйрьнең эзләреннән» дигән мәкаләгез бар. Халык телендә бер сүз йөри бит әле: «Бабичка карата ике төркем бар. Берсе – иң зур төркем – халык. Ул Бабич яклы. Икенчесе – аңа каршылар. Алар аз, ләкин көчлеләр. Өченче төркем дә бар диләр. Алары бу ике төркемнең ни эшләгәнен күзәтеп, язып баручылар. Болары да көчсез түгел сыман. Әлбәттә, киләчәктә бөтенесе дә ачыкланыр.

Әй Рәдиф, нишли генә алсыннар инде алар? Ш.Бабич турындагы барлык кыйммәтле кәгазьләрне делолардан юк итеп бетергәч.

Дүртөйледә хәзер Бабичка карата кире карыйлар. Үзем барып, үзем күреп, сынап белдем бит.

Сүз күп. Мин шул күп язып юанам. Ә кешегә кирәкми ул.

Хушыгыз.

*Сәлам белән, Фәсәхәт апагыз.*

## Гамил Афзал хатлары

*22 сентябрь, 1988 ел*
*Әлмәт*

Мелла Рәдиф!

Сине сагынып-саргаеп, бер күрергә зар вә интизар улып, күпдин-күп сәлам!

Миңа бер кош теледәй хат яз әле, дус, киләсе елда журналда минем шигырьләргә урын бирәсезме? Сездә минем шигырьләр бик күптер, җитмәсә, тагын өстәп җибәрермен.

Бу да мәгълүм булсын: «Казан утлары»ның бу 9 нчы санында «Бер булсын – берәгәйле булсын» исемле мәкалә язган Айрат Ибраһимовның адресын миңа җибәрче, зинһар, шуңа рәхмәт әйтер идем.

*Гамил Афзал әл Болгари дип белгәйсез*

***

*25 апрель, 1995 ел*
*Әлмәт*

Мелла Рәдиф Гаташ галиҗәнапларына,
бик сагынып, бик саргаеп, бер күреп сайрашырга зар вә интизар улып, күпдин-күп, чукдин-чук нефть исле сәламнәремне күндереп калам.

Бу да мәгълүм улсын: исән-сау торсак, Алла боерса, бу фәкыйрегезгә киләсе 1996 елда 75 яшь тулачак. Олы шагыйрьләр Ходай янына китеп беткәч, иң карт хәерчегез булып, мин калдым бугай инде. Шул 1996 елны билгеләп үтү кайгысы белән сиңа шигырьләрне күбрәк җибәрәм, иркенләп сайларлык булсын. Быелның 2 нче санында минем шигырьләрне бик күп итеп, яхшы, уңышлы итеп, оста гына тезеп чыгаргансыз, шуңа Сезләргә күп-күп рәхмәтләр яусын, Аллаһы Тәгалә Сезләргә иң чибәр кызларны бирсен дип хәер-дога кылам.

*Гамил Афзалов*

## Сәйфи Кудаш хаты

Мөхтәрәм Рәдиф туган!

Мин ике ай больницада ятып, аннан үз аякларым белән чыктым. Өйгә кайтып керүгә, мине «Казан утлары» нурлы йөзе белән каршы алды.

Күзләр сукырайгач, мин хәзер үзем уку бәхетеннән мәхрүм калдым. Укырга кирәкле нәрсәләрне зур кызым Сөембикә укый. «Казан утлары»ның 11 нче санындагы «Бабич»ны иң элек Сөембикә ике тапкыр укып чыкты. Ул ара да булмады, аның кызы Наилә эштән кайтып керде. Ул арып һәм ачыгып кайтуга карамастан, «Бабич»ны укыгач кына, өстәлдәге ашка кашыгын сузды. Сәгать унда, арып-талып, Сөембикәнең гомер юлдашы проф. Рөстәм Кузеев эштән кайтып керде. Журналны аңа тоттырдылар... Рөстәм «Бабич»ны эчтән, үзе генә укып чыкты. Без тыннарыбызны эчтән генә алып, аның кыяфәтен күзәттек. Ул укып чыккач, иң элек кулының сырты белән журналга сукты да: «Шәп!» – дип кычкырып җибәрде. Шуннан соң кычкырып, яңадан укыды.

Бу хәл миңа больницада врачлар бирмәгән бер шифалы дару кебек тәэсир итте. Әллә нишләп, җегәрләнеп киткәндәй булдым.

Шул минутта Бабичны терелтәсе һәм журналны үзенә укытасы килде.

Күзләрем сукырайгач, минем башланган, кайсысы яртылаш, кайсысы өч өлеш, кайсысы каралама план рәвешендә җылатып яткырган дүрт кулъязмам бар. Шуларның берсе – «Мәхәббәт һәм матурлык шагыйре» исемлесе Ш.Бабич турында аерым истәлекләр китабы. Аның 95 сәхифәсе машинкадан чыгарылган, тик «Бал корты турында баллада» дип аталган иң зур бер главасы гына язылып бетмәгән. Бу бүлек әсәрнең төп идея-эчтәлеген тәшкил итә. Аны «Галия»нең ун еллык юбилей тантанасын тасвирлап һәм азактан әдәбият кичәсендә Бабичның З.Камалига багышланган «Бал корты» исемле балладасын уку белән тәмамлап була.

Бабич бу балладаны үзенә генә хас осталык белән укып бетергәч, иң элек Г.Ибраһимов сикереп аякка басты. Аңа ияреп, барлык тамашачылар тордылар. Шуннан шул хәлдә кул чабулар астында Бабич балладасын кабатлап сөйләде.

Бу әсәрне башлап «Казан утлары»нда чыгарырмын дип уйлаган идем.

Икенче кулъязма 195 бит, менә шулай мин язган рәвештә ята. «Шагыйрьнең язылып бетми калган дәфтәрләре» дип атала. Яки М.Гафуриның соңгы көннәре турында. Өченче язмам – «Күктә юл эзләүчеләр». Революциягә чаклы татар шәкертләренең казакъ халкын агарту юлындагы хезмәтләре, татар нәшриятларының казан телендәге әдәбиятны бастырып чыгарулары, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә казакъ яшьләренең укулары һ.б., һ.б. турында язылачак.

Күрмичә язам, укый алмасаң, утка ташла.

Менә шул. «Казан утлары»нда эшләүчеләргә туганнарча сәлам!

*Сәйфи Кудаш*

## Сөембикә Кудашева хаты

*1994 ел*
*Уфа*

Хөрмәтле Рәдиф әфәнде!

Сезнең белән күрешүләр, сөйләшүләр, әтиебезнең 100 еллык юбилее көнендә аралашулар әле кичә генә булган вакыйгалар кебек тоела безгә.

Кадерле әтиебезнең зур бәйрәмендә Сез безнең шатлыгыбызны ихлас уртаклаштыгыз, бик җылы сүзләр әйттегез, аның хәтер кичәсенә ямь өстәдегез, бик зур рәхмәт Сезгә, Рәдиф әфәнде!

Сезгә җитәрлек ихтирам күрсәтә алмаганбыздыр, бик авырлык белән хәзерләнгән, безнең өчен бик кыйммәтле бәйрәмгә без хәлләрдән таеп килеп терәлдек. Бу 100 еллык юбилей күп кенә каршылыкларга очрады. Бик тиз генә хәзерләнеп үткәрделәр җитәкчеләр бу юбилейны. Шулай да ул көтелмәгәнчә җылы, матур үтте. Бәлки Сез сизгәнсездер, бу юбилейда барлыгы сигез башкорт язучысы булды, ә калганнары «Ак тирмә»дә җыелышта булдылар, юбилейга килмәделәр. Ләкин зал тулы иде, анда әтиебезне хөрмәт иткән кешеләр утыра иде, шуңа күрә дә ул залда утырган кешеләргә бу бәйрәмне үзләренең җылы тойгылары белән тагын да матурлап җибәрделәр. Әти турында ихлас әйтелгән сүзләрне кул чабып каршыладылар, бу кичә безгә шәхси өйдә үткән кебек тоелды. Килгән кунакларыбыз әтинең ихтирам иткән яраткан кешеләре иде. Сез нәкъ татарча, татар кәләпүше киеп килдегез, тирән мәгънәле, җылы сүзләр әйттегез, халык Сезнең сүзләрегезне нык алкышлар белән каршы алды. Әле булса Сезне искә төшереп сөйлиләр.

Рәдиф әфәнде! Сез үзегез күрдегез, әтиебезнең бәйрәме хөкүмәт дәрәҗәсендә үткәрелмәде, халыкча булды. Бәлки бу яхшырактыр да. Ләкин аның дәрәҗәсен төшерергә омтылулар күп булды, һәм ул сизелеп тә торды. 1960 еллардан бирле

«дусларыбыз» С.Кудашка каршы көрәш алып бара, нәрсә генә эшләмәделәр. <…> нинди түбәнлекләргә төштеләр, нахак бәлаләр яктылар, ләкин бу эшләрне барыбер документаль, рәсми рәвештә исбат итә алмадылар, чөнки әтинең бер генә гаебе дә юк. 12 язучы, килеп, КГБ архивларының астын өскә китереп, әтигә каршы документлар эзләргә тотындылар, ләкин теләкләренә ирешә алмадылар, киресенчә, әтигә ябылган ялган эшләрне кем башкарганны үзләре күрделәр. Ләкин общественное мнение дигән нәрсә бер чир шикелле, озак бетми, аны төзәтер өчен вакыт һәм көч кирәк. Шунысы шатлыклы: әтинең безгә әйткән сүзләре дөрес булып чыкты, без ул әйткәндә дә шулай уйлаган идек, ул безгә: «Сез, балалар, курыкмагыз, минем кешеләр алдында гаебем юк, кешеләр өстеннән йөрмәдем, кешеләрне утыртуда катнашмадым, ә үземне нахакка рәнҗетүчеләр күп булды», – диде һәм сабыр булырга кушты. Бу кешеләргә каршы җавап язып караса да, аны бастырып чыгармадылар. Хәзер без аларның барысын да аның яңа хәзерләнеп ята торган публицистикасына кертәчәкбез.

Ничә анонимка гына килмәде аңа! <…> да бар, аның язу стилен шундук төшендек, үзе белгән, язган кешеләре – дусларын әйтәм – алар сөйләп йөрделәр. Әти ул хатларны КГБга илтеп биргән иде, авторларын табарга сорап. Таба алмадылар, ә анонимкалар тынып калдылар... Ә 1988 елны яз көне әтигә Казаннан бер әшәке эчтәлекле, куркыныч хат килеп төште, аны мин әтигә күрсәтмәдем. Беләм, бу ялган яла,кайчан да булса дөреслек ачылыр дип көттем. Хатны «Сәйфи агай...» дип башлаган, бу инде башкортча мөрәҗәгать формасы, Казанда – ага, абый дип эндәшәләр. Ә кулын Насыйбуллин Х.А. дип куйган, адресы – Комлев урамы, №2, Союз Писателей дигән. Менә хәзер вакыт җитте ул явыз, пычрак хатны бастырып, анализ бирергә. Әгәр шундый кеше була калса, аның адресын табып булмас микән? Хәзер КГБ эшмәкәре Галәветдинов иптәшнең әтине гаепләүчеләргә җавабы бар, анда әтинең исеме аталмый, чөнки әтине барлык гаепләүчеләр дә исемен әйтмичә генә сөйләделәр, һаман исемен атамыйча гына, аны җавапка тартуны сорадылар. Чөнки үзләренең сүзләренә үзләре ышанып җитми алар, куркалар, ә тере кешене җәфалау, пычрату белән җитди булышалар, шуңа вакытларын да, көчләрен дә кызганмыйлар, саташкан воображениеләрен, чирле фантазияләрен аракы белән кыздырып кына торалар. <…>

Хөрмәтле Рәдиф әфәнде! Сез шомлы уйлар белән кайтып китмәдегезме? Мин шулай дип уйламыйм, ләкин Уфадагы хәлләрне яхшы беләм. Сез үзегез күрдегез, юбилей сәхнәсендә утырган хөкүмәт кешеләре – <…> һәм культура министры кеше күмү мәрәсимендә утырган шикелле мрачно утырдылар, авыз ачып, бер генә сүз дә әйтә алмадылар, чөнки теләмәделәр.

<…> – әтигә каршы кешеләрнең хөкүмәттә утыручы вәкиле. Аның аркасында юбилейга әзерлек тә соңлап башланды, күп нәрсәләр эшләнмәде. Президентыбыз да килмәде, чөнки аңа да әтине гел начар итеп кенә күрсәтеп торалар. Әтине җирләгәндә килеп хушлашкан иде, анда аңа 100 яшь тулу турында да сүз булган, аны үткәрү турында да. Ә тормышта алай булып чыкмады. Ярый, хәзер барысы да тарихта калды. Шулай да эч поша, дөреслек өскә чыкса да, шул турыда ныклап, беркем бернәрсә дә әйтми, курка. Без Рөстәм белән эти турында китап яза башлаган идек, инде 20 нче елларга килеп җиттек. Без аны кеше буларак, шәхси яктан күрсәтергә тырышабыз. Аның иҗатын яктырткан хезмәтләр күп булды, ә менә аның тормышын, ничек яшәвен, аның дусларын, аны нахакка җәфалауларын әле күп кешеләр белми. Шул эшне башкарып чыгарып булса, әтиебезне кешеләргә, бигрәк тә яшьләргә дөрес аңларга ярдәм итәр иде.

Юбилей көннәре артта калды, ләкин алар истән чыгарлык түгел. Халык җылы кабул итте бит әтинең бәйрәмен, туган авылында да ифрат матур кичә булды. Һәйкәл ачу тантанасы – мәңге истә калырлык, ә шул кабер ташы өчен безнең йөрүләрне белсәгез, шул уңай белән тартышларны...

Хөрмәтле Рәдиф әфәнде! «Казан утлары»ның ике саны әтине бик матур биргән, «Мирас» журналында тирән мәкалә чыккан, аның 1913–1918 елларда язылган шигырьләре ничек актуаль укыла. Ә Казан газеталары нинди матур битләр бирделәр! «Аргамак» ничек бирә башлады әтине! Шуннан соң «Агыйдел»не алыгыз. Ярый әле, академик Г.Хөсәенов әтине бирү юлын тапкан. Аңа 100 яшь тулса да, аны һаман арткарак куйганнар бит инде, янәсе, ул шуңа гына лаек... Әйдә, булсын, ләкин аның исемен әдәбияттан алып ташлау мөмкин түгел. <…> һәм К°лар шуңа омтылганнар иде. Хәзер без аның әсәрләрен хөкүмәт нәшриятында чыгару юлларын эзлибез. Хәзер чыгарабыз диләр инде, намусларына оят килде бугай.

Юбилей үтү белән Рөстәмне больницага алып киттеләр. Юбилей алдыннан аңа бик начар диагноз куя язганнар иде, ул тын ала алмый башлады, 3-4 тапкыр ашыгыч ярдәм килеп коткарып калган иде. Ә үзе юбилей үтмичә, больницага кермим дип түзде, чирли-чирли үткәрде ул көннәрне. Больницада аның бронхларын дарулар белән юдырдылар, чистарттылар дисәм дә, дөрес булыр. Менә бер генә атна әле ул өйдә, инде мин авырып киттем. Бөерләр авырта, бу да начар чир инде. Рөстәм тирән итеп тын ала башлады. Ә бит ныклап уйламыйча куелган диагноз кешене үтерергә дә мөмкин.


Хөрмәтле Рәдиф әфәнде! Әгәр Уфага килә калсагыз, Сез һәрвакыт безнең кадерле кунагыбыз булырсыз, рәхим итегез.

Әмирхан ага белән Наҗия апага безнең сәламнәребезне, телефон аша гына булса да, тапшырыгыз! Шулай ук Равил әфәнде Фәйзуллинга, Хәлим әфәнде Гайнуллинга, Галия Минскаяга, Хәсән агабызның хатыны Мөнҗия апага, Нәкый абыебызның хатыны Нәҗибә ханымга, Сибгат ага Хәкимнең хатынына, Мирсәй Әмирнең хатынына, Гомәр ага Бәширов һәм аның гаиләсенә дә безнең сәламнәребезне тапшырсагыз, без бик-бик шат булыр идек.

Сезгә Рөстәмнән бик күп сәлам!

*Зур хөрмәт белән, Сөембикә.*

# ӘДӘБИ СКАНВОРД



Язучы ... Кадыйрова

Шагыйрә ... Рәхимова

Ахунов, Гобәй

... Гарипов (башкорт шагыйре)

Мостай ...

Татар халык җыры

Язучы Рәфкать ...

...Окуджава

Джанни... (итальян язучысы)

Тереклек чыганагы

Шагыйрь Ямаш ...

Күп ишкәкле борынгы хәрби көймә

Рәссам ... Абзгильдин

«Итил суы ... торур» (Н.Фәттах)

Аллалар, батырлар турында риваять

Күк йөзе, күк гөмбәзе (иск.)

Язучы ... Фәләх

Зиннур Хөснияр романы

Су буенда үскән вак куаклык

... Кинҗәбулатов (башкорт шагыйре)

Агарган, көмеш төсле чәч

Шәехзадә Бабич туган авыл

Россия кинопремиясе

Муса ... (башкорт шагыйре)

Саф, шеренга

Ф.Әмирхан повесте

... Арлазоров

Борынгы бәрмә уен коралы

Язучы Ярослав Гашекның милләте

Нур Әхмәдиев туган авыл

Драматург Шаһиморат ...



Шагыйрь Әхмәт ...

Иван Бунин хикәясе

... Аймәт

Шагыйрь ... Мадьяров

Васко ... Гама

Дөнья

Нечкә ефәк билбау

Туфан, Сарьян

...-Жак Руссо

Рәис **ГАБДУЛЛА** *төзеде.*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *Морат, Алиш, «Сиваш», Күәм, цикл, Аким, Индус, Ханов, «Ника», «Ана», Кара, Корбан, Рой, Әрә, Риза, даими, Мансуров, Кант, Уран, ефрейтор.* ***Өстән аска:*** *Бах, Мане, Камали, Цин, Зиннур, Мөслимова, ре, Тукай, Равил, Акоп, рант, Ной, Дон, «Ташкыннар», автор, ди, «Бәби», Дилә, «Уклар», «Муса», Нәби.*

# СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН...



Халкыбызның рухияте, иҗтимагый фикере формалашуга үзеннән зур өлеш керткән якты шәхес, шагыйрь, публицист, тәрҗемәче, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Сүнчәләйнең (1889–1937) тууына – 135 ел. Укучыларыбыз аны Габдулла Тукайның якын дусты буларак та белә. Бу ике исем шул дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгән ки, хәтта Сүнчәләйнең «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын» дигән шигъри юлларын без озак еллар дәвмында Тукайныкы дип белеп яшәдек.

Журнал укучылар игътибарына радио архивында саклана торган бер язма тәкъдим ителә. Бу – 2014 елда Г.Тукайның Казандагы әдәби музеенда Сәгыйть Сүнчәләйгә багышлап үткәрелгән кичәнең язмасы. Кичәне музей мөдире Гүзәл Төхвәтова алып барган һәм ул беренче сүзне Сәгыйть Сүнчәләйнең исемен халыкка кайтаруга зур өлеш керткән, әсәрләрен китап итеп туплаган аксакал галимебез Зөфәр ага Рәмиевкә биргән. Аның чыгышыннан берничә фикерне сөземтәләп алыйк:

«XX гасыр башында матбугатта шигырьләре басылган шагыйрьләрнең саны 300гә җитә. Шулар арасында беренче ун йолдыз арасында Сәгыйть Сүнчәләй дә бар. Ләкин бу йолдызның яктысы озак еллар безнең әдәбияттан читләштереп торылды. Чөнки 1929 елда аны солтангалиевчелектә гаепләп кулга алалар, 1931 елда атарга хөкем итәләр, һәм, бу карарны 10 ел төрмә белән алыштырып, Соловкига озаталар. Сәгыйть Сүнчәләйнең исеме бары тик 1950 еллар ахырында гына кайта башлады. 1958 елда Татарстан Язучылар берлегендә аның иҗатын тикшерү буенча комиссия оеша. Аның составында Шәриф Сүнчәләй дә бар. Әгәр без бүген Сәгыйть Сүнчәләй иҗаты белән таныша алабыз икән, абыйсы Шәрифкә рәхмәтле булырга тиешбез, чөнки ул энесенең архивын саклап калган. Шул елларда Шәриф Сүнчәләй катнашы белән юкарак кына бер шигырьләр җыентыгы басылып чыккан, анда 60лап шигырь басылган. Ә инде 1990 елларда миңа С.Сүнчәләйнең бертомлыгын җыйнау, бастырып чыгару эше йөкләнде. Монда аның өч йөзләп шигыре, берничә пьесасы, хатлары тупланды...»


Филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин үзенең чыгышында Сәгыйть Сүнчәләйнең гомер юлына һәм аның Габдулла Тукай белән дуслыгына аерым туктала.

Күренекле текстолог галимебез Нәҗип Нәккаш моннан күп еллар элек Сәгыйть Сүнчәләйнең архивын кайтаруга бәйле вакыйгаларны искә алып сөйли:

«Мин институтка яңа гына эшкә килгән вакытта, гарәп язуын ярыйсы ук белүемне сизеп, Нил Юзиев мине Сәгыйть Сүнчәләйнең архивын тасвирлап кайтырга җибәрде. Ул аны Әмирхан Еники аша белгән. Мәскәүгә барган вакытларында, туганы Сорур Сүнчәләй-Еникиева янына кереп, аңа үзенең китапларын һәм «Казан утлары» журналын калдырып чыга торган булган. Берсендә Сорур ханым аңа Сүнчәләйнең архивын күрсәткән, аны Казанга алдырып, хәрәкәткә кертеп җибәрүен үтенгән. Без аның белән 5 көн буе архивны карап, басма материалларны, кульязмаларны, фотоларны барлап чыктык...»

Тапшыруда сез Казан театр училищесы студентлары башкаруында Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләрен дә ишетерсез. Инде, әйдәгез, QR-код ярдәмендә сайтыбызга кереп, шушы бөек шәхеснең якты рухына багышланган язманы тыңлыйк.

# ӘДИПЛӘРНЕ ИНТЕРНЕТТА ТАНЫТТЫ



Танылган шагыйрь һәм прозаик Әхмәт Дусайлының (Әхмәтҗан Хәсән улы Хәмәдишин) (1949–2020) тууына – 75 ел.

Татарстан Язучылар берлегенең рәсми сайтында урын алган мәгълүматларга караганда, булачак язучы Мөслим районының Дусай авылында дөньяга килә. Уку, белемгә омтылу белән бергә яшьтән үк хезмәт чыныгуы алып үсә: йөкчедән алып инженер-технологка кадәр күп һөнәрләр үзләштерә. Узган гасырның сиксәненче еллары башында КамАЗда кыручы булып эшләгәндә, беренче хикәясен яза. Шул вакыттан бирле, гәрчә шигырь язуын дәвам иттерсә дә, төп иҗат юнәлеше итеп проза жанрын сайлый. Тәүге хикәяләре, очерк-язмалары Мөслим һәм Тукай район газеталарында, «Ялкын», «Казан утлары», «Аргамак», «Идел» журналларында, «Әфган кызалаклары» (1991) күмәк җыентыгында дөнья күрә, 1992 елда повесть һәм хикәяләре тупланган мөстәкыйль китабы басылып чыга.

Чаллыда «Аргамак» журналы оешкач (1991), Айдар Хәлим аны басманың җаваплы сәркатибе итеп чакыра. Биредә эшләгән елларда Ә.Дусайлы публицист буларак та танылу ала.

1994 елда Әхмәт Дусайлы бер төркем Чаллы журналистлары белән берлектә «Хәерле иртә» исемле газета һәм тагын бер елдан газета каршында шул ук исемдә хосусый нәшрият оештыра. Мөхәррир-нашир буларак, газетаны да, нәшриятны да ул үзе җитәкли. Әлеге нәшриятта төбәк язучыларының дистәләгән шигырь һәм проза китаплары нәшер ителә.

Әхмәт Дусайлы татар язучылары турында мәгълүмат тупланган «Adiplar.belem.ru» порталын оештыручы буларак та әдәбиятыбыз тарихына кереп калды. Шушы эшчәнлеге өчен ул 2010 елда «Белем җәүһәрләре» халыкара интернет-проектлар бәйгесе лауреаты исемен алды. Шул ук елда әсәрләре өчен Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә лаек булды.

2001 елда Мөслим районының «Авыл утлары» газетасы редакциясенә компьютерлар кайта һәм якташлары Әхмәт Дусайлыны верстальщик итеп эшкә чакыралар. Язучы, Чаллыдагы эшен, фатирын калдырып, туган ягына кайта. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Салавыз-Мухан авылында яшәде.

Әхмәт Дусайлының тууына 75 ел тулу уңаеннан Татарстан радиосы аның әсәрләреннән радиокомпозиция әзерләде. Журнал укучылар игътибарына шушы тапшырудан бер өзек тәкъдим ителә. Язучының «Ак торна» исемле хикәясен Тәлгат Хаматшин укуында ишетерсез.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## XXIV ФЕДЕРАЛЬ САБАН ТУЕ

XXIV Федераль Сабан туе Марий Эл Республикасының Медведево ипподромында һәм Медведев районы Руэм бистәсендә узды. Бәйрәмдә Россиянең 72 төбәгеннән 500 ләп кунак, җәмгысе 20 меңләп кеше катнашты. Бу – Марий Элда уздырылган икенче Федераль Сабан туе. Беренчесе 2004 елда үткәрелгән иде.

Сабан туе Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановның, Марий Эл Республикасы башлыгы Юрий Зайцев, ТР Премьер-министры урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев, Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Рамил Муллинның бергәләп татар һәм мари ихаталарын каравы белән башланды.

Бәйрәмне ачу тантанасында ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов Сабан туеның яхшы оештырылуы өчен Марий Эл Республикасы җитәкчелегенә, җирле хакимияткә, бу эштә катнашкан һәркемгә рәхмәт белдерде. Марий Эл Республикасы башлыгы Юрий Зайцев бу чараны мари җирендә уздыруның үзләре өчен зур мәртәбә булуын искәртеп үтте.

Сабантуй башында ук дәртле, кызу булырга охшаган иде. Милли көрәш, узыш-ярышлар, дәртле җыр-биюләр, милли ихаталар, төрледән-төрле күргәзмәләр халыкта зур кызыксыну уятты.

Көрәш мәйданында Татарстан данын яклап бил алышкан Муса Галләмов күп тапкырлар дөнья һәм Россия чемпионы, 213 килограммлы Сергей Павликны чистага салып, баш батыр булып калды. Тумышы белән Марий Эл Республикасының Бәрәңге районыннан булган Мусага борынгыдан килгән гадәт буенча, Сабан туе батырына бирелә торган тәкәдән тыш, ТР Рәисе исеменнән автомобиль ачкычы тапшырылды. Бу – аның Сабантуйларда көрәшеп алган унынчы машинасы.

ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Марий Эл Республикасы татарларының милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасына «Газель» микроавтобусы бүләк итте. Рәис аның ачкычын мохтарият җитәкчесе Әмир Шакировка тапшырды.

2025 елда Федераль Сабан туе Якутскида узачак. «Тулпар ат» күчмә символын Саха (Якутия) Дәүләт Җыены (Ил Тумэн) Рәисе урынбасары Александр Подголов кабул итеп алды.

## ДЕРЖАВИННЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Бөек рус шагыйре, күренекле дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның тууына 281 ел тулган көнне Татарстан Республикасы Юстиция, Мәдәният министрлыклары, җәмәгатьчелек вәкилләре, әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәр, башкалабыз кунаклары Казандагы Лядской бакчасына җыелдылар. Монда алар Державинның һәйкәленә чәчәкләр салды. Аннары бәйрәм башланды. Анда Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм Заһидуллин, мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Халыклар ассамблеясе рәисе урынбасары Ирина Александровская, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, шагыйрьләр Алексей Остудин, Борис Вайнер, Наилә Ахунова, Светлана Минһаҗева, Юрий Ларионов чыгыш ясадылар. Бәйрәмне Качалов театры артисты Дмитрий Язов алып барды.

Тантана Гавриил Романовичның туган ягы – Лаешта, Державин мәйданында дәвам итте. Монда Гавриил Державин премиясе тапшырылды. Быел бу бүләккә юриспруденция өлкәсендәге эшләр каралды. Державин премиясенең быелгы лауреаты – В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты профессоры Илдар Бегишев.

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Чистай районы мөхтәсибәте – Ислам үзәгендә язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Гаяз Исхакыйның вафатына 70 ел тулу уңаеннан «Яңарыш хәбәрчесе – заман һәм традицияләр» дип аталган түгәрәк өстәл утырышы булды. Г.Исхакый иҗатына багышланган китап күргәзмәсе ачылды. Чараны Татарстан Язучылар берлеге, Чистай дәүләт тарихи-архитектура һәм әдәби музей

тыюлыгы, Чистай җирлекара үзәк китапханәсе оештырды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендә язучылар делегациясе, галимнәр, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты вәкилләре, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

## ИНСТИТУТЛАРДА ЯҢА ҖИТӘКЧЕЛӘР

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына яңа директор билгеләнде. ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов коллективка яңа җитәкчене – Илгиз Халиковны тәкъдим итте.

2006 елдан бирле институт директоры булган Ким Миңнуллин вазифасыннан китте. Ул институттан китәргә җыенмавын, киләчәктә үзен фәнгә багышлаячагын белдерде.

Илгиз Халиков 1983 елда Башкортстанның Стәрлебаш авылында туган. «Татар һәм рус теле укытучысы» белгечлеге буенча Стәрлетамак дәүләт педагогика академиясен тәмамлаган. 2008 елда диссертация яклаган. 2016 елда «Белем бирүдә менеджмент» белгечлеге буенча ТИСБИ дипломын алган.

2019 елдан Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, соңрак ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы булган.

Эльмира Галимова ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры итеп билгеләнде. Яңа җитәкчене коллективка Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов тәкъдим итте.

Аңа кадәр бу вазифада тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев эшләде. Ул институтны 2015 елдан җитәкләде. Э.Галимова моңа кадәр белем бирү учреждениесендә театр һәм музыка бүлеге мөдире вазифасын башкарды.

Эльмира Галимова 1982 елда Чаллыда туган. И.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка училищесын һәм Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. Аның кандидатлык диссертациясе Пермь татарларының традицион музыкаль мәдәниятенә багышланган.

## ЮБИЛЕЙ

Актаныштагы Әлфия Авзалова исемендәге мәдәният йортында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әмирҗан Моталлаповның 90 яшьлек юбилей кичәсе булып узды. Бәйрәмдарны Актаныш районы хакимияте башлыгы Ленар Зарипов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Факил Сафин, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, язучылар Мөхәммәт Мирза, Әнвәр Шәрипов, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Гыйбадуллина һ.б. котлады.

## БУ ЮЛЫ ИКЕ КИТАП

«ТАТМЕДИА» агентлыгының утырышлар залында Татарстанның халык язучысы Вахит Имамовның «Кәнәфи» һәм «Ерактагы якын туганнар» китапларын тәкъдим итү булды. Аларның беренчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән гамәлгә куелган «Казан утлары» журналы китапханәсеннән» сериясендә басылып чыкты. Икенче басма – татарлар яшәгән республикаларга сәфәрләр нәтиҗәсе. Мәгълүм ки, соңгы елларда «ТАТМЕДИА» тәкъдиме белән «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас», «Казан утлары» журналлары баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллиннар, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез янына барып, аларның хәлләрен белешә, тормыш-көнкүрешен өйрәнә.

Бәйрәм авторны күптән түгел генә «Татарстанның халык язучысы» исеменә лаек булуы белән котлаудан башланды. Аннары сүз «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйковка бирелде. «Әлеге «кесә китабы» сериясеннән чыгарыла торган әсәрләр, гомумән, бу проект бик уңышлы проектка әверелде, – диде ул. – Менә монысы – 27 нчесе. Ул 3 мең данә басылды. Хәзерге заман өчен зур тираж, чөнки китап укучылар аз. Әмма бу сериядә 71 мең данә китап нәшер ителгән инде, аларның 60 меңе сатылды. Хәзер әдипләр бу сериядә үз китапларын чыгарырга чират тора. «Казан утлары» журналы редакциясен, авторларны, Язучылар берлеген котлыйм!»

Китап бәйрәмендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, академик Индус Таһиров, язучы Асия Юнысова, тарихчы-галимә Тәэминә Биктимерова, җәмәгать эшлеклесе Нуриәхмәт Галишан, авторның хатыны Гөлүзә Имамова чыгыш ясадылар. Бәйрәмне язучы, «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан алып барды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

24 август – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Галиәхмәт Шаһига 75 яшь.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман А.ГАЯЗОВА «С какой же стороны встаёт солнце?», повесть М.КАБИРОВА «Жизнь», рассказ Р.БАДРЕТДИНОВА «Путники»; стихи Д.ХАЙРУЛЛИНА, Р.РАХМАН, Л.САГИДУЛЛИНОЙ, А.ХАБИБУЛЛИНОЙ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ Г.ИСХАКОВОЙ «Уроки старьёвщика».*
*«Новые имена»: стихи А.КАЛИМУЛЛИНОЙ.*
*Литературная критика: статья В.МАКАРОВОЙ.*
*«Грот Абугалисины»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА, посвящённая 200-летию К.Насыри.*
*Литературные мгновения: фоторепортаж с поездки писателей, участников проекта «Яңа исем» в Рыбно-Слободский район РТ.*
*«Памятные письма»: письма от ФАСАХАТ АПА, Г.АФЗАЛА, С.КУДАША, С.КУДАШЕВОЙ к Р.ГАТАШУ.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 135-летию С.СУНЧАЛЯЯ и 75-летию А.ДУСАЙЛЫ. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: фонтаны на Булаке (г.Казань). Фото И.АБРАМОВОЙ; Журналист, писатель РАМИС ЛАТЫПОВ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by A.GAYAZOV «In what direction does the sun rise?», story by M.KABIROV «Life», story by R.BADRETDINOV «Wayfarers»; poems by D.KHAIRULLINA, R.RAKHMAN, L.SAGIDULLINA, A.KHABIBULLINA.*
*Literary contest «Morals of the Father's House...»: story by G.ISKHAKOVA «Junkman's Lessons ».*
*«New names»: poems by A.KALIMULLINA.*
*Literary criticism: article by V.MAKAROVA.*
*«Abugalisina grotto»: article by I.ZAGIDULLIN dedicated to the 200 th anniversary of K.NASIRI.*
*Literary moments: a photo report from the trip of writers, participants of the «Yana Isem» project to the Rybno-Slobodsky district of Republic of Tatarstan.*
*«Memorial letters»: letters from FASAHAT APA, G.AFZAL, S.KUDASH, S.KUDASHEVA TO R.GATASH.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLA.*
*«Priceless voices»: articles on the 135 th anniversary of S.SUNCHALAY and the 75 th anniversary of A.DUSAYLY.*
*The rubric is led by N.AKMAL.*
*Diary of public-cultural life.*
*On our covers: fountains of Bulak (Kazan). Photo by I.ABRAMOVA; Journalist, writer RAMIS LATYPOV.*

*Тышлыкның беренче битендә:* Болак фонтаннары. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* журналист, язучы Рәмис Латыйпов.